
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1999



## Татарстан Республикасы Президенты
## УКАЗЫ



Әдәбият өлкәсендәге олы казанышлары өчен шагыйрь, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Фәйзуллин Равил Габдрахман** улына «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

*Казан, Кремль.*
*1999 ел, 28 май.*

Татарстан Республикасы
Президенты **М. Ш. Шәймиев.**

**Казан утлары**
**Qazan utlarь**

*1999*

**7**

**(921)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ
ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда

ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Зиннур МАНСУРОВ. Язмышларга өстәп язылганнар... *Шигырьләр* ... 5
Нур ӘХМӘДИЕВ. Амбирак яки кара каен кыйссасы. *Повесть* ... 13
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Әй, гомерләр. *Шигырьләр* ... 83
Әнәс ИСХАКОВ. Тауларга илтә бу сукмак. *Шигырьләр* ... 88
Чегән җырлары ... 111

«Идел» журналына—10ел ... 92


ПУБЛИЦИСТИКА


Миркасыйм ГОСМАНОВ. Каһирә очрашулары ... 116
Индусә МИНҺАҖЕВА. Милли музей сәхифәләре ... 148


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Туксанынчы еллар әдәбияты. *(Анкетага җаваплар)* ... 131
Фатих УРМАНЧЕ. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь ... 134


ХӘТЕР


Рафаэль МОСТАФИН. Шамил Усманов турында өч риваять ... 155


МИРАС


Фатыйма ИБРАҺИМОВА. Әдип иҗатына ике караш ... 160
Галимҗан ИБРАҺИМОВ. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән ... 161
А. БИКТАШЕВ. Тәнкыйть тирәсендә ... 167


ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА


Миләүшә ФАТЫЙХОВА. «Канга батты колларым ...» ... 171


КИТАП КҮЗӘТҮ


Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Тормыш учагы сүнмәсен ... 175
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Якты сагыш ... 179


ЮМОР һӘМ САТИРА


Илфак ШИҺАПОВ. Хикәяләр ... 183

Укучы сүзе ... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191
Тышлыктагы сурәтләр ... 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Н. АХМАДИЕВА «Амбирак или печаль черной березы»; стихи З. МАНСУРОВА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, А. ИСХАКОВА, цыганские песни.
«Молодежному журналу «Идел» — 10 лет»
«Публицистика»: М. УСМАНОВ. «Встречи в Каири»; статья И. МИНГАЗОВОЙ посвящена проблемам создания и развития национального музея.
«Литературная критика»: «Татарская литература 90-х годов». Статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА. Статья Ф. УРМАНЧЕ «Древняя мифология и поэзия».
«Память»: статья Р. МУСТАФИНА «Три легенды о Ш. Усманове».
«Наследие»: Ф. ИБРАГИМОВА. «Два взгляда на творчество Г. Исхаки»: статьи Г. ИБРАГИМОВА и А. БИКТАШЕВА.
«Слово молодого критика»: статья М. ФАТЫХОВОЙ «Новый взгляд на творчество Х. Такташа».
«Книжное обозрение»: А. ЗАКИРЗЯНОВ рецензирует новую книгу Ю. Сафиуллина; Р. ШАРАФЕЕВ — книгу З. Зайнуллина.
«Юмор-сатира»: рассказы И. ШИГАПОВА.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Натюрморт из цветов» — картина художницы Миляуши Нуруллиной; известный ученый—фольклорист Фатих Урманче.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": N. AHMADIEV'S story «Ambirak or sorrow of the birch»; the verses of Z. MANSUROV, L. SHAKIRZANOVA, A. ISKHAKOV, GIPSY SONGS.
"»Idel» journal is 10": articles of R. NIZAMI, R. YUNUS, R. ZAIDULLA, N. GIMATDINOVA, funny stories.
"Publicism": M. USMANOV «Meetings in Cairo»; I. MINGAZOVA'S article devoted to problems of national museum.
"Literary criticism": "Tatar literature of 90 th years" F. GALIULLIN'S article; F. URMANCHI'S article «The ancient mythology and poetry».
"Memory": R. MUSTAFIN'S article «Three legends about Sh. Usmanov».
"Legacy": F. IBRAGIMOVA «Two looks at G. Iskhaki's creative works», the articles of G. IBRAGIMOV and A. BIKTASHEV.
"Critic's word": M. FATIHOVA'S article «The new look at H. Taktash's creative works».
"Book review": A. ZAKIRZANOV'S review of U. Safiullin's new book R. SHARAFIEV'S review of Z. Zainullin's book.
"Satire": I. SHIGAPOV'S stories.
«Reader's word».
The diary of social and cultural life.
In our covers:the picture of artist M. Nurullina; famous scientist F. Urmanchi.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 28.06.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9019 Заказ 3-315
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

---

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.



## Зиннур Мансуров

### ЯЗМЫШЛАРГА ӨСТӘП ЯЗЫЛГАННАР...

#### Чәркәдәге чәнечке

*Мансуров, закадышный друг,*
*Надень венок терновый!..*

А. Пушкин

**Сәламеңне алдым әлмисактан—**
**ничә еллар, ничә яздан соң!**
**Аллаһыдан узып... Әүлиядай,**
**язмышыма өстәп язгансың.**

**Фәрештәләр шигъри фатихаңны**
**пышылдаган миңа бишектә.**
**Алмашынган төсле, адашларым**
**елагандыр шулчак биш йортта.**

**Шигърияттләр сыя шәригатькә,**
**тотыйк, диеп, шушы бер денне,—**
**шәрафәтле Хәйям шәрабенә**
**имезлегем манып бирдеңме?**

**Вәсвәсәгә салды «вәхи»ләрең—**
**(мин дә Раббымызның бер колы).**
**Тыгылгансың минем тәкъдиремә**
**башланмаган гасыр аркылы...**

**Китабыңны кат-кат актарганда**
**үз-үземә әллә фал ачтым?!**
**Ырымланган битләр арасында**
**гөлчәчәген күрдем... Парнасның.**

Тамгаланган серле такыядәй,
агып төшкән күпме җәй аша!
Язмышыма үзем җайлашаммы,
әллә язмыш миңа җайлаша?!

Исемемне атап искәрткәнсең,
хәбәр биргән кебек гаиптән.
Чәнечкеле таҗның сөенчесе
тоташ газап, тоташ гамь икән.

Карулашмыйм хөкем карарыңа—
тоеп яшим аның бар ямен.
Чәркәмдәге һәрбер чәнечкене
йөрәгемә күмеп барамын...

Исемемне укып исәйгәнмен,
рәхмәт инде сиңа, җан дустым!

... Әлмисактан килгән сәламеңне
чынга алып әллә ялгыштым?!.

## Илаһи күк дәфтәре

... Алда—кәгазь, кулда—каләм,
җитеп бетми дәрт бары.
Айлы битен ачып куйды
илаһи күк дәфтәре.

Сүрә итеп ятлар шигырь
чыкты, имеш—әфарин!..
Яшен сызып үтте шулчак
илаһи күк дәфтәрен.

Язган чакта җаным аша
үтә, чү, кем әфкаре*?
... Бүген шундый якын иде
илаһи күк дәфтәре...

## Рояльнең кара телләре

Хәтерлимен урыс пианистын
йокы алмас көзге төннәрдә.
«Уйнар өчен сезнең татар көен
җитә,—диде,—кара телләр дә»

Болдырымнан күзлим болытларны—
охшый кайсы кара рояльгә.
Кара телдән ничек акка күчеп,
җылауларга якты җыр ялга?!

* Уй-фикер мәгънәсендә.

**Үз-үземә әйтәм өзгәләнеп:**
**«Шушы хакта бүген уйлан син!»**
**Качкыннарның ачы «Карурман»ы**
**акта гына ничек уйналсын?!**

**... Бүлмәндәге рояль телләренә**
**шомырт чәчәкләре сибәрмен...**
**Яктырырмы кара язмышлардан**
**кан-яшь кебек саркып чыгар моң?..**

## Оркестр чокыры

*Дирижер һәм альпинист*
*Фуат Мансуровка*

**Бөеклекнең бары биеклектә**
**яшәгәнен белә чогыр* да.**
**Моңҗаннарга нинди могҗизалар**
**күрсәтмәдең шушы... чокырда!..**

**Ирегүче күпме йөрәкләрне**
**күтәрәсең рәхмәт юлына.**
**Чокырыңа оҗмах чәчәкләре**
**явып тора ничә ел менә.**

**Зөһрә-кызлы айдан чиләк-чиләк**
**илаһият нуры түгелә.**
**Чиксезлекнең шушы чокырыннан**
**Эверестлар биек түгел лә.**

**Мәэюсләнмә әле, маэстро,**
**моң-көй тулы «тормыш төбе»ндә,—**
**чокырыңа күкләр якыная,**
**кояш балкып тора төнен дә.**

**Янартаулар гайрәт яңарткандай,**
**кушавазлар ургый чокырдан.**
**... Кыялардан күпме кыюларны**
**упкыннарга атты сукыр дан...**

**Чокырыңа яшен чакырдыңмы—**
**ишарәңне бары Ул аңлар.**
**Фанилыкта да бит фәрештәләр**
**төшеп йөри торган урлар бар.**

**Көйләреңнең якты кайтавазы**
**урап кайта бугай... тегеннән.**
**Язмышларга өстәп язылганнар**
**күренәдер чокыр төбеннән.**

**Теркәлгәндер нота дәфтәреңә**
**хәтта сурның кайчан уйнавы.**

**... Чокырыңа карый чекерәеп**
**гомереңнең мәгърур ун тавы...**

---

*** Тау халыкларының кыллы уен коралы.**

## Кемчә яши?

Куян, күсе, тиен, чәшке, бүреме?—
ирнең башын кысып тора бүреге...

*(Мондый затлар кемчә уйлый, Ходаем?)*

Шундый күлмәк—табып булмый каюын,
кигән кызый, ахры, елан кабыгын...

*(Мондый затлар кемчә сөя, Ходаем?)*

... Кышкы юлдан бара, әһлем, бер бәндә—
баштанаяк сарык толып бөркәнгән.

*(Мондый затлар кемчә яши, Ходаем?..)*

## Гаҗизләнү

Иләмәннән сорый илдәшләре:
—Ничек анда... китап ни әйткән?
—Борчылмагыз,
хәтта җәһәннәмне
булдырганнар яхшы нияттән...

Гарьлекләргә күнгән гаярьлекнең,
гаҗизлекнең холкы, ай, коры:
—Мондый илне нинди ният белән
бар иткәннәр, шайтан алгыры!..

## Тырышу

Куркыттылар. Безне алда
көтә, имеш, төн генә.
Тырыштылар. Яши торгач,
төштек упкын төбенә.

Юаттылар. Җиргә генә
якынайдык, янәсе.
... Инде хәзер упкын төбен
казып ята «яңа»сы...

## Һиҗрәт

*Давыт Көгелтиновка*

Идел өсләп очып кына килдем,
(рәхмәт юлларыннан төшмәдем).
Җирдә мине Давыт үзе көткән—
әллә өндә, әллә төштә мин!

Күктә кече йорты* була торып,
пәйгамбәрләр намен йөртсә дә,
шулпа мисле милли чәе белән
кунак итте әдип юртада.

* Д. Көгелтинов исемендәге кече планета күздә тотыла.

Даладагы барлык лаләләрне
килешемә чәчәк аттырган...
Чалкан яткан олуг затның чәчен
чуалтмакчы була ак кылган.

Газиз угълын шулай җиргә бәйләп,
җибәрмәскә тели күгенә...
Затлы дәргаһ салып биргән илбаш—
яшәр урыннары күп кенә.

Калмыклары читкә куылганда,
туфрак киткәч аяк астыннан,
килешкәндер шагыйрь: «килмешәк»кә
сыяр почмак җирдә аз сыман.

«Җиде ятта,—ди ул,—ятим чакта
күккә күбрәк, күккә таяндым...»
Аксакалның минем уйлаганны
уйлап ятуына таң калдым.

Каһәрләнгән язмыш кабатланса,
(ялгыш әйттем—гафу ит мине!)—
кылганнарсыз калган калмыгыңны
планетаңа алыр идеңме?

Картның шулай күккә озак карап
ятуында берәр сер бармы?!
Нинди һиҗрәт, юк, юк, эчтән генә
бирдем аңа мондый сорауны.

Ниләр уйлый икән дала угълы,
искә төшерәме Алласын?
... Офыктагы сарык көтүләрен
кара болыт суырып алмасын!..

«Күчеп булмый!»—диеп,—«Күчеп булмый!!»—
Давыт агай эчтән йөз әйтте.
Иделемә кайтып егылырга
үзе мине... күккә озатты...

## Шагыйрь янәшәсендәге урын

Апрель ахыры. Кырлай. Шагыйрь туе.
Тәхетендә Тукай утыра.
Арысландай затлар арасында
күрәсеңме, тәкъсир, Ул тора.

Менә Давыт, Салих, әнә Исхак*...
Санап китсәң, барсы пәйгамбәр.
Ходабызның мондый хадимнәрен
кайчан әле бергә җыйган бар!

Җыелмаган халык җеназага—
китте шигырь, җыр-моң, уеннар...

* Шагыйрьләр Д. Көгелтинов, С. Баттал, И. Машбаш.

**Шаярткандай итте шаһ-шагыйрьләр:**
**«Тукай кырыенда... урын бар...»**

**Туең бара, Тукай, уен кара:**
**биючеләр читек кыздыра.**
**Чү!**
**Кыенсынмый утырт күрсиеңә—**
**Зәйтүнәдәй анда... кыз тора...**

## Яшәү белән үлем арасы

*Нәби Дәүли рухына.*
*18 май, 1989.*

**... Соңгы юлын кара мәче кискәч,**
**авышкандай итте ян-якка.**
**Зиһененең исән күзәнәге:**
**«Кереп булмас,—диде,—җәннәткә...»**

**Азаматтай зурлап озаталар,**
**беткән, димәк, җирдә бар эше.**
**Беркатлыдай нигә борылырга—**
**җәһәннәмнән китеп барышы...**

## Синең авылыңа кайту

**Үрдән карап, хәйран калдым:**
**«Синме шушы туфрактан!»**
**Гаҗәп авыл—алма төшә**
**тәгәрәшеп дүрт яктан.**

**Исем китә, күзем белән**
**урамнарны урыйм да.**
**Чишмә бәреп чыксын әле**
**алма төшкән урында!**

**«Мине әнкәм көтеп тора,**
**ә-әнә безнең йорт»,—диден.**
**Үрдә калдым—алма булып,**
**чишмә булып йөгердең...**

## Ачы тәҗрибә ачышы

**Еламсырап миңа елышканда,**
**юаткандай, әйттем күр генә:**
**«Яшьле күзләр, җаным, яшьле күзләр**
**күпкә тирән булып күренә».**

**Пышылдадың артык пошынмыйча:**
**«Җәрәхәтле йөрәк... җылырак...»**
**Елаккаем, аһ, шул җылылыкка**
**ирешергә ничә ел кирәк?!.**

## Күктә очрашу

Сөяркәдәй булдың сөялергә,
булдың бугай хәтта хатын да.
... Язмышыбыз тагын очраштырды
кичке күкнең аулак катында.

«Ярәштерде» еллар: янәшәңә
туры килде минем утыргыч (!).
Варшавага очып барышыбыз,
истәлекләр сөйләп үтте кич.

Фәрештәләр очкыч дирбиясен
сиздермичә бәйләп куйганнар.
«Биләүләнгән килеш... болытларда
кайчан әле,—димен,—кунган бар?!»

Яшьлектәге хәтер йомгагының
күпме җебен бергә урадык.
Хәзер сүзне сүзгә ялгап булмый,
кушылырдай уртак җыр да юк...

Самолетта безне сыйладылар,
шәраб эчтек туар таң өчен;
каушаттымы Аллаһ якынлыгы—
түшкә тамды өч-дүрт тамчысы.

«Күлмәгеңдә табы калмагае,
табыйк,—дидең,—тизрәк әмәлен».
Йөрәктәге иске җәрәхәткә
син тоз сиптең, үксез хәләлем!..

Варшавага очып барышыбыз,
истәлекләр сөйләп үтте кич.
Фәрештәкәй чиште биләүләрне—
әллә хөрлек, әллә үкенеч...

## Тамаша

Карап торам сандугачлы тал аша—
аргы ярда ике хатын талаша...

Әлләниләр алга килә, йә Аллам—
агу сорый тузбаш... кара еланнан...

Миңа гына шәйләнәме: күр, ләгыйнь—
кимәк була фәрештәнең күлмәген...

Карап торам сандугачлы тал аша—
яшел ярда менә шундый тамаша...

## Коткару

... Ишетелде күрше ишегеннән—
ирен сугә хатын кот алып:
«Бишбалтада этәч кычкырганчы,
инде кайттың... шайтан коткарып![1]»

Көләргәме, белмим, еларгамы,
көн дә тыңлап шушы «шат пар»ны.
Мәликләре качкан мәмләкәттә
коткаралар күпме шайтанны!

Бетәрлекме мондый битәрләүләр—
әйтеп булмый әле кырт ярып.
Юлбашчылар илне яшәтмәкче
халык белән... шайтан коткарып...

## Җиргә яңадан кайту

*Ш. абый авызыннан*

... Мин тал булып кайтам. Бүген төштә
мәңгелектән би-ик күп көн алдым.
Чыбыкларым канга чыланмасын—
үзем гомер буе кыйналдым.

Хатын-кызга артык авырлыклар
салмадыммы—шуны кем әйтә?
Әгәр җиргә юкә булып кайтсам,
ясамагыз миннән көянтә.

Тәкъдир мине җикән камыш итсә,
эндәшерләр: «Курай бул, әйдә!..»
Мондый хәлгә түзәр микән җаным—
моңландырды дөнья болай да.

Әгәр җиргә тагын кайта алсам,
була калсам бәбкә үләне...

... Әллә әҗәл әйтте, әллә... хәләл[2]:
—Ә син, мәхлук, башта үл әле!..

---

1 Хәмер эчү.
2 Никахлы хатын мәгънәсендә.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Нур Әхмәдиев**

## АМБИРАК
## ЯКИ КАРА КАЕН КЫЙССАСЫ

ПОВЕСТЬ

*Хатыным Венерага багышлыйм*

Тагылга барган чакта, анда уздырган берничә көнемнең гомерем буена җитәрлек рәхәт әрнү, татлы сагыш, газап китерәсен ялгыш та уйламаган идем. Ул көннәрдән соң күпме еллар узды, жилләр исте, сулар акты—ә һәр минуты истә, алар төрле борчулар һәм ыгы-зыгы тулы дөньяда җаныма жылы биреп тора. Менә хәзер дә икәү бергә яккан учакның хатирәләре чоңгылында көйрәгән утлы күмерләрне аралап, шул көннәргә кире кайттым. Хәер, кайттым дип әйтү дөреслеккә бик үк туры да килмидер, чөнки ул көннәр тәэсиреннән ерак китә алганым да юк иде минем.

* * *

Тирә-якта сихри тынлык.

Бөтен дөньясында без бары тик икебез генә сыман. Югыйсә, сирәк-мирәк булса да өздереп сайрап куйган сандугач тавышына игътибар итми калмас идек. Әнә ич: сандугачларның мәхәббәт турындагы жырына әсәрләнеп, агач яфраклары тибрәнеп ала. Ә бит ата сандугач кына сайрый, диләр. Кызык. Төнге жил, әкрен генә нидер пышылдап, яфракларны назлый һәм аларның кочагына сыена.

Шушы гүзәллек хозурында без күпме торабыздыр. Бәхетлеләр сәгатькә карыймы соң?! Ә без бәхетле, безгә рәхәт, бик рәхәт. Ул—Себернең очы белән күктәге болытларны терәткән кырыс карагайлары арасында үскән бер нәфис чәчәк. Миңа ул жир кызы булып түгел, күкнең жиденче катыннан бәхетем өчен Жиргә ингән фәрештәдер кебек тоела. Мин үзем Чатыр тавы эргәсендәге Эстәрле елгасы буенда туып үскән егет. Мәктәптән соң бер ел туган авылым басуларының ипигә май урынына ягып ашарлык туфрагында тракторда, комбайнда эшләдем—

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь һәм прозаик. «Аһәң», «Баллы яңгыр», «Күзгә-күз», «Кояш эзләүче малай» һ. б. шигырь һәм проза китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Хәзерге вакытта «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Хәзинә» газетасе мөхәррире.*

иген үстердем. Солдат итеге киеп, Балтыйк буенда башланган хезмәтемне Ерак Көнчыгышның күкләргә салават күпере өләшкән гейзерлары кабатында төгәлләдем. Хезмәттәшләремә караганда бераз алданрак кайтып, Казан университетына укырга кердем. Һәм менә биредә халык авыз иҗаты әсәрләрен җыярга килгән студент—практика узам.

Бу яктагы авылларның беренчесенә килеп төшкәч тә, җирле сөйләмне башта аңлый алмый интектек. Йә хода, болар да үзләрен безнең сыман татар санап йөргән булалар бит. Югыйсә, сүзләре «цыкылдап» тора, «кый», «ки» сүзләрен кызганмыйча сибәләр. Әтәчне—кураз, суганны—пиаз, кишерне—сәрдәк, диләр. «Ң» авазы барлыгын әллә ишеткәннәре дә юк инде. Бакчалары—бакца, кайчылары—кайцы, үрмәкүчләре—үрмәкцә. Әллә соң боларны мишәр белән башкортны кушып ясаганнармы?

Ләкин аңлашу авырлыгы озакка бармады. Бигрәк тә аларның ачык йөзе, киң күңеллелеге сөйләмне тизрәк үзләштерергә ярдәм итте булса кирәк. Әйе, алар да безнең сыман ук татар, бары тик милли мәдәният үзәгеннән ераграк яшәгән татарлар. «Өлкән туган» арасында йомылып яшәү, бердән, гореф-гадәтләрен тотрыклырак сакларга ярдәм итсә, икенчедән, үз йогынтысын салган. Әнә ич: бәрәңгеләре «картуф»ка, коелары «кулуца»га әверелгән.

И бу халыкның кунакчыллыгы, Казан тикле Казаннан килгән кунакларга хөрмәтнең зурлыгы! Безнең ашау-эчүне кайгырту вазифасы йөкләнгән Фәридун шунда ук эшнең җаен алды: баштагы көнне унбиш кешегә кыяр-кыймас дүрт-биш кило ит сораган җирдән безгә көн дә бер сарык суйдырып, кырык литр сөт кайтарта башлады. Аша да эч, корсак шәрифләрең күрмәгәнен күрсен!

Рәхәткә чыгуның нәтиҗәсе бер атна узуга сизелә башлады. Туганнан бирле юньле ризык күрмәгән татар баласының чыраена кот кунды, Салихның авызы хәтта чалшаеп ябыла башлады. Моны күреп, җитәкчебез Фәйзи Габбасович безне кисәтеп куярга кирәк тапты:

—Егетләр, Салихның яңагына шырпы тигерә күрмәгез, кабынып...

Әйе, иркенгә чыктык. Фәйзи Габбасович:

—Такмаклар, әкиятләр качмас, туйганчы ашап калыгыз,—дип, тезгенне дә бушатып җибәргәч—бигрәк тә.

Салих сөйли:

—Фәридун белән колхоз акчасына бер шешә шәраб алдык та, аларның хуҗасына кайттык. Фатир хуҗасы әби өзгәләнеп кенә тора, улым, ни кирәк, кабарга нәрсә куйыйм, ди.

Фәридун:

—Мин, әбекәй, җәй көнендә катыкка сөт кушып, яна аерткан каймак белән ашарга яратам,—ди.

Әби әйтә:

—Кузыем, катык белән сөте бар, бүген аертмаган идем, каймак беткән.

Фәридун эт әрсезе икән:

—Алайса, әбекәй, күршедән алып чыгарсың микәнни?—диюгә, теге әби тәки күршегә кереп китте бит. Оялсам да, тәмле булды тагын үзе.

Боларны сөйләгәндә Салих авызларын чапылдатып куя, әллә ниткән безгә аңлашылып җитмәгән ымлыклар чыгара.

Шәңгә, бәтерләрне әйткән дә юк, авыл җиңгиләренең сылда, ягъни колмактан ясалган баш белән әчетелгән икмәкләренең аклыгы һәм хуш исе ел буена такы-токы яшәгән студент халкының һушын ала, эшсезлектән интегеп, ялкауланырга өлгергән төкерек бизләрен куян кугандагы эт кебек ярсырга мәҗбүр итә. Фәйзи Габбасовичның поездда килгәндә:

—Анда халык бик кунакчыл, кыстап теңкәгезгә тиярләр, чамагызны онытмагыз, югыйсә оятка калуыгыз бар. Ә безгә оятка калырга ярамый—сез анда Ленин укыган университет вәкилләре булып барасыз,—дигән сүзләре хәтергә төшә.

Башлыгыбызның кисәтүләре юкка булмаган икән.

* * *

Көн артыннан көн үтеп тора. Без инде ике авылда булдык. Көндезләрен планда каралган эш белән мәшгульбез, әз генә эсселәтеп җибәрсә—су коен. Хөррият!

Бу якларда җәйләрен энгер-менгер озак тора. Кичләрен безнең өчен «икенче смена» башлана—без су буендагы болында импровизацияләнгән концерт куябыз. «Газик» әрҗәсе—безнең өчен зур театр сәхнәсе. Беренче килеп төшкән авылда клубта чыгыш ясарга теләгән идек, кая ул!—авылның карты-яше берсе дә калмаган, барысы да килгән. Клуб эчендә энә төшәрлек урын булмаса да, бу әле килгән халыкның өчтән бере генә. Этеш-төртеш. Нишләргә?

Колхоз рәисенең бераз кызмача башы шунда ук чишелеш тапты:

—Эцкен буена төшеп концерт куясыз!

Безме соң инде ул назланып та сырланып тора торган халык! Бу эссе, тынчу, Нух пәйгамбәр заманында салынган клубка караганда табигать кочагында чыгыш ясауларың мең тапкыр артык.

Халык умарта күче урынына су буена ябырылды. Без барып җиткәндә, анда чыбык-чабык җыеп учак кабызганнар, учак янәшәсенә бер «газик»ның бортларын ачып, «сәхнә» дә әмәлләгәннәр иде. «Сәхнә»не ике яктан ике «Беларусь» яктырта.

Профессиональ артистлар булмасак та, безнең талантларыбыз җитәрлек. Ялындырып тормадык, җырладык та, биедек тә, үзебезнең язган шигырьләрне дә сөйләдек. Күп номерларны кабат-кабат сорыйлар. Әнә алып баручыбыз теленә «шайтан төкергән» Инсаф «Май нәчәлник купил яңа машина» дип, әллә кемнең әллә кайчан язган юмористик хикәясен сиптерә. Халык кул чаба-чаба арып беткәч, тагын бер тапкыр сөйләргә мәҗбүр. Шаулап көлү вә алкышлардан Эчкен буендагы тынлык шартлап ярыла да, учак очкыннары булып, йолдызларга юл ала.

Икенче көнгә без инде гади студент кына түгел, «Казан әртисләре»нә әверелгән идек. Халыкка концертыбыз шулкадәр ошаган ки, ничә көн торсак, шуның санынча ул авылда һәр кичне концерт куярга туры килде.

Хәбәрләрнең яхшысы да, яманы да тиз тарала. Безнең маршрутка кермәгән авылларның берсендә «Казан әртисләре» турында ишеткән халык концертны сорап, хәтта райкомга кадәр барып җиткән. Беркөнне райкомның пропаганда бүлеге мөдире белән шул колхозның рәисе безнең җитәкчебез Фәйзи Габбасович янына килеп, концерт куюбызны сорадылар.

Безгә ни—бардык. Халык рәхмәтен ишетү—үзе үк зур савап лабаса. Болында күрсәткән концертлардан соң картлар кайтып китә, яшьрәкләр исә клубка юнәлә. Клубтан күбесе парлашып тарала да, һәр пар күнеленә ошаган җиргә юнәлә: кем су буена, кем капка төпләренә. Ике-өч көнгә бер кыз озатып, тәмам Дон Жуанга әверелеп беттек. Әй, әверелмәсә тагы, вәгъдә биргән кыз, елап калган хатын юк, яшь чакта үпкән-кочкан—җилгә очкан! Шуның өчен дә сандугачлы-таңлы яшьлек бит ул! Тик менә черкиләре, черкиләре генә күлмәгең бар дип тә тормыйлар, борыннарың тәнеңә кунганчы ук батыралар да вампир урынына каныңны суыралар. Йөрисең аннан корчаңгы кебек көне-төне кашынып. Ә янында торган авыл кызының черкиләргә исе дә китми, бары тик ара-тирә генә болай да кыска күлмәк итәген күтәреп, ак балтырларына кунган әдәпсез черкинең башына җитә. Бу алар өчен шулкадәр табигый ки, хәтта чебен тешләсә дә, без ныграк чәбәләнәбез.

* * *

Танышканыбызга әле ике-өч сәгать тә юктыр, чөнки без бу авылга кичке якта гына килеп урнаштык. Шулай да, миңа калса, аны гомерем буена беләм кебек. Хәтта дөньядагы мәхәббәт дигән изге хис тә тәңренең

безне очраштырган, таныштырган мизгелендә генә барлыкка килгәндер сыман. Әллә моңа кадәр үзем күзле бүкән генә булып йөрдемме икән? Бәлки дөнья нәкъ әнә шул серлелеге, аңлаешсызлыгы аркасында кызыклыдыр да әле: менә бит, күргәнеңә яңа гына, ә ул сиңа шундый таныш, шундый үз, гүя син аны гомереңбуена беләсең. Шул ук вакытта мәңге ачылып бетмәс сер дә кебек. Җанның мәңгелеге, үлемсезлеге хакында сөйлиләр. Дөрес булса, бәлки, безнең җаннарыбыз да кайчандыр— йөз еллармы, мең еллармы элек галәмнең кайсыдыр ноктасында очрашкан булгандыр? Бәлки, шуңа күрә без бер-беребезгә шулай таныш тоелабыздыр. Юк, ниндидер серле көч бар монда.

Айчибәр белән без клубтагы танцы вакытында таныштык. Язмыштыр, дистәләгән кызлар-чибәрләр арасыннан ни өчендер мин нәкъ аңа игътибар иттем һәм биергә чакырдым.

Ул ялындырмады. Сүзсез бер-ике әйләнүгә, мин сыналган «һөҗүмгә» күчтем:

—Сезнең кебек гүзәл затка мулла бабай ни атлы кушты икән?

Кыз көлде:

—Казан җегетләре барысы да сезнең кебек тәмле теллеме?

—Ник алай дисез?

—Безнең авыл җегетләре боргалап тормайца гына, исемең нимәцек дип сорар иде кый!—Ул тагын көлде.

—Ә сез ул егеткә ни дип җавап бирер идегез?

—Айцибәр дип. Үзегезнекен әйтмәсәгез дә була, мин концертта сезнең шигырь укыганыгызны тыннадым. Карагыз әле, Рәшит, ул шигырьне ыцынлап та үзегез яздыгызмы?

—Ник алай дисез?

—Мин шигырь яза торган кешене башкаларга охшамагандыр дип йөри идем.

—Кызык. Сезнеңчә, нинди булырга тиеш инде алар? Ике башлы, өч аяклымы?

—Алай түгел дә...—Айчибәр бер мәлгә югалып калгандай булды. Ә сез менә шушы минутта минә багышлап шигырь цыгара аласызмы?

Менә сиңа мә! Шигырьләрне аз-маз язгаласам да, мин аларны интегеп, кат-кат төзәтеп кенә язам бит. Чичәннәр барын бар да ул, мин түгел. Тик ничек тә сынатмаска кирәк иде бу чибәркәй алдында.

Һәм минем башымда бер-бер артлы шигырь юллары бөреләнә башлады. Айчибәрне үземә тарта төшеп, югары көчләр миңа ирештергән юлларны колагына пышылдадым:

Толымнарыңа уралып,
Бер онытыласым килә,
Чиядәй иреннәреңнең
Утын тоясым килә,
Күзләрең тирәнлегенә
Карап торасым килә...

Айчибәрнең күзләре бәхетле елтырады, ул куллары белән мине ныграк кочаклый төшкәнен сизми дә калды.

—Рәхмәт. Унсигез яшемә җитеп, әле минә багышлап беркемнен дә шигырь язганы юк иде. Ыцынлап та үзен цыгардынмы?

—Юк, фәрештәләр колагыма пышылдады, мин шуны сиңа кабатлап кына бардым.

Айчибәр бүтән сүз дәшмәде, мине клуб буенча бөтереп алып китте. Ул вальсны искиткеч җиңел әйләнә, менә-менә аңа ияреп очып китәрмен сыман. Без әйләнәбез. Гармунчы әйләнә, клуб та әйләнә. Кайчакта, онытылып, баянның туктап калганын да сизмисең, һаман әйләнә бирәсең. Гомуми көлү тавышы гына сине гарештә очкан җиреңнән фани дөньяга кайтара. Җитәкләшеп, берәр урындыкка барып утырасың. Ә клуб әйләнүдән туктамый.

Галилей:—«Ә Җир барыбер әйләнә!» дигән сүзләрен тикмәгә әйтмәгәндер, күрәсең.

Әйе, Җир әйләнә, Кояш системасы, галактикалар әйләнә. Гади күзгә күренмәсә дә, материядәге атомнар әйләнә. Без дә бит шул ук материя инде. Бөтен хикмәт—хәрәкәттә. Хәрәкәт—тереклек өчен зарури шарт, хәрәкәт—яшәешнең аерылгысыз хасияте. Борынгы бабаларыбыз табигать законнары һәм фәлсәфә фәне белән таныш булмасалар да, сизгер күңел, еллар буе тупланган тәҗрибә аларга моны ике генә сүз белән бик дөрес һәм шагыйранә әйтергә мөмкинлек биргән:

—Хәрәкәттә—бәрәкәт!

Йә, ни дә булса өстәп карагыз шуңа! Җир әйләнүенә хәзер ышанмаган кешене табуы кыен. Яңа гына танышып, күзләренә сөю чаткылары белән бергә аерылышканчыга кадәр үк сагыш, моң тулган егет белән кыз өчен ул тизрәк әйләнә. Җир шары, тукта, әйләнмә, югыйсә йөрәкләр үз орбитасын югалтачак! Тукта сана, хәлебезгә кер сәнә!

Без бергә кайтырга сүз куешмаган идек, ничектер юлларыбыз туры килде. Ай-һай, юллармы икән? Син, егет, шаяртма, фатирың бөтенләй башка урамда ич! Юк, күрәсең, безнең хәрәкәтләр белән кирәк чакта йөрәк, яшьлек үзе идарә итә торгандыр.

Кызлар янында аптырап кала торган гадәтем моңарчы юк иде. Тел-әдәбият бүлегеннән лә без! Тегене-моны сөйләшеп, юктан да тәм табып көлә-көлә атлый торгач, Айчибәр сискәнеп куйды:

—Ой, бакчага килеп цыктык кый!

Туктап калдык. Шунда мин, беренче тапкыр диярлек Айчибәрнең күзләренә карадым. Йолдызлы төн төсле серле, сихерле күзләрен, әллә оялып, әллә мина гына шулай тоелды, ул түбән текәде. Сак кына кагылып, тезенә кадәр салындырган толымлы башын күкрәгемә кыстым һәм кайнар сулышы битемнән дә алда йөрәгемә килеп бәрелде.

—Рәхәт бит, Айчибәр!

—Минә дә.

—Син матур, Айчибәр!

—Оялтма, зинахар! Йөз дә беренче кешегә сүләйсеңдер инде.

Айчибәр хаклы: бар иде алай дигәнем. Кайсы кыз үзен мактаганны яратмас, моны гына беләбез. Ләкин бу очракта мин кыланып, ярарга тырышып түгел, чын күңелдән әйттем.

Без сүзсез генә басып торабыз. Күзләр, йөрәк болай да бер-берсен яхшы аңлый.

Кинәт Айчибәр:

—Әйдә!—диде дә кулымнан тотып йөгереп китте. Ул ап-ак күлмәген җилфердәтеп, очкан күбәләк шикелле, алдан бара. Аның озынча бармакларын минем ычкындырасым килми. Камыш бармак дип, җырларында бабаларыбыз шушындый бармакларны әйткәннәрдер, мөгаен.

Кая баруыбызны сорамаган идем. Күл буена килеп чыкканбыз икән. Айчибәр сулышын еш-еш ала иде. Туктаган уңайга, мин аны сабый баланы күтәргән җинеллек белән, биленнән тотып әйләндерә башладым.

—Ә Җир барыбер әйләнә!

Айчибәр:

—Җитәр кый!—дип назланып тыпырчынган була, үзенең көлүе күл аръягындагы урманга бәрелеп, кире кайта. Ай нурында аеруча серле күренгән камышлар да әсәрләнеп калган.

Ихтимал, судагы балыклар да уянып тыңлыйлардыр. Ә алар, гомумән, йоклыйлар микән соң? Колагымда—көмеш чың. Мин бүтән бер тавышны да ишетмим.

—Башымны әйләндерден кый. Төшер инде. Йә йөрәгем оцып цыгар!

Айчибәрне җиргә төшереп, башымны җилкәсенә салдым. Менә ул, ике яңагымнан тотып, мине кулы ераклыгына этәрде һәм күзләремә карады. Төнлә ниләр генә күреп буладыр ул күзләрдән. Аннары, мин сизми дә калдым, кинәт үзенә тартып, иреннәремнән үбеп алды.

—Бусы синә шигырен өчен.

Мин тагын ни дә булса уйларга өлгерә алмый калдым, ниндидер көч белән үзенә тартып, ул шашып-шашып үбәргә керешә.

Йа, раббым, йа, ходаи! Үбүнең мондые да була микәнни! Үбү түгел, ялкын, ут йоту иде бу. Сулышым капты, җелекләрем кайный дип торам. Бер мизгелгә фани дөньядан аерылып, ниндидер бушлыкка очтым. Карышырлык көчем дә калмады. Калса да карышмас идем.

Ничек кинәт башласа, шулай туктады да Айчибәр. Һәм, миңа карамаска тырышып, чирәм өстенә утырды.

Мин исә, беренче тапкыр хәмер эчкән кеше сыман, ни исерек, ни аек булып, Айчибәрнең иреннәре тәменнән айный алмый торам. «Үптеме соң ул мине?» Күпмедер тынычлангач, аның янәшәсенә урнаштым. Айчибәр башын җилкәмә салды. «Чынмы соң бу?» Айчибәрнең йөрәге атылып чыгардай булып тибә, хәтта миңа ишетелеп тора. Ул чиксез дулкынланган иде. Ирексездән иреннәрем аның ромашка исе аңкып торган чәчләренә, янагына кагылды һәм иреннәрендә туктап калды. Күктә берничә ай кабынды да, дөньябыз ниндидер билгесезлектә югалды. Айчибәр кочагыма сыгылып төште, яшел чирәм түшәккә әверелде. Ни эшләгәнемне хәтерләмим, ләкин Айчибәрнең камырдай йомшак гәүдәсенә кинәт ныклык инде, ул минем кулны үзеннән алып ыргытты һәм сикереп торды. Хәтта ай яктысында да күренде: көйдерердәй итеп карады ул миңа һәм әкрен генә:

—Мин синнән мыны көтмәгән идем. Көллегез дә бер төсле икән!— диде дә, куллары белән битен каплап, китеп барды.

—Айчибәр!—Яшен сугып та аварга өлгермәгән агач хәлендә калдым мин. Ни эшләргә? Беренче уем артыннан йөгерү, гафу сорау иде. Ә гафу итәрме соң ул мине?

Икенче яктан үҗәтлегем, мин-минлегем баш калкыта: исең киткән икән иске чикмәнгә! Үҗәтлегем: йөрмә, укасы коелмас, аның кебек кыланчыкларны беренче тапкыр гына күрүең түгел, ди.

Үз-үземне юатып, кул буенда бераз басып торганнан соң, фатирыма юнәлдем. Иптәшләр күптән кайткандыр, хуҗаны уяту да ярап бетмәс. Бер кичкә кер мичкә дигәндәй, печәнлек тә менә диган булыр сиңа бүгенгә.

Йокларга тырышам, күз йомылмый. Йөрәкне үкенеч исемле корт кимерә, кайтканда ук күңелгә килгән уйлар тынгы бирми. Акланырга да тырышып карыйм, бер үк вакытта үземә ачуым да килә. Кыз беткәнмени дөньяда! Казанга кайтып сызгырыйм гына, дүрт яктан дүртәү муенга килеп асылыныр. Без дә төшеп калганнардан түгел, тоз бетмәсә, кыз бетмәс! Ләкин белеп торам: бу әтәчләнү, акланырга тырышып җәфаланган җанның чәбәләнүе генә. Чынлыкта миндә үз-үземә карата нәфрәт хисе күптән өстенлек алган иде инде. Ярсуыма чыдый алмыйча, сәндерәдән ничек сикереп төшүемне сизми дә калганмын. Хәзер үк Айчибәрдән гафу үтенергә барырга кирәк. Капка төбенә чыккач кына, мин Айчибәрнең кайда торганын да белмәгәнемне белдем. Икенчедән, җиде төн уртасында аның өенә барып керергә мин кем? Казанның бер килмешәге генә ләбаса мин.

Ятагыма кире менүдән башка чара калмады.

* * *

Төн.

Узган елдан калган урман печәне әз генә хәрәкәтләнсәң дә, кыштырдарга тора. Үлән белән бергә чабылган мәтрүшкәләрнең, кеше кулы өзәргә өлгерәлми калган каен һәм җир җиләкләренең үзенчәлекле исе борынны кытыклый. Бу ис сизелер-сизелмәс кенә. Әгәр дә мин алты-җиде яшьтән кулга чалгы алып печән чапмасам, аны җыешып, күбәләргә, чүмәләләп, кышын малларга салып үсмәсәм, бу әчкелтем-хуш исне, ихтимал, тоя да алмас идем. Печәнле сәндерә—җәйге җылы

көннәрдә минем бишегем ул. Анда йоклар чаклар житүен ел саен зарыгып көтеп алам.

Печәнлектә кеше беркайчан да ялгыз булмый. Анда һәрвакыт әллә никадәр бөжәк, башка жан иясе була. Менә хәзер дә миннән ерак түгел жирдә тычканнар чи-чи килә. Якыннан гына нәрсәдер чабып узды. Мөгаен, шул тычканнарның берәрседер.

Төн. Караңгы. Сәндерәгә керә торган ишектән айның ымсындыргыч яктысы төшә. Бу минутта Айчибәр ни эшли икән? Ул инде күптән тәмле төшләр күреп йоклыйдыр. Кызларга ни аңа: кызлар хәтере—тишек иләк, диләр—үпте дә онытты. Алай дисән, нигә соң ул бик рәнжеп карады, нигә бик сыкрап:

—Мин синнән моны көтмәгән идем,—диде.

Уйларымны әтәч кычкырганы бүлде. Хужаларның әтәче. Аның эше рәхәт—титибикәләре янында, мәхәббәт газабы кичереп интегәсе юк. Үзенекеләр житмәсә, күрше тавыклары янына «ужымга» чыгып керү дә гөнаһ саналмый. Ә сиңа катырак кочаклаган өчен дә үпкәләсеннәр, имеш.

Әтәч кычкырды. Димәк, озакламый таң атачак. Ә мин һаман да йокыга китә алмый интегәм. Чыннан да, беренче әтәч кычкырганга күп тә узмый, сәндерә ишегеннән офыктагы болытларның каурыйлары алсу төскә керә башлаганы күренде. Тиздән жир кояш нурларында иркәләнәчәк. Ә мин үземне сүгеп ятам: юньсез син, юньсез син, юньсез син!..

Аның рәнжүле тавышы сәндерәгә эленеп калган да колакта зеңләп тора:

—Мин синнән мыны көтмәгән идем...

—Мин синнән мыны көтмәгән идем...

Бу сүз минем йөрәгемне, бавырымны, талагымны изә, талкый. Бөтенләй яктырып беткәч кенә йокыга киткәнмен.

Күңелне туктаусыз актарып торган газаплы уйлар хакимлегендә алдагы кичне көтәсе калды.

* * *

Практикадагы студентның көне ничек узарга тиеш? Эштә. Йөрәгем бик янса да, йокыдын торуга, көнем сүзгә жор, уен-көлкечән буларак танылган әби-бабайлар янында узды. Һәм юкка түгел, алардан берничә әкият, унлап табышмак, егермеләп яна дүртьюллы жыр язып алдым. Кичкырын өйгә кайтып барганда, Бибикамал исемле әбигә сугылып чыгарга киңәш иттеләр. Әбинең кызыклы гына «Атбакат» дигән кушаматы да бар икән.

Менә кайда тап булдым мин чын хәзинәгә! Йөзьяшәр әбинең хәтер сандыгы без эзли торган «жәүһәр вә асылташлар»га гаять бай булып чыкты. Үзе сүзгә бик хирыс икән: кайберәүләр шикелле кыстатып, ялындырып тормады. Яшьтәше белән сөйләшкәндәй, самоварын тастырханга китереп утыртты да, чәй эчә-эчә, дүртьюллыкларны бу як халкында урам көе булып әверелгән «Тагыл көе»нә әкрен генә жырлый башлады:

Елга суы ага икән,
Ярларга кага икән.
Гашыйк булган жегетләрнең
Жөрәге жана икән.

Уф, әллә соң күрәзәчеме бу Атбакат карчык? Йөрәгем янганын белеп, юри шундый жырлар жырлыймы?

Тагыл күленә төшәем,
Суын алып эчәем.
Сөйгән жарым ташлап китте,
Әйтце, дус, нимәшләем?

Әллә соң яшьлектәге мәхәббәте картаймыш көннәрендә сагыш булып җырга әверелдеме? Ник бер эчтәлектәге җырларны гына яздыра ул миңа? Их, әбкәй! Кушаматың Атбакат булса да, Айчибәр каршында мине яклый да, аның белән кавыштыра да алмыйсың бит син! Җырларың исә дөрләп янган учакка чүмеч-чүмеч май сибә.

Самовар күмеренең уты сүнүгә, әбием кинәт туктап калды:

—Җарый, кузыкаем, утыз җыр булгандыр кый. Бөгенгә җитеп торыр бу шайтан такмагына.

Санап карасам, исем-акылым китте: егерме тугыз да, утыз бер дә түгел, төгәл утыз җыр язганмын икән.

—Инде, җегетем, цаем суынган, җанартып киләем.

Мин инде хушлашырга уйлаган идем. Кич җитеп килә, клубка чыгасы, Айчибәрне күрәсе бар. Ләкин Бибикамал әбинең хәтерен калдырырмын, хәзинәсендәге башка җырларга юлны бикләрмен дигән шик туктатып калды.

Алгы яктан әбиемнең җырын ишетү мине уйларымнан бүлдерде. Беренче җырын башыннан ук ишетмәдем, икенчесен исә дәфтәремә утыз беренче җыр итеп язып алырга да өлгердем.

Вагоннарда үткән цакта,
Җил кисте цәцләремне.
Сездән айрылганнан бирле
Түгәм күз яшьләремне.

Кайнаган самоварын күтәреп, Бибикамал әби өстәл янына узды. Ә мин тагын уйга калдым: самоварның кайнап торуы нәрсәгә кирәк соң аңа? Үзе бит башта ясап куйган чәен дә эчмәде. Шул көенә суынды. Табындагы самсы, шәңгәсенә дә кагылмады. Күрәсең, самоварның шаулап, гөжләп утыруында әбиебез яшәү, тормыш мәгънәсен тоядыр, җан рәхәте табадыр.

Суык чәен түгеп, әби каймак белән яңасын ясады һәм тәмләп карады. Тәме күңеленә хуш килгәч, мине кыстый башлады:

—Эц, кузыем, эц. Каймак белән генә ясаган цай әзәл даруыннан кәм төгел кый! Кана, тагын бер цынаяк ясаем!

Әбинең чәе чыннан да шифалы икән, шундук маңгаемнан тир бәреп чыкты. Берәрне эчкәч, Бибикамал әби йола җыры «Амбирак»ны сузып җибәрде:

Амбирактин, җамбирактин,
Кияү килә җырактин...

Кәләше янына кияү килә. Ә мин? Их, нәрсәсен искә төшереп торырга соң аның!

Карлыгац кылаеп оца,
Канатын җәеп оца.
Бер алланың бирмешләре,
Кемнең җарын кем коца.

Бу җырның вариантын ишетергә туры килгән иде инде. Сүзгә чос әби үзенең яшь вакытларын, сөйгәне белән кавышкан минутларын мәзәк итеп искә төшереп алды һәм моңа кадәр без белмәгән кыз озату йоласы турында сөйләде.

... Егет кызга өйләнгәч тә, бездәге шикелле, бер-ике кич кунуга, кәләшен үз йортларына алып кайтып китми икән. Ул бер ай һәм аннан артыграк та кыз йортында яши, шуннан эшкә йөри.

Көннәрдән беркөнне кыз озату йоласы уздыралар. Атка бирнәләр төяләр. Ә өйдә, кияү белән кызны түргә утыртып, кечкенә генә мәҗлес башлана. Башка мәҗлесләр кебек, бусы да уен-көлке, җыр белән үтә. Кыз озатканда гына башкарыла торган җыры да бар икән. Китеп баручы кыз әти-әнисенә саубуллашу җыруын көйли:

Тагыл куле—олы кул лəй,
Тирəсендə тал-тирəк.
Атай-инəй, үлмəй торын,
Бала баккалы кəрəк.

Жырлашкач, елашкач, кияү белəн кəлəшне атларга утырталар да, урам буйлап, жырлый-жырлый, кияү йортына озата баралар. Изге күңелле халыкның—безнең ерак Себердəге туганнарыбызның күркəм йоласы бу. Айчибəрне дə шулай озатырлар микəн? Əллə минем төсле кайдан да булса килгəн берəр «килмешəккə» насыйп булырмы?

Чəйдəн соң амин иттек. Бибикамал əбигə кушылып, мин дə «Аллаһы əкбəр»,—дип, битемне сыпырдым. Əбкəйнең мона бик күнеле булды:

—Бəрəкалла, бик инсафлы бала икəнсең кый,—диде ул, минем бу гамəлемə бəя биреп.

Иртəгə дə күрешергə сүз куешып, инде ишек тупсасына житкəн идем, əбием сорап куйды:

—Кузыем, синə кара каен турлысында сүлəүце берəр кем булдымы?

Аңлап житкермəдем: нинди кара каен хакында əйтə ул?

Кара тамгалы багана—хурлык баганасы турында түгелдер ич? Хурлык баганасын күрергə туры килмəсə дə, алар хакында укыган-ишеткəн бар. Юк, ул бит ап-ачык итеп, кара каен, диде. Каеннарның карасы да була микəнни? Төньякта үсə торган кəрлə каеннар бу яктагы каеннарга караганда бераз карарак карасын, лəкин алар кара каен дип əйтерлек дəрəжəдə үк түгел.

—Юк, əбкəй, ишеткəнем юк.

—Алайса китмəй торын, сүлəем.

Сəгатемə карадым: сигезенче киткəн. Мəскəү вакыты белəн, димəк, биш тулып узган. Бүген көн уңышлы үтте. Кайтып тиз генə чалбарымны үтүклəп кияргə дə, Фəйзи Габбасовичны күрергə кирəк. Əле бит болында тагын концерт куясы бар. Ə Айчибəр?.. Аның белəн очрашып сөйлəшү барысыннан да мөһимрəк. Бу хакта Атбакат əбигə ничегрəк аңлатырга?

—Əбкəй, иртə кичтəн хəерлерəк, дилəр, əллə соң бу хакта сөйлəшүне иртəгəгə калдырыйкмы? Син дə алжыгансыңдыр, вакыт та сонарып бара.

—Куй, кузыем, китап бүгенге эшне иртəгəгə калдыргалы кушмай. Иртəгə кем бар да, кем юк—барысы да Ходай кулында.

Бу сүзлəрдəн соң юк-бар сылтау табып, каршы килү əдəпсезлек булыр иде.

—Тыңлыйм, əбкəй,—дидем мин, кабат түргə узып һəм кесəдəн блокнотымны чыгардым. Аның авызыннан ишетелгəн һəр сүзне язып алырга, килəсе буыннарга калдырырга əзер идем.

Халык авыз ижатын жыю—комнан алтын, салам эскертеннəн энə эзлəүгə бəрабəр. Ник дисəң, əби-бабайлар белəн көчкə-көчкə генə уртак тел табып, аларның жаена гына торып язганың күбесе фəнгə инде күптəн билгеле, шул сəбəпле кыйммəте югалган булып чыга. Ə менə көннəр буена самоварыннан аерыла алмаган Атбакат кушаматлы шушы Бибикамал əбинен хəтер сандыгында мона кадəр без белмəгəн, ишетмəгəн никадəр хəзинə ята булып чыкты. Боларны тапшыргач, Фəйзи Габбасовичның ничек куанасын күз алдыма китердем һəм үземə дə рəхəт булып китте. Каян килгəн бу əбигə шул кадəрле күңел жəүһəре? Тыңлап карыйк əле, əбиебез бу юлы ни сөйлəр икəн?

—Бу авылда... Атын кем əле, кузыем?

—Рəшит.

—Безнең авылда, Рəшит куаныцым, ул кыйссаны миннəн башка белүце кортка да калмагандыр инде. Əжəлем житмəгəц, һаман яшəем кый. Җегетем, син аз гына сабыр ит, ашыкканыңны сизсəм дə, синə бүген мыны сүлəгəле кəрəк. Ходай тəгалəнекен белмəссен, адəм баласы бүген бар, иртəгə жук. Хəзер, хəзер цаемны гына карап алаем да... Җөзгə житеп килəм кый.

Бибикамал әби самоварын башта тотып карады, аннан соң торбасына күз төшерде—күмере барын-югын тикшерде, капкачын ачып, суы күпмелеген чамалады. Күрәсең, җитәрлек тоелмагандыр, самоварын өстәлдән төшереп, башта чүмеч белән су өстәде, соңыннан морҗа белән стена арасындагы чуен чүлмәктән соскы белән күмер алды һәм аны тәртүшкә[1] ярдәмендә ашыкмыйча гына самовар торбасына салды. Кырыенда торып, сүзсез генә суының кайнап чыкканын көтте. Ашыксам да, мин боларны сабыр гына күзәтергә мәҗбүр идем.

Самовар кайнап чыкканнан соң, Бибикамал әби, фарфор чәйнектәге калган чәйне түгеп, өстәл астыннан борынгылыгы беренче караудa ук күзгә ташланып торган чигүле тастымалга төргән такта чәй алды. Калтыранган сөякчел бармаклары белән бер почмагын шактый мул итеп сындырды.

—Шушы кытай цаеннан да шифалырак цай юктыр кый. Һәр йотымы әзәл даруыннан кәм түгел.

Бибикамал әбинең чәй эчүгә изге бер йола итеп каравы ихтыярсыздан аңа булган хөрмәтне арттыра иде. Юк, йола гына түгел, аның бу хөрмәте табыну дәрәҗәсенә күчкән. Моны чагыштырсаң да, бары тик французларның йөзәр еллаган шәрабка ихтирамы яки джунгли индианнарының үз аллаларына, изге рухларга табынуы белән генә чагыштырып булыр иде.

Сәгатемә күз салдым. Мин бит инде бу әби янында дүрт сәгатькә якын утырам икән. Ничә тапкыр чәй ясап эчерде. Тик мона кадәр күзле бүкән булып утырганмын, аның чәйне пешерү һәм ясавына нинди зур әһәмият бирүенә игътибар итмәгәнмен.

Ул икебезнең дә чынаякларына башта кашык белән сөт өстен генә җыеп салды. Аннан соң чәйнектән дегет төсле куе чәй агызды. Чынаяк тулар-тулмас хәлдә тагын бер кашык сөт өсте өстәде һәм калганын самовардан агызып бетерер дип көткән идем, юк, кайнар суны әз генә тамызды да калганын кабат чәйнектән койды.

Әбәү, шушы кадәр куе чәй эчәргәме? Әүвәл баш тартырга уйлаган идем, соңыннан ул фикеремнән кире кайттым. Бибикамал әби бит миңа үзенең ихтирамын күрсәтә. Ничек диләр әле: «Такта чәем—якты чыраем»мы? Казанда тулай торакта без берәрсеннән, күпчелек очракта, кызлардан, ник дисәң, егетләрнең гадәттә бар чагында—бүредәй, юк чагында шүредәй була, берәр пешерерлек чәй тапсак, чәйнеккә аны уптым-илаһи тондырабыз да, аннан атна буена шуны кайнарлатып кына эчәбез. Төнге ун-унберләрдә калтырап-туңып кайтып керәсең дә чәйнегеңне гөжләтеп җибәрәсең!.. Их, егетләр, ул чәйнең тәме лә, тәме! Шуны без ай буена да эчәр идек, тик жиденче, сигезенче көннәргә киткәч, суга чәй төсе чыкмый башлый шул.

—Торна күз[2] белән эц, кузыем,—диде Бибикамал әби, янып торган мук җиләге салынган савытны миңа табан этәреп,—Цөйгә хәзер үзем йөри алмаем кый, узган көз оныгымнын кызы җыеп алып кайткан иде. Әй бар иде яшьрәк цаклар!—Бибикамал әбинең күзләренә иңгән нурдан һәм янак тиреләренең җыерчыклары бер мәлгә тигезләнеп алудан аның яшьрәк чакларында шактый гүзәл һәм көч-куәте ташып торган хатын булуын чамалавы кыен түгел иде.

—Җыланнар мыжлап торган цөйдән унар циләк ция[3] белән торна күз җыеп кайта торган идем. Хәзер нимишләптер аякларым да тыннамай башлады, билләрем дә сыкрай, әллә йөз яшькә дә җитмәс борын картаям инде,—Бибикамал әби авызындагы сынар тешен күрсәтеп кеткелдәп алды.—Инде, кузыем, тынна, кара каен кыйссасын сүләем.

—Тагыл аръягындагы урман эценә бераз кергәц, анда тузлары кара бер пар каен үсеп утыра. Элек-электән сабантуйларын шул җирдә уздыралар.

1 Тәртүшкә (диал.)—кисәү агачы.
2 Торна күз—мук җиләге.
3 Ция—нарат җиләге.

Менә сина мә! Мин бит Бибикамал әби сүзен «борын-борын заманда, кәҗә команда» диебрәк башлар һәм берәр әкият сөйләр дип уйлаган идем. Күл аръягындагы кара каеннын (тузга язмаганны, андый каен була димени) безгә, безнең фольклор практикасына ни кагылышы бар? Болай да жилпуч-жилпуч кибәк жилгәреп, бер уч бөртек жыябыз. Әбиебез әллә саташамы? Йөзгә житкән кешедән барысын да көтәргә була. Ә болай үзе бер дә саташканга охшамый. Хәтеренә дә сокланырга гына кала—теләсә кайсы студентынны көнләштерерлек. Әнә бит мина никадәр яна жыр яздырды. Әгәр дә ана КПСС тарихы укытсан, ни эшләр иде икән? Мин Бибикамал әбине сынар тешен күрсәтеп иләмсез зур борынынын як-ягына төсләре билгесез ике кысык күз утырткан, доцент Королевка Ленинның «Материализм һәм эмпириокритицизм» әсәре буенча зачет биргән хәлдә күз алдына китереп, көлеп жәбәрүдән чак тыелып калдым. Картлар күнеле пыяла, бер сүз әйтсән, уала, диләр. Картларнын, карчыкларнын да төрлесе бар, практика узган көннәрдә аларга аеруча ихтирамлы булырга, хәтерләрен калдырудан сак булырга кирәклеген анлаган идем. Аннан сон, без бит авыл малае, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга балачактан өйрәнгән.

Әбкәй, әйтерсен, уйларымны укый:

—Кара каен дигәц, бу кортка юкны сөйләгәле жыена, дип уйлайсындыр.—Ул чәен уртлый-уртлый сүзен дәвам итте.—Атаем шулай сөйләгән иде. Мин туардан күп еллар элек авылда Әбелгәрәй атлы жегет баласы яшәгән. Авыл халкы аны Әбүш дип кенә йөрткән. Әбүш жәшьтән ятим калса да, би-ик гайрәтле булып үскән. Унсигез жәшләрендә анын белән бил алышыр кеше тирә-юньдә калмаган. Жәтим дә үскәц, үзе жарлыларнын да жарлысы булгац, тамагын Мәсабих атлы бер байда көнлекче булып туйдырган: жирен сөргән, көтүен көткән, пецәнен цапкан, урагын да урган, ашлыгын да суккан. Ел әйләнәсендә шулай.

Мәсабих байны карунның да каруны булган дип сөйләйләр. Көнтөн эшләтсә дә, хезмәтцеләрен ашлы-туклы гына тоткан. Өц-дүрт кешелек эшләгән Әбүшнен дә туя ашаган көннәре сирәк икән. Үзе житкән жегет, өстендә байдан калып, кырык жирдән жамалган кием бахыркайнын. Мәсабих мәлгыннән китеп, бәхетен бүтән жирдән эзләр иде, байнын Калбизамал атлы Әбүштән ике жәшәр кецки кызы булган. Анын бер бите ай, берсе кояш икән. Син, кузыем, Калбизамалны Кәлбизамал дип жаза күрмә.

—Ник, әбкәй, анысы гына әлләни зур бәла түгелдер лә...

—Менә-менә, сез, жәшләр, нимә сөйләгәнегезне үзегез дә белмәйсез. Калбизамал булса, чибәр, күркәм күнел, Кәлбизамал булса, көцек матурлыгы була. Ата-ана үз баласынын исемен көцек белән бәйләмәс. Бала—жөрәк жимеше кый!

Безнен яклардагы гадәт буенца Калбизамалны Калбеш дип йөрткәннәр. Менә шул Калбешкә—ундүрт, Әбүшкә уналты жәшәр булганда, болар арасында гыйшык уты кабына һәм ул тора-бара пужарга әверелә.

Үзенен бае кызына гыйшык тотучылар турында язылган әкиятләр дә, төрле хикәятләр дә буа буарлык. Шулай да мин Бибикамал әби сөйләгәнне төшереп калдырмаска тырышып язып барам. Күнелем сизә: ахыр чиктә бу мәхәббәт кара каенга барып бәйләнергә тиеш. Тик ничек?

—Бер-берсенә гашыйк булганнарын башта алар үзләре дә аннамайлар, оцрашкан цакларында күз карашыннан да унайсызланып, тизрәк киту жагын карайлар.

Бибикамал әби сөйләгәннәр күз алдыма жанлы сурәт булып килеп баса.

Ике ел уза. Әбүш белән Калбешнен мәхәббәте турында чыш-пыш, имеш-мимеш китә. Әлбәттә, кызынын хезмәтче белән яратышуы Мәсабих байга ошамый һәм көннәрдән беркөнне ул Әбелгәрәйне бер тиен бирмичә, куып чыгара. Яшьләргә очрашу, күрешүләр авырлаша, ә мәхәббәтләре көчәйгәннән-көчәя генә бара.

Яшь йөрәкләр җаен тапмый каламы соң! Әбелгәрәй белән Калбиҗамал бергә булырга вәгъдә куешалар.

Көн артыннан көн уза, Калбиҗамалга да берзаман унсигез яшь тула. Унсигез яшь—балигълык яше. Мәсабих бай йортына егерме чакрымнар ераклыктагы Тәрсүк дигән авылдан, Калбешне өченче хатынлыкка сорап, яучы килә. Кемнән диген—Мәсабихнең әшнәсе, тирәюньдә байлыгы белән дан алган Нигъмәтулладан. Бер тиен өчен җанын сатарга әзер торган Мәсабих, кызының һәм хатынының күз яшьләренә, ялваруына карамый, ризалыгын шунда ук бирә. Ничек инде ул мондый форсатны кулдан ычкындырсын. Егерме баш елкы, тагын ниләрдер бәрабәренә кызын сата.

Моны ишеткәч, Әбүш ашау-эчүдән яза, ни эшләргә белми, ахырда очрашып сөйләшергә җай чыга боларга.

Бибикамал әби сөйли, ә мин Әбүш белән Калбешнең тавышларын ишетәм.

Әбүш. Калби, Калбиҗамалым минем!

Калбеш. Нимәшләйбез, җаным? Атаем башкайларымны ашай кый!

Әбүш. Мин сине бераүгә дә бирмәем! Минә ябешеп цыгарга син ризамы, Калбешем!

Калбеш. Аны ник сурайсын, Әбүш? Риза, риза, җаным! Цыксам, кайда яшәрбез?

Әбүш. Борцылма, Калбиҗамалым. Аткан угым тиеннен күзенә тия, мангаена сугып, үгезне җыгам. Син минем менә бу сөялле кулларыма кара—алар балта тота белмәйме? Син дип типкән җөрәгемне тынна: Калбеше янында булганда, ул армаяцак та, талмаяцак та. Беләкләремә күз салып бак—сине күтәреп, көненә йөзәр цакрым үтәцәкмен. Кирәксә, тайганы җыгармын, киек җанварлардан гайре җан иясе аяк басмаган карурманда гүрнәцә салырмын. Куян—йомышцын, аю хезмәтцен булыр. Бәхетебездән судагы кондызлар, күктәге җолдызлар көнләшер, Калбешемасыл кошым! Китик хәзер үк!

Калбеш. Мин риза, җаным! Язмышымны синә ышанып тапшырам! Җир цитенә алып кит—барам; дигезләргә алып кер—керәм; тау куышында яшибез дисен икән—тау куышына да риза, тик мине үзеннән калдырма гына, Әбүшем-Әбелгәрәй баһадирым! Тик бүген үк түгел, иртәгә, җәме. Мин әйберләрне җыйнаштырып, бераз хәстәрен күрәем. Иртәгә мине шул-шул вакытта бакца артында көт.

Алдагы көнне кайсы сәгатьтә очрашасын сөйләшеп, качып китәргә сүз куешалар. Ләкин бәндә аягын тыгам дигәндә, Иблис таягын тыгарга өлгерә. Тегенди-мондый хәл килеп чыкмасын дип, Мәсабих бай кызын иртән үк ак келәткә яба да, йорт әйләнәләй сакларга берсеннән-берсе явызрак, бүрене дә күкрәге белән бәреп кенә ега торган алты эт, мылтыклы сакчылар куя һәм кызы янына пешекче хатыннан башка бераүне дә якын китермәскә боера.

Билгеләнгән вакытта, Әбелгәрәй бакча артына килеп, сөйгәнен көтә башлый. Бер сәгать көтә, ике сәгать—көтеп-көтеп тә көтек булгач, сизенә моның күнеле эшнең кая табан барганын. Келәт тирәсенә тегеләй дә барып карый, болай да, кая ул! Этләр котырып өрергә тотына, сакчылар, мылтыкларын әзер тотып, күзләре белән төн караңгылыгын бораулыйлар. Әбелгәрәйнең чарасызлыктан йөрәк мае сыза, бераүне дә күрмәс, ишетмәс хәлгә килә. Калбиҗамал сүзенә карап, качып китүне кичектергәне өчен үзен битәрли.

Әбүшнең йөрәгенә кан сава дип тормыйлар—никах укыла, шундый асыл кызны кулга төшерүенә куанып, хәзер булачак тәмле-татлы минутлар дулкынында йөзүче һәм бабасы Мәсабих бай белән авыз иткән әче балдан симез корсагын сыпыра-сыпыра, бераз кызарга өлгергән Нигъмәтулла бай, никахлы хатыны янына зөфаф киченә керә.

Шул көннән соң Әбелгәрәй авылдан юкка чыга. Ятим кеше кемгә

кирәк, баштарак егетнең кая китүе белән артык кызыксынучы булмый. Аның каравы монда кадәр авыл халкы ишетеп өйрәнмәгән яңалыклар карьядән карьягә тарала:

—Нигъмәтулла байның бурлы айгырын урлаганнар икән...

—Киштемнән Кубасовның ике атын алып чыгып киткәннәр...

—Ат караклары адәм түгел, Иблис кавеменнән икән...

Юкка чыккан атлар турында гына түгел, кайбер ярлы-ябагайларның өенә билгесез затлар кереп, күчтәнәчкә ит калдырып чыгулары турында да чыш-пышлар йөри башлый. Ярлыга нәрсә, Ходай тәгалә ач балаларымны кызганып биргәндер, дип, шауламыйча гына бит сыпырып дога кыла да, шундук казан тутырып ит пешерә.

Малларның берсе югалу турындагы хәбәр тынып өлгерми, якын-тирәдәге дистәләгән авыл байларының әле аты, әле сыеры яки бозавы урлануы турындагы хәбәрләрдән гавам гөж килә. Калбиҗамал туеннан соң ярты еллар узгач, Мәсабих байның абзарында өч сыерын суеп, иң яраткан атын урлап качалар. Урланган маллар суга баткандай эзсез югала. Нигъмәтулла байның гына, урланганга өч ай дигәндә, бурлы айгырының тиресен төнлә белән бакча артындагы киртәгә элеп китәләр.

Ат караклары шулкадәр тиз күченәләр ки, бүген монда булсалар, иртәгә алар турында хәбәр йөз-йөз илле чакрым ераклыктагы бүтән җирдән ишетелә.

Безне капчыкка яшерә алмаган кебек, тора-бара төнге «аучыларның» башлыгы Тагыл авылыннан Әбелгәрәй икәнлеге саркып чыга.

Халык арасында исеме мәгълүм булганчы ук, Калбиҗамал бу гаярь егетләрнең берсе аның Әбүше икәнлеген күңеле белән сизә. Очрашасы килгән, бер күрер өчен әллә ниләр бирергә әзер торган минутлары аз булмый Калбеш гүзәлнең. Бер ялгызы калган чакларда Ходай тәгаләгә:

—И раббым, сыңар күзем белән генә күз салаемцы, очраштыр мине Әбүшем-Әбелгәрәем белән!—дип ялвара.

Хак тәгалә аның теләген-догасын кабул итә, көннәрнең берендә Калбиҗамал кичкә каршы бакча артындагы чишмәгә баласының чүпрәкләрен чайкарга төшә. Шунда камыш арасыннан:

—Калбиҗамал!—дигән тавыш килә. Чү, Әбеш тавышы түгелме соң? Йөрәгендәге һәр күзәнәген астын өскә китерердәй, күңелендә җил-давыл, гарасат уятырдай мондый тавыш тагын кемдә булырга мөмкин? Үзе дә сизмәстән Калбеш чишмә суына карап чәчен-башын төзәтә, күлмәк итәкләрен сыпырып куя. Юктыр, юктыр, саташа гына торгандыр, Әбелгәрәй аны инде күптән оныткандыр, аның кебек баһадир егеткә кызлар беткәнме? Аннары мин бит инде хәзер ир хатыны гына түгел, бала әнисе дә.

Калбиҗамал ашыга-ашыга догасын укый, торып як-ягына карана. Берәү дә күренмәгәч, кабат кер чайкавын дәвам итә. Тик инде чишмәгә төшкәндәге тынычлыгы качкан, кемнеңдер карашы аны эзәрлекли, үтәдән-үтә бораулый һәм әледән-әле башын күтәреп карарга мәҗбүр итә.

Ул никадәр генә сизгер булырга тырышмасын, артына бу кәсебенә керешкәннән соң аю кебек көчле, селәүсен кебек елгыр, мәче кебек сак, төлке кебек хәйләкәр булырга өйрәнгән Әбелгәрәйнең ничек килеп басканын абайламый кала...

Мин Әбелгәрәй белән Калбиҗамалны күрәм, тавышларын ишетәм, аларның әчкерсез мәхәббәт ялкынында җанымны җылытам. Ул да булмый, ерактан, рәшә артыннан Айчибәрнең шәүләсе чагыла һәм тиз арада чынбарлыкка әверелә. Иң гаҗәбе, Бибикамал әби сөйләгән Калбиҗамал белән Айчибәр бер-берсенә һаман якыная баралар һәм... бер кешегә әвереләләр. Баксаң, Калбиҗамал Калбиҗамал түгел, Айчибәр икән, Әбелгәрәй исә—мин. Әнә ич, рәнҗү тулы күзләрен төбәп, Айчибәр йөрәгемне парә-парә китерүче сүзләрен теш арасыннан саркытып чыгара:

—Мин синнән мыны көтмәгән идем...

Бибикамал әбинең тавышы мине хыял дөньясыннан кайтарды һәм

Айчибәргә табан сузылган кулларым һавада асылынып калдылар.

Әбелгәрәй сөйгәненә:

—Калбеш, Калбиҗамалым!—дип иркәләп дәшә.

Калбиҗамал борылырга өлгерә алмый, Әбелгәрәйнең көчле куллары аны күтәреп ала да кочагына кыса.

—Калбешем!

Йа, хода, сыктап күз яшьләрен түккән, ул күз яшьләре белән мендәрләрен чылатып бетергән чакларда бер күрер өчен җаннарын фида кылырга риза иде бит Нигъмәтулла байның яшь хатыны. Раббысы аның ялваруларын ишеткәнме?

Көтелмәгәнлектән югалып калган Калбеш башта бер генә сүз әйтә ала:

—Син? Әбелгәрәй, синме бу?

—Мин, Калбеш, мин!

—Ник югалдың? Ник бер хәбәр дә бирмәден?—Калбиҗамал үзе шелтәли, үзе ундүрт яшьтән бирле сөеп тә кавыша алмаган мәгъшугының кочагына һаман сеңә бара. Иреннәре кушылганын да сизми алар. Бии-бии таштан ташка сикереп аккан чишмә челтерәве, үләннәрнең бер-берсенә иркә пышылдавы, күктәге кояш—барысы да ике ирен арасында эреп юкка чыга. Ләкин бу шулкадәр тиз арада була ки, кинәт исенә килеп, Калбиҗамал Әбелгәрәен читкә этәрә.

—Ай, Әбүш, төшер, мин хәзер кеше кешесе кый. Синә нәмәхрәм. Никахлы ирем, балам бар. Җибәр, ил-күз алдында рисвайга калырбыз...

—Аллаһы тәгалә үз бәндәләрен ярлыкар, җаным. Без ахырзаман көнгә кадәр бергә булырга яратылган кый.

—Язмаган булгандыр, Әбүш.

—Калбиҗамал, бер сүзен житә, әйт кенә, дөньядан юк итәм, жанын җәһәннәмгә җибәрәм мин сине үзенә бәйләп куйган ул капкорсакны!

—Кирәкми, Әбүш, кирәкми, җаным. Яхшымы, җаманмы—ул минем ирем. Ризалыгым жук.

—Бергә булсак, Калбеш, бөтен карурманнын ханбикәсе итәм мин сине!

—Ышанам, Әбүш, ышанам, тик зинһарлап сораем: ана кагылма—ул балам—йөрәк парәмнен атасы. Мине дә тынычлыкта калдыр. Сон инде. Хуш бул!

Бибикамал әби сөйли. Ә мин, әйтерсең, бер читтә Әбеш белән Калбешне күзәтеп торам. Әнә бит Калбиҗамал Әбелгәрәенә күтәрелеп карарга да кыймыйча, чайкалып бетмәгән керләрен алып, тиз-тиз китеп бара. Калбиҗамалдан янагына буялып калган күз яшьләрен сөртергә дә онытып, тораташтай каткан хәлдә егет аны күздән югалганчы карап тора. Аннан соң, ишетелер-ишетелмәс кенә сызгырып куя. Ул сызгыруга, нәкъ әкиятләрдәге сыман, күз ачып йомган арада, янына ярты еллар чамасы элек бер урыс алпавытыннан алып чыккан, аны инде күп бәлаләрдән коткарып калырга өлгергән аты килеп баса һәм хәрәкәтсез торган хуҗасына борыны белән төртеп, йомшак кына кешнәп куя. Әйтерсең: «Мин әзер, хуҗам, киттек»,—дип әйтергә тели.

Калбиҗамал сүзендә тора. Күзләрендә моң-сагыш, йөрәгендә мәхәббәте тау елгасыдай ургып ташыса да, Әбеш белән бүтән очрашмый.

Җәй артыннан көз, көз артыннан кыш житә дә кабат яз белән җәй килә. Әбелгәрәйнең Тагылдан чыгып киткәненә бишенче ел китә. Сөйгән кызыннан аерылу ачысыннан Мәсабих һәм Нигъмәтулла байларга үч итеп башлаган бу уенның мәнге дәвам итмәячәген аңлаган Әбелгәрәй туктарга, аны белми, танымый торган берәр якка китеп, шунда урнашырга ниятли. Ләкин өердә атаманның китү, таралу турындагы сүзләрен тыңларга да теләмиләр. Шуңа күрә Әбелгәрәй аркадашлары сүзеннән чыкмый гына түгел, эз яшерү өчен колачын җәелдерергә мәҗбүр була.

Икенче яктан, бер йолкыш кул астына тупланган жыен әтрәк-әләмнең Шадрин, Шатраулардан алып Төмән, Тубылларга кадәр биләмәдә

баш булып йөрүенә губернатор хәзрәтләренен дә, шул тирәдәге татар вә урыс байларынын да теше сызлый. Ун-унбиш кешедән торган төркемгә каршы илле-алтмыш, вакыты белән йөзәр кешедән торган гаскәр җибәрәләр. Ләкин Әбелгәрәйнекеләргә әллә җеннәр, әллә Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итә. Инде бу юлы тотылдылар дигәндә генә, урманга керәләр дә эзсез югалалар. Урман күптән инде аларнын туган йортларына әверелгән. Әз генә ялгыш адым ясауга йотарга әзер торган сазлык аларны йотмый, эзәрлекләүчеләрнен күпмесе шунда батып һәлак була. Бүре белән кыр сыерлары да сирәк йөргән сукмаклардан Әбешнекеләр җилдереп уза, хөкүмәт гаскәрләре адашып кала. Әбелгәрәйнекеләрне ядрә алмый, кылыч кисми, утта янмый, суда батмый. Киресенчә, һәр очрашу солдатлар ягыннан янa корбаннар белән тәмамлана.

Гаскәр белән эш чыгара алмагач, авылларда Әбелгәрәй өере белән элемтә тотуда шикләнгән берничә кешене кулга алып, төрлечә юмалап та, куркытып та карыйлар. Алай да әйттерә алмагач, камчы белән суктыралар. Менә шунда Эчкен авылынын Саескан Ишмүге түзми, ярдәм итәргә сүз бирә.

Әбелгәрәйнен дүрт иптәше белән Мехондагы кенәз Красильниковнын ат абзарына керүен көтеп торалар һәм ут ачалар. Ат каракларынын икесе бәрелеш вакытында үтерелә, урыс Чтапан белән казакъ Микебай качып котыла, ә яралы Әбелгәрәйне кулга алып, бәйләнгән хәлдә Тагылга озаталар. Туган авылында хөкем итсеннәр, янәсе.

Әбелгәрәйнен тотылуы турында да, хөкем көне турында да хәбәр көне-сәгате белән тирә-юньгә тарала.

Куанычыннан байлар бәйрәм итә. Ә Калбиҗамал кара кайгыга бата. Хөкем көнне Тагылга татары, урысы, казагы, кыскасы, кем иренми, шул килә. Атларын урлаткан байлар тантана итсә, ярлы-ябагай Әбелгәрәй батырны күреп калырга ашыга. Кызы Калбиҗамал белән Нигъмәтулла байга хәбәр итәргә Мәсабих чапкын җибәрә.

Мәсабихнен подвалыннан алып чыгып, куллары бәйләнгән Әбелгәрәйне халык алдына китереп бастыралар.

Халык хөкеме дип аталса да, шулкадәр бай җыйналган җирдә ярлыларга кем сүз әйттерсен. Байлар сүзе бер була: Әбелгәрәйне кырмыска оясы янындагы агачка бәйләп куярга.

Урманлы җирдә андый агач табу кыен түгел. Әбелгәрәйне күл аръягындагы куш каеннын берсенә чишендереп бәйләп куялар. Килеп коткарырга тырышучылар булса дип, сакка солдатлар бастыралар. Черки тешләүдән, кырмыска ашаудан Әбелгәрәй ни эшләргә белми, ләкин баулар нык, солдатлар уяу... Берничә тәүлектән Әбелгәрәй баһадирнын сөякләре генә кала. Сөякләрен авыл зиратына күмәргә рөхсәт итмәгәч, көтүчеләр шул каен төбенә җирлиләр.

Әбелгәрәйдән котылу куанычыннан Мәсабих бай кияве белән бәйрәм итә. Әбүшен күмгән көнне, атасы белән ире исерешеп егылуга, Калбиҗамал күл аръягына юнәлә һәм: «Әбелгәрәй җаным, хуш, бәхил бул!»—дип әйтә дә куш каеннын игезәгенә асылына.

Иртәгәсен Калбиҗамалны Мәсабих бай өеннән, авылдан эзлиләр, күлне айкап чыгалар, тапмыйлар.

Әле тагын да эзләгән булырлар иде, көтүдә тыныч кына йөргән сыерлар бер урынга җыйналып, бакырыша башлыйлар. Ни булганын белергә барган көтүче Сафагәрәй каен ботагында Калбиҗамалнын асылынып торган гәүдәсен күреп, телсез-өнсез кала. Аңына килгәч, малаен авылга хәбәр итәргә йөгертә.

Шушы хәлләрдән сон, Аллаһы Тәгаләнен кодрәте илә бер могҗиза була: моңа кадәр ап-ак кәүсәләре белән күзләрне иркәләп үсеп утырган каеннын тузлары карала.

—Кара каен турлысындагы кыйсса, кузыем, менә шул,—дип сүзен тәмамлады Бибикамал әби.—Атаем әйтә иде: каеннар картаеп корый, череп ава торганнар, аларны кисәргә берәүнен дә кулы күтәрелмәгән.

Төпләреннән яшь үрентеләр цыккан, алары да кара булып үскәннәр. Кара каеннарга кагылган кешеләргә кайгы килә, диләр. Тагын халкы шуна күрә ана кагылмый, цитләтеп уза...

Сөйләп тә куйды соң бу әбкәй. Тәннәрем чымырдап китте. Сүз дә юк, кыйсса үзе гыйбрәтле, үзе мавыктыргыч. Ул Пушкинның «Дубровскиен» хәтерләтсә дә, безнең татар әдәбиятында язылганга, ишетелгәнгә охшамый. Әллә мин генә белмимме? Фәйзи Габбасовичка сөйләргә кирәк моны.

Китәргә кузгалдым.

—Сау бул, әбкәй!

—Хуш бул, кузыем. Хозыр-Ильяс юлдашын булсын. Цаемны гына эцеп бетерәем дә ятам. Әллә нимәгә йөрәгем кага башлады.

Бибикамал әби яныннан чыкканда, караңгы төшә башлаган иде. Яшь чак, дәртле чак, кесәдә чүкеч, кулда пычак, диләрме әле? Чүкече белән пычагы юк-югын, әмма яшьлек дәрте бездә буа буарлык. Өстем бөтен, тамагым тук, Айчибәрдән бүтән кайгым юк.

Безнекеләр инде болындадыр. Әнә ич, авыл яшьләре ашыга-ашыга шул якка бара. Фатирыма кереп торырлык вакыт калмаган, чалбарын ник үтүкләнмәгән, дип, кире борып кайтармаслар әле. Концерт та куйдык, клубка да кайттык, биедек тә, ләкин кичәге ямь юк иде. Өметләнеп көтүемә карамастан, Айчибәр күренмәде. Әллә соң үч итеп, берәрсен озатыйммы? Әнә ич алар күзгә карап тора—Казан егете озатканга, ихтимал, каршы килмәсләр.

Юк, күнелем тартмады. Айчибәрнең өен кемнән дә булса белешергә кыюлыгым җитмәде. Кайттым да печәнлеккә аудым...

Бүген шактый арысам һәм алдагы төнне дә адәм рәтле йокы күрмәсәм дә, тиз генә йокыга китә алмадым. Аның каравы... уянганда кояш шактый күтәрелеп өлгергән иде. Печәнлектән төшкәндә үк игътибар иттем: авыл халкы каядыр ашыга. Безнең якта булса, чөгендер утарга дияр идең, бу якларда аны утыртмыйлар икән.

Юынып, өйгә кердем. Тик хуҗалар берсе дә өйдә юк, аларның алты яшьлек оныклары Чулпан гына курчаклары белән уйный.

—Чулпан, картнәң белән картәң кая китте?

—Кана, шуны да белмәйсенме? Бибеш әбкәй үлгән кый!—Күтәрелеп тә карамастан, кызчык уйнавын дәвам итте.

—Нинди Бибеш?

—Атбакат әби.

Булмас! Әле бит кайчан гына тәмләп чәй эчкән идек үзе белән.

Бу сабый ялгышадыр дигән өмет белән, капкалап та тормыйча чыгып киттем.

Ләкин сабыйның ялгышмавына, Бибикамал әбинең вафаты хак икәнлегенә аның өенә барып житкәнче үк ышанырга туры килде. Әнә ич аның капка төбенә күпме кеше җыйналган. Сәлам биреп, өйгә уздым.

Өйдәге бердәнбер агач карават, бәлки әле ул Бибикамал әбидән яше буенча өлкәнрәк тә булгандыр, гомере буена торган стена буеннан идән уртасына күчерелгән. Аның өстендә баштанаяк ак җәймә белән капланган Бибикамал әби ята. Ә бит кичә мин бу караватның бик пөхтә җыештырылган булуына сокланган һәм мендәрләрнең кулдан тукылган чигүле ефәк япма белән каплануына игътибар иткән идем.

—Картнәм истәлеге,—дигән иде Бибикамал әби, япмага төбәп каравымны күргәч.

Кичә мин саубуллашып чыгып киткәндә, урын-җир әле җәелмичә калган иде. Бүген исә—мәңгелек йортына күчәр алдыннан хуҗасы анда соңгы тапкыр ята.

Үземә игътибар иттермәскә тырышып, баш очына якынрак килдем. Татар авылы, татар гаиләсендә үскән малай буларак, мәетне юганга кадәр аның битен ачып карарга яраганын беләм. Калтыранган бармакларымны йөгәнләргә тырышып, әбкәйнең битенә каплаган җәймәне

күтәрдем. Исән чагында ук Мисыр фиргавеннәре мумиясен хәтерләткән бер гасырлык чырае әле ямьсезләнергә, үзгәрергә өлгермәгән. Ул менәменә хәйләкәр елмаер да йә кара каен кыйссасын сөйли башлар, йә чак ишетелерлек тавыш белән «Амбирак»ны сузып җибәрер сыман. Һәм, әлбәттә, өстәл түрендә үзе белән бергә картайган күмер самовары гөжләп утырыр. Ләкин әбиебез хәрәкәтсез, йөзендә галибәнә тынычлык, ул фани дөньяда Аллаһы Тәгалә биргәнгә канәгать мин дигән сыман ята бирә. Могҗизалар әкиятләрдә генә була шул...

Бибикамал әбинең йөзенә текәлгән килеш, мәрхүмә әйләнәләй утырган хатын-кызларның сүзләренә колак салам:

—Бибеш әбкәй цайны сөт өсте белән генә эцә иде кый. Ярты литрлы банка белән ике-өц көнгә бер яна аерткан каймак кертә идем. Сөтебез күп, сыерыбыз икәү кый. Бүген иртәнге цайдан соң сөт аертып, Бибеш әбкәй янына керсәм!.. Башын өстәлгә кыңгыр салган, кулындагы цынаягы кыйшаеп, эцеп бетермәгән цае өстәлгә түгелгән. Йоклый бу дип уйлаем кый! Бибеш әби, дим, дәшмәй. Килеп башына кагылдым, инәкәем!.. Сап-салкын. Нимә диярргә дә белмәйцә, куркып, цыгып җөгердем.

Ул инде бу хакта әллә ничә тапкыр сөйләгәндер. Ләкин авылда йола шундый: мәрхүмгә кагылышлы вакыйгалар килүчеләр арткан саен өр-яңа баштан бәян ителәчәк.

Күзләремне элпә, колагымны томан каплады. Шуна күрә сөйләгәннәрне мин ерактан, мәрхүмәнең пакъ җаны очарга тиешле кояш янындагы ак болыт артыннан ишетәм:

—Әйтерең бармы, изге кортка инде, изге. Нимәцекләр үлгәнен сизмәй дә калгандыр, бахыр.

—Тиз авыру, ансат үлем бир, Ходаем, дип гел теләк теләй торган иде, мәрхүмә...

—И-и, аны кайсыбыз гына теләмәй соң... Барыбызның да теләге фәрештәләрнең «амин» дигән цагына туры килмәй кый.

—Йөзгә җитсәм, яна теш цыга, дип шаярта иде Бибеш әбкәй.

—Куе цай эцте дә шифалы үләннәр суы гына эцте.

—Филшер Фатиха килгәнце, бөтә авыл Бибеш әптәйдә дәваланды. Янбашым кузгалгац, бүлницәдә сихәт тапмаган идем, Бибеш әбкәйнең җылы мунцада бер сылавы җитте.

—Сүләмә инде, ахирәт. Беренце балам-кузыемнан өзлеккәц, мине дә ул гына аякка бастырды бит.

—Ә сөлекне аның кебек оста утызуцы тагын кайсы авылда бар? Тәрсүктәме? Юк. Эцкендәме? Урыс бицәләр дә Бибеш әптәйгә җөри торганнар иде. Өценце ел да Синәвин күлдән сөлекне үзе җыеп алып кайтты.

—Туганнарына хәбәр житкезүце булдымы икән?

—Булмайни! Олы инәм, Мәһруйбану артыннан Ысвирлауга прсидәтел үз машинасын җибәргән, ди. Ганзамал әптәй белән Котлыниса әптәйгә почта Шайшәрип тилиграм суккан.

—Карале, Шәукыя әптәй, Бибеш әби сезнең җакын туганыгыз кый?

—Җакын булмыйца ни, җакын! Минем картнәм белән Бибикамал әптәйнең атае туганнан туган гына кый!

Авылның бер күзенә ак төшкән остабикәсе мәрхүмә рухына багышлап ясин чыга. Кешеләр керәләр, гәп коралар, чыгалар, кайтып житәсе балаларын, туганнарын көтәләр.

Мин исә уйларыма чумып, басып тора бирәм. Димәк, Бибикамал әбине исән чагында күрүче иң соңгы кеше мин булып чыгам. Ихтимал, ул әҗәле якынлашуын сизгәндер, югыйсә кара каен турындагы кыйссаны, китәргә җыенган җиремнән туктатып, кичә сөйләп калырга ашыкмас иде. Әле ярый калганмын, әле ярый тынлап язып алырга түземлегем дә, әдәплелегем дә җиткән. Югыйсә Йосыф—Зөләйха, Фәрһат—Ширин,

Таһир—Зөһрә, Ромео—Джульетталарныкыннан һич кенә дә ким булмаган Әбүш белән Калбеш мәхәббәте турындагы кыйсса Бибикамал әби белән гүргә иңәр иде.

* * *

Көннең икенче яртысында, вакыт табып, кем иренми, шул утырып йөзә торган көймәләрнең берсендә күл аръягына юнәлдем. Бибикамал әби сөйләгән кара каенның барлыгына ышанасым килде.

Күл аръягында камыш урманнары авыл ягындагы ише генә түгел. Камышлыкка житәрәк сусемнәр колониясе. Алар үзләре ямь-яшел, ләкин ерактан караеп күренәләр, көймә белән узучы артыннан башларын сузып карап калалар. Абайламыйча ишкәкне тирәнрәк батырсаң, эләгеп, йолкынып чыгуларын көт тә тор.

Көймәне басма буена туктатып бәйләп куйдым да ярга аяк бастым. Хәзер кая барырга?

Дөрес, эндәшсәм, авылның берәр малай-шалае миңа бик теләп иярәчәк һәм юл күрсәтәчәк иде. Ләкин, беренчедән, мин кара каенның булуына ышанып житмәдем. Сорасам, көлкегә калырмын дигән шик тә булды. Икенчедән, бу хикәят шулкадәр әсәрләндергән иде ки, була калган очракта аны ялгызым гына карыйсым килде.

Күл артында тоташ урман. Урманнан ниндидер каенны эзләү диңгез төбеннән тишек чуерташ эзләүгә тиң булмасмы? Кайданрак эзләргә бу кара каен дигәннәрен?

Климаты белән бездәгедән әлләни аерылып тормаса да, бу якларның гажәпләндергән үзенчәлекләре житәрлек. Башта жир өстенең күкәй тәгәрәтеп уйнарлык тигез булуы хәйран итә. Ирексездән, шагыйрь Равил Фәйзуллинның:

Аһ, тау юклыклар,<br>Кыя юклыклар...

дигән шигыре күңелгә килә. Ничек инде ул монда гына тау булмаска мөмкин? Татарстанда үр өстендә үр, тау өстендә тау.

Кар-бураннарда, яңгыр-сазларда шоферларның да, атлы-жәяүлеләрнең дә теңкәсенә тия торган үрләр житәрлек безнең якларда. Сугыш елларында чәчүлек орлык салган чаналарын кышкы бураннарда, язын карлы-бозлы суларны ера-ера стансадан кайтуларын әнкәйнең елый-елый сөйләгәне хәтердә. Ютазыдан кайтканда Кәрәкәшле үре, Бөгелмәдән кайтканда Салаяз тавы күпләрнең желегенә төшкән, ә кемнәрнедер вакытсыз гүргә керткән.

Ә монда... монда тип-тигез. Монда урман күп, күлләр күп. Тагын биләмәләрендә сигез күл. Тагын халкы браконьер дигән сүзне белми: ул күлгә ау сала да, суыткычка балык сакларга куйганмыни, үзенә кирәк чакта—иртәнме ул, көндез яки киченме—симез-симез кәрәкәләрне алып чыга. Мондагы хатын-кызларның балык арчыганын күреп шаклар катасың: пычак тоткан куллары ашыгу-кабаланусыз гына шулкадәр тиз хәрәкәт итә, күз иярми. Биредә сазлыклар күп, камыш күп, камыш арасында мүк күп. Урыс авылларында бер машина мүккә бер ат бирәләр, дип сөйлиләр.

Бездә жир тулы таш булса, монда аны ялгыш та таба алмыйсың. Ташсыз жирләр дә бар икән. Ком да юк. Ком кирәксә—егерме чакрымнан алып кайталар. Күл буйларында, инеш-чишмә ярларында ләм, ягъни мондагыча әйтсәк, нәш кенә.

Очлары белән болытларны кытыкларга яраткан мәһабәт каен, усак, нарат, чыршылар үсә биредә. Имән белән юкәне ишетеп кенә беләләр. Килеп төшкән көнне койма баганаларын нараттан утыртканнарын күреп, гажәпкә калган идек.

Монда килергә мәжбүр иткән соравым тынгы бирми: Бибикамал

әбинең кара каен дигәне чыннан да үсәме, әллә буыннан-буынга күчкән кыйсса җимешеме? Кайданрак эзли башлыйм икән?

Башны кашып торганда, келт итеп искә төште: әбиебез бит Сабан туе мәйданы дигән иде. Шулай булгач, Мәйдан тирәсен караудан башларга кирәк бу эшне.

Хәерле юлга чыкканмын икән—ярты сәгать тә үтмәде, эзләгән каеныма терәлә язып туктап калдым. Бер төптән чыккан кара киемле пар каен, мичәүгә җигелгән ат кебек, икесе ике якка каерылып үскән. Чыннан да каенмы соң бу, әллә каенга охшаган башка берәр агачмы?

Ачыклык кертәсем килеп, тузларын сыдырып карадым, өзеп алып ботагын, яфрагын чәйнәп, тәмен татыдым—чып-чын каен булуында шигем калмады.

Каеннын каралары,
Ник язмыш аралады?—
Көне-төне тынгы бирми
Йөрәгем яралары.

Әбелгәрәй монын кайсысы төбенә күмелде икән? Кайсысында Калбиҗамал сылуның гомере өзелгән? Сорауларыма җавап бирергә теләгәндәй, баш очында каяндыр кинәт барлыкка килгән козгын каркылдады, каен ыңгырашып куйгандай итте. Әллә миңа ишетелде генәме? Кара каен турында кичә ишеткән кыйсса, Бибикамал әбинең көтелмәгән вафаты, Айчибәрне күрүем, үпкәләтүем, аның миннән качып йөрүе (мин моны шулай бәяли идем)—болар өнме, төшме, әллә чынбарлык-саташу арасындагы аерым халәт кенәме?

Чынбарлык икәнен расларга теләгәндәй, козгын кабат каркыллап куйды. Ана икенчесе җавап кайтарды. Башымны күтәреп карасам, кара каеннарның икесенә дә кунаклаганнар да, минем күңелемә шом салалар. Томшыклары кояшта күзгедәй ялтырый, чак кына куркыныч янауга, сумала төсле кара канатларын җилпергә әзер торалар.

Инде кара каенның барлыгына ышандым, менә алар минем каршыда гына. Хәзер бу тирәдән табанны ялтыратсаң да ярый торгандыр. Хуш, Әбелгәрәй баһадир—татарның Дубровские! Хуш, Калбиҗамал, сезнең хактагы кыйссаны мин илләргә таратырмын.

* * *

Бибикамал әбине икенче көнне җирләделәр. Халык шулкадәр күп килгән иде, әйтерсең, Мәскәү түрәләрен яки джунгли кабиләләре башлыкларының берсен күмәләр. Тик тынлы оркестр җитми дә ботлары тоташкан тирәләрен тропик яфраклар белән генә каплаштырган индианнарны учак тирәли мәҗүси биюгә чакырып, барабан какмыйлар. Купшы сүзләр сөйләнми һәм балавызга катырылган ясалма чәчәкле веноклар юк. Бу җирләү гади татар карчыгы Бибикамал әбинең үзе кебек үк гади. Әмма шушы гадилек аша да кешенең зурлыгы күренә икән.

Халыктан аерылмыйча, Фәйзи Габбасович һәм группадаш егетләр белән без дә зиратка кадәр озата бардык. Безгә анда бару, әлбәттә, фарыз эш түгел иде. Ләкин авыр минутларда бер казанда кайнаган кешеләргә халык ышаныч беләнрәк карый башлый. Әле бит без берсекөнгә генә китәсе кунаклар. Димәк, алда бүгенге көннең калганы һәм тагын башланмаган көн бар. Көн ярымда әле күпме кеше белән очрашу көтелә. Бергә булмасак, алар безгә ничек карарлар?

Икенчедән, «донорларыбыз», ягъни безгә җыр җырлыйсы, әкият сөйлисе, бәет көйлисе әби-бабайлар, апа-агайларның үз аягында булганнары һәммәсе дә йөзьяшәр Бибикамал әбине соңгы юлга озатырга килгән. Мондый чакта читтә калмау—татар авылларында язылмаган канун, ихтыяри-мәҗбүри йола. Әйе-әйе. Аллаһы Тәгалә һәм үз вөҗданы гына

йөкли торган фарыз йола. Бигрәк тә Бибикамал әби кебек ак, асыл әбине җирләгәндә.

Күмәргә бармасак та, анысы шөгылен табуын табар идек. Килгәнгә ничә көн, туйганчы су коенган юк. Көймәдә йөзсәң дә, комачау итмәс иде. Казанга кайткач, үкенеп сөйләргә генә калачак. Өскә авам дип торган урманда күпме матурлык, гүзәллек, сер безне көтеп, ымсындырып тора шикелле. Туйганчы йоклау турында хыялланучылар да юк түгелдер.

* * *

Мәрхүмәне җирләүдә катнашучылар арасында Айчибәр дә күзгә чалынды. Ул хәтта зиратка хәтле килде. Кабер янына ир-атлар гына кергәч, ул да башка хатын-кызлар янында калды.

Айчибәрне күрүгә, кәефем күтәрелеп китте. Әнә бит ул минем сылукаем, кара кашлы карлыгачым толымнарын ефәк яулык эченә яшергән дә койма аша үрелеп, болай карап тора.

Бүген аны күргәннән соң, янына барып, ничәмә ничә тапкырлар сүз катарга, гафу үтенергә җай эзләдем. Йөзләгән кеше арасында табарсың сиңа андый җайны! Бигрәк тә мондый көнне! Өстәвенә кыз бу очрашуны теләмәсә...

Күмүне тәмамлап зираттан чыкканда, койма артында һичбер гамьсез уйнап йөрүче бала-чага һәм үлән чемченүче яшь бозаулардан башка җан иясе калмаган иде. Кызганыч. Айчибәр белән тагын сөйләшеп булмады.

Шомландырып, көтмәгәндә салкынча җил исеп куйды. Тегенемоны сөйләшеп атлаган халык төркеме, сүз берләшкәндәй, күккә күтәрелеп карады: күл артыннан кинәт кара болытлар пәйда булган иде. Урманның әле күптәнме генә колакларны иркәләп, аларга ял биргән шавы усал гөрелтегә әверелде. Күл аръягыннан чыккан болытларның мәкерле холкын туган көненнән бирле үз башыннан җитәрлек кичергән Тагыл халкы башта адымын тизләтте, соңра йөгерергә үк кереште. Чөнки алар белә: ул болытлар һәрвакыт афәт, афәт үк булмаса, барыбер берәр бәла-каза алып килмичә калмыйлар—йә кар-боз ява, йә яңгыр атналар, айлар буена туктамый коя. Аяк асты сазга әйләнә, чабылган печәннәр чери, урган игеннәр үреп чыга.

Ләкин бу йөгерү генә тиздән яшен ташы булып атыла башлаган чыпчык башы зурлыгындагы бозлардан берәүне дә коткара алмады. Күпчелек, өйләренә кайтып җитәргә өлгермәде, яшеренергә урын эзләргә мәҗбүр булды. Без, аяк астындагы сазга игътибар итмәстән, Фәйзи Габбасович артыннан мәктәпкә табан йөгердек.

Эре бозлар, аяусыз камчыдай, эзәрлекли. Саклану өчен бүтән берни дә юк, баш өстенә кулларны күтәреп котылмакчы булабыз. Котылырсың сиңа алай гына! Әнә генә ул безне коткарасы мәктәп. Егерме биш-утыз метрлар ара сөлектәй егетләр өчен бер талпыну, бер ыргым.

Килеп җиттек дигәндә, күзе-башы тонган Салих минем юлга чыгар алдыннан гына стипендия акчасына алган сандалиемнең үкчәсенә китереп басты. Чак барып төшмәдем. Егылуын егылмадым, шулай да клеенкадан келәй белән ябыштырып эшләнгән сандалиемнең тасмалары әллә җебүдән кубып, әллә өзелеп килеп чыкканнарын күрдем дә чүт кенә елап җибәрмәдем. Еларсың да, хәзер генә кайдан алыйм мин яңа аяк киемен?!

Болай атлап та булмый, монда басып торып та булмый, ул сандалины кулыма тотып, башкалар артыннан йөгерүдән бүтән чара калмады. Барысы да шаркылдап көлешә-көлешә каршы алдылар. Сәбәбен сораган идем, Фәйзи Габбасович мине озынча көзге каршысына китереп бастырды. Кыяфәтемне күргәч, көлүчеләргә үзем дә кушылдым. Көзгедән миңа бер аягына сандали кигән, икенчесе шәп-шәрә, чалбар балакларыннан алып чыраена кадәр мул булып пычрак чәчрәгән бер йолкыш карап тора иде. Хәер, сабакташларымның кыяфәте дә минекеннән әлләни артык түгел.

Аерма тик шунда—аларның аяк киемнәре исән һәм бераз булса да мина караганда алар азрак чыланган. Кыскасы, ертык тишектән көлә. Рәхәтләнсеннәр әйдә.

—Бу яктагы яңгырларны беләм мин,—диде, Фәйзи абый, көлеп арыгач.—Бер башласа, туктауның ни икәнен белми. Юллар изелеп, «Беларусь» та йөри алмый башлаганчы, безгә чыгып ычкынырга кирәк. Шуңа күрә бүген әйберләрегезне җыйнаштырып, кызларыгыз белән әйбәтләп саубуллашып куегыз. Ишетсен колагыгыз: алимент сорап, минем исемгә хатлары килерлек булмасын. Онытмагыз: миндә тагын дүрт ел укыйсыгыз бар. Андый-мондый хәл чыкса, имтихан биргән чакта Фәлән-Фәләнечнең әллә кайсы районнан язган сәлам хаты гына коткара алмас. Ярар, нәфескә чик куйыйк, начар эшләмәдек. «Йосыф-Зөләйха» кыйссасының милади белән бер мең дүрт йөз утызынчы еллар тирәсендә күчерелгән бер нөсхәсе өчен генә дә килерлек булган монда, егетләр. Иртәгә безне станциягә илтергә бүген үк колхоз рәисе белән машина сөйләшеп куям. Җиңгәгез дә сагынгандыр, ул да адәм баласы...

Фәйзи Габбасович һәрвакыт күпмәгънәле итеп сөйли. Без көлеп, елмаеп куябыз, кызлар, унайсызланып, кызарып чыгалар.

Янгыр туктауга, өйләргә таралыштык. Анда бер, юк, ике генә эш калды: чемоданны җыясы да кызлар белән саубуллашасы...

«Әй, Фәйзи Габбасович, студент чемоданының нәрсәсен җыясың инде аның. Ә менә Айчибәр белән адәм рәтле саубуллашасы иде...»

Кара каен үскән якның болытлары Бибикамал әби белән хушлашу өчен генә килделәрме, әллә табигать иртәгә китәсе Казан шәкертләренең хәленә кердеме—рәхмәт төшкән яңгыр туктады да бөтән яумады. Ялтырап кояш чыкты һәм ике-өч сәгатьтән бүгенге бозлы яңгыр истәлеге булып чокырларда тавыклар эчәрлек сулар гына калды.

Җитәкчебезнең иртәгә китәбез дию болай да үзенә урын таба алмыйча интеккән җанымның тынычлыгын алып, бөтенләй фикеремне чуалтып куйды. Мине иртәгә ничәдә китүебез дә, ни белән китүебез дә кызыксындырмый. Айчибәр белән мөнәсәбәтләребезне җайга салсак, мин Шадринскидан Казанга кадәр шпаллар санарга, Урал таулары, кыялардагы тау куышлары аша җәяү кайтырга да риза идем. Тик аңлашыйк кына. Тик күңелемә Айчибәр кара каен күләгәсен генә салып җибәрмәсен...

Авылның чыбыксыз телефоны искиткеч тиз эшли. Безнең иртәгә китәсебез сәгате-минуты белән халыкка таралып өлгергән. Иртәнге якта иң әһәмиятле вакыйга булып Бибикамал әбинең үлеме торса, безнең китүебез билгеле булгач, йөзъяшәр Атбакат әби темасы шунда ук популярлыгын югалтты. Бигрәк тә яшь-җилкенчәк арасында...

Китәсе булгач, бүген болынга чыгып тормадык, яшьләр клубка агылды. Сугышка кадәр манарасы киселгән мәчеттә инде алма төшәрлек тә урын калмады, ә яшьләр килә дә килә, килә дә килә. Күзләремнән моң булып тамган сагышымны тыярга тырышып, мин Аны көтәм. Ә Ул юк та юк, юк та юк. Их, син, миһербансыз, кансыз, шәфкатьсез җан! Җитмәсә, шәфкать туташы булырга җыенасың. Газраил, Газраил, Газраил...ым минем!

Өметләнеп, сабырсызланып, күзләремне күгәртеп көтүемә карамастан, Айчибәр күренмәде. Белдем, аңладым: без китмичә торып, ул урамга ике аягының берсен дә атламаячак. Ярар, ни хәл итәсең, тау Мөхәммәткә бармый икән, Мөхәммәт үзе тауга барала бит. Мәхәббәт хакына Әбелгәрәй күрәләтә әнә нинди юлга баскан. Ахыры һәлакәт белән бетәсен күңеле сизмәгәндер дисенме...

Айчибәрне күрмичә китәргә ярамый, ярамый иде. Югыйсә үземне тыярмын, барган уңайга поездан сикереп төшеп калмам дип, һич ант итә алмыйм. Өйләре кайдалыгын сорашып, шунда юнәлдем.

Түр өйләрендә ут юк, бары алгы якта гына. Пәрдә корылган булганга, өйдә кемнәр бары күренми. Ни булса, шул булыр, тәвәккәлләп, сак кына ишек шакыдым. Җавап ишетмәгәч, шакуымны кабатладым.

Ишек ачылып, Айчибәрнең тавышы ишетелде:

—Ишек ацык кый, кер!

Монда кадәр бик тәвәккәл килгән булсам да, ишек төбендә шүрләп калдым. Аякларым бозлы судан чыккан кебек, дер-дер калтырарга керешге. Ни дияр? Әти-әнисе нәрсә әйтер?

Бәхеткә каршы, Айчибәр өйдә үзе генә иде. Билгеле инде, мине көтмәгәндер ул бу минутта, кашлары кушылырга җитеп уйнаклап алды. Күкрәгенә төшкән толымын артка ташлап, бары:

—Син... Сез...—дияргә көче җитте.

—Исәнме, Айчибәр!

—Тс-с, атайлар аръяк якта йоклый. Нимәгә килден? Хәзер ук цыгып кит!

—Айчибәр, синсез беркая да китмим. Биш кенә минутка булса да чыгып кер әле. Бу бик кирәк, Айчибәр! Мин сиңа сүземне әйтмичә китә алмыйм.

Әй, фәрештәм! Минем нинди халәттә торганымны, сүземнән кире кайтмаячагымны аңлады ул. Чыгып көтеп торырга кушты.

Өстендәге халатын күлмәккә алмаштырып, Айчибәр чыгып та җитте.

—Тыннаем, сүлә!

Сүзне ничек башларга белми торам.

—Әйдә, тыннаем кый, сүлә. Нимә сүләйсен?

—Айчибәр! Их, Айчибәр!..

—Туганнан бирле исемем шулай минем.

—Без иртәгә китәбез... Гафу ит мине...

—Минем гафу итүем нимәгә кәрәк сина? Киткәц, бигрәк тә.

—Айчибәр, чынлап, гафу ит. Мин алай теләмәгән идем.

—Син кызлар янында гел шулаймы?

—Ничек?

—Әүвәл койтыланасын да соныннан гафу сорайсынмы?

Ничек ышандырыйм, ничекләр анын күнелендәге үпкә бозын әз генә булса да ничек эретим? Горурлыгымны җинеп әйттем:

—Мин гафу үтенгән иң беренче кыз—син, Айчибәр! Чөнки син, син... Син...

Айчибәр көлеп җибәрде:

—Аннаттын кый! Йә, ярый, әйдә икенце нимә сүләек.—Ул минем күзләремә карады. Карашы үзәкне өзүче бу күзләргә ниләр яшеренгән икән?

—Их син, Казан жегете!—Айчибәрнең тавышы калтырады.—Булмаса, күлгә төшеп, камышларны тыннаек. Китәм дә дисен...

Күл өстендә бер генә җыерчык та юк. Ай нурыннан аръякка күпер салынган. Кер чайкый торган басмага житәкләшеп кердек тә, без тын калдык.

—Тынна, Казан жегете, Тагыл камышларын тынна. Нимәдәендер серләре, моннары, җырлары бар аларнын. Айлы төндә мин шулай тыннарга яратам.

—Кем белән?—Мәгънәсез сорау бирүемне сизсәм дә, тыелып кала алмадым.

Ярый әле Айчибәр әлләни игътибар итмәде.

—Ялгызым. Ә синә бу камышлар нимәләр сүләй?

Әкрен генә кыштырдаган камышларны тыңлыйм. Ашыкмыйча гына сөйлим. Миңа чыннан да шулай ишетелгән сыман тоела.

—Дөньяда иң гүзәл кыз—Айчибәр, диләр алар. Иң матур күл—Тагыл күле. Әгәр бу авылда айның үзеннән исем алган сылу яшәмәсә, без болай зифа булып үсмәс идек, диләр.

—Хыялый тел бистәсе син,—дип елмайды Айчибәр.—Тузга язылмаганны цын булса да сүләгәле кәрәкмәй кый.

—Әнә ич, ишетәсеңме, камышларның кайберләре курай уйный, икенчеләре җырлый, өченчеләре исә кушымтасын эләктереп ала. Ә теге

үзе шаян, үзе ялкау җил малае—дирижер. Бакалары исә—тамашачы. Арада: «Бака-ка-ка»,—дип, бас партиясен сузарга тырышканнары бар.

—Синә шагыйрь булырга кирәк.

—Табигать үзе бөек шагыйрь, Айчибәр! Композитор һәм рәссам.

Бу хакта уйлаганым юк иде моңа чаклы һәм башка җирдә, башка шартларда, әлбәттә, мондый нәтиҗәгә килә дә алмас идем. Үз ачышларын ачар өчен Архимедның ваннага керүе, ә Ньютонның башына алма төшү кирәк булган. Миңа исә табигать иҗат иткән илаһиятлыкны күрергә, ишетергә, аңларга нәрсә сәбәп? Менә шушындый рухи халәттә янымда син булу, айлы төндә, камышлы күл өстендәге дымлы басмада икебезнең басып торуыбыз кирәккән. Каенны себерке һәм утын, кыңгырау чәчәкне печән дип кенә йөргән чакларыбыз азмыни без мәхлукларның...

Моңа кадәр кызлар алдында сер бирү, аларга ялыну дигән төшенчәне белмәгән Казан егете, бер ел элек кенә армиядән кайткан старшина башым белән шушы авыл кызына алиһәгә табынган сыман табынам. Гомеремдә, әйтерсең, кызлар чырае күрмәгән бер мәмәй авыз, боламык. Үз-үземә ризасызлык белдерәм дә, ирексездән кабат Айчибәр турында уйлый башлыйм. Кайсы ягы, нәрсәсе белән җәлеп итте соң ул мине? Әллә соң менә шушы аңлатып бирә алмаслык халәт ярату үземе? Бәлки мавыгу гынадыр? Ник өзеләм-өзгәләнәм соң мин?

Ул да онытылып, нәрсә хакындадыр уйлый. Беләсе иде. Тик аның якты күңеле минем өчен Андромеда томанлыгы төсле буй җитмәс дәрәҗәдә ерак һәм караңгы. Үзен кочып алып иркәләүдән, суырып үбүдән чак тыелып торам. Рәнҗетүдән куркам. Беренче көнне ул миңа кычкырмыйча-ачуланмыйча гына ничек итеп сабак бирде—йөрәгемә аркылыга һәм буйга буразналар булып сызылган.

—Айчибәр!

—Нимә синә?

Баядан бирле әйтергә теләгән үтенечемне җиткердем:

—Миңа бирәр сурәтеңне бир әле.

—Кирәкмәй, бирмәем. Минем сурәтем булмаганнан гына коллекциян ярлыланмас кый. Ул синә, кайткац, икенцеләргә күрсәтеп мактангалы өцен кирәкме? Сез, җегетләр, үзегез озаткан, коцкан кызлар белән бер-берегезгә мактанасыз, диләр.

—Синең миңа ышанмаска хакың бар шул...

Шушы сүзем тәэсир иттеме, әллә башка сәбәп беләнме, ул бераз уйланып торганнан соң:

—Ярай, хат белән салырмын,—диде.

Күктә әйтерсең берьюлы ике ай кабынды.

—Рәхмәт, Айчибәр, мин сиңа поездга утыру белән хат язармын... Икене, юк, икене генә түгел, өчне, бишне, унны язармын!

—Улкадәр юмартланма. Җөрегән җирләрендә оцраган бер кызга әллә ницәшәр хат яза башласаң, конвертка стипендиян җитмәс.

—Җитмәсә, вагоннар бушатырмын!

—Әйттем кый, кирәкмәй дип. Бармакларын кабарыр, йә имтиханында «икеле» алып куярсың тагын.

—Ышан, Айчибәр!

Башын артка ташлап, ул көлеп җибәрде:

—Ышанам инде былай булгац.

Бу сүзләре өчен мин аңа чиксез рәхмәтле идем. Хисләремне белдерергә теләп, сак кына чәчләренә кагылдым. Айчибәрнең тәне аша электр тогы уздымыни: калтыранып куйды. Күзләренә карадым: анда үпкә, рәнҗү ишенең әсәре дә калмаган, болытсыз күзләреннән дөньяларны онытырырдай җылы бөркелә иде.

—Су коенабызмы, Айчибәр?

Бу соравымнан башта ул аптырап калды. Күрәсең, Казан егетеннән мондый тәкъдим көтмәгән иде. Ялгыш ишетүен раслыйсы килгәндәй:

—Син... су төшкәле теләйсен?—дип сорады. —Аннан соң,—төннә

белән су кызлары урлар диеп курыкмайсынмы?—дип шаяртып өстәде.

Мин дә шул ук рухта җавап кайтардым:

—Ай кызы мине су кызларына бирмәс дип уйлыйм.

—Тәртибенә карарбыз.

Ул чишенә башлады. Аннан күреп, мин дә күлмәгемне салып, басма янәшәсендәге көймәнең утыргычына куйдым. Үзем чишенәм, үземнең күзләрем Айчибәрдә. Аның тәне кояш нурларына манылган, хәтта ай яктысында да сизелеп тора. Ә мин... Нәрсәсен сөйләп торасың инде, аның тәне белән чагыштырганда, минеке кызыл эремчек янәшәсендәге яңа сауган сөт кебек. Булыр да, җәй уртасы җитеп, өстеннән күлмәгенне салып, тәнеңне эт кояшына гына булса да күрсәтеп карамагач.

Үзенә йотылып карап торуымны сизеп, Айчибәр унайсызланды:

—Алай карама минә, оялтасын кый! Йә күз тидерерсен. Күз тисә, син киткәц, нимәшләем?

—Минем күзем тими, чөнки...

—Дәвам ит. Нимә цөнки...

—Чөнки...—Мин ык-мык килеп тотлыгып калдым.—Чөнки мин... солдатта булган.

Айчибәр рәхәт иттереп көлеп җибәрде:

—Әйттен кый. Солдатта булганнарның күзе тимәйме?

—Тими шул.

—Ник?

—Солдат—ил сакчысы бит, димәк, ул кызларны да күз тиюдән саклый белә инде.

—Алай икән.

Айчибәр минем белән шаяртып сөйләшә-сөйләшә, толымнарын сүтә.

—Ник сүтәсең, чыланыр ич.

—Цыланцын, Тагыл суы цәцкә шифалы. Әйдә, тизрәк су төшәек. Йә үзенне церкиләр ашап бетерер...

Чыннан да, районныкы ук булмаса да, авылның бар черкие зеңелдәп торган болыт булып ябырылган һәм канымны эчәргә керешкән иде. Эчәрләр дә, Казан егетләре аларга көн дә ризык булмый ич.

Җитәкләшеп, гүя бакча балалары, суга кердек. Су шулкадәр җылы, малайлар әйтмешли, май кебек.

Тирәнәя башлагач, колачлап йөзеп киттек. Айчибәрнең чәчләре таралып төшкән, сылу гәүдәсе күлнең чип-чиста суында айның бар яктысын үзенә җыйган төсле күренә. Кулына алтын тарак тоттыр да аңа карап су кызының сынын иҗат ит. Ул чума, ара-тирә миңа су чәчрәтә, йә колачлап йөзеп китә. Мин бар көчемә тырышсам да, аны куып җитә алмыйм. Сусыз җирдә үсеп, әле ярый, керү белән төпкә китмәслек кенә булса да йөзәргә өйрәнгәнмен. Безнең авылда йөзә белмәүчеләрнең үзеннән буа буарлык.

Күпме вакыт коенганбыздыр, ләкин мин ничә көннәр буена күл кырында коры йөргәннең үчен алдым.

Ниһаять, чыгып, черкиләр белән сугыша-сугыша, өстәге суны бераз саркыткач, киенә башладык. Тик Айчибәрнең, күпме генә саркытса һәм бора-бора сыкса да чәчләреннән су агу туктамады.

Озын кара чәчләр, җеп еланы төсле, маңгаена, түшенә, аркасына сылана. Үзләре ай нурында сәйлән төсле ялтырый.

Суда чакта сизелмәгән иде, чыккач күл буеның дымлы салкыны туңдыра башлады.

Яшьлек нинди генә хәлдә дә чарасын таба. Киенеп бетүгә, Айчибәр:

—Куып тот!—диде дә йөгереп китте. Мин аның артыннан томырылдым. Әллә соң бу Себер кызлары җитезлекне биредәге бай табигатьнең үзеннән ала микән? Айчибәр әле кыр кәҗәсе кебек түмгәктән түмгәккә сикерә, әле төлке койрыгын уйнаткандай, гәүдәсен җитез генә боргалап, әрле-бирле хәрәкәтләр ясый да, тоттым дигәндә, тагын кулдан ычкына. Ничек кенә булмасын, Казан егетенең абруена тап төшермәдем—

Айчибәрне куып житеп, күтәреп алдым. Без инде жылынган идек, күл буендагы утыргычларның берсенә урнаштык. Юктан да кызык табып, көлешә-көлешә хәтсез вакыт уздырдык.

Тагын күле аръягындагы урман өсте сизелер-сизелмәс аллана башлады. Димәк, озакламый таң атачак.

Яныбызда гына сандугач сайрап жибәрде. Сүз куешкандай, икәүләп тынып калдык. Никадәр генә күрергә тырышсак та, сандугачның үзен табып булмады. Безнең яндагы жырчыга арырактан берсе жавап кайтарды. Алар чиратлап та, бергә дә сайрадылар. Куанычлары эчләренә сыймый, күрәсең. Әти сандугачлар гына сайрый, диләр бит. Нинди гүзәл кош бу сандугач! Мәхәббәт, бәхет жырчысы. Ярым шәмәхә, ярым зәңгәр тавышым белән тын гына жырлап жибәргәнемне сизми дә калганмын:

Сандугач, сандугач!
Китмә, китмә, сандугач.
Син китәсең, мин калам.
Сагынганда жырлар өчен,
Жырыңны отып алам...

Әй, сандугачым, сиңа багышлап әнә нинди жыр—сагыну жыры ижат иткәннәр. Һәм ул жыр Айчибәргә ничек тәэсир ясады. Нинди тылсымга ия бу моң дигән нәрсә!

—Сандугачлар берсен-берсе ничек яраталар. Берсе үлсә, икенчесе дә яшәми икән,—дидем мин, фәлсәфәгә бирелеп.

—Ә кешеләр арасында мәхәббәт юк ул!—Моны әйткәндә, Айчибәрнең тавышы тыныч һәм сагышлы иде. Ниләр уйлап тетрәнгәндер. Мин бит аның турында берни белмим диярлек. Гәрчә моңа кадәр, мәхәббәт сагышыннан газап чигеп караганым булмаса да, аның барлыгына көчкодрәтенә, миңа да бер килеренә ышана идем.

... Елаткан да жырлаткан да
Саф мәхәббәт бар бит ул.

Халык әйткән моны. Ә халык алдаша белми.

Кыяр-кыймас каршы төштем:

—Син хаклы түгел, Айчибәр,—дидем.—Мәхәббәт бар ул, бар. Мин аның барлыгына ышанам.

—Ә синең үзеннән дөньяны онытып сөйгәнең бармы соң?

Моңарчы миннән берәүнең дә болай каттый итеп сораганы юк иде әле. Үземнең дә уйлаганым булмады. Ни дип жавап бирергә: бар дияргәме, юк дияргәме?

—Ә Таһир-Зөһрә, Хәлил-Галиябану мәхәббәте?

—Татьяна белән Онегин, Ромео белән Джульетта мәхәббәте дип тә өстә.—Айчибәрнең тавышына жинелчә мыскыллау төсмере чыкты.—Сон, Казан жегете, алар бит барысы да язучылар тудырган әкият... Син миңә әкият сөләмә. Кецки балаларны күлдән яки картуф арасыннан алып кайтмаганнарын гына беләбез. Мавыгулар күп булыр, ләкин мавыгу ул бит гомерем буена акылдан шашып жарату дигән сүз түгел. Их булсын иде ул андый мәхәббәт! Яратсын иде мин яраткан мине гомерем буена, аның өчен янып көл булсам да үкенмәс идем.

—Бәлки мин сине нәкъ шулай яратамдыр...

Айчибәр сүземне әйттереп тә бетермәде:

—Кыланмасана, Рәшит, барыбер ышанмаем кый,—дип бүлдерде.

Мин үгезне мөгезеннән алырга карар кылдым:

—Ә Әбелгәрәй белән Калбижамал гыйшкы турында ни әйтер идең?

Айчибәрнең күзләре зур булып ачылды:

—Син... Син әллә алар турлысында да беләсеңме?—Аның тавышыннан мин Айчибәрнең чиксез гажәпләнүен сиздем һәм күнелемдәгесен әйтеп калырга ашыктым:

—Беләм шул. Бибикамал әбкәй сөйләде. Вафатыннан алдагы көнне

мин аның янында төштән алып кичкә кадәр утырдым. Ну хәтер дә соң үзендә!—Бибикамал әби күз алдымда кабат җанлангандай булды.—Беләсеңме, ул миңа шулкадәр күп яздырды, ун көннекен бергә кушсаң да, аның кадәре үк булмастыр.

—Ул бит минем картнәмнең әнисе белән бертуган иде,—Айчибәрнең күзләрендә яшь тамчылары күренде.

—Шулаймыни?—Мин чын-чынлап гаҗәпкә калдым.—Беләсеңме, аның белән чәй эчкән иң соңгы кеше мин булганмын. Мин киткәндә, ул өстәл янында моңсу гына утырып калган иде.

—Анау көнне инәй эремчек шәңгә шәйләгән иде, бар, кызым, Бибеш картнәнә илтеп кил, дип әйткән иде... Бармадым кый.

—Килгән булсаң икән шунда, Айчибәр!

—Сине оцратудан куркып, урамга цыкмадым. Көнелем дөрес сизгән кый. Син картнәй янында булгансын кый.

—Тотып ашамас идем әле. Шәңгә белән сыйланыр идек. Тәмле ризыктан безнең кайчан баш тарткан бар? Син үзең дә студент кеше бит.

—Ашамый гына тор әле! Йә эцен авыртыр.

—Синең иркенә куйсаң, ачтан үтерергә дә күп сорамассың.

—Сорамам да шул! Бетмәс монда Казаннан килеп әлләкем булып йөрүцеләр. Әнә Тагыл суын эц.

—Синең белән бергә булса, мин агу эчәргә дә риза.

—Юк инде, Рәшит агу эцкәле мин риза түгел.

Шулай шаярып сөйләшеп утырганда, әллә каян гына кара каен исемә төште.

—Ә мин сезнең кара каеныгызны да күрдем,—дидем бераз мактана төшеп.

—Ыцынлапмы?—Айчибәрнең әле генә шат тавышында курку, шом чаткылары чагылды.—Син ыцынлап әйтәсенме?

—Чынлап әйтмичә соң! Кул аръягына шуның өчен махсус чыктым. Койма өстеннән кереп, әле үзләрен тотып та карадым. Моңа кадәр каеннның карасын күргәнем юк иде. Беләсеңме, мин бит анда бер теләк тә теләдем.

—Нимәдәен теләк?

—Айчибәргә дә Калбиҗамалныкы сыман көчле гыйшык бир, дидем.

—Зинахарлап дип әйтәм, шаяртма!—дип ялварды Айчибәр, читкәрәк тартыла төшеп.

—Икмәктер, Айчибәр! Тукта, ник болай куркып калдын? Ни булды?

—Их, Рәшит, кара каеннарга кагылган кешеләр бәхетсез була. Мин бит сине ошаткан идем кый. Бәхетем синдер төсле тоелган иде. Никләр бардын ул кара каен кабатына, никләр кагылдын? Бибеш әбкәй кисәтмәдемени?

—Ул әйтүен әйткән иде дә,—дидем мин аптырап.—Соң ... сон, Айчибәр, без бит синең белән совет чоры балалары, комсомоллар. Юккабарга ышанырга ярамый инде. Хорафатлардан без өстен булырга тиеш. Армиядә безнең замполит әйтә торган иде...

Ләкин Айчибәр фикеремне түгәлләргә ирек бирмәде:

—Замполитыгыз нимә сүләсә дә сүләсен, анда эшем юк. Тик безнен тагылныкылар ул каенга орынмыйлар. Әүвәл заман, мин кецки булганда, аларнын ихатасы юк иде. Көлле халык, җыенда сүләшеп, ун еллар элек аларны коймалап алдылар. Ай, ник бардын, ник бардын анда, Рәшит?

Берничә минут элек күңелендәге риясыз шатлыгы белән котып бозын эретердәй кызның тавышында берьюлы аптырау, үпкә, чарасызлыкгаҗизлек төсмерләре яңгырады. Миңа биргән соравы да җавап алуга өметләнеп түгел, бәлки киләчәкне кузаллаудан туган ачыргалану авазлары иде. Мин нишләргә дә белмәдем.

—Айчибәр, тынычлан, йә, тынычлан инде. Нәрсәне дә булса ялгыш әйткән булсам, гафу ит...

—Гафу үтенмә, Рәшит. Синен монда гаебен юк. Тик шуны хәтеренә

сендереп куй: кара каенга кагылган кыз белән жегетнен бәхетле булганы юк. Зәйнетдин дәдәй белән Айфәрә әптәйнен атлары дулап, Зәйнетдин дәдәй үлде, Айфәрә әптәйнен баласы гарип туды. Ибәтулланын кара каен төбендә эцеп йоклаганы булган, ницә тапкырлар өйләнде, бер бицәсенен дә атнадан-айдан артык торгына жук. Әй, нимәгә боларны синә сүләем, син бит барыбер иртән китәсе кеше. Оцрашасы калмаган безгә, Рәшит.

—Алай димә әле, Айчибәр. «Ни генә эшләнсә дә яхшыга»,—дигән Панглос.

—Кем ул Панглос?

—Вольтернын шундый бер герое бар... Без әйдә болай итәбез: укуыңны дәвам итәргә син Казанга киләсең. Казанда медицина институты барын беләсеңме?

—Белмәенцә кый! Безнен группа житәкцебез Любовь Николаевна Казанныкы, шунда институтны бөткән. Бөткән дип мин дөрес әйтмәем шай. Казанца нимәцек була?

—Бетергән яки, тагын да дөресрәге, тәмамлаган диярго кирәк.

—Әйе-әйе, тәмамлаган. Син минем сүзләрдән көлмә, яме. Мин, дүрт классны Тагылда татарца укыгац, кырык биш цакрым жәяү йөреп, сигезенце классны район үзәгендә урысца тәмамладым. Училищеда да урысца. Шуна күрә казанца койты сүләшәм.

—Ә миңа синең тагылча сөйләшүең ошый. Сезнең сөйләмдә ниндидер үзенчәлекле янгыраш, музыкальлек бар дип әйтимме... Әле бит син минем тәкъдимгә жавабыңны бирмәдең: Казанга киләсеңме?

—Белмәем, Рәшит. Мин училищены быел бөттем, әй, бетердем. Эшкә Әлмән районынын бер авылына билгеләделәр. Өц елга. Өц ел узмаенца аннан китеп булмай. Әти-әни дә каршы килер.

—Әти-әни дип инде... Син бит житкән кыз... Үзенә үзең хужа.

—Булса ни. Алар бит барыбер әти-әни. Мин аннан сон аларнын бердәнбер кызы кый. Сез жегетләргә үз язмышыгызны хәл итү жиңелрәк.

Бу сүзләрне әйткәндә Айчибәр бераз тынычлана төшкән иде инде. Мин аны янума тарта төштем һәм икәүләп сүзсез калдык.

Таң ата башлады. Урман өстеннән шуышкан кояш нурлары күлгә килеп життеләр. Бер-бер артлы кошлар, йоклаган сыман тоелган табигать уянды. Күл аръягыннан күкенең моңлы тавышы ишетелде. Ул кемгәдер, тырышып-тырышып, гомер вәгъдә итәргә тотынды. Әй, кәккүккәй, урман чегәне син! Алдашкан буласың.

Болай да бик матур күл беренче кояш нурларыннан гажәеп гүзәл алтынсу сары-яшькелт төскә керде. Өстеннән пар күтәрелә башлады. Күңелемә шигырь юллары килде:

> Гашыйкларның төнге сере күлдән
> Күтәрелә танда пар булып.

Шул матур кояш, шәфкатьле мәрхәмәтле, борынгы кешеләр табынган Кояш безне аерды. Айчибәр:

—Хуш бул! Озатма, кешеләр күрсә, яхшы түгел,—дип, хушлашырга кулын сузды. Мин аны кулыннан үземә тартып китердем. Иреннәреннән, күзләреннән, яңакларыннан үптем.

Бу минем киләчәктәге газапларымны сизенүем булгандырмы, әйтә алмыйм. Айчибәр:

—Житәр, ашап бетерәсен кый,—ди. Үзе һаман миңа сарыла төшә.

—Хуш бул!

—Сау бул, Айчибәрем!

Ул бер ике адым китә дә, кире килеп кочагыма ташлана. Ниһаять, сукмактан суга төшүче хатыннар күренде.

Инде аерылышабыз гына дигәндә, Айчибәр һуштан яздырырлык сүз әйтте:

—Рәшит, китмә, кал тагын бер генә көнгә!

Менә шуннан аңла син кыз баланы: әле качып йөриләр, ялындыралар, әле, китмә, кал, дип кыстыйлар. Нәрсә бу: кыланумы, әллә кыз баланың әхлакый этикеты белән хис-тойгыларының үзара көрәшеме? Әллә алогизмга корылган логикамы, ягъни, үзебезнең телдә әйтсәк, мантыйксыз мантыйкмы?

—Ни сөйлисең син, Айчибәр? Группадан ничек калыйм? Фәйзи Габбасович үлсә дә калдырмаячак.

Фәйзи абый, әлбәттә калдырырга риза булмаячак. Ләкин калмауның тагын бер бик житди сәбәбе бар иде: болай да юк акчага кырып-себереп аяк киеме алгач, кесәдә жил сызгыра иде. Кемнәндер бурычка сорау оят, Казандагы сыман акча беткән саен бушатырга монда вагоннар да юк. Тик бу хакта кызга ничек әйтәсең? Горурлык дигән нәрсә дә бар бит әле. Югыйсә, үземнең һич кенә дә китәсем килми.

—Рәшит, бер генә көнгә кый. Теләйсенме, Фәйзи дәдәй белән үзем сүләшәм. Кал, ә! Зинахарлап сораем.

—Айчибәр,—дидем, бераз уңайсызлана төшеп,—хәзер калып булмый, иң яхшысы, уку елы башланганчы тагын килермен.

Күңел төбендәгесен дә күрергә теләгәндәй, Айчибәр, текәлеп, миңа бик озак карап торды.

—Мин сине калырсын дип уйлаган идем. Әйтәм кый, кара каен бәхетсез итә дип. Хуш!

Ул әкрен генә атлап китеп барды.

—Айчибәр!

Тавышымны ишетсә дә, борылып тормады, әкрен генә атлап, тыкрык артында күздән югалды. Ә мин саубуллашкан урында сын төсле басып тора бирәм. Кат-кат күлгә карыйм. Кат-кат саубуллашам. Китеп бара алмыйм. Кыска гына вакыт эчендә никадәр якын, никадәр кадерле булып өлгергәннәр бу камышлар. Хәтта үзләренең бертуктамый бакылдаулары белән туйдырып бетергән бакаларына кадәр күңелгә якын лабаса! Сау бул, күлкәй—Тагыл күле! Сау бул, Айчибәрем!

Күлнең аръягындагы урманга кадәр ишеттерерлек итеп минем: «Айчибәр!»—дип кычкырасым килә. Ләкин, кычкырсам да, мөгаен, тавышым чыкмас, эчке өннең ярсуы ирек бирмәс иде.

Шул көнне иртән без киттек. Машина әрҗәсендә Айчибәрләрнең өе турыннан узганда, ул ачык тәрәзәдән кулын болгап кычкырып калды:

—Хуш булын!

Моны башкалар ишеттеме, юкмы, белмим. Сикереп төшәрдәй булып, күздән югалганчы, томырылып-томырылып аңа карап бардым.

Сау бул, Айчибәр!

Сау бул, Себер гүзәле!

Бибеш әбиләр турыннан узганда йөзьяшәр карчыкның тавышы ишетелгәндәй булды:

Амбирактин, җамбирактин,
Кияү килә җырактин.

Хуш, Тагыл—«Амбирак»лы, Айчибәрле, «Атбакат» әбекәйләре булган авыл!

Күл аръягына—кара каен үскән җиргә карадым. Үзем дә сизмәстән, йөрәгемә курку, шом йөгерде.

* * *

Станциядә Тагылның иң әрсез черкие төшеп басар урын да юк. Пассажирларның күпчелеге Казан, Мәскәү ягына юл тота. Билетлар бүгенгә дә, иртәгәгә дә алдан сатылып беткән. Касса тирәсендә закон көчленеке—этеш, төртеш, аты-юлы белән сүгенгән кешеләргә дә игътибар итүче юк.

Болай гына билет алырга өмет юклыгын күргән Фәйзи Габбасовичнын әмере кыска булды:

—Мин әйтмичә торып, берегез беркая таралышмый. Рәшит, син минем белән! Безне шушында көтеп торыгыз.

Белмим, Фәйзи абый ни өчен үзе белән нәкъ мине алгандыр, югыйсә бер дә башкалардан артык җирем юк. Икенчедән, миндә билет кайгысымыни!

Җитәкчебез вакланып тормады, туп-туры вокзал начальнигына юнәлдек.

Юнәлүен юнәлдек, ләкин анын янына эләгүләре бик җинел түгел икән. Кабул итү бүлмәсендә егермеләп кеше көтеп тора, барысынын да йомышлары начальникта.

Фәйзи абый, күрәсен, ел саен экспедицияләргә йөреп шомарып беткән, секретарь кызга мөлаем елмайды да:

—Сенлем, обком заданиесе белән университеттан доцент Фәрдиев,— дип үзен таныштырды.—Виктор Корнеевичка минем биредә көтеп торуым хакында житкерегез әле, зинһар.

Халык көн саен күп кереп торса да, дипломатиянен барлык нечкәлекләрен истә тотып болай нәзакәтле эндәшүчеләр еш булмыйдыр, ахры, секретарь кыз:

—Хәзер,—диде дә эчке телефон трубкасын күтәрде.

—Виктор Корнеевич, сезгә Казан кунаклары, обкомнан...

Вокзал начальнигы безне ишек төбенә үк килеп каршы алды. Фәйзи Габбасович үзенен исемен әйткәннән сон:

—Бу безнен Рәшит дигән егетебез, минем ярдәмчем,—дип, мине таныштырырга да онытмады.—Сез инде, хөрмәтле Виктор Корнеевич, заманында Ленин укыган Казан университеты турында ишеткәнегез бардыр...

Ленин исеме телгә кергәч, кем инде юк дип торсын! Ишеткәне югы да, көлкегә калудан куркып, бар, диячәк.

—Бер генә минутка!—дип бүлдерде безне вокзал начальнигы һәм кынгырау төймәсенә басты. Ишектән секретарь кызнын бәхетле йөзе күренде.

—Галочка, безгә кофе кертегез әле.

Кофе кергәнче, Фәйзи Габбасович экпедициянен максаты, кайларда булуларыбыз хакында кыскача сөйләп бирде.

—Сезгә, Виктор Корнеевич, бик зур гозеребез—кайтып китәргә билетлар табарга ярдәм итсәгез иде. Югыйсә, үзегез беләсез: студентларга юл чыгымнары өчен тәүлеккә илле генә тиен түләнә: ун тиен урын жир өчен, кырык тиене—ашарга. Тагын бер яки ике тәүлек вокзалда ятсалар, ачтан үләчәк бит безнен совет студентлары.

—Анлыйм, анлыйм,—диде начальник,—без укыган елларда тагын да авыррак иде. Сугыштан сонгы елларда студентлар арасында ШУКРУТ дигән сүз дә бар иде.

—Анысы ни инде, Виктор Корнеевич?

Фәйзи Габбасович чыннан да белми идеме, әллә әдәп өчен генә сорадымы—анламассын. Әмма көннәр буе эш турында гына сөйләшеп, билет сорап кергәннәргә юк дип чыгарырга өйрәнгән вокзал начальнигынын үзенен дә, яшьлек елларын исенә төшереп, бер бушанасы килде бугай.

—Без бит сугыштан сонгы елларда укыдык,—дип сөйләп китте.— Ашау-эчү карточкага. Күбрәк кәбестә шулпасы. Менә шуннан студент халкы уйлап чыгарды инде ул ШУКРУТны. ШУКРУТ ул, туганкайларым, широкое употребление капусты работниками умственного труда дигән сүз. Анладыгызмы инде?—Хужа кабинетын янгыратып көлеп җибәрде. Ана без дә ихластан кушылдык.

Ул арада секретарь кыз подноска утыртып, борыннарынны ярырлык хуш ис анкытып торган өч чынаяк кәһвә кертте.

—Рәхмәт, Галочка. Алданрак китә торган поездга Казанга кадәр уналты билеп тапсыннар әле.

—Хәзер, Виктор Корнеевич,—Галя ишекне япкач та әле үкчәләрнең шак-шок килүе бераз ишетелеп торды.

Начальникның күңеленә без бик хуш килдек, ахрысы, сейфыннан моңа кадәр мин ишетеп кенә белгән әрмән коньягы чыгарды.

—Каршы килмәссез бит?

Моның ише чакта мин үземнең хокуксыз икәнемне беләидем, дәшмәдем, Фәйзи Габбасович исә:

—Ничек инде хужа теләгенә каршы киләсең,—дип, әдәпле генә елмайды.

«Сөйләшә белсәң, менә бит ничек икән ул. Өйрәнә тор, Рәшит иптәш, әле яши генә башладың. Кирәге сиңа да чыкмый калмас».

Кечкенә рюмкаларга салган коньяк олы телдән үтмәде, кече телгә житмәде. Шулай булса да, өлкәннәр кабатлау турында уйламадылар. Сүз күптән ШУКРУТтан безнең экспедиция хәлләренә күчкән иде.

—Тагыл дип әйтәсезме? Хәтерлим. Хәтерлим андый авылны. Партиянең шәһәр комитетында инструктор булып эшләгәндә, барып чыгарга туры килгәләгән иде. Халык әйбәт анда, бик эшчән, ачык күңелле.

Аның берничә сәгать элек кенә без саубуллашып киткән авыл турында әйткән җылы сүзләре йөрәккә сары май булып ятты. Әйтерсең, сүз безнең авыл һәм минем нәсел-нәсәбем турында бара.

—Хәтерем ялгышмаса, ул авылның күл аръягында кара каен да үсә иде...

Тагын кара каен! Мине эзәрлекли башлады түгелме соң бу кара каен? Аның хакында ишетмәсәм, үзен барып күрмәсәм, бәлки яхшырак та булыр иде. Әле бит тотып та карадым. Аңа кагылганымны белгәч, әнә ничек өзгәләнде Айчибәр.

—Ул кара каенны бәхетсезлек китерә, дигәннәр иде. Халык бит ул җыен хорафатларга ышанырга ярата...

Бу сүзләрдән минем ут йотканымны әңгәмәдәшләрем сизмәде. Виктор Корнеевич кара каен турында тагын нидер әйтмәкче иде, ишектән билетлар тоткан секретарь Галочканың керүе сүзебезне бүлдерде.

—Сезнең белән танышуыма шатмын,—диде Виктор Корнеевич, ишеккә кадәр озата барып.—Юлыгыз төшкәндә, кергәләп йөрегез.

—Рәхмәт, Виктор Корнеевич. Казанга килсәгез, кунакка рәхим итегез.

Вокзал начальнигы башта Фәйзи Габбасовичка, аннан соң миңа кул бирде.

Икенче каттан төшеп барганда, Фәйзи Габбасович вәкарь белән бер генә сүз әйтте:

—Өйрән!

Билет турындагы хәбәрне сабакташларым «ура» кычкырып кабул иттеләр. Итәрлек тә шул, кемнең тагын бер-ике тәүлек вокзал идәнендә ауныйсы килсен.

Поезд китәргә әле өч сәгатьтән артык вакыт бар, кызларның, акчалары булмаса да, кибет карыйсы килә. Егетләр берәр җирдә сыра эчеп чыгарга каршы түгел. Фәйзи Габбасович ресторанда ашап алмакчы. Минем генә һичкая барырга теләк юк, өстәвенә бер уймак әрмән коньягы канны рәхәт кытыклый.

Кая да булса җыенмавымны белгәннән соң, студентларның житез акылы шунда ук карар кабул итеп өлгерде:

—Син монда калгач, Рәшит, әйберләрне саклау камерасына тапшырып тормыйбыз. Анда түлисе акчага юлга ашарга алырбыз.

Чемодан, сумка ише нәрсәләрне бер почмакка илтеп куйдылар да студентлар күз ачып йомганчы кайсы кая таралышып беттеләр. Бу минутта миңа иң кирәк нәрсә ялгызлык, уйларым белән бергә-бер калу иде.

Адәм баласы бары тик ялгыз чагында гына уйларының чуалган йомгагын тәртипкә китерә ала.

Юлдашларым җыелганда хатым әзер, конвертка адрес язасы һәм почта тартмасына илтеп саласы гына калган иде. Конвертның тышында авылдагы, эчендә Казандагы тулай торак адресын күрсәттем. Язарга уйласа, кайчан кайда буласымны белеп торсын...

* * *

Айчибәр вәгъдәсен үти торган кыз икән. Авылга кайтып, ун көннәр үтүгә, анардан хат алдым. Конверт эчендә толымнарын түшенә салындырып төшкән сурәте дә бар иде. Хаты гына сәер: *«Рәшит,—дигән иде ул,—мин мәхәббәтнең барлыгына ышанмыйм. Шулай да онытма, мин җавап бирмәсәм дә, исенә төшкәндә, язгалап тор.*

*Истәлеккә берсе зәңгәр, икенцесе сары цәцәк—Тагыл болынында үскән цәцәкләр салам. Зәңгәре—танышуыбызны, сарысы аерылышуыбызны исенә төшереп торсын.*

*Тагыл кызы Айцибәр».*

... Туйдырды бу каникул дигәннәре! Күпме ял итәргә мөмкин? Хәер, авыз тутырып ял дияргә дә оят. Бераз акылы бар кеше, каникулга кайттым дип кенә, бер сәгатен бишкә бүләргә торган печән өстендә яки уттай урак чорында авылда тик ятар микән? Моның өчен йә авыру, йә соң дәрәҗәдәге сөрхәнтәй булырга кирәк. Әнә бит, мәктәп балаларына кадәр эшкә чумган: кайсы колхоз көтүен көтә, кайсы—ындыр табагында, ә яшелчә бригадасының ярты эшен алар башкара.

Бу язылмаган кагыйдәдән мин генә ничек читтә калыйм? Өйдәге эшләрне дә карашырга өлгерә алмадым, кайтканның икенче көнендә үк (каян ишеткәндер) колхоз рәисе Сәлах абзый өйгә килеп җиткән.

—Рәшит энем, әрмәннәр сыерларга таштан ферма өйде,—ди бу.— Кешеләр җитми, шуның түбәсен ябышырга ярдәм ит.

—Ник соң әрмәннәр үзләре ябып та бирми? Түбәсенә калгач кына...—дидем, тискәрегә сукалап. Чөнки колхозда эшләү, бигрәк тә төзелештә чиләнү минем планнарда каралмаган иде.

—Ябабыз дигәннәр иде лә,—Сәлах абзыйның уңайсызланганы тавышына чыкты.—Бигрәк кыйммәт—биш бәя сорыйлар. Әллә колхозда әндри казнасы бар дип уйлыйлар. Каян табыйм мин алар сораган кадәрлене... Стенасын да өйдертмәгән булыр идем дә, ничарадан бичара аларга кушарга туры килде.

—Соң, Сәлах абзый, үзебезнекеләр бушка эшләми торганнардыр ич?

—Әлбәттә бушка түгел. Тик, Рәшит энем, безнең халык намуслы ул, тиешеннән артыгын бирсәң дә алмый.

Башка бер дәлил дә тапмасаң, башыңны белмәмешкә салудан да яхшысы юк.

—Сәлах абзый, ни бит... осталар янына чыгып, балта тота белмәгән башым белән адәм көлдерер хәлем юк. Каян килеп балта остасы булыйм ди мин,—дигән булдым.

—Ә-ә, шаяртма, энем.—Колхоз рәисенең алай гына бирешергә исәбе юк иде күрәсең.—Авылда кемнең кем икәнен яшерә алмассың. Атаклы Касыйм оста малае бит син. Әтиең белән бергәләп эшләп үскәнеңне без күрмәгән дип уйлыйсыңмы? Аннан соң шуны да онытма: часть командирына дача йорты төзеп биргән өчен ялга кайтардылар дип, кем мактанып йөрде? Син түгелме, энем? Әллә ул вакытта шыттырдың гынамы? Һи-һи, мин бит инде карт чыпчык, алдавы җинел түгел...

Анысы хак. Иллә дә нечкә җирдән әләктереп алды Сәлах абзый. Оста һәм хәйләкәр булмаса, утыз ел колхоз җитәкчесе булып эшли алыр

идеме икән? Менә бит нәрсә ди: солдаттан ялга кайткан идең, ди. Булды шул андый хәл. Армиядән ялга кайту бәхете теләсә кемгә эләкми, шуңа күрә мин дә кайткан куанычтан мактанып ташлаган идем. Телемнән кем тарткандыр. Картлач шуңа төрттерә.

Ләкин минем дә бирешергә исәбем юк:

—Әтиләрнең дә караштырасы эшләре бар. Бигрәк көтмәгәндә булды әле бу, Сәлах абзый.

—Рәшит энем, мин дөньяга бүген генә килмәгән, син мине дә аңла: әгәр башка чарасы булса, гозерләнеп, сиңа килер идемме?

Моңа кадәр безнең әңгәмәне дәшми-тынмый гына тыңлый торган әти сүзгә кушылды:

—Улым, Сәлах абзаң кешене юкка бимазалап йөри торган адәм түгел. Олы башын кече итеп кергән икән, сүзен аяк астына салып таптау килешмәс.

—Әти, ә үзебезнең эшне кем эшләр?

—Анысы өчен кайгырма, берәр җае чыкмый калмас.

Шул сөйләшүдән соң, каникул буена кулымнан балта белән чүкеч төшмәде.

Балта эше—авыр эш. Монда кулың эш белү генә җитми, физик көч тә, чыдамлык та кирәк. Көне буена тук та тук килеп, кулбашларыңа кан төшә, уч төпләре беләүләнеп ката. Хет пычак кайра.

Бер карасаң, кызлар кайгысы калмаска тиеш иде кебек. Ләкин Айчибәрнең озатып калгандагы «Хуш бул», дигән сүзе һәрдаим колагымда яңгырап тора.

Безнең аерылышканга ике айдан артык вакыт узды. Шул арада мин аңа унлап хат яздым. Балта сабы тотып, кичен кан төшеп, язылмас хәлгә килгән бармакларны каләмнең бер дә тыңлыйсы килми: гадәттә ярыйсы гына чыга торган хәрефләремнең кытай иероглифларыннан әлләни артык җире юк.

Табигатьнең дә, мәхәббәтнең дә үз кануннары бар күрәсең. Юкбар мавыгу гына булса, Айчибәр инде онытылырга тиеш иде. Юк, йөрәгемне сагыш сулкылдата. Билгесезлек җәрәхәте бу сагышны торган саен көчәйтә генә. Ник язмый, ник бер хәбәр дә бирми бу миһербансыз кыз?! Кайдан килгән аңа мондый битарафлык? Кемгәдер, нәрсәгәдер үч итәме әллә? Ике авыз сүз язып салганнан кулы корыр дип куркамы? Әллә хисләремнең чынлыгына ышандыра алмадыммы, минем хатларымны уен дип кенә кабул итә микән?

Әле тагын өч-дүрт көн авылда тору мөмкинлегем булса да, түзмәдем, августның егерме җидесендә әнкәйгә кичкә мунча ягарга әйтеп, Сәлах абзый янына идарәгә киттем.

Гаҗәп акыллы бу Сәлах абзый, озын-озак аңлатып торырга да туры килмәде. Керә-керешкә:

—Рәшит энем, ник кергәнеңне беләм, эштән туктап, укырга китәргә җыенуыңдыр. Рәхмәттән башка әйтер сүзем юк, бик нык ярдәм иттең. Кызганыч, каникулың тагын берәр ай булмады. Мин хәзер районга ашыгам. Тиярене исәпләп, кассир Нәсимә өегезгә кертеп чыгар. Хәзергә акчасын гына бирербез, ашлыгын кешеләр белән бергә көзен алырсың. Миңа сорауларың юкмы?

—Юк.

—Алайса, бигайбә. Ашыгам.

Төзү бригадасында бергә эшләгән агайлар минем китү турындагы хәбәремне авыл кешеләренә хас тыныч кына кабул иткән сыман иде, кичен бригадирыбыз Әмир абый, мин китәргә җыенгач:

—Рәшит, ашыкма әле,—дип туктатты.—Күпме бергә эшләдек. Аллага шөкер, бәла-казага тарымадык, ачуланышмадык. Ферма артындагы чирәмлектә бераз сөйләшеп утырсак, каршы килмәссең бит?

Көтелмәгән сүздән аптырап калдым. Моны ничек аңларга? Бер дә эчү-мазар белән шөгыльләнмиләр иде. Югыйсә, эчим дигән кешегә сәбәбе

чыгып тора. Эшенең авырлыгы, буыннар язам дигән сылтау белән көн дә эчәрлек. Ә болар ул якка хирыс түгел. Мин эшләгән ике ай эчендә бары бер тапкыр—Бака Наиленең туган көнендә генә эштән соң аларның өенә сугылып чыккан идек. Анда да озак утырмадык.

Бәлки мин мондагы йоланы белеп бетермимдер. Мөгаен, саубуллашыр алдыннан аларны сыйларга тиеш булганмындыр. Беттем, үч иткәндәй, кесәмдә бер тиен дә акча юк. Тәкъдимнәрен кире кагу да егетләрчә түгел.

—Ни бит, агайлар, алайса сез урнаша торыгыз, ә мин тиз генә әйләнеп килим... Наил абый велосипедын да биреп торса, бер аягым тегендә, берсе монда булыр, күз ачып йомганчы килеп житәрмен...

Әмир абый:

—Син, шәкерт, өлкән абзыйларыңны рәнжетмә,—диде, ике әйттермәслек кырыс тавыш белән.—Синнән берни дә кирәкми. Монда барысы да бар.—Ул кабарып киткән сумкасына шапылдатып сугып алды.—Юлга жыенасың барын беләбез, шуңа күрә озаклап утырырга ният юк.

Чирәмлеккә төшкәч, гажәпләнүемнең чиге булмады: башта берничә гәзит жәйделәр, ул гәзитләр өстенә ике ярты менеп кунаклады. Әмир агайның сумкасыннан тавык чыкты. Ул тавыкны кул белән генә ботарладылар. Кыяр, помидор, яшел суган—кыскасы, авыл жирендә мөмкин булганның һәммәсе дә бар иде табында. Ләкин мине гажәпләндергәне бу түгел әле. Аларның юмарт күңелле икәнлекләрен беләм. Безнең авыл халкы, гомумән, кысмыр түгел. Тик кай арада бу хәзерлекне күреп өлгергәннәр? Ничек мин берни дә сизми калганмын? Иртәдән кичкә кадәрле бергә булдык ич. Ай-һай, хәйләкәрләр!

—Рәшит үскәнем,—диде Әмир абзый, беренче чәркәләрне чәкештергәндә,—гадәтебезне беләсең, хикмәт салуда гына түгел. Бу жыйналуыбызның сәбәбе бүтән: бригада егетләренең сиңа рәхмәт әйтәсе килә.

—Ни өчен?—дип сораганымны сизми дә калдым. Чыннан да авылның мөхтәрәм затлары әйтердәй ни эшләдем соң әле мин? Алар белән рәттән эшләдем. Бары шул гына. Ә моның өчен миңа тиешле хакын түләрләр, Сәлах абзый алдамас.

Әмир агай тамагын кырган иде, Бака Наиле аңардан өлгеррәк булып чыкты:

—Эшне әйбәт кешеләр белән эшләгәндә генә, жанга рәхәт була, Рәшит дус. Синең белән эшләү безгә рәхәт булды. Менә шуның өчен рәхмәт. Кулың эш белә, көченне жәлләмисең. Исән-сау укып бетер, зур кеше бул.

Мондый сүзләрне ишетү уңайсыз булса да, рәхәт иде. Әллә кайларда абруй казанып та, туган авылында сиңа чүп итеп кенә карасалар, ни үкенеч. Битләрен жил кисеп, кояш өтеп бетергән тыгыз тәнле, яшьләренә күрә шактый таза күренгән, эчләре бер кәррә кинәсез, намуслары балта йөзе кебек туры булган бу абзыйларның бер төрле уйлап, икенче төрле сөйли торган кешеләр түгеллегенә иманым камил иде. Тик болай зурлаулары... Башка сыйдырырлык түгел. Ярар иде осталыгыңны күрсәтердәй нинди дер катлаулырак эш башкарсаң. Бәбкә ясап утыртып, аңа кырыклы тактадан аслык тезү өчен осталык кирәкми. Күрәсең, аларның кешене бәяләүдә үз үлчәмнәре бар.

Рәхмәтемне матур итеп, жиренә житкереп әйтермен дигән идем, барып чыкмады, әллә хәмер тәэсире, әллә күңел йомшаудан күзгә бәреп чыккан яшь тамчылары комачаулады.

Чирәмдә утырган шушы бер сәгать күңелемә якты хатирә булып кереп калды.

Күңелем сизенгән икән, Казанга ашкынуым тикмәгә булмаган: Айчибәрнең авылда ике күземне дүрт итеп көткән хаты тулай торакның вахтер янындагы өстәлендә кояш нурларыннан саргаеп өлгергән иде инде. Кайчан язылуы, кайчан килүе дә билгесез. Их, бу хатның мине

биредә көткәнлеген белсәмме!? Күптән очып килгән булыр идем. Тик ни өчен ул миңа авылга түгел, Казанга язган? Укуларның сентябрьдә генә башланасын белә иде бит.

Хәзер үк, хәзер үк ачып укырга кирәк. Юк, ачмыйм, биредә—кеше үтеп-сүтеп йөри торган җирдә ачмыйм. Шатлыгымны берәү белән дә бүлешәсем, сөенечле тойгыларымны бүлдерәсем килми. Минем сөю—минем шатлыгым гына! Ә бәлки... конверт эчендә шатлык та түгелдер. Кызлар күңеле—Андромеда томанлыгы. Томанлыкта ни булмас...

Берсеннән-берсе авыррак чемодан белән сумка тоткан көйгә ничек итеп биш катны бер сулыш илә йөгереп менгәнемне дә, бүлмә ишеген ничек ачканымны да хәтерләмим. Тәрәзә каршысына килеп, ымсындырып торган конвертны әйләндереп-әйләндереп карадым. Дүрт күз белән көтеп алган хатның конвертын ертмыйча, имгәтмичә ачасым килгән иде. Ләкин ул нык ябыштырылган, җитмәсә, бармакларым да тыңлаусызга әйләнгән.

Тәвәкәлләп, конвертны ерткалап ачтым. Айчибәрнең шакмаклы дәфтәр битенә бөжрәга тартым түгәрәк хәрефләр белән язган хатын ашыгып укырга керештем.

*«Рәшит, исәнме!*

*Менә ышан инде синә: хатны еш язам дип вәгъдә биргән идең, кайда ул хатлар? Әйтәләр иде аны Иделгә таянма, ир-атка ышанма, дип. Хак икән. Ярар, язасын килмәсә, үзеңне көчләмә. Шулай да Тагылда цакта танышып калуыбызга мин үкенмәем: ул күңелемдә якты нур булып җылытып тора.»*

Тукта, тукта, Айчибәр бит миңе хат язмауда гаепли. Ә мин язган бер дистә хат кая киткән? Адресы буталган дисәң инде... Бер генә хат язган булсам, андый хәлләр дә булгалый дип, шуңа сылтар идең. Ун хат берничек тә югалып бетәргә тиеш түгел ләбаса.

*«Синең әле авылда икәнеңне белсәм дә, хатымны Казанга язам. Сәбәбе—авылдагы адресыңны таба алмадым. Әллә үзем бирәр җиргә куйганмын, әллә инәй быргыган. Хәтердән генә язгалы җөрьәт итмәем, ялгышсам, барып җитмәяцәк. Төгәлен сорагалы почтага кермәем. Юкса анда индексы булырга тиеш. Почтада хәзер армиядән кайткан Зәңгәрәй эшләй. Җай цыкса, гел бәйләнергә генә тора. Аның белән оцрашасы килмәгәнгә күрә, клубка да сирәк—яхшы фильм килсә генә цыгам.»*

Аһ, кабәхәт, аһ, сволочь! Барып тешен коярга! Күңелемдә үзен моңа кадәр бер тапкыр да күреп карамаган Зәңгәрәйгә карата күңелдә көнчелек уты кабынды. Кара син аны нишли! Йодрыкларым төйнәлеп, сулышымны еш-еш ала башладым. Зиһенемдә бер уй яшен төсле сызылып үтте: ә бәлки?.. Бәлки барып җитмичә югалган хатларның да сәбәпчесе шул Зәңгәрәйдер. Почтада эшләвеннән файдаланып, Айчибәргә бирми яткыргандыр. Әйе-әйе, тагын кем булсын! Ун хатның унысы да берьюлы югала алмый.

Тагынниләр язды икән? Укуны дәвам иттем.

*«Тагылда көлле халык пецән эшендә. Атаем белән мин дә үз паебызны цабып бөттек. Инәем аурап тора, шуңа күрә пецән хәзерләү үзебезгә генә калды. Яхшы торса, өц кәбән цыгар, ди атаем. Алдагы атнада минә эшкә башларга. Эшкә Әлмән дигән районга билгеләделәр. Кызганыц, бөтә авырлык атаемның үзенә генә кала инде.*

*Кицә, пецәннән кайткац, күлгә су төшкәле бардым. Икебез су төшкән җирне хәтерләйсеңме? Тагыл камышлары Рәшит атлы Казан җегетенә сәлам әйтергә куштылар.*

*Язарга уйласаң да, Тагылга бүтән язма. Онытып бөтмәсәм, Әлмәнгә барып урнашкац, бәлки үзем язармын әле. Күңелсез минә...*

*P.S. Күл арьягындагы кара каенның берсен яшен сугып аударды. Тагыл халкы моны нимәцек журарга да белмәй.*

*Хуш бул. Айцибәр.»*

Җәйге ялга таралышкан шәриктәшләрем берәм-берәм килә башлады. Хәл сорашу, хатирәләр китте. Без инде хәзер авызын ачса, үпкәсе күренә торган беренче курслар түгел, тәҗрибәле студентлар. Җиргә дә алар сыман кыяр-кыймас түгел, хуҗаларча басып йөрибез.

Адәм баласы һәрвакыт нидер көтеп, өметләнеп яши. Шунсыз мөмкин түгел. Ач кеше—тамагын туйдыруга, бәхетсезе бәхеткә өметләнә. Бәхетлесе исә бу сәгадәтле минутларның бакый дәвам итүен тели.

Ә мин Айчибәрдән хат көтәм. Ул хат һичшиксез киләсенә ышансам, бәлки азрак дулкынланыр, бу кадәр тәкатьсезләнмәс идем. Ләкин андый ышаныч юк. Бәлки ул миңа бүтән һичкайчан язмас...

Айчибәрдән хат килмәгәнгә карамады, беренче сентябрьдә укулар башланды. Әмма өч көн укуга, тревога белән диярлек үк күтәрделәр дә, көзге байлыкны урып-җыюда ярдәм итәр өчен, пароходка утыртып, Актанышка озаттылар. Айчибәр әллә хат язмады, әллә язып та миңа килеп ирешмәде.

Актаныш ул сиңа Казан арты түгел, хат килмәдеме икән дип, тиз генә урап кайта алмассың. Бәлки тулай торакта Айчибәрнең хаты көтәдер дә һәм ул, мин булмагач, вахтер янындагы өстәлдә иясен тапмаган башка хатлар арасында кадерсезләнеп ята бирәдер. Ичмасам, адресын да белмим, бүген үк хат юллар идем.

Нигә бик акрын уза бу көннәр? Күпме эшләдек инде, ә килгәнебезгә нибарысы бер атна узган. Без менә дүртенче көн кырдан кукуруз ташып, силоска салабыз. Эшкә киеп йөри торган чалбарлар шул арада кукуруз ширбәте сеңеп, шыкырдап катарга өлгерде. Чалбар шундый хәлгә килде: салып бастырып куйсаң, чатлы багана кебек басып торачак.

Әле ярый эш бар. Ниһаять, Актанышның узмас тоелган бер ае үтеп китте. Һәм безне ачык машинада Казанга илтеп куйдылар. Төнлә белән генә кайтып җиттек.

Ура! Айчибәр хат язган. Бу юлы минем бүлмәгә менәрлек тәкатем калмаган иде. Бүлмәдәшләремә төенчегемне бирдем дә, кабалана-кабалана, конвертны ачтым. Хатны кулга алуга, Айчибәрнең күңел түрендә сакланган татлы исе борынга килеп бәрелгәндәй булды.

*«Хәерле көн, Рәшит!»*

*Бу хатым сиңа көндез барып ирешер, шуңа күрә аны хәерле көн теләүдән башладым.»*

Ялгыштың, кызый, ялгыштың. Сәгатемә карап алдым: тагын биш минуттан унике тула иде. Йә, тагын ниләр яздың икән?

*«Әгәр дә соң кайтып, хатымны киң белән, йә төнлә алсаң, көн урынына киң яки төн диеп укырсың.»*

Кадерлем минем. Монысын язып тормасаң да була иде ич. Синең хатыңны тәүлекнең кайсы гына вакытында алып укысам да, кичләрем ямьләнеп, төннәрем яктырып, көннәрем нурга күмеләчәк.

*«Районның баш врачы мине эшкә зур бер совхозның иң ерак бер бүлекчәсенә фельдшер-акушерлык пункты мөдире итеп билгеләде. Монда яшәүчеләрнең күбесе җирле халык. Авыл кешеләренең әле кайберләре һаман да җир идәнле землянкаларда яшәй. Һәр өйдә диярлек бишәр-алтышар бала. Килгән көнне үк сиңа хат яза алмадым, гафу ит. Тиз арада өйләрен йөреп чыккалы кәрәк иде. Бер йөз егерме йортның көллесендә дә булдым. Кешеләрнең кайберсендә туберкулез билгеләре сизелә, кайберләренең күзләрендә—трахома. Бирелә, әйтүләренә караганда, еш кына дизентерия белән дә авырап торалар икән. Балалар арасында авыручылар бигрәк тә күп. Аларның барысын да исәпкә алып, баш врач янына киттем.*

*Сүләгәнемне тыңлагач, Самуил Маркович, социалистик чынбарлыкны бозасың дип, үземне сүкте. Чөнки, бездә туберкулез, трахома кебек эпидимияләр бөтте дип, бөтә дөньяга кыңгырау кактык. Бу авылга килмәгән булсам, бәлки*

*мин дә ышанмаган булыр идем.*

*Баш врачтан бүтән җиргә күчерүләрен сораган идем, шартын белгәч, тизрәк цыгып китү җаен карадым. Аңлайсындыр сүзнен ни турлысында барганын...*

*Монда бер генә көн дә торасым килмәй.. Кайцан да булса күцерерләрме, җукмы—белмәем. Бәлки мәҗбүри өц елымны шушы җәһәннәм поцмагында уздыргалы туры килер. Шуна күрә кайту белән җин сызганып, эшкә керештем. Мин бит монда универсал: уколлар кадаем, җәрәхәтләрен дә бәйләем, йөкле бицәләрнен исән-аман котылуларына да җаваплы. Бер ай эцендә биш бала туды. Әйтерсен мин килгәнне генә көтеп торганнар. Ул биш баланын берсен, больницага илткәндә, үземә кабул иткәле туры килде. Минем белән горурлана аласын: хәзер мин Айцибәр генә тәгел, кендек әбисе дә. Бер ана үз кызына минем хөрмәткә Айчибәр дип исем куштырган.*

*Авылны, күлне, күлнен балыгын сагындым. Монда урман да юк, күл дә юк, дала да дала. Сез килгәц, безнен авыл бигрәкләр дә җәмьләнеп киткән иде. Тагыл халкы сезнен турлы озак сүләде. Бәлки хәзер дә искә төшерәләрдер. Медпункттан туфлиләремне урлаганнар иде, беренце хезмәт хакымнан янасын алырга туры килде.*

*Рәшит!*

*Сирәк булса да, мине дә исенә ал. Хат язарга уйласан, адресы конверт тышында күрсәтелгән.*

*Хуш бул, Казан җегете.*

*Сине үбеп: Айцибәр.»*

Хатны укып бетергәч, ашыкмыйча гына бүлмәгә күтәрелдем. Егетләр тугарылып йоклый иде инде. Өч йөз илле чакрымнар араны ачык машинада дырык-дырык кайту уен түгел шул, яшь тәнне дә вата, арыта. Йокласыннар әйдә, аларның бит көттереп алган хат аша җанына җылы индерә торган Айчибәре юк.

Мин дә бик арыган идем. Ут яндырып тормыйча гына чишенеп, урыныма аудым. Ләкин төрле якка борылып ятуларымның да, тырышып-тырышып күз йомуларымның да файдасы тимәде. Йөзгә, меңгә кадәр санап та карадым, кая ул!

Бигрәк кызык бу адәм баласы. Айчибәрдән түземсезләнеп хат көткән чакларда да йоклый алмый интектем. Бүген хатын алып укыдым, тагын йоклый алмыйм. Тегеләй дә ярамый, болай да ярамый икән безгә.

Йокыга китәргә тырышуымның файдасыз икәнен аңлагач, тормый чарам калмады. Ичмасам хат языйм, күңелемне ак кәгазь битләренә бушатыйм.

Егетләргә комачауламас өчен ут яндырып тормадым, кәгазь-каләм алдым да уку залына юнәлдем. Безнең бәхеттән, ул тәүлек әйләнәләй ябылмый.

Тормыш синең кәефеңә, тамагың туклыгына карап тормый: нарасый минутларны сабый сәгатьләр, сәгатьләрне нечкә билле көннәр, аларын юан еллар алыштыра. Кеше картаюы турында уйласа-уйламаса да, Җир үзенең Кояшы тирәсендә әйләнүеннән туктамый. Мәхәббәт дәвам итә, кешеләр туа, яши һәм үлә. Меңләгән, миллионлаган адәм балалары арасында бәйләнеш яши. Айчибәр белән минем дә арада хатлар йөри. Аларны сөю хатлары дияргәме—алай дисәң, ул хатлар гел сөю сүзләреннән генә тормый. Гади хат диярgә дә телем бармый—Айчибәрдән килгән теләсә кайсы хат минем кулымны көйдерә, сулышыма каба, сабыйлар шикелле куанганымны үзем генә беләм.

Айчибәрне аңлавы кыен: әле айлар буена бер хат та язмый, әле бер-бер артлы өч-дүрт хаты килеп төшә. Кайсы кош теледәй кыска, кайсы берничә биткә сузылган. Ул хатларны мин кат-кат укыйм, укып туялмыйм. Армиягә бармыйча, мәктәптән соң туп-туры университетка укырга кергән бүлмәдәш малайлар, мин хат укыганда яки язганда:

—Әткәй эпистоляр жанр буенча диссертация әзерли. Комачауламагыз!—дип көләләр. Әткәй дию‌ләре минем берничә яшькә өлкәнрәк

булуыма төрттерүләредер инде.

—Көлегез, көлегез!—дип, сер бирмәгән булам. Эчтән генә: «Сез, селәгәйләр, юеш танаулар, чын ятрутның ни икәнен аңлыйсызмыни,»—дип, үзләрен кызганып та куям.

Хатларында, әйтәм ич, Айчибәр сөям дими, сөймим дими. Мактанмый да, зарланмый да.

Декабрь башларында ул фатирда бергә яшәүче Галяның кияүгә чыгуы турында хәбәр итте. Кемгә чыккан диген? Совхоз директорының хатының аерттырып барган, имеш.

*«Галяның китүе бер яктан әйбәт булды,—дип язган иде Айчибәр.—Янына тегә ирнең килеп йөрүе ошамый иде миңа. Икенче яктан, ялгызым гына да куркыныч. Сезгә, җегетләргә, рәхәт. Кыз бала һәр очракта да үзен яклай алмый бит ул. Берәр тәртипле кызны иптәшкә кертсәләр, әйбәт булыр иде, тик бу койты авылга килергә минем кебек башына тай типкән җүләрләр күп түгел икән...»*

Декабрь азакларында язган хаты исә тынычлыгымны алды.

*«Их, Рәшит, сине тыңламаенца, тиле булганмын икән: Казанга укырга керергә кыстаган иден бит. Китә ала идем мин, кызыл диплом белән берәү дә тоткарламас иде. Укырга да, ихтимал, керә алган булыр идем. Безне бигрәк патриотик хисләр белән тәрбияләделәр шул. Ярдәмемә иң мохтаҗ җиргә эләгү, ул халыкны дәвалау турында хыялланып яшәдем. Ләкин мондагы тормыш шартлары мин күзаллаганнан күп тапкыр койтырак. Иң аяныцы—бирEDәге кешеләрнең сәламәтлеге өчен көрәштә ялгызлыгым. Җанымда хәтта сөйләшер, серләшер кешем дә җук. Рәшит, без социализмны аерым утрауларда гына төзедекмени? Районның баш врачына да, совхоз директоры белән авыл советы рәисенә дә тәртип кәрәкми. Алар төкерәләр генә ярдәм сорай башласан.*

*Кицләрен бик көнелсез. Син биредә булсан, мондагы карангылык—цигенер, таралыр иде. Юклыгын бик сиздерә. Беркая да цыкканым юк, монашка төсле яшәй идем. Цөнки җегетләр озата кайталар да, капкадан кертми торалар. Әле ярый, практика үткәле Азамат исемле агроном җегет килде. Бөдрә цәцле, озын буйлы, цибәр, үзе бик интеллигентный күренә. Аның белән өц тапкыр киногa бардым.*

*Бу хатым ямансурак ноталарда язылды. Ләкин син мине сыгылып төшкән, сыгыт базары ацкан дип уйлама. Характерым нык лыгын беләсен. Үзем өцен бер хакыйкать ацыкладым: мин барыбер югары белемле врач булацакмын. Цөнки кайбер җирдә, бигрәк тә медицина өлкәсендә югары белеме булмаганнарны кешегә дә санамыйлар.*

*Зарлануым өцен гафу ит.*

*Үзеңдә ни хәл? Көннәренне нимәцек уздырасын? Себер кызын искә аласынмы?*

*Хат яз.*

*Айцибәр.»*

Хаттагы Азамат турындагы сүзләр җенемне кузгатты. «Бөдрә чәчле, чибәр, озын буйлы, имеш.» Бу кызларның барысы да бер калыптан сөрелгән. «Интеллигентный күренә...» Күренмәгәе тагын. Әллә без төшеп калган малаймы? Ирексездән көзгегә күз төшердем: озынчарак булса да, сөйкемле генә йөз, кашым—каш, күзем күз урынында. Ярар, чәчләрем бөдрә түгел, ди. Негрларның гына ул һәрберсенең чәче бөдрә. Колакларым бераз зуррак зуррагын, житмәсә тырпаебрак та тора. Һи, монысы белән горурланырга гына кирәк, чөнки зур колак—талант билгесе, ди. Галимнәр белми әйтмәс. Аннан соң ир-атка нигә кирәк ул музейга куярлык матурлык? Әни әйтә иде, ир-ат маймылдан чак кына чибәррәк булса, шул житкән дип. Акылың булсын да, кулың эш белсен, хезмәт сөй—кешене бәяләүнең, минемчә, критерийлары әнә шул.

Мантыйки яктан караганда шулаен шулай да ул, күңел бит шайтан, иблис,—гүзәлгә омтыла. Ләкин гүзәллек тә чагыштырма төшенчә. Ә

нәрсә соң ул гүзәллек? Бәлки ул объектның синең күзаллавың белән тәңгәллегедер. Хәтта бәхәссез матурлык эталоны дигәнгә дә каршы мин. Әнә бит мәшһүр Леонардо да Винчинең «Джаконда»сын ничек мактыйлар. Мактасыннар. Бирәүгә дә киресен исбатларга җыенмыйм. Ә шәхсән үзем Джаконданы һич кенә дә матур димәс идем. Картинаның оста кул, тиңдәшсез даһи тарафыннан ясалуына исә тамчы да шикләнмим. Монысын күрмәс өчен сукыр булырга кирәк.

Фу, Айчибәрнең шушы хаты аркасында әллә нинди фәлсәфәгә биреллдем. Кайдан килгән хәсрәт фәйләсүф! Тукта, ә нигә болай чыгырымнан чыгам соң әле мин? Көнләшмимдер ич? Көнләшергә Айчибәр өчен кем соң мин: иреме, йә булмаса вәгъдә биргән егетеме? Әле бит аның миңа бер тапкыр да хәтта яратам дип әйткәне дә юк. Шулай булгач, көнләшергә хакым бармы? Боларны гына аңламаслык дивана түгел лә мин. Аңлавын бик аңлыйм, ләкин көнләш, көнләшмә дип, йөрәккә әмер бирә алмыйсың.

Бирешмәскә бик тырышсам да, көнчелек корты үзенең этлеген эшләде. «Ник исең китте аңа,—дия иде ул,—ул Азамат белән киного йөрсә, әллә син монахмы? Казанда да кинотеатрлар бетмәгән. Ул җир иданле авылда җимерелергә торган клуб кына бар, монда—менә дигән кинотеатрлар, мәдәният сарайлары!

Беткә ачу итеп, тунын утка ягарга җыенган кешедәй, ярсуыма чыдый алмыйча, җил-җил генә җыендым да, бүлмәдәш малайларны гаҗәпкә калдырып, беренче курстагы Зәбирәнең ишеген шакыдым. Чакыруымны ишеткәч, ул баланың куанулары! Менә шулай була ул, Айчибәр иптәш! Сез киного йөрсәгез, без дә кимен куймыйбыз.

Тагын ун-унбиш минутлардан без Зәбирә белән Камал театрына спектакль карарга юнәлдек. Киносы качмас, аны көн саен әллә ничә җирдә, әллә ничә сеанс күрсәтәләр.

Зәбирә, бичара, бу чакыруга ниндидер өметләр баглаган булгандыр. Ә мин исә, тузга язмаган бер көнче күбәләк, театрга барып җиткәнче үк, аны ник чакыруыма үкенә башладым. Унсигезен дә тутырмаган кыз бала дуамал баштан ясалган бу чакыруны җитдигә санап, дуслык-мәхәббәткә ишарә дип аңласа? Ни хакым бар минем кешенең тойгыларында уйнарга? Моңа кадәр ата-анасының канаты астыннан чыкмаган кызларның зур шәһәргә килеп эләгү белән болай да күңелләре иләс-миләсләнә. Безнең бүлеккә керүчеләр әле тыйнаграк, ни әйтсәң дә, татар мохитыннан. Рус, тарих бүлекләренә керүчеләрнең кайберсе шунда әлләкем булып китә: ир-атны котыртырлык итеп киенә башлый, авызларында сигарет, җай чыкса, хәмереннән дә баш тартмыйлар, «ирекле мәхәббәт»—кайберләренең девизына әйләнә, тагын да гаҗәбе, алар моннан оялмыйлар да.

Зәбирә тыйнак кыз. Килмәгән бер генә җире дә юк. Татарларда сирәк очрый торган аксыл-сары чәчләрен биленә кадәр таратып салган. Зур күзләре сагында торучы озын керфекләр, иннек якмаган көе дә өлгергән чияне хәтерләтүче иреннәр... Ни дәрәҗәдә чибәр икәнен үзе аңлый микән? Юк, аңламыйдыр, аңласа сиздерер, әз генә булса да чытлыкланыр иде.

Янәшәмдә шундый кыз утыра, ә минем күзем сәхнәдә, уемда—Айчибәр. Ара-тирә үземә Зәбирәнең көйдергеч карашы юнәлтелгәнен сизәм дә, җинаять өстендә тотылгандай, уңайсызлык хисе кичерәм. Тәнәфестә буфетка чакырган идем, баш тартты, кермәде.

Спектакльдән соң без тулай торакка култыклашып җәяү кайттык. Кызны ни беләндер җәлеп итәргә, сөйләшергә, һич югы әдәплелек йөзеннән спектакль хакында бер-ике сүз кыстырырга тиешлегемне дә аңлыйм. Үземне мәҗбүр итә алмыйм.

Кайтып җиткәч:

—Рәхмәт, Зәбирә,—дип, тизрәк саубуллашу ягын карадым.

Ул: «Үзеңә рәхмәт. Тик, Рәшит абый, әйт әле: ни өчен чакырдың син мине?»—дип, ушымны алды һәм, мин ни дә булса җавап биреп

өлгергәнче, ялт кына кереп китте.

Гафу ит, Зәбирә! Ни эшлим соң? Матур сүзләр көткәнсеңдер, бәлки кочаклау, үбү өмет иткәнсеңдер—чибәр, тәрбияле кызның моңа хакы бар. Мин гафу синең алда, мин гафу. Гаеплемен...

* * *

Кешенең җаны аның сурәтенә күчә, диләр. Хактырмы бу, юктырмы, белмим. Һәрхәлдә, ислам дине кануннарында кеше сурәтен ясау тыела. Шунадыр инде, Явыз Иван явыннан һәм совет чоры атеистларыннан исән калган берничә мәчеткә кергәнем бар, диварларында ник бер адәм сурәте булсын.

Ә чиркәүгә керсәң... Христос та Мәрьям ана, пәйгамбәрләр дә изгеләр... Сурәттән дә күп нәрсә юк. Күпме рәссам, гыйбадәтханәләр бизәп, мәшһүрлеккә ирешкән, даһи дигән ат алган. Икона ясаучы танылган осталар булган...

Юк, ни генә әйтсәң дә, җан белән сурәт арасында аңлатып бирә алмаслык бәйләнеш бар. Моның шулай икәнлегенә минем ышанасым килә. Әнә ич, Айчибәрнең хат белән җибәргән бердәнбер сурәтен алып караган саен, тән буйлап рәхәт дулкын йөгереп уза. Әйтерсең, бу сурәт кенә түгел, Айчибәрнең үзе һәм мөнә-мөнә аның күзләрендә очкын уйный башлар, иреннәрендә елмаю җәелер, чәчләре бер хәрәкәттән күкрәгенә таралып төшәр сыман. Әллә тикмәгә шулай тоела дип беләсезме?

Әмма никадәр генә гүзәл, камил булмасын, сурәт сурәт инде ул— иясен алыштыра алмый. Азамат белән киногa йөриме ул, йөрмиме—мин аны күрергә тиеш! Тик ничек? Әлбәттә, ул хәтта теләсә дә монда килә алмый. Эш кешесе. Унбер ае узмый торып, аңа чираттагы ялын бирмәячәкләр.

Ничек диләр әле: тау Мөхәммәт янына килмәсә, Мөхәммәт үзе тауга бара, диләрме? Димәк, күрешүнең бердәнбер юлы бар, Айчибәр янына үзем барып кайтырга. Чыннан да, нигә бармаска?.. Юлга җитәрлек кенә рәт бар—җәй көне эшләгән акча әле тотылмаган диярлек. Әгәр дә егетләр белән бергә вагон бушатырга йөрмәсәм, аның көле күптән күккә очкан булыр иде. Яшәрсең сиңа утыз биш сум стипендиягә генә. Утыз ике теш гел үзенә эш сорап тора. Кино, спектакльләрен дә күрәсе килә.

Акча бар, тиздән каникул да җитә. Егерменче гыйнвардан унынчы февральгә кадәр ял итәчәкбез. Имтиханнан соң ук Айчибәр янына китсәм, Чиләбе, Уфа аша соңыннан әтиләргә кайтырга була. Мина бит аны бер күрү, күзләренә бер карау да җитә.

Тик теге каһәр суккан Азаматны телгә алган хаттан соң өч хат язып салдым, ник бер җавап килсен! Моны ничек аңларга? Хат язарга вакыты җитмиме, әллә теләмиме? Бәлки араның өзелүе шулдыр, синең кирәгең юк, хат язып маташма, дип, турыдан-туры әйтә генә алмыйдыр... Һавадагы торнага өметләнеп, кулдагы чыпчыкны кем ычкындырсын. Әле белергә кирәк кайсыбызның торна, кайсыбызның чыпчык икәнен.

Әйе, әйе, вакытны янга калдыру өчен Айчибәр янына самолет белән очарга кирәк. Кайтканда күз күрер. Каникуллар чорында билетларга кытлык булырга мөмкин, бүген үк алып куярга кирәк.

Бик шәп фикергә килүемә куанып, аэрофлот кассасына киттем. Самолет Курганга атнасына бер тапкыр гына оча икән. Минем бәхеттән, егерме беренче гыйнвар очыш көне иде.

Билет кесәдә. Хәзер имтиханнарны исән-имин генә биреп бетерергә дә очарга гына. Көтмәгәндә барып төшсәң, күрешү шатлыгы зуррак булыр иде булуын. Әгәр дә ул өйдә булмаса? Кая да булса киткән чагына туры килсәм? Кайтырсың аннан терсәгеңне тешләп... Кайчан киләсемне әйтеп, хат яздым. Белеп торсын.

Дөньямны онытып, китәр көнне көтеп йөрим. Бу көннәр ник шулкадәр акрын уза икән? Егерме бере җиткәнен көтә-көтә көтек булып

беттем бит инде. Саташа башламасам ярар иде. Үземчә көчтәнәчләр дә алган булдым. Студентта акча булмый дисәләр дә, марканы төшерергә ярамый. Тегенди-мондый гына җирдән түгел, Казан тикле Казаннан яраткан кызы янына баручы егет бит мин!

Күңел шаша, күңел ашкына, татлы хыяллар диңгезендә йөзә-йөзә, соңгы имтиханны да бирдем. Иртәгә Айчибәр янына очам. Шатлыгым зур, шуңа күрә егетләр белән бераз «мыек чылатып алуга» да каршы килмәдем.

Утны сүндереп йокларга яткан гына идек, ишекне шакыдылар.

—Керегез.

Бу сүзне Фәрит әйтте бугай.

Ишек ачылып, коридордан төшкән ут яктысында Зәбирә күренде.

Зәбирә! Ни эшләп йөри ул монда, кеше йокларга яткач?

—Рәшит абый, сиңа телеграмма.

Ул кулындагы кәгазьне өстәл өстенә куйды да шунда ук чыгып китте.

Телеграмма! Айчибәрдәндер. Бүтән тагын кемнән булсын? Хатымны алуга, «кил, көтәм» дип язгандыр.

Утны яндырып, кәгазьгә күз салгач, эсселе-суыклы булып киттем. Гүя мине башта мунча мичендә тыгып чыгардылар да бәкегә ыргыттылар. Телеграммада: «Әтиең авыр хәлдә кайт Әниең», дип язылган иде. Биш сүз, бары тик биш кенә сүз. Тик нинди коточкыч сүзләр!

Нәрсәнедер алдан планлаштырып, бик ашкынып көтсәң, шулай була ул. Менә хәзер дә, максатыма ирешергә берничә сәгать калгач, уй-ниятләрем челпәрәмә килде. Татлы хыялларым пыяладай уалды, бәхет куыгым шартлап, моңа кадәрге ләззәтле ымсыну билгесезлек, борчу, хәвеф белән алмашынды. Әтигә ни булды икән?

Әтидән уйларым авылга, авылның халкына күчә. Әй, бигрәкләр дә мескен инде бу авыл халкы! Сталин системасында күпме еллар буена бары тик таяктан гына торган хезмәт көне дигән нәрсәгә эшләп тә, авызыннан өзеп, шәһәрне туйдырган һәм, әкияттәге кебек, рәхәткә бер чыгасына ышанып яшәгән беркатлы халык. Районнан җибәрелгән вәкилне күргәч, котлары ботларына җиткән, күбесе үз гомерендә Маяковский данлаган уракльы, чүкечле паспортны бер тапкыр да күрмәгән һәм үзенең кол икәнен аңламаган крепостнойлар! Әлбәттә, алар да үзләренчә бәхетле булгандыр. Ник, мескен икәнлегенне белмәү бәхет түгелмени? Минем әти-әни дә шул чорның яхшысын, яманын үзләре аша уздырган сабыр вә күндәм кешеләре иң.

Уйлана торгач, үзем өчен бер нәтиҗә чыгарам: шәхесне сыта, изә торган системага белемле, мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле кешеләр түгел, куркудан аңын югалткан адәми затлар өере кирәк булган.

Соң шулай булгач, Казаннан өч йөз илле чакрымнар читтә яшәгән, иң ерак дигәндә дә Бөгелмә стансасыннан ары китәлмәгән авылдашларым ничекләр итеп югары белем алсыннар. Бүгенгедәй шартлар эләксәме?! Безнең авылның әллә кайчан инде үз профессорлары гына түгел, академиклары да булыр иде. Әле «коридоры» белән җиде, ун гына класс тәмамлаганнарының да бишесенең берсе—«Ломоносов», икесенең берсе—«Кулибин».

Югары белем дигәннән, моңа кадәр авылыбыздан җиде-сигез кеше институт тәмамларга өлгерсәләр дә, миңа кадәр университетта укучылар булмаган. Моның белән әти-әни авыл кешеләренә хас рәвештә тыйнак кына горурланалар иде. Янәсе, кемнеке дисәгез, безнең төпчегебез укый ул университетта!

Ә мин уйлап куям: әгәр дә Сталин режимы дәвам иткән чак булса, университет сукмагына әйләнеп карау мөмкинлеге дә булмас иде.

Тарихчылар заманга иң оста җайлашучылардыр мөгаен: кичә генә аны күкләргә чөеп мактап, Хрущевка тәлинкә тоткан һәм шуның белән тамак туйдырган, фән кандидаты, докторы дигән исемнәр алу өчен ниләр генә кыйланмаган галим-голәмә хәзер Никита Сергеевич Хрущевны

сугә. Имеш, ул тегеләй, имеш, ул болай. Ул—волюнтарист, ул—Берләшкән Милләтләр Оешмасының трибунасын туфли үкчәсе белән төйгән... Әллә чын, әллә юк. Кайсысына ышанырга да белмәссең. Ә минем әти, Хрущев турында сүз чыкса:

—Хрущев авыл халкын да кешегә санаган берләнбер патша,—дия иде. Югыйсә бар үстергән, бар эшләп тапканыбыз налог түләүгә китеп бара иде. Кешегә ияреп, ул аны бер генә тапкыр да яманламады.

Әткәй... Ни булды сиңа? Әле бит сәламәтлегенә бер дә зарланганын юк иде. Ярдәм сорап килүчеләргә һәрвакыт булыша иден: берсенә келәт, икенчесенә мунча бурадың, өен житкерешеп, бәхетле иттен...

Ни җаным белән монда ятмак кирәк—Айчибәр янына барырга дип җыйнап куйган әйберләремне алдым да аэропортка ашыктым. Бу вакытта самолетлар очмаганын да беләм, тик күнел сыкрауга түзеп булмый. Әле бит Курганга очарга алган билетны тапшырасы, Бөгелмәгә билет та аласы бар. Студентларның иң күп йөри торган вакыты—билетның булмавы да мөмкин. Ләкин телеграмма белән утыртырлар әле.

Билет булмавы мөмкин дип, күнелем дөрес сизенгән икән. Тапшырасы билетны җиңел генә тапшырдым. Анда кыен булмады, бераз акчасын гына тотып калдылар. Ә билет алырга дип барсам, Бөгелмә сүзен ишетүгә, кассир кыз: «Юк!»—дип, кырт кына кисте.

Телеграмманы тотып, дежурный янына бардым. Анысы телеграммага күзенең агы белән генә карады да:

—Авыру икәнен раслап, врач кул куймаган, мөһере дә сугылмаган,—дип, кабинасыннан ук чыгып китте.

Их сез, кешеләр! Әтием авыр хәлдә ята бит. Гомер буена балта чапкан, күпме кешене йорт-җирле, бәхетле иткән әтием. Минем әнкәй кебек Иделдәй сабыр хатын җир йөзендә тагын бар микән? Ул маржалар кебек чәч йолкып еламас, башларын стенага бәрмәс. Ләкин, нинди хәйлә белән ялган телеграмма сукмас. Гомердә дә моңа кулы бармаячак. Ә сез ышанмыйсыз. Врач кул куймаган, мөһере юк, имеш! Авыл җирендә каян алсыннар сиңа ул врачны! Әле ничек телеграмма җибәрергә телефоны эшләгән...

Иң кыены, беләсезме, ни икән? Чарасызлык, гаҗизлек. Әллә ниләр эшләрдәй буласың, читлектәге кош сыман талпынудан, бәргәләнүдән узмыйсың.

Кассадан кассага ташлануларымның, этелә-төртелә чират торуларымның файдасы тимәде. Утырырга урыннар юк иде, калган төнне тәпи өсте уздырдым. Барып зарланырдай, хәлемә керердәй ник бер кеше булсын. Кичер, Айчибәр, хәтта синең турыда да оныттым мин ул минутларда. Күз алдымда бары әткәй генә булды.

Иртәнгә һава бозылып китте. Югыйсә, төнлә белән күктән чекрәеп йолдызлар карый иде. Күз күреме начар диеп, Бөгелмәгә рейсларны һаман кичектерә килделәр. Аэропортта кешеләр арткаңнан арта барды. Көн урталарына анда алма төшәр урын да калмаган иде инде.

Ниһаять, кырмыска оясына кислота тамызгыларымны, моңа кадәр үз җаена гөжләгән аэропорт халкы кинәт хәрәкәткә килде. Әллә артык игътибар белән тыңламаганга, игъланның кая икәнен ишетми калганмын. Ярый әле икенче тапкыр кабатладылар. Бөгелмәгә икәнен белгәч, өмет бит ул шайтан кебек, бәлки... дигән өмет белән Бөгелмәгә очучылар язмышы хәл ителә торган секция янына мин дә килеп бастым. Их, бар бит ул бәхетле кешеләр, багажларын үлчәтеп, билетларын регистрацияләр дә самолетка чыгу юлына юнәләләр. Ә мин, әтинең авыр хәлдә икәнлеген белгән килеш, әллә була, әллә юк билетка өметләнеп, көтә бирәм.

Кинәт башыма бер фикер килде: нигә әле миңа да алар белән чыгып, самолетка утырырга тырышып карамаска? Дөнья хәлен белмәссең. Очучылардан берәрсе бәлки хәлгә керер. Бар кеше дә мондагылар сыман туң йөрәкле түгелдер әле.

... Кешеләр бер-берсен этә-төртә очу кырына чыгалар. Аларга карап

аптырыйм: кулында билетың була торып, ник инде ашыгырга? Горурлыгынны саклаган хәлдә, салмак кына кереп утырып булмыймыни? Юктыр, безнең Рәсәй чынлыгы, яшәвебез рәвеше шушыдыр.

Билетлы пассажирлар беткәч, алар артыннан минем дә бик кереп китәргә исәбем бар иде. Хәтта ачык капкадан эчке якка жиде-сигез адымнар ары үтәргә дә өлгердем. Кизү хатын:

—Гражданин, сез кая? Хәзер үк кире борылыгыз!—дигән дәһшәтле тавышы белән туктарга мәҗбүр итте.

Нишләргә? Әллә йөгереп, пассажирлар арасында югалыргамы? Юк, барыбер табарлар, хәтта самолетка утырып өлгерсәм дә, сөйрәп төшерерләр. Аннан соң, авылга, хәл эчендә яткан әткәй янына кайтасы урында, бөтенләй башка жиргә илтеп тыгарлар. Безнең милиция кулына эләксәң, беттең. Аңлатам, төшендерәм димә, файдасыз, барыбер хәлеңә кермәсләр. Аларга сөйләдең ни дә, таш баганага сөйләдең ни.

Узган май аенда булган бер вакыйга исемә килеп төште. Зачетлар биреп йөргән чак. Көтеп алган яфрак исе күңелне алгысыта, тынчу бүлмәдән качарга өнди. Көне буена китаптан хәреф чүпләп түмгәккә әверелгән башларыбызга һава сулатырга дип, ял паркына чыктык. Таганнар янында ике кыз белән танышып, озата киттек. Алар Идел буе районында ук яшиләр икән. Сөйләшә-сөйләшә атлый торгач, автовокзал каршындагы яңа өйләнешүчеләр паркына кереп киткәнбез. Паркның түр башына житүебезне көтеп кенә торганнар диярсең, агачлар арасыннан каршыбызга жиңнәренә кызыл тасма бәйләгән дүрт дружинник белән бер милиция сержанты килеп чыкты. Дружинникларның икесе кызлар иде.

Сержантның вазифасы бәлки шулдыр, әллә кызлар алдында бик эшлекле булып күренәсе килдеме:

—Документларыгызны күрсәтегез,—дип таләп итте.

—Соң инде, иптәш сержант,—дим көлгән булып,—без бит һава суларга гына чыккан кешеләр. Кем инде андый чакта үзе белән документ ала...

Сержантны минем җавап ярсытты гына:

—Анысы мине кызыксындырмый. Документларыгыз кая дип сорыйм мин сездән!

Чәр-чәр килеп, өтер кадәр генә гәүдәле дружинник кыз сүзгә кушылды. Өрсәң очарга торган хәсрәт капчыгы.

—Ни эшләп йөрисез бу вакытта?

Сәгатемә карадым: әле унберенче ярты да житмәгән иде.

—Йөрисе килгәнгә йөрибез,—дип җавап кайтарды Рамил.—Нәрсә, әллә йөрергә дә ярамыймы?

—Нормаль кешеләр хәзер өйләрендә утыра.

Телемнән тартай тартты бугай:

—Ә сез нормаль түгелмени? Юкка-барга бәйләнеп йөрисез?—дип, усалланып җавап кайтардым мин. Бу исә аларга бөтенләй ошамады. Дружинник кызларның икенчесе дә үзен күрсәтәсе итте:

—Егетләр, карагыз әле, болар безнең белән ничек сөйләшәләр. Бераз акылга утыртырга кирәк үзләрен!

Шулай инде ул, жәнжал чыгарырга кирәк булса, эт өерендә башлап әнчеге өрә башлый.

Башланды шуннан, башланды шуннан! Кысылмасам, кысыр калырмын, дип курыккандыр, моңа кадәр дәшми торган дружинник егетләрнең дә ябык чыраендагы зур борыны өстенә калын пыялалы күзлек атландырганы әтәчләнеп алуны кирәк тапты.

—Анагызны фәлән итим!—дип, тәэсирлерәк итү өчен сүзен сүгенүдән башлады.—Әле ярый без очрадык. Кадеребезне белеп, рәхмәт әйтәсе урында... Югыйсә үзегезнең корсагыгызга пычак терәп, кызларыгызны күз алдыгызда чиратка салсалар...

—Петя, ул кызлар бәлки шуның өчен генә кергәннәрдер дә...

Кызларның теге өтер кадәрлесе, үз сүзеннән бик канәгать калып хихылдады.

Егетләр булсак та, мондый ук оятсызлыктан Рамил дә, мин дә сүзсез калдык. Кара, ни сөйли бит! Җитмәсә, үзе дә хатын-кыз нәүгыннан лабаса.

Без ни дә булса кылырга өлгергәнче, паркта танышкан кызларның Айсылу исемлесе:

—Теленне тый, кабахәт!—дип, тегенең чәченнән урап алды.

Сыер дуласа, аттан яман була, диләр, әгәр дә сержант белән ике дружинник егет аерып алмаса, теге «өтер» чәченнән колак кагачак иде.

Айсылу аның чәченә ябышмаса да, безне болай гына җибәрмәячәкләре көн кебек ачык иде. Күрәсең, аларга да план житкерелгән булгандыр. Шуңа күрә, кызларны аеруга, сержант тупас тавыш белән:

—Әйдәгез, штабка киттек. Там разберемся!—дип, минем жингә килеп тә ябышты.

Шулай да дипломатиянең соңгы чарасын кулланып карарга булдым.

—Иптәш сержант, җибәрегез, ә! Без беркемгә тимәдек, безгә дә тимәделәр. Паркка ун минут чамасы элек кенә килгән идек. Парк бит бу. Йөрергә дә ярамагач, аның ник кирәге бар?

Ләкин сержант азакка кадәр мине тыңлап та бетермәде:

—Әле сез милициягә карышасызмы? Беркетмә төзергә туры килер. Киттек!—диюгә, дружинниклар да безне тарта-йолка башладылар.

Рамил белән күзгә-күз карашып алдык. Бәлки качып та котыла алыр идек—куак арасына сикердең дә юкка чыктың. Ә кызлар ни эшләр? Юк, аларны бәладә калдырып китү егетлек түгел. Бердәнбер чара—буйсынырга кала.

Автовокзалдан ерак түгел бер йортның подвалында булып чыкты безне ирексезләп алып килгән иректе халык дружинасы штабы.

Керә-керешкә сержант алама өстәл артындагы бердәнбер урындыкка утырып, беркетмә язарга керешге...

Фу, бу минутта шушындый җирәнгеч хатирә искә төшмәсә, ярамый идемени соң! Болай да күңелнең үзенә урын тапмый борчылган чагы.

Әйе, ул вакытта безне өченче яртыга кадәр утырттылар штабта. Башта исем-фамилияләребезне, кайда эшләү-укуыбызны, торган җирне сорадылар. Аннан шуны телефон аша шалтыратып ачыкладылар. Күпме әшәке сүз ишеттек, мәсхәрә, кимсетү кичердек. «Тәртип сакчылары» кызлар бар дип тә тормадылар. Кан исенә исергән ерткыч кебек, безнең көчсезлегебездән, җавап кайтара алмаячагыбыздан тәм табып, ләззәт чиктеләр. Шушы әшәкелектә, кыргый оргиядә дружинник кызлар да егетләрдән кимен куймадылар, әгәр арттырып та җибәрмәгән булсалар... Армиягә яңа алынган вакытта «дед»лардан да моның кадәр мыскыллаулар күргәнем юк иде. Әнә бит, карап торуга алар өтек кенә, ләкин аларның кулында власть бар, алар көчле, алар кодрәтле. Менә хәзер безне изеп ташласалар да, үзләренә берни булмаячагын белеп, алар тантана итә, кыргый ләззәт кичерә. Кайдан килгән мондый кансызлык? Югыйсә, үзләре дә студентлар икән бит. Хәтта сержанты да читтән торып университетның юрфагына укырга кергән. Диплом алгач, ул кемгә әверелер? Бу кызлардан туган балалар кем булыр?

Яңа өйләнешүчеләр паркында башланган мәжараның сасысы университетка кадәр барып житте һәм группаның комсомол җыелышы белән тәгәлләнде. «Җәмәгатьчелек тәртибен бозган, тәртип саклаучыларга хезмәт вазифаларын үтәгән чакта каршылык күрсәткән, аларга кул күтәргән, мыскыллаган өчен» безне чак кына комсомолдан чыгарып, университеттан кумый калдылар. Ярый әле эчмәгән булганбыз.

Группалашлар каты бәрелмәде. Алар безнең очраклылык һәм әшәкелек корбаны икәнлегебезне аңлый иделәр. Тик милициядән килгән кәгазьне дә җавапсыз калдырырга ярамый. Димәк, җыелыш җыеп, «университет студенты исемен пычратучыларга» карата чара күрелергә тиеш...

Бөгелмәгә очасы самолетка моңсу караш ташладым да, кире борылып, тимер койма артына чыктым. Хис ташкыны белән чагыштыр-

ганда салкын акыл өстенлек алды. Алыр да, авызың бер пешсә, салкын шулпаны да өреп кабарсың. Ә минем авыз бер генә пешмәде инде. Тагын күпме пешәр.

Торам басып, торам самолетка утыручы кешеләрдән көнләшеп. Бу минутта миңа алар дөньяда иң бәхетле кешеләр булып тоелды. Озата барган дежур хатын, вазифасын үтәгәннән соң, Берлинны алган төс белән, кире кайтты. Бөгелмә самолеты двигательләрен кабызды. Өметем киселгәннән киселә бара. Дөресрәге, ул күптән инде нульгә тигез.

Ләкин дөньяда могҗизалар булып тора. Көтмәгәндә язмыш миңа да елмайды. Аэропорттан чыгып, капкага ике ир якынлашты. Аларның берсе очучы киемендә иде. Анысы икенчесен култыклап алган. Миңа аерым-аерым сүзләре ишетелә:

—Абый, дим, ну, кеше бул инде. Мине бөтен дөньяга хур итмә! Хәзер үзеңне алып китәләр бит...

Абый дигәне милицияне урысчалатып өч хәрефкә җибәрә. Ул дөм исерек булып, аягында чак басып тора. Үзе нидер мыгырдана, киреләнеп, читкә тартыла. Башыма яшен тизлегендә уй ничек килгәндер, алар янына барып басканымны сизми дә калганмын.

—Гафу итегез, сез Бөгелмәгәме?—дип, очучының җиңенә кагылдым.

—Әйе,—диде ул сискәнеп. Аннан миңа карагач, җинел сулап куйды.— Уф, милицияме әллә дип, котым очты. Йә, шуннан?

—Минем әти авыр хәлдә, әни телеграмма суккан. Билетлар юк. Алып кайтыгыз, зинһар, мине. Ике бәясен түлим. Ышанмасагыз, телеграмманы күрсәтәм!—Кулымны кесәгә тыга башлаган идем, очучы:

—Кирәкми, туган, болай да ышанам,—дип туктатты.—Акчаң да кирәкми. Менә бу юньсез—минем абый. Шуны самолетка алып керергә булышсаң—вәссәлам! Югыйсә, бер үземә генә авыр. Җитмәсә, билдәге радикулит кузгалып маташа. Дежурныйлар эндәшсә, җавап бирмә, алар белән үзем сөйләшермен. Аңладыңмы?

—Аңладым, рәхмәт.

Инде моннан соң да Ходай юк дип әйтеп кара! Өмет бөтенләй киселеп, кешеләр күнелендәге күгәргән тунлыктан гайрәтем тәмам чигеп беткәндә, менә бит нинди миһербанлы бәндәләр ярдәм кулын суза. Яшибез болай булгач! Рәхмәт сиңа, летчик иптәш! Рәхмәт аның нәкъ миңа кирәк вакытта эчеп исерә алган абыйсына! Рәхмәт теләсә кемне ләх итә алган совет аракысына! Ә самолетка утырту... Самолетка утырганчы, мин ул абзыйны сыртыма салып, аэропорт тирәсен җиде тапкыр урап чыгарга да риза. Тик туктатмасыннар, аркылы төшмәсеннәр генә!

Бәхеткә, аркылы төшүче дә, туктатучы да булмады. Әле генә мине очу кырыннан куып чыгарган тәртип саклаучы ханымнар өчен хәзер без әллә бар, әллә юк идек.

Самолетта буш урыннар берәү дә калмаган, очучы кергәнне генә көтеп торалар икән. Безнең арттан ук ишек ябылды. Очучы:

—Сезгә икегезгә менә шушында басып кайтырга туры килер. Зинһар, абыйга күз-колак булыгыз инде. Ә син, абый, үзеңне тәртипле тот,— дип, самолетның койрыгына төялгән авыр чемоданнар, буаз сумкалар, иләмсез рюкзаклар янында калдырды да кабинасына юнәлде.

Ил—14 самолеты очу кырындагы түмгәкләрне санап барды-барды да, кинәт үкереп, һавага күтәрелде. Шул вакытта койрык бераз уйнап алды, ләкин ул бер минутка да сузылмагандыр, самолет тотрыкланып, болытлар арасына кереп чумды һәм һәр минут безне Бөгелмәгә якынайта башлады.

Койрыкта иллюминатор юк. Ачык ишектән салонга карыйм. Пассажирларның һәммәсе үз эшенә чумган: берәү газетага борын төрткән, икенчесе алдындагы журналдан башваткыч чишә, өченчесе ашый, кемдер инде башын кырын салырга да өлгергән. Бер утыргычта икәү кәрт суга. Багаж белән мәетләр генә йөртә торган койрыкта баручы без фәкыйрьләрдә берәүнең дә эше юк.

Минем юлдашым, кереп басуга:

—Таныш булыйк,—дип, көрәктәй кулын сузды да, исемен әйтергә өлгергәнче, баскан урынында йокыга да китте. Башта ул чыннан да аяк өсте йоклады. Тора-бара, йокы авырлыгыннан, ахры, аяклары сыгыла барып, чүгәләде һәм шул чүгәләгән хәлендә берничә тапкыр гырлап та алды. Хәер, никадәр көчле гырласа да, җиде-сигез мең метр биеклектән оча торган самолетта двигательләр тавышыннан бераз оеган, бераз миңгерәүләнгән пассажирлар моны сизәрлек хәлдә түгел иде. Минем дә ис китмәде. Ис китсә дә, кая барыйм—койрыкта урын тар, ишеген ачсаң, кар катыш ак болытлар кочагына чумасың. Өстәвенә аңа, аның бөек исереклегенә минем рәхмәтем зур иде. Әгәр дә ул айнык булса, очучы энесе минем белән вакланып торыр идеме икән. Ә мин әти хакына исерек белән янәшә кайту гына түгел, хурлау-түбәнсетүләргә дә түзәсе идем.

Исерек дигәннән, юлдашым ике тапкыр ишек ягына табан талпынып карады. Туктаттым. Ярый, тарткалашып тормады. Рәхмәт үзенә, әйбәт исерек икән, сүземне тыңлап, урынына кабат чүгәләде дә йоклавында булды.

Иллюминатордан тышка карыйм. Өстә зәңгәрсу-кара күк йөзе, аста—төрле төстәге симез-симез болытлар. Алар арасындагы ачыклыктан еракта-еракта җир күренеп китә. Җир күренүгә, иллюминаторга ныграк текәләм: безнең авыл түгелме? Авылыбыз күренсә, өебезнең морҗасыннан чыккан төтеннән дә әтинең хәле ничек икәнлеген белер идем сыман. Ләкин акылым шунда ук каршы төшә: юләр син, Рәшит, Казан белән Бөгелмә арасында кайдан килеп сезнең авыл булсын, ди.

Уйларымнан юлдашым бүлде. Аңа мондый житезлек кайдан килгәндер, ул кинәт сикереп торды да шүрлекләргә куелган әйберләрне актарырга кереште.

—Нишлисең син?

—Болай ятып булмый, аэропортка барырга кирәк,—ди бу.—Озак кайтмый торсам, хатын ачулана.

Көлсәң көл, еласаң ела. Чынлап торып ишеккә барырга тели.

—Агай, ашыкма. Урамда буран, самолетлар очмый. Буран басылгач, үзем әйтермен,—дип, көчкә тынычландырдым тегене.

Аны тынычландырып бетерүем булды, стюардессаның:

—Һава шартлары начар булу сәбәпле, самолет Бөгелмәгә төшә алмый, шуңа күрә кире Казанга кайтабыз,—диеп, котыбызны алды. Салонда ыгы-зыгы купты. Стюардесса аларны юата, тынычландыра, кемгәдер минераль су бирә.

Их, тагын булмады. Бөгелмәгә дә югыйсә ерак калмагандыр. Сәгатемә карадым: инде илле минутлап очабыз. Күп булса, тагын җиде-сигез минуттан төшеп утырасы булганбыз. Парашютым булса, сикерепләр генә төшәр идем.

Язмышларына буйсынган пассажирлар тынычланды. Казанга кайтабыз дигәнгә күнегеп кенә килгәндә, динамик тагын шытырдады һәм баягы тавыш яңгырады:

—Хөрмәтле пассажирлар! Бөгелмә аэропорты кабул итә башлау сәбәпле, самолет курсын үзгәртте. Тагын ун минуттан Бөгелмәгә төшәчәкбез.

Ура! Мең яшә, чибәр туташ, авызыңа бал да май!

Чыннан да самолет бераздан җиргә төшеп утырды. Пассажирлар урыныннан кузгалганчы, сәрхүш агайның очучы энесе яныбызга килеп житте һәм җиңел сулап куйды:

—Уф! Рәхмәт сиңа, туган, исән-имин алып кайтып житкердең.

—Үзегезгә рәхмәт.

—Салып алса, аның гадәте шатун аюныкы кебек. Бик интектермәдеме?

—Зарар юк,—дидем мин, сер бирмичә. Берничә тапкыр саруымны

кайнатып алганын әйтүдән ни файда. Киресенчә, Бөгелмәгә кайту мөмкинлеге тудырган өчен очучыга рәхмәтем шулкадәр зур иде, акча суздым. Ләкин ул:

—Юкны сөйләмә,—дип, кырт кисте.—Син, туган, нинди ярдәм күрсәткәнеңне үзең дә белмисең. Киресенчә, акчаны сиңа мин түләргә тиеш...

Ярар, акча алмыйсың икән, бигрәкләр дә зур рәхмәт. Студенттан акчаның кайчан артканы бар...

* * *

Мең бәла белән аэропорттан район үзәгенә кайтып җиттем. Кичке сигез. Бу вакытта түгел, көндезләрен дә безнең авыл ягына транспорт табуы кыен. Диспетчер апа:

—Иртәнге алтыда ул якка вахта автобусы барырга тиеш, көтеп тор,—дип тынычландырмакчы.

—И апа җаным, көтәрлек булсам, самолет койрыгында кайтмас идем мин. Әтием, әтием авыр хәлдә ята! Таш яуса да, миңа кайтырга кирәк.

—Балакаем, тыңла олы кешенең сүзен: бу буранда адашып харап булырсың бит. Кунар урының булмаса, өебезне өйрәтәм, абыең өйдә, безгә кереп кунарсың.

—Рәхмәт, апа-җан. Казан тиклем Казаннан кайтып, тагын ун сәгать буена ничек җаным түзсен. Йөрмәгән юл түгел, ничек тә кайтып җитәрмен.

Төн. Уразайга каратып, юлга чыктым. Сукмак катылыгын тоеп булмый, кар көртләре сарган. Тик бу юл миңа таныш: өч ел буе шушыннан урта мәктәпкә укырга йөрдем. Атнасына ике-өч тапкыр кайтып-килә идек.

Буран этеп екмакчы булып көчәнә, теләгенә ирешә алмагач, гарьлегеннән ыңгыраша һәм тагын да зәһәррәк һөҗүмгә күчә: керфекләрне каерып, күзгә кар тутыра, борын тишекләрен, колакларны томалый, өскә кигән көзге пәлтәне тарта, йолка. Авызны ачсаң, теш араларында курай уйный башлый.

Этләшмә, табигать. Дөньяга бүген килмәгән—давылын да, карынбуранын да күргән бар. Кайтам булгач, кайтам! Унбиш чакрым ара безнең кебек егеткә еракмыни ул!

Борылып карыйм: утыз мең кеше яши торган район үзәгенең иң якты уты да күренми. Кола яланда мин япа-ялгызым. Тырыша-тырмаша ташбака адымы белән булса да атлыйм. Авыз кибә. Эчәсе килүгә түзәр әмәл калмагач, кар кабам. Аны шунда ук йотмыйм, башта авызда эретәм. Кичәдән бирле авызга бер тәгам ризык кергәне юк. Ничек эчәсе киләдер, югыйсә ашыйсы килми.

Буранлы чынбарлыкны ертып, каршыма кинәт Айчибәр килеп чыкты һәм аның үпкәле тавышы ишетелде:

—Әйттем кый, Рәшит, кара каеннарга кагылган кеше бәхетсез була дип...

—Айчибәр, син ничек монда килеп чыгасы иттең?

—Мине бирегә мәхәббәтем китерде. Сине фаҗигадән йолып алгалы килдем.

Айчибәр каршымда гына. Кулымны сузып, аны тотмакчы булам. Ул тоттырмый, алгарак күчә дә җырлый башлый:

Амбирактин, җамбирактин,
Кияү килә җырактин...

Аның җыры үксү белән алышына:

—Их, Рәшит, никләр кара каеннарга кагылдың?

Чү, галлюцинация башландымы әллә? Кайдан килеп кара каен

искә төште? Карга утырганмын да оеп барам ич! Инде күптән Уразайга житәргә тиеш идем. Кайсы якта ул Уразай? Шулай ук юнәлешне югалттым микәнни? Бәлки хәлнең калганын саклау өчен көн яктыруын утырып кына көтеп алыргадыр?

Ләкин ниндидер эчке тавыш кисәтте: «Карга утырма, Рәшит, утырма. Утырсаң, тора алмассың, харап булырсың».

Атлавын атларга, ләкин кайсы якка табан? Әһә, район үзәгеннән чыкканда, жил сулданрак исә иде. Шул арада гына юнәлешен үзгәртеп өлгермәгәндер әле.

Бу хакыйкатькә төшенү дәрт бирде, көч өстәде. Яшибез әле болай булгач!

Атлау торган саен авырая барды. Тагын күпме вакыт узгандыр, жил өереп китергән буран элпәсе аша күземә ут яктысы чагылып киткәндәй тоелды. Тагын галлюцинацияме, тагын саташаммы?

Саташсам саташамдыр, тик тору—һәлакәт—шунда табан атладым. Юк, ут диеп ялгышмаганмын—мин чыннан да Уразайның безнең авыл белән ике арада салынган сыер фермасына килеп чыкканмын. Ә авыл үзе кайда соң? Мин аны кайсы яктан урап узганмын? Ничек силос базларына төшеп харап булмаганмын? Бик тирән бит ул базлар. Бу афәттән кем саклаган?

Ут яктысында сәгатькә карадым. Төнге ике тулып килә. Башка вакытта бер сәгатьтә уза торган араны алты сәгатькә якын кайтканмын. Алда тагын жиде-сигез чакрым. Вокзалдагы апа хаклы булган мине юлга чыгарып жибәрәсе килмичә. Чак харап булмадым ич.

Аяклар үзеннән-үзе сыгыла. Күзне йокы баса. Жылыга—сыер абзарына—кердем дә салам өстенә аудым. Яландагы мәхшәрдән соң сыер тизәге катыш борынны ярып керә торган әчкелтем силос исе мина ожмахның үзе үк булмаса да, аның ишек алды булып тоелды. Күшәп яткан сыерлардан аңкыган сөт исе эш булмау сәбәпле үз вазифасын оныта башлаган ашказаны бизләрен кытыклый. Их, менә хәзер берәр жамаяк яна сауган сөт эчсән иде!

Торырга талпынып карадым. Баш күтәрелде, ә гәүдәне әйтерсең таш белән бастырып куйганнар иде—көч житмәде... Нәкъ армиядәгечә: торгызуын торгыздылар, тик уятырга гына онытканнар.

Тук, тук, тук!

Әткәй белән икебезгә мунча бурыйбыз. Пазын сызып бирде дә әти минем ничек чапканны карап тора. Миңа әле унөч кенә яшь. Ләкин әти алдында сынатасы килми. Үч иткән сыман, мин чабасы урында гел ботак туры килеп тора. Ул усак ботагының әшәкелеге. Әти сөйли иде: бер балта остасы чуаш үләргә ята икән. Әйткән ди: барыгызны да пәхиллим, чыршы белән усак потагына гына пәхиллегем юк.

Селтәнәм, селтәнәм, әллә жил комачаулый, бер дә теләгән урынга чабылмый. Минем үҗәтлекне карап торган әти көлемсерәп акыл бирә:

—Улым, ботакның астыннан да, ана каршы балтанның очы белән чабып куй, жинелрәк булыр.

Мин ул өйрәткәнчә эшлим. Аннан соң вак-вак итеп ботакны китеп алырга керешәм. Ни сәбәптәндер ап-ак усак бүрәнә комач төсенә әйләнде һәм йомычка урынына балта тигән урыннан кан чәчрәп чыкты һәм әтинең битенә килеп сыланды.

Әти:

—Ай!—дип кычкырып жибәрде. Ул арада бөтен өсте кан белән тулды. Мунчаның бар буралган каләресе жимерелеп, бүрәнәләре төрлесе төрле якка табан тәгәрәде.

—Балакаем!—Әнкәй мангаемнан сыйпый. Мин өйдә икәнмен бит. Ә кайчан кайтып житкәнмен? Ник мин аны хәтерләмим? Әти кая китте?

Әтине эзләп, күзләремне ачтым. Каршымда берничә хатын-кыз. Кемдер башымны тоткан. Үзләре берсен-берсе бүлдермичә генә сөйләшәләр:

—Маңгае ут кебек яна.

—Буранда адашып килеп кергәндер, мескен.

—И-и, котырып та куйды төнлә белән бураны. Әле ничекләр монда килеп эләккән...

—Сорагыз әле, кайсы авылныкы икән?

—Өстенә дә юка киенгән.

—Сез кемнәр?

Аларның сыер савучылар икәнен сорауны бирүгә үк үзем дә аңлаган идем. Минем соравым аларны башта сискәндереп җибәрде. Ләкин сискәнүләре шунда ук куанычка әверелде:

—Уянды, уянды!

—Балакаем, өшегән җирләрең юкмы? Ничекләр монда килеп чыктың?

—Кайтуыңмы, баруыңмы?

—Аллаһы Тәгалә саклаган үзеңне, катып үлә язгансың бит...

Сәгатемә карадым: биш тулып килә. Димәк, мин өч сәгатькә якын черем иткәнмен. Тукта, ничек оялмыйча барин кебек ятам соң әле мин? Анда бит әти хәл эчендә. Авыл бит әнә тегендә, кул сузымы җирдә, якында гына.

Сикереп торырга теләдем, тәнем үземә буйсынмады. Шулай да бу апалар янында сер бирергә ярамый. Яратмыйм үземне кызгануларын! Авырлык белән булса да, торып бастым.

Чыгып китәргә җыенуымны белгәч, сыер савучылар каршыма басып, үгетли башладылар:

—Яктырганны көтәр идең...

—Бураны бераз басыла төшсә дә, юлы юк бит аның...

—Юк-юк, китмисең, күрәләтә сине үлемгә чыгарып җибәрер хәлебез юк.

Бу киң күнелле апаларга хәлемне аңлатмыйча чарам калмады:

—Әти авыр хәлдә дип телеграмма алган идем. Әнкәй суккан...

Апалар кинәт шым булды. Бер мәлгә кабер тынлыгы урнашты. Хәтта сыерлар да күшәүләреннән туктаган кебек тоелды. Үзара карашып алганнан соң, арада өлкәнрәге әйтте:

—Үскәнем, әз генә көтеп тор. Хәзер трактор түбән оч хатыннарын алып килә. Аннан соң Алмас сине авылыгызга илтеп куяр. Ул йөреп кайтканчы, булган саламны без кул белән ташый торырбыз. Бу хәлеңдә чыгарып җибәреп, гомер буена вөҗдан газабы кичерергә мәҗбүр итмә безне.

Төнге одиссеям миңа бераз акыл керткән иде инде. Алай трактор да илтәсе булгач, көтү дөресрәк булыр. Тракторның бит аның иң акрыны да миннән кызурак йөри. Хәл дә юк сыман.

—Рәхмәт сезгә, апалар!

Күнелем тулып, күзгә яшь бәреп чыкты. Бөтенләй таныш түгел кешеләрнең, хәлемә кереп, ярдәм итәргә атлыгып торулары чарасыз итте. Гел шулай мин, көтелмәгән яхшылыкка очрасам, бугазыма төер утыра, сабый баладай мәлҗерәп төшәм.

Ул арада трактор килеп туктаган тавыш ишетелде. Ишек ачылып, ферма эченә тагын сыер савучылар, аларга ияреп, бер яшь кенә ир-егет тә керде.

Хатыннар исәнлек-саулык сорашкан арада, әлеге дә баягы апа тракторчы егеткә хәлне аңлатты.

Авыл кешесе авыл кешесе инде: сөйләп бетергәннәрен дә көтмәде, Алмас миңа:

—Киттек!—дип әйтте дә ишеккә кузгалды.

Башымны ия төшеп, сыер савучыларга рәхмәтемне белдердем. Саубуллашуым да шушы булды.

Мин чыкканда, Алмас арбасын тракторыннан ычкындырып маташа иде. Икәүләп кабинага кереп утырдык.

—Хәзер үземнең лимузин белән авылыгызга күз ачып йомган арада илтеп куям мин сине!..

Трактор алга ыргылды. Алмас башта кар күмгән зур юлга чыкты, аннан үзе генә белгән билгеләрдән чамалап, ак буран пәрдәсе аша безнең авылга табан юнәлде.

Авыл әле йокыда. Анда-санда өйләрдә ут алганнар. Безнеке капкарангы. Бу караңгылыктан йөрәккә шом өрелә. Алмас белән хушлаштым да тыңларга теләмәгән аякларымны өстерәп, ыңгырашып ачылган түң капка аша кар баскан сукмактан өйгә уздым. Әнкәй гаҗәпләнер инде. Ә нишләп ут юк? Мөгаен әтинең хәле арулана төшкәндер дә, йокласын дип, сүндергәннәрдер. Гаҗәпләнүемә, ишектә йозак иде. Йөрәк жу итеп китте. Хәлсезлегемне дә онытып, берничә йорт аша гына яшәүче өлкән абыйларга йөгердем. Алар әле тормаган.

Башта һау-һаулап каршы алган Актырнак, танып, койрыгын кысты һәм яныма йөгереп килде дә өй ишегенә кадәр озата барды. Монда да ут алмаганнар, монда да караңгылык нindидер куркыныч турында кисәтә сыман. Тизрәк ут яндырсыннар иде.

Ашыгып ишек дөбердәтергә керештем.

Тәрәзәләрдә гөлт итеп ут кабынды. Кемдер тиз-тиз ишек янына килде һәм шылтыратып, келәне ычкындырды. Җиңги икән.

—Рәшит,—диде жиңги, гаҗәпләнеп,—балакаем, синме соң бу? Ничекләр кайтып життең? Әйдә, ник катып торасың, өйгә кер?

Өйгә уздык.

—Җиңги, әтиләр кайда?—Өйгә керү белән беренче соравым шул булды.

—Энем, әткәйнең хәле бик авыр. Район больницасында ята. Операция ясаганнарына өч көн, алга китеш юк. Әнкәй дә, абыең да куна-төнә аны саклыйлар. Буран булгач, кичә бара алмадым, өченчекөн барып кайткан идем.

Өнсез калдым. Бураннарда адаша-адаша, төне буе кайттым, үлемнән чак калдым—мин авылга, әти янына ашкындым. Әнине дә әйтер идем инде, кайда ятканын күрсәтеп булмый идемени! Белгән булсам, монда кайтып йөрмәс, вокзалдан туп-туры больницага гына йөгергән булыр идем. Хәер, әнине дә гаепләп булмый, ул мескеннең дә зиһене таралгандыр кинәт килгән кайгыдан. Әле ничек телеграмма сугарга башы житкән.

—Җиңги, жиңги дим, әйт инде, көттермә: әтигә нәрсә булды? Йөрәкме?

Җиңги юк дигәнне аңлатып, башын селкеде.

—Егылдымы?

—...

—Авариягә очрадымы?

—...

—Интектермә, жиңги, әйт.

—И энем, сөйләсән, кеше ышанмас. Әткәй бит колхозның нәсел үгезен карый иде. Шул үгез, никтер пәриләнеп, мөгезе белән әткәйне чөеп ыргыткан. Корсагын мөгезе эчәгеләренә кадәр ерткан. Дүрт сәгать операция ясадылар. Аңына килгән саен, сине сорый.

—Белмәдем бит, белмәдем. Төне буе кайттым, жиңги. Төне буе! Мин әтине өйдәдер дип уйладым. Адашып беттем.

—Ярар, энем, бик өзгәләнмә. Барысы да Ходай кулында. Тәкъдирендә шулай язгандыр. Ай, бу башсызлык дигәнең! Чәем кайнап чыкты, мин сине сүз белән сыйлап утырам икән.

Сөйләнә-сөйләнә, жиңги табын хәзерләргә керешге.

—Буран бик котырды, вахта автобусы килә алмас, сөт илтә торган трактор белән китәрсең. Син бит ачтыр. Әйдә, чәй эчеп, капкалап ал, хәл керсен. Төсең качкан, арыгансындыр.

Җиңги кулы белән маңгаемны тотып карады:

—Ут булып янасың ич син. Мәле, аспирин эчеп җибәр. Юк-юк, берне түгел, икене эч. Аннан бөркәнеп ятарсың. Курыкма, үзем уятырмын.

Тәмле иде җиңгинең чәе. Бер-бер артлы өч чәшкә эчкәнемне сизми дә калганмын. Аннан соң түр яктагы диванга кереп яттым. Җиңги малтуар карау хәстәренә кереште. Абый өйдә булмагач, бүген аңа эш күп.

Әти турындагы борчулы уйлар йоклап китәргә ирек бирми. Ни булган үгезгә, ник ярсыган? Бүтән вакытта бер дә пырдымсызланмый иде бит. Эскерт кадәр гәүдәле нәсел үгезенең ярсыганын күз алдыма китереп карадым: кан баскан күзләр, очлы мөгезләр һәм мөгез очында—әти...

Абыйларның өч баласы тәмле-татлы төшләр күрә-күрә йоклыйлар. Аларның кечесе—кыз. Ул аерым яткан. Ә игезәк абыйлары Хәким белән Хәбиб—гел бергә. Уянгач, алар бер сәгать тә сугышмый-талашмый тора алмыйлар, юктан да эләгешеп китәләр. Шул ук вакытта үзләре бер-берсеннән башка да яши алмыйлар. Әнә хәзер дә берсе аягын икенчесенең өстенә салып йоклый. Алар өчен тышта буран да, көч-хәл белән кайтып ауган Рәшит абыйлары да юк. Аларның башы астына баллы кашык салынган.

Балаларның тәмле итеп мышнавына вакыт-вакыт өй почмагына килеп кабыргасын сыдырткан җилнең кызганыч улавы кушыла. Мич казнасына кереп оялаган әрсез чикерткәнең кычкыруы ачуны китерә. Бу авазлар тик тә чарасызлыктан гаҗизләнгән йөрәккә шом сала.

Ләкин җинги биргән мәтрүшкә чәе һәм кура җиләге кайнатмасы үзенекен итте: тәнгә тир бәреп чыкты, ниндидер җиңеллек ингәндәй тоелды, һәм күз кабаклары үзеннән-үзе йомылды.

Күпме йоклаганмындыр, җиңгинең сак кына эндәшүенә уянып киттем:

—Рәшит, районга барасыңмы? Сөт тракторы синнән башка китеп куймасын. Аннан калсаң, ат эзләргә туры килмәгәе.

—Ә вахта автобусы?

—И-и, аңа ышансаң, әле кайчан бураны туктый да кайчан юл ачалар. Мондый буранда нефтьчеләр үзләре дә куна-төнә яталар.

Тәнгә таш бастырганнармыни, аякларны да селкетәсе килми. Баш авыртуы күзне әчеттерә. Ни булгандыр, хәтта тел дә бик авырлык белән генә кыймылдый. Кипкән иреннәремне ялыйм да тирә-ягымны йотарга телим. Ләкин йотып булмый, каты матдә кебек, тамак төбенә җиткәч, ул буалып кала. Тамагым шеште микәнни? Казанда чакта сау-сәламәт идем ләбаса.

Тырыша торгач, көч-хәл белән төкерегемне йотам. Моның ише чакта иң яхшысы—мөмкин кадәр күбрәк кайнар чәй эчү. Чәй, чәй, чәй!..

—Җиңги, чәең бармы?

—Бар, Рәшит, бар. Балалар ашап утыралар.

—Нишләп бер дә тавышлары чыкмый?

—Һи, әйттең сүз! Чыкмыймы соң! Торганнарына ярты сәгать тә юк, әллә ничә тапкыр талашып алдылар. Абыегыз арып кайткан, уятасыз дигәч кенә бераз тындылар.

Игезәкләрнең Хәбиб дигәне унбиш минутка алданрак туган һәм «салага» сүзен кайдан ишеткән дә ничек исендә калдырган диген син, хәзер Хәкимгә ачуы килгәндә «салага» дип кенә җибәрә. Көлсәң көл, еласаң ела.

Энекәшләр күз алдымда диярлек үсәләр дә, аерып бетерә алмыйм—ике тамчы су кебек охшаш алар. Хәер, абый белән җиңги еш кына үзләре дә аларга исемнәрен бутап дәшә.

Алгы якка мин чыкканны көтеп кенә торганнармы, малайлар икесе ике яктан җилкәмә килеп асылындылар. Мондый чакта бәләкәч Фәйрүзә абыйларыннан калышамы соң: анысы да каршыма килеп, кулларын сузды. Аларның үз кырыгы кырык, минем хәлемдә эшләре юк.

Чәй эчкәннән соң абыйның калын итеп олтан салынган киез итеген сорап алдым һәм фермага киттем. Бүген сөт илтергә ДТ тракторы

биргәннәр икән, «Беларусь»ка гына ышанмаганнар.

Их, бу юл юклыклар! Менә хәзер жылы, унайлы автобуста асфальт юлдан гына жилдертәсе иде дә бит—егерме минуттан район үзәгендә булыр идең. Күпме нефть чыгарып, һаман элеккегечә яшәп ятабыз. Әллә кемнәр Татарстан газын яга, ә безнен якта, утын житмәгәч, тирес сугалар. Бардыр ул, бардыр бай илләр, рәхәт яши торган жирләр. «Дуслык, туганлык хакына» барысы да бөтен байлыгын читкә озатмый бит.

Трактор чанасына мул итеп салам салынган, утырасы жиргә торыпша жәелгән. Сөт савытларын төягәч, кузгалып киттек. Хәлем булмаса да, сөтне мин дә төяшкән булдым. Кеше эшләгәндә карап торсан, «интеллигент» дип көләләр безнең авылда.

Кышын ат жигелгән чанада йөрергә яратам мин. И-и, ул чактагы хозурлык! Бураннар уйнатып жилдерәсең. Ат тоягыннан сибелгән кар энже булып читкә оча. Бернинди сикертү юк. Кызурак юырткандa, атның аяк хәрәкәтләренә күз иярми һәм, әйтерсең, чана гравитация чиген уза—кинәтрәк сикерткәндә очып-очып киткәндәй буласың, авырлыкны югалту халәтен кичерәсең. Чанага жәелгән печәннән жиләк, меньяфрак, мәтрүшкә, тукранбаш исләре килеп, сине жәйге урман аланына кайтара. Мондый рәхәтне тагын кайсы транспортта татып була, әйтегез?

Трактор чанасында да рәхәт. Урта мәктәптә укыган чакларда, жәяүләп кайтып килгәндә берәр трактор куып житсә һәм чанасына утыртса, бәхетеңнән үзенне жиде кат күктә сизәсең. Ләкин трактор трактор инде, анда исе дә, тавышы да бүтән. Өстәвенә бүген ДТның ташбака алымы белән баруы эчне пошыра, чанадан төшеп, алдан йөгерәсе килә башлый. Ә акыл белән уйласаң, ярый әле ДТ биргәннәр дип шөкрана кылырлык.

Барасы юлны тракторчы кайдан, ничек чамалый торгандыр, әйтүе кыен. Буран һаман котыра, алда ак пәрдә, як-якта күзне томалый торган шундый ук аклык. Адашмыйча бәла-казасыз бару өчен монда тракторчының ике түгел дүрт күзле булуы, үзе генә белгән билгеләргә таянуы, аерым тою сәләте һәм, ким дигәндә, әлеге юлдан ике көнгә бер тапкыр узып торуы кирәк. Илдус абый нәкъ менә шундый кеше иде. Әле алай да, Жәнәй кулына житкәч, чак кына чокырга мәтәлеп төшми калдык.

Әкрен барса да, трактор трактор инде, сәгать уннарда без район үзәгенә килеп життек. Мин май заводына керә тормадым, борылышта ук чанадан төшеп калдым да жәяүләп больницага киттем. Бу бит минем өч ел буена белем эстәп йөргән жирем—һәр урам-тыкрыгы таныш. Шуңа күрә ишек аллары дип тормыйм, мөмкин кадәр турыдан барырга тырышам. Үзем атлыйм, үзем аяк астындагы карны сизмим. Хәлемнең жинел түгеллеген чамалыйм, мөмкин булса, хәзер ястык та сорап тормас, хәтта менә шушы кар өстенә ятар идем.

Ләкин ятып түгел, берничә минутка утырып кына торырга да хакым юк. Мине Әтием көтә...

Хастаханә ишеген ачып керүгә, борынга мин белгән һәм белмәгән, бары тик авырулар янында гына була торган ямьсез, тынчу, укшытырлык авыр ис килеп бәрелде. Минем томаланган борыным да сизәрлек булгач, сау-сәламәтләр ничек түзәдер. Противогазсыз бер минут та торырлык түгел ич монда.

Кая барыйм, кемнән сорыйм? Мин бит әтинең кайсы катта, кайсы палатада ятуын да белмим. Шул хакта кемнән сорарга икән, дип торганда:

—Улым, кайчан кайтып життең?—дигән арыган, талчыккан тавыш ишетелде.

Чү, әллә тагын саташаммы? Бу бит минем әнием, әнием тавышы! Ул ничек мине монда төшеп каршы ала? Киләсемне кайдан белгән?

Әни белән без кочаклашыр-кочаклашмас кына күрештек. Ул мине, яки мин аны сагынмаганнан түгел. Ул татар хатыннарына хас рәвештә гажәеп дәрәжәдә тыйнак. Минем аның беркайчан да, дөньясын онытып, шатлыгыннан очып йөргәнен дә, кайгысыннан сыгылып төшәр хәлгә килгәндә дә сиздергәнен күргәнем юк. Ул—мәңгелек сер оясы, сер

хәзинәсе, аның күңеле—очсыз-кырыйсыз карурман.

Әни белән очрашкач, телеграммада әтинең больницада ятканын язмаганнарына үпкәмне белдерермен дигән идем, онытылды. Үз анаңа ничекләр рәнҗергә, үпкәләргә мөмкин?!

Кешенең кешедә эше юк, кемне алма—аның үз кайгысы. Бигрәк тә больницада. Больница ул клуб түгел, монда кызык эзләп, күңел ачар өчен килмиләр. Барчасын нинди дә булса кайгы, хәсрәт китерә.

—Абый кайда? Әти янындамы?—Әни белән күрешкәннән соң беренче соравым шул булды.

Сынаган сыман карап торганнан соң, кызарып беткән арган күзләренә килеп тыгылган яшьләрен җиңе белән сөртеп, әни күкрәгемә капланды.

И газизем! Бөтенләй кечерәеп калгансың ич. Кайчандыр син миңа гаять зу-ур булып күренә идең.

—Әни, нишләп монда утырасың? Әйдә, әти янына керик. Ничәнче катта? Кайсы палатада ул?

Әни җавап бирми. Аның сүзсезлеге болай да телгәләнгән күңелемә хәвеф өсти.

—Әнкәй!

Ул мине ишетми.

—Әнкәй!

Икенче тапкыр дәшкәч, ул башын күтәреп миңа карады.

—Ничек кайтып җиттең, балам?

Хәзер минем ничек кайтуым мөһиммени! Иң мөһиме—мин инде кайткан, монда килгән.

—Самолет белән очтым. Авылдан сөт тракторы белән килдем.

Гаҗәпләнүеннән әни бер адым артка чүкте:

—Авылга кайтып йөрдеңмени?

—Кайттым шул. Белмәдем бит монда ятканын. Телеграммада язмагач, өйдәдер дип уйладым.

—Әй бу пушты кызын! Үзең белеп сук дигәч: «Ярар, апа, борчылма»,—дип алып калган иде. Соң, ул сөт тракторы белән килгәч, май заводында абыеңны күрмәдеңмени?

—Юк, мин заводка кереп тормадым. Борылышта төшеп, туп-туры монда йөгердем. Әйдә, анысын соңыннан да сөйләшербез, башта әти янына керик.

—Әтиең анда түгел шул инде, балам...—Әнинең болай да зәгыйфь тавышы калтырап чыкты.

—Кайда?

—Аны авылга алып кайтырга кирәк. Абыең шуның өчен трактор артыннан китте. Идарәгә шалтыратып, ат сорамакчы иде, телефонда элемтә өзек булып чыкты...

—Хәле яхшырды, терелдеме?

—Терелсә иде дә бит...

Күңелемдә шик байтактан уянса да, аны раслатасы, әче хакыйкатьне ишетәсе килмәгәнгә, турыдан-туры сорый алмадым, көчем житмәде. Күзләренә текәлеп, әнкәйнең үзе әйтүен көттем.

Күз карашымны күтәрә алмады, моңа кадәр хәсрәтен тыярга тырышкан әнкәйнең буасы ерылды:

—Әткәң... әткәң... юк инде. Иртәнге бишләрдә өзелде. Урыны оҗмахта булсын...

—Әткәй... үлде?

Читтән карап торучыларга ничек тоелгандыр, кинәт дөньялар әйләнергә, аяк астымда җир убылырга кереште һәм мин ниндидер билгесезлеккә очтым.

Очам, очам, оча торган коридорым тарайганнан тарая, караңгылан-ганнан караңгылана бара. Әле генә җылы, рәхәт иде, хәзер салкын.

Күпме очканмындыр, хәлем бетеп егыла башладым. Төшеп бәреләм дигәндә генә, ике ягымнан ике фәрештә култыклап алды.

Тагын очтык. Күпмедер вакыттан соң:

—Арыгансыңдыр, Рәшит, ял ит,—диеп, фәрештәләр мине күз алдында кинәт пәйда булган агач ботагына утырттылар да юкка чыктылар.

Нинди агач соң бу? Ничек кинәт үсеп чыкты? Тукта, теге каен, Тагылдагы кара каен түгелме? Әйе, әйе, шуның берсе. Икенчесе кайда икән? Ә, Айчибәр бит берсен яшен сукты дип язган иде. Колагыма җыр ишетелде:

Кара каенга кагылма,
Кайгыларың күбәер.

—Улым, исәнме...

Әти тавышы. Әнкәй аны үлде диган иде бит, ялгышты микәнни... Тик тавышы бар, үзе күренми.

—Улым, мин монда...

Аска табан карасам, кара каенның ботагында ап-ак күлмәк кигән әти утыра.

—Улым, син төшендә бура бураганны күрдең. Хәтерлисеңме, балта белән чапкач, чәчрәп кан чыккан иде. Син белмәдең генә: ул кан түгел, минем җаным иде. Үкенеч, кайтып өлгерә алмадың, югыйсә, сине бик күрәсем килгән иде. Ходай насыйп итмәгәндер инде...

Әти сүзен әйтеп бетерә алмады, көтмәгәндә әллә кайдан ике козгын килеп чыгып, берсе аның башын, икенчесе йөрәген чукырга кереште. Әти чәбәләнә:

—Коткар, улым!—дип кычкыра.

Мин инде, ул әйтмәсә дә, аны бу хәшәрәтләрдән араларга омтылам, ләкин урынымнан кузгала алмыйм. Ник дисәң, кара каенның кап-кара ботагы чалбар каешыннан кысып алган да җибәрми. Ә козгыннар әтине чукыпмы чукый. Тора-бара аның ак күлмәге күзгә күренеп карала башлады, аннан кинәт ялкын төсенә керде. Әле генә кул сузымы җирдә булган әти дә, каен да юкка чыкты. Караңгы шомлы коридорда япа-ялгызым калдым.

«Беттем!»—дип уйларга гына өлгердем, коридорның аргы башында яктылык күренде. Кулларымны канат иттереп, сихри бер көч коточкыч зур тизлек белән мине шунда табан очырды. Ләкин коридорның яктыга чыга торган авызы шул тиклем тар иде, тәнем буалып калды, җаным ымсындырып торган яктылыкка чыгып очты. И андагы киңлек, андагы рәхәтлек!

Кай тарафка очарга белми торганда, ир белән хатын кыяфәтендәге ак халатлы ике фәрештә килеп чыкты һәм:

—Ашыгып кердең, синең урының хәзергә монда түгел,—дип, тәнем кысылып калган караңгы коридорга кире озаттылар.

Җаным белән тәнем кавышканда, тәнемне нәрсәдер бик каты авырттырып алды.

—Температурасы утыз сигез дә җиде...

—Укол әзерләгез...

Тукта, кемгә, нинди укол? Фәрештәләр бит болай сөйләшергә тиеш түгел. Мин кайда?

Авырлык белән күзләремне ачтым һәм янымда торган ак халатлы ир белән хатын-кызны шәйләдем. Кемнәр болар? Ник өстемә иелгәннәр? Нәрсәдән шулкадәр куркышып калганнар? Ирнең кулында галәмәт зур шприц ни өчен? Андый шприцны минем авылда ветфельдшер Мөнәвир абыйда гына күргәнем бар. Сыерларның канын шуның белән ала иде. Сыерлар искә төшүгә, алдымда кинәт күзенең агын кан баскан нәсел үгезе пәйда булды. Ул сыңар мөгезенә корсагыннан әтине элəктергән дә ишек алдын ду китереп чабыпмы-чаба. Коррида түгелдер бит? Кан белән бөтен дөнья тулган.

Әти! Әтине коткарырга кирәк!

Күземне кабат ачмак булам, ачылмый. Сикереп тормакчы булам, аякларым кузгалмый.

—Әти!

—Чү, улым, чү, тынычлан!

Үгез дә, әти дә югалды. Маңгаемда кытыршы кул тоям. Әлеге кулны мин бүтән меңләгән куллар арасыннан да таныйм—бу әни кулы. Ул биредә ни эшли, кайдан килеп чыккан? Ник мин урында ятам?

—Әни, син?..

—Мин, балам, мин. Ни булды? Уф, бөтенләй куркуга салдың кана...

Тегермән ташыдай авырайган күз кабакларым ачыла һәм мин каршымда бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калган әниемне күрәм. Авыз ачып сүз әйтергә өлгермим:

—Энекәш, ни булды?—дигән тавыш ишетелә. Бусы—абый тавышы.

Абый. Мине малай чакларда яклаган да, киреңксә берне менеп төшәргә дә күп сорап тормаган дус та, казый да.

Бәлки саташам, төш күрәмдер?

Юк төш түгел. Әнә ич әни, аның янәшәсендә абый, алардан аз гына арттарак аптыраулы кыяфәтләрен ни эшләтергә белми торган ак халатлы кешеләр.

—Без кайда?

—Куркыттың бит, студент...

Ак халатлы ир, әни белән абыйны аралап, яныма атлады.

—Фани дөньядан чак кына китеп бармадың ич. Кайда шулкадәр суык тигерден?

Соравын аңлап бетерә алмыйм: нинди фани дөнья, кемгә суык тигән? Сүз бит әти турында барырга тиеш иде.

Тәнемнең келәйгә катырылган күзәнәкләрен көч-хәл белән хәрәкәткә китереп, аягыма бастым.

—Мине әти янына алып барыгыз!

Хәлем авыр булса да, хәзер инде мин саташмавыма ышанган идем: кайдадыр якында үлем түшәгендә ятучы әтием булырга тиеш.

Тагын:

—Әти янына алып барыгыз!—дип кабатладым.

Бу юлы тавышым үтенүдән дә битәр әмер булып яңгырады, ахрысы, абый:

—Рәшит, атларлык хәлең бармы соң?—дип сорады.

Раслап, баш селектем. Башыма бүрегемне, өстемә пальтомны кидерттеләр.

Бер яктан абый, икенче яктан шәфкать туташларының берсе култыклап, мине коридор буйлап алып киттеләр. Артыбыздан шәүләгә әверелеп калган әни теркелдәде.

Урамга чыгып, ишек алдына аерым салынган бер катлы ямьсез бинага кердек. Борынга шунда ук формалин катыш мәет исе килеп бәрелде. Күңелдәге шомга бирелдәге салкынлык өстәлеп, тән куырыла.

Абый бер кушеткага күрсәтте:

—Әнә безнең әти...

Ул күрсәткән якка карадым. Анда өсте ак җәймә белән капланган кушеткада берәү ята. Ә әти кайда?

Менә шул чакта гына зиһенемә әнкәйнең «әткән юк инде» дигән сүзләре барып житте һәм үземнең хәзер моргта басып торуыбызны аңладым. Нәрсә булды соң миңа? Ник бик озак аңлыйм?

Җәймәне күтәреп, озак карап тордым: күзләре эчкә баткан, саргаюлы-каралып киткән йөзен кыл кебек тырпаеп торучы сакал-мыек баскан бу гәүдә чынлап та әтинекеме соң?

Ничекләр генә ышанасы килмәсә дә, бу—әти иде. Ми күзәнәкләремне көйдереп, башымнан әче хакыйкать узды: ул бит инде беркайчан да миңа «улым» дип әйтмәячәк, күрешергә сөялгә әверелгән кулын бирмәячәк. Әтием үлгән! Хәзер мин атасыз ятим. Менә ни өчен әллә нинди төшләр күреп саташып беткәнмен икән.

Җанымда нинди хисләр бәргәләнгәнен чамалаган абый мине үзенен

кукрәгенә кысты һәм мин гомеремдә беренче тапкыр сулкылдап елап җибәрдем. Әни дәшми, абый булдыра алган кадәр юатырга тырышып, сөйләнә:

—Илдуска әйттем, сөтен бушатуга, монда киләчәк. Башка чара юк, трактор белән алып кайтырга туры килә. Их, энекәш, әз генә кайтып өлгерә алмадың. Көткән иде ул сине. Иртәгә күмәрбез инде.

Әткәй юк!.. Бу хакыйкатьне аңласам да, кире кайтарырга көчсез икәнлегемне тою, чарасызлык күзләремне кабат яшь белән томалады.

Бераздан абый:

—Рәшит, син әнкәй белән монда калып тор, мин күмгәндә кирәк нәрсәләрне хәстәрлим әле. Ялан-ялан районга килеп йөреп булмый. Әнкәйгә күз-колак бул инде, өзлегеп китмәсен дим.

—Ярар, абый...

* * *

Трактор җай гына кайта. Чанада иң түрдә әти ята. Аны рәхмәт төшкән авылдашларның берсе биргән толыпка төреп салдык. Әнкәй әтинең бер ягына, абый белән мин икенче ягына урнаштык.

Буран шактый кимегән, ләкин бөтенләй басылырга уйламый да. Әти инде хәзер ыжгырган буранны да, бер-берсен кабатламас энҗеләргә әверелгән миллион-миллиард кар бөртекләрен дә, авылдашларның тавышларын да сизми-ишетми-күрми. Ә бәлки ишетәдер, җавап кына бирә алмыйдыр. Әле җаны ерак китәргә өлгермәгән булырга тиеш.

Авылдашларга тагын бер рәхмәт—юк-бар сорау биреп аптыратып, җанны ашамыйлар. Бушагач җиңеләеп калган сөт савытлары кабатына һәрберсе үз җае белән урнашкан да күршесе белән гәп корып кайта. Сикәлтәләрдә, салулаган чакларда бер-берсенә бәрелеп, фләгәләр туң тавыш белән аваз биреп алалар.

Безнең сөйләшәсе килми. Кайгыбыз зур. Өстәвенә минем үз хәлем дә—хәл. Ачу китереп, буран:

—Рәш-ш-ит, йә-тт-тим-м!—дип бар дөньяга фаш итә: сызгыра, үксеп елап та ала. Аның елавын вакыт-вакыт тракторның көчәнеп үкерүе басып китә. Минем елыйсым килә, күз яшьләрем мена-менә тамар да иде, юк, елый алмыйм. Әнкәй белән абый да—сүзсез. Чынбарлык изә, талкый, ләкин аның каршында без көчсез.

Әтине алып кайтып китәр алдыннан миңа тагын бер укол ясадылар. Врач әйтте:

—Энекәш, тамагыңда ангина, ярты үпкәң шешкән. Бу хәлеңдә сине кайтарып җибәрергә хакым юк. Гаиләгезгә килгән кайгыны да аңлыйм. Ни эшлибез? Калам дисәгез, хәзер үк палатага озаттырам.

Нинди палата, нинди калу турында сүз булырга мөмкин? Ни сөйли бу доктор? Әллә авырулар дәвалый-дәвалый, миенә зәгыйфьлек килгәнме? Минем бит әти үлгән, ангина турында сөйли торган чакмы?

—Зинһар, саклана күрегез. Кайту белән фельдшерга әйтегез, укол кадап торсын. Әтиегезне күмүгә, больницага керергә кирәк булыр. Онытмагыз, үпкә белән шаярмыйлар...

Әтине мәңгелек йортына озатырга бөтен авыл җыйналган иде. Бездә шундый гадәт, кайбер башка җирдәге сыман, өй борынча әйтеп, кабер казырга бригадир җыеп йөрми. Мөмкинлеге булган һәр ир-ат күрәчәген күтәрә дә иртән үк зиратка юнәлә. Сәгать уннарга, гадәттә, кабер инде казылып та беткән була.

Минем кабер казышырлык хәлем юк иде, абыйларда ятып торырга мәҗбүр булдым. Барысы да әзер булгач, зиратка алып китәр алдыннан үземне кереп алдылар. Бер үкенече—исән чагында әткәйнең бәхиллеген алырга өлгерәлми калсам, икенчесе—үз кулларым белән гүргә иңдерә алмадым. Күмү уникенче яртыларда тәмамланды. Картларга сәдака тараттык

та халык өйләренә кайтып китте. Зиратта тагын бер кабер, күңелләрдә бушлык, сагыш artты.

Калганын хәтерләмим. Аңыма килгәндә, больницада ята идем. Хәлем бик авырайгач, әтине күмгән көнне үк, ат җигеп, больницага алып килгәннәр. Врач әйтә, тагын өч-дүрт сәгатькә соңарсалар, әтиең янәшәсенә урнаштырасы гына булыр иде, ди. Үпкәм ялкынсынуы өстенә аңкау бизләре соң чиккәчә шешеп, сулыш алдырмый башлаган, температурам кырык градуска җитеп, барысын да тәмам куркуга салганмын.

Кулыма каләм алырлык хәлгә житкәнче, ялыктыргыч көннәр, атналар уза торды. Әтинең өчесен, җидесен миннән башка гына үткәрделәр. Абый укыган җиремә авыруым хакында телеграмма сукты. Ә Айчибәр белән ни эшләргә? Мин бит аның каршында алдакчы булып калдым. Үзем киләм, көт диеп яздым, үзем баралмадым. Менә бит ничек килеп чыкты. Гаебем дә юк, ләкин аңа карап кына нәрсә жинеләя?

Хәзер ни эшләргә: хат язаргамы, әллә телеграмма сугаргамы? Бу бит янгынны сүндергәннән соң буш көпшә белән селтәнү генә булачак. Телеграмма сугуның кыенлыгы юк, тик анда ни генә аңлатасың, ә хат язарга хәлем дә юк, фикерләрем дә таркау.

Каникуллар тәмамланганга да инде бер атна. Безнекеләр җыйналгандыр инде. Нинди гаделсезлек: алар укырга йөри, ә мин больницада тараканнар белән сугышып ятам. Температурам шактый төште инде: утыз жидедән чак кына артык. Шәфкать туташлары моны субфебриль температура, диләр. Әй, хикмәт аның ничек аталуындамыни! Тизрәк тереләсе, бу таракан питомнигыннан, соры диварлы, тәрәзә пыяласына кадәр дару исе сеңгән палатадан тизрәк якты дөньяга чыгасы иде.

Янбашлардагы укол кадаган урыннар кара янып, шешеп чыкты. Кызык, өч атна буена тәүлегенә алтышар тапкыр пенициллин кадаган шул урынны кисеп алып, этләргә бирсәң, ашарлар иде микән? Тфү, әллә ычкынам инде, башка әллә ниткән тузга язмаган уйлар килә.

Яшь йөрәккә иркенлек кирәк. Туйдым, туйдым бу больницаларыннан!

Ләкин вакыты житми—җил дә исми, яфрак та селкенми. Син ашыкканга карап, ул кабаланмый. Мине больницадан чыгарганда, февраль бетеп килә иде инде. Әтинең кырыгын уздыргач, Казанга киттем.

Исәнме, Казан! Исәнме, тулай торак! Минсез сезгә күңелсез булмадымы? Һи, юклыгымны мөгаен сизмәгәнсездер дә. Беткәнмени монда минем кебек студентлар. Ә мин сезне сагындым. Үзем югыйсә, бераз яшәүгә, авылны өзелеп юксына башлаячагымны да беләм. Нишлисең, адәм баласы шулай яратылгандыр инде.

Мине барыннан да бигрәк Айчибәрдән берәр хәбәр бармы, булса, бара алмавыма нәрсә дигән—менә шул кызыксындыра.

Вахтер янындагы өстәлдә хат тапмагач, дулкынлануымны басарга тырышып, бүлмәмә кердем. Малайларның әле берсе дә дәрестән кайтмаган. Өстемне дә сала тормыйча, хат эзли керештем. Гадәттә койка өстенә куялар иде, анда берни дә күренми. Әһә, менә кайда ул хатлар! Егетләр аны минем тумбочка тартмасына салганнар икән. Рәхмәт, дусларым, изгелегегезне онытмам.

Тә-әк, бусы Наилдән—бергә хезмәт иткән Сарапул татарыннан. Монысы көтеп торыр. Икенчесе—редакциядән. Алардан җавап алуыма өметләнми дә идем. Монысы да көтәр, беркая да китмәс. Өченчесе...

Өченчесенең җибәргән адресын хәтта укып та тормадым, бөжра-бөжра итеп язылган хәрефләргә караганчы ук, күңелем сизде: бу—башка берәүдән дә түгел, Аңардан—Айчибәрдән булырга тиеш. Дөньяларым яктырып, сулышым иркенләп китте. Гүя Тагыл күленең камышлы җиле шушы конвертны озата килгән һәм миңа сафлык бөркеде.

Ашыга-кабалана, әйтерсең кемдер аны миннән тартып алырга җыена, Айчибәрнең хатын ачтым. Дәфтәр битенә нибарысы биш-алты юл язылган иде, һәм аның беренче сүзләре үк мине бозлы суга ыргытты. Аннан

тартып чыгарды да утка салды. Үпкә катыш мәхәббәт сүзләре көткән йөрәгем сулкылдап еш-еш тибәргә керешге. Күпмедер вакыт күзләрем язганны күрә, укый алмый интекте. Әле бит ныклап терелеп тә житмәгән идем, әллә шуңа тәнгә салкын тир бәреп чыкты. Графиннан стаканга су агызып эчтем. Аякларымның хәлсезләнүе караватка утырырга мәҗбүр итте. Чү, йөрәк, тынычлан, тынычлан, тынычлан...

Их, тынычлан диеп кенә тынычлана алсаң иде лә!

*«Рәшит!*

*Киләм дигәч, көткән идем, бик көткән идем сине. Ат сорап, район үзәгенә кадәр каршы алгалы да бардым. Мин инде мәхәббәтнең барлыгына да ышана башлаган идем. Бөтә ышаныцымны, өметемне җимерден, хисләремне таптадын. Ләкин мин синә үпкәләмәем. Минә биргән вәгъдән юк. Бүтән кызны тапкансындыр. Тик нимәгә киләм дип, мине алдадын?*

*Хуш, бәхетле бул, Казан җегете. Бүтән хат язма. Бәлки мин кияүгә дә цыгармын.*

*Тагылда танышкан көннәр яшьлегемнен гүзәл хатирәсе булып, җөрәгемне гел җылытып торыр. Шул көннәр өцен рәхмәт синә.*

*Айцибәр.»*

Хатның язылу датасына игътибар иттем: әтине күмгән көн.

Их, Айчибәр, Айчибәр! Әгәр дә минем ни хәлдә калганымны белсәң, бу үпкә сүзләреңне язар идеңмени син? Бөтенләй күрешмәгән, танышмаган булсак, бәлки безгә яхшырак та булган булыр иде. Җаным болай да урынында түгел, өстәвенә син үпкәлисен. Әтине жирләдек, үлемнән үзем чак калдым. Ләкин аңымда чагымда гел сине уйладым. Болай караганда беребез дә гаепле түгел. Язмышыбыз шундый булганга, кемгә үпкәләргә? Карале, бөтенләй фатализм тарафдары булып барам түгелме соң?

Тагын кара каен турындагы җыр искә төште:

Күл кырында кара колын,
Көзгә кергәч көрәйде.
Кагылдым кара каенга,—
Кайгыларым күбәйде.

Кара каен, кара каен... Чынлап та шул кара каенны күргәннән соң, хәсрәт җимешен шактый ашадым түгелме? Ә бәлки кара каенны кайгы китерә дип әйтүе белән Айчибәр хаклыдыр? Аны бит ул үзе уйлап чыгармаган. Халык теленә юкка кермәс...

Ни эшлим? Айчибәргә барысын аңлатып, хат языйммы? Акланыр идем—гаебем юк. Рәнҗетәсең син мине, Себер гүзәле, рәнҗетәсең. Дөнья син һәм мин уйлаганнан күпкә катлаулырак, күпкә хафалырак бит ул, кызый.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Лекцияләр тәмамлангандыр да, студентлар кайта башлагандыр. Чыннан да, озак та үтмәде, безнең егетләр дә шау-гөр килеп кайтып керделәр. Китте күрешү, китте «тел, лөгать вә фикер алмашу.»

Өстенә кигән пальтосын да салып тормыйча, Алмас кулыма телеграмма тоттырды:

—Монысы, әткәй, әнкәйдән сиңа сәлам хат.

«Әнкәй» дип Айчибәрне әйтәләр инде алар.

Телеграмманы күрүгә, күңелдә өмет уянды: мөгаен, хатында язган гаделсез үпкә сүзләре өчен үкенеп, Айчибәр гафу үтенергә уйлагандыр...

Өмет өмет урынында, ләкин дөньяда этлек кануннары хакимлек итә. Телеграмма хаттан бер көн алда сугылган һәм айдан артык вакыт мине көтеп яткан булып чыкты. Анда бары тик бер сүз язылган иде: «Алдакчы!»

Үзем дә инде ахмак—бара алмагач, теге вакытта ник аэропорттан Айчибәргә телеграмма сукмадым икән? Әтинең авыр хәлдә ятуы турындагы

хәбәр бигрәк башыма кендек белән орган кебек тәэсир итте шул.

Ярар, булганы булган, болай җебеп төшү егет кеше эше түгел.

—Харис!

—Һәрсә, әткәй?

—Менә сиңа акча, бер аягың монда, икенчесе тегендә булсын, алып кайт бер литр! Очрашуны бәйрәм итәбез бүген. Бүген безнең сабан туе! Тиз йөр!

—Баш өсте!—дип, Харис чыгып китте, малайлар миңа гаҗәпләнеп карадылар, ләкин берсе-бер каршы сүз әйтергә базмады. Бөтенләй үк фәрештә булмасам да, бергә яшәп, минем тәкъдим белән бүлмәдә мәҗлес оештырылганы юк иде әле.

Харис урам аша гына булган кибеткә кереп чыкканчы, безнең бәрәңге пешеп, эскәтер урынына җәелгән гәҗит өстенә авылдан алып килгән күчтәнәчләр менеп утырды.

Утыз-кырык минуттан сырлы стаканнарның төбенә салып, чәкештерергә һәм тост әйтергә өлгергән идек инде. Әнкәй җибәргән пешкән каз, өй ризыгын тансыклаган бүлмәдәшләремнең күңеленә хуш килде.

—Сал тагын берне!

Беренчесе әле башка китмәгән иде, икенчесе иш янына куш булды: телләр чишелде, күңелләр бушый барды. Әллә өченчесеннән, әллә дүртенчесеннән җырлап та җибәрдек. Гомер булмаганны Харис урысча да җырлады:

Ширука страна моя радная...

Урысча әйбәт кенә сөйләшә торган Әтнә ягы егете җырлаганда ни өчендер «широка» дими, «ширука» ди.

Утыра торгач, әткәй белән булган хәлне дә, үземнең ничек авырып ятуымны да сөйләдем. Айчибәрне мәрхәмәтсезлектә гаепләдем. Елап та алдым бугай. Бүлмәдәшләр тынычландырырга тырыштылар...

Аракы эчеп кенә барлык борчу-мәшәкатьләреңнән котылып булса икән. Баш авыртуга түзә алмыйча, бик иртә уянып киттем. Бүлмәдәшләр әле таралышып йоклыйлар. Бәхетлеләр!

Башым үтереп авырта, мин бар гаепне Айчибәргә сылтарга тырышам. Аңардан шундый хат килмәсә, кичә аракы эчми идем бит мин. Аракының мәхәббәттән ни аермасы бар? Икесе дә бөтен барлыгыңны били, тилертә, ушыңны ала. Кичә мин нык исергәч, Айчибәр янына китәм дип, киенә башлаганмын. Ярый әле егетләр туктатып калганнар. Югыйсә җылы түшәк урынына кызыл погонлы абзыйлар бүтән җирдә урын табарлар иде.

Шулай да кайсысы көчлерәк соң: аракымы, мәхәббәтме? Армиядә хезмәт иткән чакта безнең ротадан Павел Куприянов дигән урыс малае, көтәргә вәгъдә биреп калган кызы кияүгә чыкканын белгәч, каравылда торган чагында атылып үлде. Ап-айнык булган. Йә, хода, үзең сакла, башка әллә нинди тиле-миле уйлар килә башлады.

Юк, аракы белән эш барып чыкмас, тешем-тырнагым белән укырга ябышырга, үзен әллә кемгә санаган үпкәчел бу Тагыл кызын онытырга кирәк. Авырган көннәрдә болай да программадан шактый артта калганмын. Шулай да Айчибәргә барысын тәфсилләп хат языйм, акылы булса—аңлар.

Шул көнне үк язган хатыма түземсезләнеп җавап көтә башладым. Унбиш, егерме көн узды, бер ай үтте, ләкин җавап килмәде. Аңа атап Тагылга язган хатым да эзсез югалды.

Карадан кара каурый
Карлыгач канатында.
Күрешүләр кирәкмәгән
Кушкаен кабатында.

Күл кырында кара колын,
Көзгә кергәч көрәйде.

Кагылдым кара каенга,—
Кайгыларым кубәйде.

Күз өстендә кара кашын,
Карачы көлеп кенә.
Кайгыларым юылырмы
Күлләргә кереп кенә?..

Нигәдер Атбакат әбидән язып алган шушы җыр сүзләре күңелгә ешрак килә башлады. Үзем дә сизмичә, мин аны кайсыдыр көйгә җырлап йөрим икән.

Кайдан, кемнән белешергә, кемнән ярдәм сорарга? Хатларымны Айчибәр алмадымы, алып та җавап биреп «вакланмадымы?» Исәнме ул, әллә аның белән бер-бер хәл булдымы? Бәлки ул бәлагә тарыгандыр һәм аңа ярдәм кирәктер?..

Көч-хәл белән Беренче майны көтеп алдым да, ял көннәренең күбрәк булуыннан файдаланып, Айчибәр эшләгән Әлмән районына юл тоттым. Авызым бер пешкәч, бу юлы инде мин телеграмма сугып тормадым.

Амбирактин, җамбирактин,
Кияү килә җырактин.

Ярар, мин көйсез кияү түгел, «Амбирак» әйтеп каршы алмасалар да риза. Куып кына чыгармасыннар.

* * *

Күпмесендер ат белән, соңгы унбиш чакрымын җәяү килгәннән соң, ниһаять, Айчибәр эшләгән авылга аяк бастым. Шушы яшемә җитеп, моңа кадәр бу якларда булырга туры килгәне юк иде әле. Безнең район Ык буенда урнашкан, ә елганың аръягында Башкортстан. Ләкин анда күпчелеге татар авыллары. Урыс, мари, хәтта ногайбәкләр яши торган авыллар да бар.

Айчибәр язган хатлардан С. авылын бераз күз алдына китерә идем, әлләниләр күрермен дип уйламаган-өметләнмәгән дә идем. Тик үзенә аяк баскач, фантазиямнең искиткеч ярлы икәнлегенә төшендем. Йөздән артык капкалы авылда өйләрнең яртысыннан күбрәгенең түбәсе салам белән ябылган һәм болай да шыксыз авылның бөтен ямен алып торалар. Безнең авылда читәннең ни икәнен онытканга бишбылтыр, бүгенге мәктәп балаларының аны күргәне дә юк. Ә биредә читән коймалар күп, мал абзарларының диварлары да читән. Ул читәнгә, ышык булсын диптер инде, сыер тизәге чәпәштергәннәр. Югыйсә, өсләренә урман авам дип тора. Кая карама, тирес, чүп өемнәре. Кайбер хуҗалыкның ихатасы гына түгел, йорты да юк. Аның урынына морҗасыннан төтен чыгып торган землянкалар бар. Тагын шунысы нык күзгә ташлана: ишек алдында, урамда пычракка баткан, аяклары, әле яз башланырга гына өлгерсә дә, тезгә кадәр чебиләргә өлгергән бала-чага бихисап иде. Алар кары эреп, кояш турырак карый торган җирләргә җыйналганнар да чыр-чу киләләр. Тавышларын еш кына казлар кангылдавы күмеп китә. Түбә саламнарын чемченгән кәҗәләр, танып калырга теләгәндәй, узган-барганга текәлеп карыйлар да, синең ишене генә күргән бар дигәндәй, кыска койрыкларын селкеткәләп, янә салам чемченүләрен дәвам итәләр.

Урамда күзгә күренеп торган бердәнбер кое баганасына атларын дилбегә белән бәйләп куеп, арбада өч адәм «баш төзәтә». Күптән кырынмаган чырайлары шешенеп беткән, күзләреннән иман нуры качкан.

Беренче тәэсирләрем Айчибәрне искә төшерде һәм мин аны кызганып куйдым: мескенем, ул бит монда бер көнгә генә килгән кеше түгел, шушында эшләп, шушы пычракта халыкның сәламәтлеге өчен

көрәшергә тиешле кеше. Бу кадәр хәерчелек, шакшылык, тәртипсезлекнең асылы нидән гыйбарәт? Ни уйларга да белмәдем. Хәер, ул хакта уйланырга вакытым да, теләгем дә юк иде. Тизрәк Айчибәрне табарга, анлашырга кирәк.

Авыл сер саклый белми. Түбән очта шылт итсәләр, берничә минуттан ул хакта Югары очта сөйли башлыйлар. Шул сәбәпле Айчибәрне дә йөз егерме йортлы авылда эзләп табуы кыен булмас. Тик аның исеме белән «сарафанлы радиоларга» авыз чайкатканчы, туп-туры медпунктка—эшләгән җиренә барырга кирәк. Мөгаен ул бүген эшлидер.

Медпунктның кайдалыгын сораган идем, ике кечкенә малай болдырына кадәр үк озатып куйды. Һәм, мин биргән кәнфитләрне алуга, берберсе белән узыша-узыша, йөгереп китеп тә бардылар.

Медпунктның ишеге ачык иде. Мондагы чисталык, пөхтәлек авылның гомуми пычраклыгы янәшәсендә күзгә артык нык бәрелеп тора. Нарат иДәннәр күптән түгел кырып юылган, сап-сары булып тора, ылысның хуш исе борынны кытыклый. Өйалды ишегенә кызыл бәрхеттән чаршау, тәрәзәләргә ак пәрдәләр эленгән. Даруларның әчкелтем исе борынга килеп бәрелде. Керәм дә Айчибәрне кочагыма алам. Ул бит мине көтми, гаҗәпләнүенең чиге булмас. Юк, җитте аңа бу сөргендә ятарга, коткарырга кирәк. Әгәр дә бүтән чара калмаса, иртәгә үк, тукта, нигә иртәгә, бүген үк язылышабыз да Казанга китеп урнашабыз. Авылда язылышыр өчен шәһәрдәге сыман икешәр ай чират торасы юктыр әле.

Ә Казанда ничек яшәрбез? Алдан ук кайгырмыйм әле, илдә чыпчык үлми, диләр, баш исән булса, җае табылыр. Айчибәр үз җае белән эшкә урнашыр, мин исә, аллага шөкер, сәламәтлегемнән инде зарланмыйм, куркыныч минутлар артта калды, кирәксә, бушатырга вагон бетмәс.

Шушы ләззәтле уйлар белән пычракка баткан туфлиләремне тавыштын чыгармаска тырышып салдым да баскычтан ук җәелгән палас буйлап эчкә уздым. Анда кем дә юк, бары тик электр плитәсендә стерилизатор гына быгыр-быгыр килеп бар көченә кайный.

Монда кеше булмагач, түр бүлмәгә узар өчен, озак уйлап тормыйча, ишек тоткасына үрелгән идем, туктап калдым. Бу бит медпункт, бәлки эчтә берәр хатын-кыз чишенгәндер, башта шакырга кирәк. Аны да, үземне дә, Айчибәрне дә уңайсыз хәлдә калдыруым бар.

Ишекне шакылдаттым һәм, Айчибәр тавышын ишетүгә өметләнеп, хәтта бер адым артка да чиктем.

—Керегез!

Юк, бу мин көткән тавышка охшамаган, димәк, минем җанкисәгем үзе генә түгел.

Йөрәк дөп-дөп килә. Әйтерсең, яңарак кына мең метрга йөгереп кайтканмын һәм судьяларның нәтиҗәне игълан итүләрен түземсезләнеп көтәм. Әгәр дә анда Айчибәр булмаса? Әй, булмаса да, хәзер чигенер урын калмады. Юк икән, һич югы кайдалыгын сорап белермен. Монда кадәр килгәч, тапмый китү юк инде ул.

Эчкә уздым.

—Исәнмесез!

Мин хыялланган Айчибәр атлы гүзәл урынына илле-илле биш яшьләр чамасындагы, кысыграк күзле, аркасы бөкре хатын каршы алды. Ул биш энә белән кәҗә мамыгыннан шәл бәйләп утыра иде.

—Гафу итегез, миңа фельдшер кирәк иде.

—Санитарка гына ярамыймыни? Ай бу егетләрне, барыһына да кыд кәрәк. Беддәй корткалар белән һөйләшүсе дә юк,—үз сүзләреннән кызык табып, апа кеткелдәп көлеп куйды. Шуннан соң гына башын күтәреп миңа карады һәм, бетмәс монда синең ишеләр дигәндәй, шәл бәйләвендә булды.

Ихтыярсыздан бу апаның кулларына игътибар иттем: ул шулкадәр оста бәйли ки, үзе каядыр читкә караган чакта да, биш энәсе гармунчы бармагындагы баян төймәләре сыман биешә.

Айчибәр хакында сорыйм гына дигәндә, санитар хатын бәйләвеннән туктап, текәлеп миңа карап тора башлады.

—Тукта, тукта, һин Рәшит түгелме һун? Казан егете...

Менә сиңа мә! Әллә күрәзәче каршына килдем инде. Кайдан белә ул, бу шүрәле каргаган якларга бисмилла аяк басуым лабаса.

—Ә-әйе,—дидем, гажәпләнүдән тотлыга төшеп.—Кайдан белдегез?

—Кайдан белдегед дип... Һурәтенде Айсибәр гел өстәлендә тота ине.

—Апа, ә Айчибәр үзе кайда?

—Кайда дип... Белмәйһеңмени? Ул бит моннан китте.

—Ничек китте?

—Кыдлар нисек китәләр һун? Кияүгә сыкты да китте.

—Шаяртасыз?

—Әй, кустым, ул яшьтән удганмын шул.

Бу хәбәр башка күсәк белән органдай тәэсир итте. Беркавым аңгыраланып торганнан соң, көч-хәл белән кайтарып сорый алдым:

—Ки-яү-гә чыкты?

—Сыкты шул. Ә һин шуны белмәнеңме?

—Кайчан чыкты? Кемгә чыкты?—Мин төпченүемне дәвам иттем.

—Кыскырмагыд, һаңгырау түгел лә. Адаматка сыкты, тагын кемгә сыксын!

Азамат исемен ишетүгә, Айчибәрнең элегрәк язган хаты искә төште: «Бөдрә чәчле, чибәр, озын буйлы, интеллигентный.» Димәк, менә шул интеллигентный егет Айчибәргә кармак салып өлгергән булып чыга.

—Ул һине ярата ине. Беткә асу итеп, тунын утка якты Айсибәр. Еландай телләремне сыгарып әйттем, ялгышаһың, кыдым, дидем, тыңламады. Киләм диеп тә һинең килмәй калуыңа үпкәләне ул... Адаматы да тынгы бирмәне, көсек һыман гел артыннан тагылып йөрене. Мин барыһын да белеп тордым. Үден харап итте балакаем...

—Ник алай дисез, апа?

—Адамат белән бәхетле булмаясак ул, күңелем һидә. Берәүне яратып, бүтән белән бәхетле булып булмай.

—Кая киттеләр алар, апа жаным, әйт, зинһар!

—Белмәем, кустым, белмәем. Адресын калдырманы. Гомер эсендә бер тапкыр адәм рәтле филшерга тиенде авыл, кызганды ходай аны беддән. Күддәреңне акайтып карама, кустым, белмәем дип әйттем бит инде һиңа. Ай, һинең менән һөйләшеп, шприсләрем эреп юкка сыкканнардыр кана.

Санитарка хатын, бәйли торган шәлен ташлап, бөкреләргә хас булмаган җитезлек белән алгы якка чыгып китте.

Башым сыгылып төште, күңелдәге тантана гарьләнү катыш үкенечле тойгылар белән алмашынды. Ни эшлим, кая барыйм? Ник болай дуамалландың, Айчибәр? Айчибәр түгел, Кансибәр син, бик беләсең килсә!

Стерилизатор күтәреп, санитарка апа керде.

—Әле ярый өлгереп калдым. Янып харап була язганнар.

Миңа монда торуның кызыгы калмаган иде инде.

—Кая киткәннәрен дә белмәгәч, хушыгыз, апа. Айчибәрдән алай-болай хат килсә, миннән сәлам язгыгыз,—дип, ишеккә таба атладым.

—Тукта, киска каршы кая бармаксы булаһың?—дип туктатты санитар хатын.—Һин бит юлдан, арыганһыңдыр, ашыйһың да килгәндер. Әйдә үдебезгә кайтаек, иртән китәрһең. Айсибәреңде барыбер куып өтәлмәһһең инде.

Шунда гына тамагым чатнап кипкәнен һәм ашказанымда бүреләр батальонының һөҗүмгә күчкәнен тойдым. Бәлки чыннан да бу апаның сүзенә колак салырга һәм куныш китәргәдер? Район үзәгенә кайчан барып житәм әле мин. Илтеп куярга берсе дә атлыгып тормый. Килгәндә дә, әнә, ярты көнем юлда узды. Таныш түгел җирдә төнгә каршы юлга

чыгу башсызлык булыр иде. Әле һәр карышын белгән үзебезнең якта да гомерем белән чак хушлашмый калдым. Язмышны кат-кат сынатмыйлар. Аның өчен бөтенләй башсыз булу кирәк.

Бу апага әле булса рәхмәт укыйм. Җир идәнле өенә алып кайтып, тамагымны туйдырды, балалары белән рәттән җылы түшәктә йоклатты. Ә иртән, рәхмәт төшкере, районга баручыларның берсенә аның ире утыртып җибәрде, Саубуллашканда апа әйтте:

—Ярата иде ул һине, Рәшит. Бик әйбәт кыдды югалттың.

Болай да янган йөрәккә ник май сибәсең икән, апа! Бөтенләй янып бетсен диптер инде...

* * *

Район үзәгеннән тимер юл стансасына илтә торган автобуста барам. Хәзер минем алда ике юл бар: беренчесе—Курганнан Казанга йә самолет, йә поезд белән кайтып китү; икенчесе—Тагылга бару.

Акылым белән беренче юлның иң яхшысы икәнен аңлыйм, ләкин йөрәкнең килешәсе килми. Югыйсә Тагылга баруның бер мәгънәсезлек, файдасызга вакыт уздыру икәнен дә беләм. Хәзер инде поезд киткән, Айчибәр сайлыйсын сайлаган—Азаматка кияүгә чыккан. Ярар, адресын да белдем ди. Шуннан? Шуннан... йөрәк әмеренә буйсынып, Тагылга китеп барам. Казан качмас, анда кайтырга кайчан да соң түгел.

* * *

Тагылга икенче көнне иртәнге уннарда гына барып життем. Исәнме, Тагыл, исәнме миңа ләззәтле сагыш, сагышлы моң, моңлы мәхәббәт бүләк иткән матур, төзек авыл, Айчибәрнең туган авылы. Әле «Казан әртисләрен» онытып бетермәдеңме?

Урам буйлап ашыкмыйча гына атлыйм. Узган җәйнең монда уздырган көннәрнең хатирәсе өермә булып бөтерелә.

Үземне тануларыннан курыкмыйча, шул хатирәләрне яңартып, Айчибәрләр йортына табан киттем. Хәер, танысалар ни зыян? Мин монда ат урларга килмәдем.

Менә бусы Рәшатлар торган фатир. Әнә Атбакат кушаматлы Бибикамал әбиләр өе. Тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән кадакланган. Шул такталарны күргәч, йөрәгем жу итеп китте. Бибикамал әби исән чагында борынгылык белән бергә аннан ниндидер җылылык та бөркелеп тора иде.

Туктап, шактый озак карап тордым. Мин күрмәгән тугыз-ун ай эчендә картаеп, жиргә иңә төшкән бу йорт. Оҗмах дигән нәрсә булса, синең урының оҗмахтадыр, әбкәй, аның да, кем әйтмешли, люкс номерындадыр. Бәлки минем әткәй белән икегезнең дә җаннарыгыз бер тирәдәдер.

Бусы—Мөслим ягыннан укытучы булып килеп, биредә бөтенләйгә төпләнеп калган Әлфия апалар.

Үзгәргәнсеңме син, Тагыл, юкмы? Үзгәргәнсең. Ямең кимегән. Әй, Айчибәрсез калган авылда ямь була димени!

Берәүне дә күрәсем, берәү белән дә сөйләшәсем килми иде. Бәхетемнән, танып эндәшүче булмады. Һи, үзем дә инде,—гомер эчендә бер тапкыр өч-дүрт көнгә килгән кешенең кемгә кирәге бар. Һәммәсенең шатлык-хәсрәтле мәшәкатьләр тулы үз дөньясы.

Тукта, йөрәк, тукта, артыгын шашынма. Айчибәрләр йорты дигәч тә, анда синең ризыгың киселгән. Ул йортның чибәре хәзер монда үзе дә кунак кына.

Каршы яктагы капка төбендәге утыргычта Айчибәрләр йортын шактый вакыт күзәтеп утырдым. Әллә үлеп беткәннәр инде, биек койма

белән әйләндереп алынган ихатага ни керүче, ни чыгучы юк. Урамнан узган-барган исә мина борылып караса карый, карамаса, үз юлын дәвам итә.

Язмышны үзгәртергә кодрәтем житмәсә дә, Айчибәрнең хәзер кайда яшәвен бик беләсем килә иде. Тик аны теләсә кемнән сорау килешми. Ул бит хәзер фельдшер кыз гына түгел, ир хатыны! Гөнаһсыз кызыксынуым әллә нинди төсмерләр алып, гайбәт таралырга жирлек бирер. Әйтәм ич, авыл сер саклый белми ул дип.

Кемне дә булса күрүемә өметемне өзеп, инде кузгалып китәм дигәндә, Айчибәрләрнең капка астына асып куйган тактаны башы белән сөзеп, Пожарник килеп чыкты һәм унга-сулга каранып тора башлады. Пожарник ул кечкенә гәүдәле йорт эте. Кечкенә булса да, усал, бик зәһәр өрә һәм, беренче тапкыр күргәндә, мине чак кына балтырдан каптырмый калды. Соныннан дуслаштык тагын үзе белән.

—Пожарник!

Исемен ишетүгә, ул карашын мина юнәлтте. Күрәсен, таныды, чынлык өчен борынын бу якка сузып иснәде дә яныма чабып килде.

—Вау!

Бу анын шатлык авазы иде. Ул, арт аякларына басып, ал аяклары белән мине кочаклап алды һәм куанычыннан чиный-чиный, кулларымны яларга тотынды. Башка вакытта эттән ялата торган кеше түгел мин, тик бу бит Айчибәрләр эте.

Рәхмәт, Пожарник, онытмагансын Рәшит абзанны. Кызганыч, сина кучтәнәч алмаганмын. Апан да синен шикелле хәтерле булса икән.

Песидән күп булса ике тапкыр чамасы гына зуррак булган бу эт очрашуыбызга шулкадәр шатланган иде ки, ул тыныч кына урынында басып та тора алмый, бии, үзе ике япьле йонтәс койрыгын болгый. Күрәсен, бу анын кадерле кунак алдында ритуал биюен башкаруыдыр. Айчибәрнен Пожарник хакында көлеп сөйләгәннәре хәтердә жанланды.

Анын исеме башта Шарик була. Койрыгы да башка этләрнекеннән аерылып тормаган.

Тагылда этсез йорт, мөгаен, юктыр. Айчибәрләрнен бер як күршеләрендә—немец овчаркасы, икенче якларында—бүре ала торган бурзай. Үзләренен эте кәрлә булганга, Айчибәрнен игезәк энеләре, алты гына яшьтә булсалар да, егет солтаннары бит, бик гарьләнәләр икән. Аларны ирештерергә яратучы авыл агайларынын берсе котырткан боларны көннәрдән бер көнне:

—Көцекнен койрыгын киссән, ул зур үсә.

Малайларга шул житә калган. Йөгереп өйләренә кайтканнар да берни шикләнмәгән Шарикны берсе тотып торган, икенчесе койрыгын түмәргә куеп, утын яра торган балта белән чапкан. Әллә малайлар үзләре кыек чапканнар—өзеләсе койрык икегә аерылып, көлтәгә әверелеп калган. Әлбәттә, эт тә дурак түгел, анын да исән-имин яшисе килә, тагын бер чапканны көтеп тормаган, тотып торучысынын кулын тырнап, урамга чыгып ычкынган һәм кичкә кадәр чинап йөргән.

Үз башына бәлане Шарик болай да эзләп кенә йөргән. Айчибәр сөйләгән иде: бервакыт әнисе мунча мичененң көлен алып, утын тутырган да шырпыга чыгып киткән. Ә бу юньсез Шарик эсседә әлсерәп йөргән жиреннән тоткан да ачык ишектән кереп, мичнен түренә үк барып яткан. Бу хакта бихәбәр әнисе коры утынга ут төртеп жибәрә һәм китеп тә өлгерми, йоны көя башлаган эт чинап, мичтән атылып чыга. Моны күреп әнисе: «Жен бар, жен бар!»—дип, куркуыннан мунчадан чыгып йөгерә. Әле ярый ишек алдында этиләре йөргән чак була, иске бишмәт каплап, Шарикнын утын сүндерә. Ярый әле сүндереп өлгерә, авыртуга чыдый алмыйча, Шарик шунда печәнлеккә-мазарга менсә, шартлап торган кызу көндә ихата-кура янып көлгә әйләнер иде. Шул вакыйгадан сон Шарикка Пожарник дигән кушамат тагыла һәм мажара эзләүче эт шактый вакыт йоны өтелгән көе йөри.

Шарик куанды дип кенә, монда көн уздырып булмас, кая барырга, кемнән сорарга? Килгән-киткән хатлар почта аша уза, бәлки анда кереп карагадыр? Әйе, әйе, анда керергә! Айчибәр хатта ничек язган иде әле, почтада армиядән кайткан Зәңгәрәй исемле егет эшли башлады дипме? Башка эш чыгара алмасам, Зәңгәрәйне күреп булса да китәрмен, нindirәк егет икән.

Почтаның ачык чагына туры килдем. Мин барып кергән бүлмәдә элемтәчеләр киеменнән бер яшь егет утыра һәм алдына куелган кәгазьләргә карап, шалт-шолт чут төймәсен тарта. Бүлмәгә электр плитәсе өстенә куелган савыттан сургуч исе таралган. Гаҗәп, безнең якта элемтә бүлекләрендә гел хатын-кыз, аның да өлкән яшьтәгеләре эшли иде. Ә монда әле генә армиядән кайткан әзмәвердәй егет утыра һәм үзен зур начальникка саный кебек.

Керүен кердем, хәзер үземне кем дип таныштырырга? Ничек сүз башларга белми аптырабрак торганда, егет мине искәртеп алды һәм кәгазьләрен чут белән бастырып куйды да елмаеп:

—Тыңнаем, сүләгез, н: йомыш?—диде.

Әле мин һаман ничек сүз башлыйсын хәл итеп өлгермәгән идем, шуңа күрә тотлыга-тотлыга алдашырга тотындым:

—Гафу итегез, ы-ы, беләсезме, теге, ни, ыһым, миңа, ни, Айчибәрнең, теге ни, адресы кирәк иде,—дип, авыз эченнән ботка пешердем.—Өйләрендә, ыһым, кеше юк икән. Ни, урамда берәү почтага кереп сорарга, ыһым, киңәш итте.

Букадәр мәгънәсез сүзләремне ишеткәч, елмаеп тынлый башлаган егет бөтенләй көлеп җибәрде:

—Менә хәзер кем икәнегезне әйтмәсәгез дә ярай. Сез—Казаннан Айцибәргә хат язуцы җегет-бала.

Тирләп чыккан маңгаемны ирексездән капшап алдым: кем икәнлегем анда язып куелмагандыр ич? Медпунктка кергәч, башкорт хатыны да исемемне һич ялгышусыз әйткән иде. Ярар, ул Айчибәрдә сурәтемне күргән, шуннан танысын, ди. Бусы кайдан белгән, Айчибәр кеше саен фотомны өләшеп йөрмәгәндер лабаса!

—Кем әйтте, кайдан белдегез?

—Анын өцен прокурор булу кәрәкмәй,—диде ялгышмавыннан канәгать егет.—Исемегез Рәшит кый. Танышаек...

—Сез Зәңгәрәй бит,—дип, мин дә өлгерлек күрсәттем.

Яшермим, Зәңгәрәй янына Айчибәрне тартып алырга җыенган көндәшләремнең берсе дип кергән идем, аның елмаюы шулкадәр дустанә иде ки, ихтыярыма каршы килеп булса да, кул бирдем. Хәзер инде бүлешерлек Айчибәр юк, без авыз ачып йөргән арада, ул башкага кияүгә чыгып өлгергән.

—Кайдан белден, дисен син?—Зәңгәрәй кинәт кенә «син»гә күчте.—Тагылда тагын кем казанца сүләсен! Өстәвенә Айцибәр белән кызыксынсын. Шуннан сон синен кемлеген турлысында тамцы да шигем калмады.

Әле генә елмаеп сөйләшкән Зәңгәрәй кинәт җитдиләнде, тәрәзәгә табан борылып, тынып калды. Ләкин бу тынлык озакка бармады, ул, борылып, сүзен дәвам итте:

—Синен каршында гаебем бар минем, Рәшит, гафу сораем...

—?..

—Солдаттан кайтып төштем кый. Курганга әптәйләргә кереп тормаган булсам, сез киткәнце кайтып өлгерәсе икәнмен дә бит... Кыскасы, сез киткәннен икенце көнендә кайттым. Туганнар янында рәхәт рәхәтен, тик көнел клубка, яшьләр арасына тарта. Цыгып киттем. Анда җегет-балалар, кызлар клубны ду китерәләр. Кицә генә киткән Казан әртисләре турлы сүләйләр. Киткән цакта үзем цебеш цаклы гына идем кый, солдат шулпасы килеште, метр да сиксән булып кайттым. Үзен кай тарафларда хезмәт иттен?

—Булды инде—Балтыйк буенда да, Ерак Көнчыгышта да...

—Ә мин Байкал аръягында хезмәт иттем. Сагындырган иде. Сезнен якларда нимәцектер, безнен авылда солдаттан кайтуцыны сырып алалар. Мине дә ул кицне герой иттеләр кый: берсе шешә алып килде, икенцесе өенә цакыра. Эцкәле туры килде бераз. Өйдә дә тамакны аз-маз цылаткан идек. Үзен беләсен, эцкәц кыюлык арта. Минем авылга кайткан көнем, бәхетле көнем, кызлар озаткалы барасым килә. Кайсына сүз кушкалы? Ышансан ышан, ышанмасан ышанма, армиягә алынганцы, кызлар белән йөрүнен нимә икәнен дә белмәй идем. Күзем шунда озын толымнарын салындырып утырган бер кызга төште. Утыра ялгызы гына. Биергә цакырып карайлар, цыкмай. Сизәсендер инде кем турлысында сүз барганын. Мин аны таныем да, танымаем да сыман. Жегет балалардан сораем кем кызы дип. Рәхимжан дәдәй белән Зылак әптәйнен кызы диләр. Шуннан гына исемә төште. Айцибәр ул дүртенце класстан сон авылда укымады, Кубасовода, Мехонда урыцса укыды. Шуна күрә авылда бик күренмәде дә. Аннан сон анын болай цибәр булып үсәсен кем белсен. Белсәм, йөрисе юлларына гөл булып үсеп цыгар идем, диләрме әле. Сораем малайлардан жегете бармы, дип. Жук, диләр, кырагай, берәүне дә жакын китермәй, диләр. Алайса, дим, кыз абзагызныкы.

Армиядә цакта увольнениегә цыккац, урыс бицәләре бераз сөйләшкәле өйрәткәннәр иде. Киттем Айцибәр янына. Бөтә шартын китереп, биергә дә цакырдым. Цыкты, карышмады. Кайтуым белән тәбрик тә итте. Киц буе бергә биедек. Озата цыккац, әйтә бу, Зәнгәрәй дәдәй, озатып жөрмә, минем жегетем бар, ди. Кем, дип сораем. Син аны белмәйсен, Казан жак жегет-баласы, ди. Солдаттан кайткан көнен булганга гына синен белән биедем, ди.

Кызларнын ялындыра торган гадәте барлыгын ишеткән бар иде, Айцибәр дә кылана гына торгандыр дип, анын саен әрсезләнәм. Әрсезләнәм дигәц тә, син Рәшит, әллә нимә уйлама, ул кит дисә дә китмәенцә, өйләренә кадәр озата бардым. Шул гына. Кырагайлыгы хак икән, күпме озатып, бер үптермәде дә.

Зәнгәрәй көрсенеп, монсу елмайды. Шул вакытта мин көндәшем булырга жыенган бу эчкерсез егетне хәтта бераз кызганып та куйдым. Ана караганда мин, уйлап карасан, күпкә бәхетлерәк икәнмен бит. Айчибәрнен кайнар сулышын, эреп бетә язган иреннәренен тәмен гомердә онытасым юк.

Кара каенга кагылдым,
Кайгыларым күбәйде.

Тфү, тагын кара каен искә төште, тагын сагыш, тагын парә-парә телгәләнү!

Зәнгәрәй сүзен дәвам итте:

—Әйе, кыргыйлыгы узар, арабыз якынаер дигән өмет белән Айцибәрне авылда цакта һәр киц озаттым. Булмады. Гафу ит, Рәшит, менә шул цакта синен көн саен диярлек килеп торган хатларынны да Айцибәргә тапшырмадым мин.

Әһә, менә кайда югалган икән минем хатлар!

Түзмәдем, үрелеп Зәнгәрәйнен якасыннан эләктереп алдым:

—Кабәхәт!

Әллә сон тешен кояргамы? Почтада эшлим дигәч тә, Алланын кашка тәкәсе түгел бит ул. Беркем дә юк чак. Ләкин Зәнгәрәйнен керфеген дә селкетмичә күзләремә туп-туры карап торуын күргәч, сугарга күтәрелгән кулым кире төште.

—Тыныцлангалы өцен кәрәк булса, сук, Рәшит. Бәлки мин дә жавапсыз калмам. Көцекнен оясында көцле икәнен онытма. Икебез дә цырайларыбызны кара яндырып йөрербез. Матур булмас кый. Тик онытма, үзем әйтмәсәм, хатларынны биру-бирмәвемне белмәй кала иден бит кый.

Әллә бу Себер егетенен тавышында гипнозы бар инде. Кинәт

кабынган ачу ялкыны үзеннән-үзе сүнде.

—Хатларынны ацып укыган дип уйласан, ялгышасын. Укымадым да, Айцибәргә дә тапшырмадым. Шайтан коткысына биреллдем, диләрме әле? Барыбер файдасы тимәде. Менә алар. Почта работнигы алай иткәле тиеш түгел иде, анысын беләм. Ацулансан, ацулан, син хаклы.

Зәнгәрәй сейфын ачты һәм бер көлтә хат сөйрәп чыгарды. Җәйге каникулда йөрәк җылымны кушып язган хатларым. Аларда бит минем ташып түгелергә торган хисләрем иде. Шуларны тапшырмый калырга ничек кулы барган аның?! Ни эшләтергә Зәнгәрәйне моның өчен? Тагын ярсуым кузгалды...

Зәнгәрәй сүзен дәвам итте:

—Аннан Айцибәр Әлмән районына эшкә китте. Авылга шуннан соң ике генә тапкыр кайтты, анда да кицен клубка цыкмады. Кызлар аша цакыртып бактым, барыбер цыкмады. Ирексезләп яраттырып булмай кый. Февраль азакларында кияүгә цыгу хәбәрен ирештерделәр. Кияве килеп алды. Амбирак әйтеп озатты Тагыл халкы. Айцибәрне менә шунда сонгы тапкыр күрдем. Нигәдер, артык кәефле күренмәде. Минә генә шулай тоелдымы исә... Ярай, Рәшит, буласы булган, тузасы цабата тузган. Тик анламаем, нимишләп сине ташлап башка жегеткә цыкты икән? Сине жарата иде кый!

Сәбәбен белсәм дә, аны Зәнгәрәйгә әйтеп торасым килмәде. Үзе дә сизенде, ахры, кабатлап сорамады.

—Ә-ә, онытып торам кый, синен сонгы язган хатын да миндә кый. Анысы Айцибәр кияүгә цыгып, авылдан бөтенләйгә киткәц килде. Башта Зылак әптәйгә биримме әллә дигән идем, йә Айцибәрнен иренә барып эләгер дип, кире уйладым.

Зәнгәрәй янәдән сейфын актарырга кереште һәм тагын бер конверт тартып чыгарды.

—Таныйсынмы?

Танымыйча соң!

—Зәнгәрәй, Айчибәр әниләренә хат язадыр ич?

—Яза, өц хаты килде.

—Кай тирәләрдән яза?

Зәнгәрәй тиле түгел, минем ник мондый сорау бирүемне шунда ук төшенеп алды.

—Сорама, Рәшит, Әйтмәем. Уйлап кара: синә нимәгә ул хәзер? Киселәсе киселгән кый!

—Зәнгәрәй, дустым бул, бир адресын, син аны беләсең!

—Әйттем кый, Рәшит, сорама, дип. Мәхәббәтнен күзе сукыр, диләр, йә берәр ахмаклык эшләп ташларсын.

Әйе шул, Зәнгәрәй дөрес әйтә: хәзер хат язу түгел, утырып еласаң да, вакыйганы үзгәртә алмыйсың. Хәтта эзләп янына баруның да файдасы юк... Ник ул бер тәндәге акыл белән хис бер-берсенә буйсынмый икән?

Хатларымны кесәмә салып, китәргә кузгалган идем, Зәнгәрәйнен:

—Рәшит, ашыкма—дигән әмерен ишетеп туктап калдым.

Зәнгәрәй почта ишеген эчтән бикләде һәм аптырап басып торган жиремнән өстәл янына тагын бер урындык куеп, ирексездән диярлек шунда китереп утыртты.

—Беренце оцрашуыбыз, бүтән күрешәбезме, жукмы, белмәем. Күрәм, кәефен бик шәптән түгел, арыгансындыр да, әллә сон берәр «Шадрин малаен» урталайга сындыраекмы?

Миңа барыбер иде. Хуплап та, каршы килеп тә сүз әйтмәдем, бүкән кебек утыра бирдем.

Өстәл тартмасын ачып, Зәнгәрәй аннан башланмаган бер шешә аракы һәм икмәк телемнәре чыгарды, мин бала вакытта гына күргән ат казылыгы куйды. Стаканнарны ашыкмыйча гына кәгазь белән сөрткәч, шешәнең ак яулыгын казык теше белән бик тиз ачты һәм аракы агызды.

—Хәзер цай да куеп жибәрәм.

Почмакта утырган кисмәктән чәйнүккә су агызып, Зәнгәрәй аны плиткә өстенә утыртты. Мин дә Айчибәргә күчтәнәчкә алып килеп тә кире кайтып бара торган (бер өлешен башкорт түтинең балаларына калдырдым) тәм-томнарымны өстәлгә тездем.

—Әйдә, Рәшит, берне тотаек. Акланып әйтүем түгел, ләкин анла: Айцибәр белән арагызнын бозылуына мин сәбәпце түгел. Айцибәрне рәнжетмәдем, зыян-зәүрат салмадым. Ә көнеленә яткан кызга һәр жегет-баланын сүз кушарга хакы бардыр дип уйлаем. Эцәек. Водка—есть витамин, сказал Хо Ши Мин; аракы эчсән, жомахка керерсен, дип әйткән Ким Ир Сен.

Кемдер ишекне шакылдатты. Зәнгәрәй бармагын иренен тидерде. Шаулама, янәсе. Без тынып калдык. Шаку тагын бер-ике тапкыр кабатланды да аяк тавышларының ерагайганы ишетелде. Зәнгәрәй тәрәзә янына килеп, пәрдә ярыгыннан карады.

—Гайжамал икән,—диде ул.—Ирдән кайтканына ай да юк, дәртенә цыдаша алмай. Сыер сава үзе, кеше юк цакта фермадан кайтышлый да сугылып цыга.

—Ник?

Зәнгәрәй шаркылдап көлеп жибәрде. Шунда гына үземнең ахмак сорау бирүемне аңладым.

—Көлдереп үтерәсен кый, Рәшит. Бу Казан жегетләре барысы да синен төсле беркатлымы? Ирдән кайткан бицә бер йомышсыз нимә дип керсен инде жегет жанына...

Аракы башка китте. Ят ризык дип, казыллыкка күбрәк үреләм. Ул авызга керүгә, эреп китә. Бабайлар тәмен белгән шул казылыкнын, болай да ашаганнар, юлга да ала торган булганнар.

—Аракы ут итә, дип әйткән Хрущев Никита.—Зәнгәрәй, шулай сөйләнә-сөйләнә, стакан төбенә тагын тамызды.

Аракыны дәүләт башлыклары исеменә ябыштырып болай сөйләгәнне ишеткәнем юк иде әле минем.

—Кайдан аласың мондый каламбурларны?—дип сорамый түзмәдем.

—Һи, бар инде ул бездә маллар!—Күренеп тора, Зәнгәрәй минем ачыла башлавыма ихлас сөенә иде. Үзем аңа сукмаганыма куанып утырам. Себер егете белән сугышып кына, Айчибәрне кире кайтарып булса икән!

Чәкештергәч, Зәнгәрәй үзенекен йотып куйды. Минем әле һаман кулымда тотып торуымны күргәч, чираттагы афоризмын ыргытты:

—Почему не пьешь ты то, сказал Иосиф Броз Тито. Эц, яманнан ярты кашык калдырма.

Сөйләшә-сөйләшә эчә торгач, әкренләп без бу шешәне төпләдек. Бүтән эчәсем килмәсә дә, Зәнгәрәйнең сый-хөрмәтен генә ашап-эчеп утыру намусыма тия.

—Зәнгәрәй, мин тиз генә чыгып керим әле,—дидем, урынымнан кузгалып.

—Нимәгә? Кецки йомышын кыстаймы әллә?

—Юк ла...

—Сон?

—Кибеткә барып киләм.

—Водку пить надо в меру, сказал Жавахарлал Неру. Житте кый, бүтән эцмәйсен кый! Минә дә житте. Цай эцәек. Хәзер районнан поцта да килгәле тиеш.

Чәй эчкәннән сон, Зәнгәрәй белән, күптәнге жан дуслар кебек, кул биреп бик жылы аерылыштык.

Минем инде Тагылда бер эшем дә калмаган иде. Дөресрәге, башта ук юк иде ул эш. Бары тик күңел ярсуына түзә алмыйча гына килдем ләбаса. Килдем, күрдем, белдем. Хәзер китү ягын карарга кирәк. Ләкин күл буена төшмичә, Айчибәр белән бергә йөргән жирләрне күрмичә китә аламмы сон?!

Әле май башы гына шул, күл өстендәге боз да эреп бетмәгән.

Талгын җилдә камышлар әкрен генә шаулаша. Узган җәйдә без күргән яшеллек, ямь юк иде әле күлдә.

Күл буйлап атлый торгач, үзем дә сизмәстән кара каен янына килеп чыкканмын. Башта танымый тордым. Пар каен иде бит мин күргәндә. Кара булса да матурлар, мәhабәтләр иде. Ә хәзер әнә берсе авып ята. Айчибәр яшен суккан дигән иде. Тузы кара булса да, эче нәкъ ак каенныкы төсендә икән. Яшен суккан җире генә кара көйгән.

Кагылдым кара каенга,
Кайгыларым кубәйде.

Юк, мин аңа бүтән кагылмыйм инде. Әллә чыннан да шушы каен сәбәпче булдымы соң ахыргы берничә ай эчендә күргән кайгы-хәсрәтләремә? Әткәйнең җаны фани дөньядан очты, үзем чак кына hәлак булмый калдым. Айчибәр ятлар кочагында, ә мәхәббәт йолдызлар аръягындагы томанлыкка болыт булып таралган. Тик минем сөю-сәгадәтнең барлыгына бик, би-ик ышанасым килә. Кешеләр, ишетәсезме!? Мәхәббәт бар ул, бар, Айчибәр! Минем бу ачыргаланып раслаган авазым сиңа бер барып ирешми калмас.

Кара каеннан ерак түгел агач төбенә утырдым да, иң кадерле уенчыгын суга агызган бала төсле, үксеп елап җибәрдем. Бу минутта мин үземне кемнәрдер бик нык җәберләгән кебек, бик бәхетсез хис иттем. Айчибәрне дә кызгандым. Шушы каен төбендә үлемнәрен тапкан Әбелгәрәй белән Калбиҗамалны фаҗигасен дә искә төшердем. Күз яшьләрем эрергә өлгермәгән ак кар өстенә агып төшә торды, эзсез югала торды.

Елау кешене тынычландыра дигәннәр иде, хак икән. Күпмедер вакыттан соң, җаным җиңеләеп калды hәм, үз йомшаклыгымнан оялып, кем дә булса күргәләгәнче кузгалып, тиз-тиз кайту юлына атладым.

Хуш бул, Тагыл! Синең белән бу икенче hәм соңгы тапкыр хушлашуыбыздыр, бәлки.

Карадан кара каурый
Карлыгач канатында.
Күрешүләр кирәкмәгән
Кушкаен кабатында.

Күз өстендә кара кашын,
Карачы күлеп кенә.
Кайгыларымнан котылам
Күлләргә кереп кенә.

Кайгы-сагышларым зур булса да, мин инде бу күлгә кермәм. Бозлары эреп бетмәгән hәм суы салкын булган өчен генә түгел, Тагыл ул—Айчибәр белән икебез бергә чакта гына керә торган изге күл, мәхәббәтебез күле. Ялгызыма исә җәрәхәтле җаным, яралы йөрәгемне дәвалап, алгы көннәргә—назлы вә давыллы көннәренә—әзерләргә кирәк.

Бу яра-җәрәхәтләрне ничек дәваларга, әрнүләрдән ничек котылырга? Әле бит иртәгә ахырзаман түгел, минем өчен тормыш әле башланмаган диярлек. Алдагы көннең сынаулы назлары, шомлы давыллары ымсындырып та, өркетеп тә тора.

Атлый торгач, авыл читенә килеп җиткәнмен. Авыл белән зират арасында моңа кадәр могҗиза белән генә җимерелеп төшми калган җил тегермәне бар. Шуның яныннан узганда, сынган канатларына кунаклаган кара каргаларга игътибар иттем. Аларның бүтән беркемдә гаме юк, карр-карр килүләрен, янәшәдәге зират тупылларына оя ясауларын беләләр. Бер уйласаң, ул каргалар миңа hәм дөньядагы миллионнарча адәм балаларына караганда күп тапкырлар бәхетлерәк бит. Аларның табигать тарафыннан геннарына салынган кодлары адәм балаларының катлаулы

язмышларыннан күпкә ачыграк, барысы да билгеле: оя корасы, күкәй саласы, бала чыгарасы, җәй чыкканда ачык авыз хуҗаларның каз-үрдәк бибиләре белән сыйланасы... Йөз мең ел элек тә шулай булган, киләчәктә дә, әгәр карга дигән зат саклана икән, шулай булачак. Бусы—бәхәссез. Ә минем алда тоташ билгесезлек. Һәм ул билгесезлек гомер буе мине озата барачак...

Соңгы тапкыр Тагылга күз салдым да язгы яшәү авазлары белән тулы урман юлыннан шул билгесезлеккә табан атлап китеп бардым.

## Соңгы сүз

Бу вакыйгадан соң егерме еллар вакыт үткән иде. Өлкә гәзитләренең берсеннән үземә адресланган хат килеп төште. Конвертны әлләни исем китми генә ачтым, чөнки андый хатларны алган бар иде. Ни гаҗәп, конверт эчендә тагын бер конверт белән бер бит кәгазьдә хат бар иде. Анысы редакция хезмәткәреннән. Башта шунысын укыдым.

*«Рәшит абый, Сезгә тапшыруларын сорап, безгә бер хат килде. Адресыгызны белми икән, тапшыруыбызны бик үтенеп сораган. Ул хатны ачып тормадык, шул көе генә Сезгә җибәрәбез. Бәлки кирәкле-кызыклы хаттыр.*

*Сезгә исәнлек-саулык телибез.»*

Конвертны ачам дигәндә генә хәрефләрнең язылу рәвешенә игътибар иттем. Тукта, һәр хәрефеннән боҗралар ясап болай кем яза иде соң әле? Кинәт йөрәктә татлы сулкылдау кузгалды. Күңелем нидер сизенеп, сулышым кысылды, йөрәгем күкрәк читлеген дөп-дөп бәрә башлады. Хат, әйтерсең, кулымны пешерә, кабалана-кабалана, конвертны ачарга керештем. Әйе, ул Аңардан—Айчибәрдән иде.

*«Рәшит!*

*Кемнән-кемнән, син, әлбәттә, миннән хат көтмәгән идең. Тагыл кызы Айчибәрне хәтереңә төшерәле. Бөтенләй оныткансыңдыр дип уйламыйм, чөнки син оныта торган кешегә ошамаган идең.*

*Хат язуымның ике сәбәбе бар.*

*Беренчесе—Тагылга кунакка кайткач, Казанда чыккан газеталарны карап утыра идем, синең сурәтең белән бит тулы шигырьләреңә очрадым. Шагыйрь булгансың кый. Молодец! Синең белән кайчандыр таныш булуыма горурланып та куйдым әле. Мәхәббәт турлы язган шигырьләрең бигрәк тә ошады. Мин алыста—Сахалин өлкәсендә яшәем—татарча газета-журналлар алдырмыйм. Моннан кайткач, Аллаһы боерса, язылачакмын.*

*Кыскача гына үзем турлы берничә сүз. Теге вакытта килим диеп тә килми калгач, минем өчен җир белән күк тоташты һәм дөньяда яшәүнең кызыгы бетте. Ахры, нык яраткан булганмындыр сине. Әллә үземә кул салыймы дигән чакларым да булды. Күрәсең, ниндәен койты уйлар башыма килде. Юк, кул салмадым, ә синнән, бөтә дөньядан үч алгалы уйладым. Әнә, син шулаймы, син шулай икән, әллә минем исем китәме?! Үч алу тойгысы шулкадәр көчле иде ул чакта, чөнки мин сине ул телеграмманы шаяртып кына биргәнсең дип уйладым, нинди дә булса җитди сәбәп чыгып, килә алмау ихтималы турлы башыма да китерә алмадым. Әле бүгенгә кадәр чын сәбәбен белмәем.*

*Хәтерләйсеңме, хатымда Азамат исемле җегет-бала турлысында язган идем? Куып-куып карасам да, ул бит арттан йөрүеннән туктамады. Синә үч итеп, ана озаткалы рөхсәт итә башладым. Ә беркөнне ул куна калды һәм мине көч белән үзеңеке итте. Минә инде кияүгә чыгудан бүтән чара калмады.*

*Рәшит, гафу ит мин тиленә. Боларның, ихтимал, синең өчен кызыгы да юктыр һәм мондый ук интим нечкәлекләрне язгалы тиеш тә булмагандыр.*

*Хәтерләйсеңме Тагыл күле арьягындагы пар кушкаенны? Син шул каенга кагылуыңны әйткәч, күңелем шул вакытта ук бергә булмасыбызны сизенгән иде, хак шулай булып чыкты да.*

*Азамат турлысында тагын берниҗә сүз. Авылда практикасы тәмамлануга, ул мине үз авылларына кайтарып, кайнәмдә калдырды. Үзе диплом яклагалы Курганга китте. Соныннан аны Сахалин өлкәсенә эшкә билгеләделәр. Анда барып төшү белән озак та үтми өстемнән йөри башлады. Үзе гүләйт иткәле җаратканн кешене көнче була, диләр кый, хак дөрес, Азамат та көнләшеп җанымны ашады. Ипекәй тотып ант итәм, хыянәт итү дигән уйнын башыма ялгыш та кереп караганы булмады. Җәнҗал цыгарып кына калса бер хәл, бала хакына бәлки түзгәле дә булыр иде, кул күтәрүдән дә тайцанмады. Бер тапкырында баш миемне селкеткәнце тукмады, терелгәц, анын янына бүтән кайтмадым. Район үзәгендә больницага эшкә урнаштым. Сонра, ялгыз биҗә дип ир-атлар бик бәйләнә башлагац, хатыны авариядә үлгән бер урыска кияүгә цыктым. Цит җирдә татарны кайдан табасын. Николай койты кеше түгел иде үзе, урыны оҗмахта булсын—өц ел элек үпкә рагыннан гүргә керде.*

*Ләкин, Рәшит, нимәцек кенә яхшы кеше булмасын, урыс—урыс инде ул. Анын поцмакка карап цукынуларын күргәц, җаннарым актарыла иде. Шуна күрә кызым-кузыем, йөрәк парәм Гөлнара, ана инде җегерме җәш тулды, берәр урыска кияүгә цыкканцы, татарлар күбрәк яшәй торган җиргә күцеп кайткалы кәрәк. Ләкин Тагылга төгел. Кайцандыр син белгән халык анда хәзер койты якка нык үзгәрде. Барысы да шул эцке аркасында. Ә монда урыс та хохол, татарлардан без генә. Әле кая кайтасын хәл итмәдек. Без Гөлнара белән икәү генә, Николайдан бала табарга теләмәдем.*

*Авылга бер кайтуымда Зәнгәрәй дәдәй синен, Тагылга килеп, минем турлы сораштырганынны әйткән иде... Хәзер үкенүдән файда юк, язмыш елгасы, терсәгенне тешләсән дә, кирегә акмай, үткәнне кире кайтарып булмай.*

*Рәшит!*

*Хат язуымнын икенце сәбәбе шул—син бит язуцы кеше. Яз шушы турлы бер повесть. Минем хатам, үз бәхетемә үзем аяк цалуым турлысында яз, кешеләрне мәхәббәтнен барлыгына ышандыр. Хәер, нимәгә өйрәтәм, син бит язуцы кеше—үзен белерсен нимәцек кирәк икәнен.*

*Синен тормышын турлы берни белмәем, ләкин гаилән бардыр дип уйлаем. Синә кияүгә цыккан кеше ялгыш та бәхетсез була алмас, цөнки син, өц-дүрт көн генә оцрашып-күрешеп калсак та, еллар узгац анладым—ярым-йорты гына сөя торган кеше түгелсен. Адресымны күрсәтмәем, йә хат яза башларсын да моны бицән дөрес анламас. Син инде, мин әйткәнцә, бар кешегә гыйбрәт булырдай әсәр яз. Синекен димим, минем ялгышларымны бүтәннәр кабатламасын иде.*

*Тулы бәхетемне тапмасам да, мин Ходайга кайцандыр синен белән оцраштырганы, сонарып булса да олы мәхәббәт барлыгына ышандырганы өцен рәхмәтлемен. Шушы хис цит җирләрдә берсе артыннан берсе сузылган көннәремнен сорылыгын җиңелрәк кицерергә ярдәм итә.*

*Күрәсенме, Рәшит, өц-дүрт җөмлә язгалы утырдым да су буйлы язганымны сизмәй дә калганмын. Гафу ит буталцык, озын хатым белән кыйммәтле вакытынны алган өцен. Язуцынын вакыты болай да аздыр инде анын. Бүтән язмам, курыкма.*

*Тагыл кызы Айцибәр.»*

Айчибәрнең хаты мине бик дулкынландырды. Аның теләген мин васыять урынына кабул иттем һәм, хөрмәтле укучым, шушы кыйссамны сезнең хөкемгә тапшырам.

*Әлмәт шәһәре*
*1998 ел.*

⁂

## ШИГЪРИЯТ



**Лена Шагыйрьҗан**

### Әй, гомерләр...

*Элегия*

Яшьтәшләр олыгаеп, картаеп баралар...
Очтылар оядан оныклар вә балалар...
Елгалар саекты, түмгәкләр калыкты,
Үзгәрде без торган авыллар, калалар...

Көн саен түгел дә—шом сала күңелгә:
Берәмләп-сәрәмләп китәләр танышлар.
Җырлар да елдан-ел яңгырый бүтәнчә,
Үзгәрә тавышлар, күз-караш, багышлар...

Карыйм да дустыма, үземне күрәм мин,
Көзгедән күргән күк: искерәм, беләм мин...
Уенчак күңелем сүрелә көннән-көн,
Бик сирәк шаярам, бик сирәк көләм мин...

Азаеп барамы уенда кызыклар?.
Тик аның каравы—муенда сызыклар..
Карусель туктаусыз, карусыз әйләнә,
Тарая бара күк, тирә-юнь, әйләнә...

Минем дә бар иде чәчәкләр җыйганым,
Иң татлы хисләрнең хуш исен тойганым.
Аздырмы тапканым, күптерме—җуйганым,
Бал-җимеш тәмнәрен татыплар туймадым.

Минем дә бар иде өзелеп сөйгәнем,
Сызылып эчемнән, янганым-көйгәнем.
Күз нурым түгелде, очкыны сүрелде,
Күңелем моң белән күмелде...

## Матәм җилләре

*Мәрхүм Нил абыем истәлегенә*

Бу җилләре тагын ник котыра,
Әллә соң бу минем үчле җанмы?
Әллә канатлары каерылган
Рухым соңгы тапкыр талпынамы?.

Бу җилләрдә—минем җан ачуым,
Үзәгемнең шартлап өзелгәне.
Уласам да ятып—әҗәл өчен
Ул бит фәкать—черки безелдәве...

Бу җилләрдә—минем газраилгә
Ябырылып яуган каргышларым.
Әллә инде күңел манарам да
Кыйшаеп шул җилдә авышканмы?

Карт тирәкләр кебек сыгылып сыкрыйм,
Бу иңемдә—потлап-потлап ташлар.
Нәфрәт-газапларның тамырларын
Бәлки җилләр төптән йолкып ташлар?..

Бу тормыштан үлем тәме килә,
Бу җилләргә үлем шомы сеңгән.
Бу һавадан үлем исе аңкый.
Бу җанымда яшәү дәрте сүнгән...

Әллә соң бу кансыз газраилнең
Котыра-котыра бәйрәм итүеме?
Әллә—тәннән айрылган бер җанның
Кубарылып җирдән китүеме?

Түзәр микән йөрәк, ярылмыйча,
Үтәр микән кара кайгыларым?!
Җитәр микән тотып җигәр көннәр
Котырынган җилнең айгырларын?!

Җигүен бер анысы җигәрмен дә,
Җиңеп булмас әҗәл афәтләрен...
Учларыма батып кергән инде
Тырнак очларымнан—нәфрәтләрем...

Канга—канмы? Әллә Җанга—җанмы?..
Күпме тора җирдә хәзер үлем?!
Чөмертәсе иде вәхшиләрдән
Ташып аккан кан-яшь, газап күлен!

## Гаҗизлектән

Бик тә иске, бик тә мескен
Җир шары.
Олагырга мәллә моннан
Бер яры?..
Искелеге—хакыйкатькә
Ялганган.
Мескенлеге—«дөрес» ясау
Ялганнан...
Җир читенә түгел, Җирдән
Качсаң да,

Кайтып, Җирне өр-яңадан
Ачсаң да,—
Алдар Ялган, башны ташка
Орсаң да.
Үзе белән никахлашып
Торсаң да...
Инде гарык булдым, дисәң
Ялганнан,
Хыяллансаң котылырга
Яманнан,—
Иң әүвәле—үз-үзеңнән
Чыгып кач!
Күгәреп беткән дөньяңның
Күген ач!..
Утырма син гел ояда,
Оема!
Төкер дә кит череп-кипкән
Коега...
Гап-гади матдәгә җисемең
Әүрелсен.—
Әүрелсен дә, таш кыяга
Бәрелсен...
Бәрелсен дә, челпәрәмә
Уалсын.
Бетсен бар да! Уалсын да,
Югалсын!
Бетсен Чынлык шул мизгелдә!
Берьюлы—
Бетсен Ялган! Җуелсыннар
Бер булып...
Кирәкми дә аерып тору
Аларны.
Шуңардан бит күрдек бөтен
Зарарны.
Тоташсыннар, берексеннәр
Үзара.
Маташмыйча берсен-берсе
Узарга...
Җир ярылса—калыр барыбер
Ялганы.
Ярамаган тагын безгә
Калганы...
Көн итәргә җайлы булыр
Шыр ялган.
Чынлык эзләп, күпмебез ба-
шын ярган...
Кайда кеше—шунда Чынлык
Вә Ялган.
Икесе дә бер үк канга
Буялган...

## Ял итсен дулкыннарым...

Агып барам агымда,
Маяк та юк алдымда.
Кем юксыныр, кем эзләр?—
Табыл да, югал монда...

Гаепләмә, апаем,
Гаҗәпләнмә, агаем!..
Авыр юлда арыдым—
Тыныч кына агаем?..

Йөзен каршы—агымга,
Бетте бөтен көчләрем.
Дулкыннарым ял итсен,
Талды ярсу хисләрем...

Килә инде яшисем
Үз хәлем белеп кенә.
Су өстендә тирбәлгән
Төнбоек кебек кенә...

Гаҗәпләнмә, апаем,
Гаепләмә, агаем.
Туйдым пәри туеннан—
Салмак кына агаем?..

Хәтта «дөнья бетсә дә»,
Агыймчы үз җаема,
Агыйм үз уңаема,—
Тынгы кирәк җаныма...

Сүиде мәллә «либидо»?
Түгәрәкләнде хәят.
Шушы бөек халәтне
Яулап алдым, ниһаять...

## Иләһи мәҗүсилек

Үзем иләһи булмакчы,
Үзем һаман мәҗүси:
Айга карап теләк телим—
Күктә—йолдыз мәҗлесе...

Күзем—Айда, үзем кайда?—
Моңга батып, онытылам.
Бер ашкынам йолдызларга,
Бер Аллаһка омтылам.

Мәҗүсидер мин, билләһи,
Чишмә-Суга табынам.
Адашам тылсым кырында,
Югалам да, табылам.

Һәр агачның, һәр чәчәкнең
Тыңлыйм дога кылганын...
Сәлам бирәм Иясенә
Һәрбер күлнең, елганың...

---

**Либидо** - фрейдизм термины: теләк көче мәгънәсенә.

Әле Җирдән, әле Күктән
Ялварып бәхет сорыйм.
Бер Аллага инансам да,
Йолдыздан язмыш юрыйм...

Бисмилладан башласам да
Мең дә бер эшләремне,
Ышанам ырымнарына,
Юрыймын төшләремне...

Шәригатькә буйсынаыймны,
Әллә—Табигатькәме?..
Әллә... хакмы күрәзәче,
Фалчыларның әйткәне?...

Аллам бардыр, Аллам бердер.
Кояш та бит бер генә...
Илаһилык баскычыннан
Бер төшәм дә, бер менәм...

## Мәхәббәт турында

Бер син генә түгел инде
Мәхәббәттән куркып качкан...
Көлде күктән ялгыз Аем:
«Әй, тилекәй, серен ачкан...»

Тиңнәрсез тилмерде йөрәк,
Үз-ишсез өзелде үзәк.
Әллә дөнья күлмәгендә
Булдым инде сәер бизәк!

Мәхәббәт ул җан юлдашы:
Бер яшьлектә, бер картлыкта...
Елларны да, юлларны да
Санамый ул ераклыкка.

Гакыл белән хис көрәше
Бу дөньяда мәңге бакый...
Гакыл исә, исенә төшкәч,
Сөю тәрәзәсен шакый.

Боз тауларын эретерлек
Кайнар иде юкса хисем.
Бер җавап юк! Калмады һич
Кыл да кыймылдатыр көчем.

Мәхәббәт ул серле талант,
Гыйшык-мыйшык кына түгел.
Кыйшык-мыйшык йөрүләрдән
Җәберләнә генә күңел.

Кемнәр генә бетерер түләп
Чын Мәхәббәт, Сөю хакын?!
... Мәхәббәт хакында тагын
Нәрсә язсын ялгыз хатын?..

*1996-1998*



# Әнәс Исхаков

## ТАУЛАРГА ИЛТӘ БУ СУКМАК

*Төрле еллардан*

* * *

**Өем, өем таулар—**
**Таулар уртасында бер авыл.**
**Тау сукмагы Утыз Имәнине**
**Барысыннан да күбрәк белә ул.**
**Мин дә атлыйм гасыр сукмагыннан,**
**Тузгыган җыр сарыла колакка.**
**Ирекле җыр дала буйлап йөри;**
**Башын салмас түбән коллыкка.**
**Тау сукмагы...**
**Барам Имәнигә,**
**Юл урамый, таулар тирәли,**
**Гүя тау башында кютә мине**
**Яшел кәләпүштән Имәни.**

### Көзләр рәсеме

**Көзләр йөри,**
**Җилләр сискәндерә басуны,**
**Күк йөзләре сүрән...**
**Әллә моңсу, әллә ачулы.**

**Көзләр йөри,**
**Шәрәләнгән кырлар буйлатып.**
**Тузаннарны юа,**
**Уҗымнарда яңгыр уйнатып.**

**Көзләр йөри,**
**Хәзерләнгән кебек еракка.**
**Бөтенләйгә түгел,**
**Вакытлыча килгән кунакка.**

---

Әнәс Гатуф улы ИСХАКОВ (1945) — *шигырьләре моңа кадәр көндәлек матбугатта, күмәк китапларда басылды. Ә. Исхаков - Азнакай районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы.*

* * *

Төрле чагы була болытларның:
Агылганы, туктап калганы,
Тузаннарны җыеп узганы,
Күңелгә җыр булып тамганы.
Болытларга барам,
Болытларга агам,
Күңелемдә шундый тибрәнеш.
Болытлардан бозлар яуганда да,
Юк күңелдә сыкрау,
Юк әрнеш.
Әрләмә лә мине...
Бу җанымнан
«Өтер хаталар»ын эзләмә.
Кил янымa, онытылыйк әле
Болытларга охшаш бу мәлдә...
Онытылыйк,
Кояш күрми торсын,
Кайчак көтә күңел төннәрне.
Әй, бу тормыш болытларга урап
Сынамаган дисең кемнәрне...
Сынатмыйк ла,
Онытылыйк әле бу мәлне...

## Миләш

Юл аркылы үрелеп,
Ике миләш кушылган
(Юлым үтә шушыннан).
Кызыл ут тәлгәшләре...
Тибрәлә талгын җилгә.
Кыңгыраулар көенә
Моң тама сары җиргә.
Туйга җиккән дугадай
Бизәнгән чуклар тагып...
Миләшләр юлга багып
Төшәрләр төсле тамып.
Ут тәлгәшләрен кагып,
Сокланам, уйга калып.

## Син киткәч

Коймаларны санап буран йөри,
Төтенләнеп ярсып тирбәлә.
Ишегемне килеп дөбердәтә,
Гүя бәла якын тирәдә.
Мичтә соңгы кисәү сүнеп бара,
Кайнар күмер көлгә күмелде.
Күкрәгеңә куеп йөрәгемне,
Җылытасы килә күңелне.
Син кайдадыр, миннән ерак кебек,
Гайбәт йөри ике арада.
Якты дөнья гүя сүнеп бара,

Аклык төренгәндәй карага.
Ишегемне ачып чыгып киттең...
Юк, борылма инде, борылма!
Соңгы кисәү соңгы сүзен яза
Кайнар эз калдырып корымга.

* * *

Таулар сары, басу өсте
Әйтерсең кызган таба.
Көйдереп барча дөньясын
Кояш тамчысы ява.

Күкнең болытсыз гөмбәзе
Зәһәрле зәңгәр төстә.
Яңгырлар сорап табына
Кеше илаһи көчкә.

Дөньяларын дер селкетеп
Йөргән иде лә бәндә.
Нинди көчсез, нинди мескен
Адәми зат бу мәлдә.

Сыный кешене Табигать,
Түземлеме, юкмы син?
Җирдәге кипкән кылганмы?
Җәядәге укмы син?

* * *

Бәхетем миңа
Таң нурлары төсле тоела.
Саран төсе
Кагыла да китә уема.
Бәхет куам,
Шуңа, ахры, һәрчак юлда мин.
Ә бәхетем
Күренә дә, китә югалып.
Үргә менәм,
Ә ул инде күчеп өлгергән.
Төшсәм, бәхет—
Күтәп тора башка бер үрдән.

## Саубуллашу

Уйна сызып, җырла өзеп,
Язларым бара узып.
Яшьлегем кала өзелеп,
Кала ул кулын сузып.

Кырлар исе, кояш исе—
Беренче сөю хисем—
Калалар еллар артында,
Калалар, инде нишлим?!

Вакытлыча булган икән
Җитәкләшкән юлыбыз...
Аккош кебек ак парым бар—
Китәбез, сау булыгыз!

Карыйм әле үткәнемә
Талганчы ике күзем.
Йөрәгем кала шул якта,
Калалмасам да үзем.

## Болгар ташлары белән сөйләшү

Шәһәр эзләп килеп чыктым—
Каршылады чал кылган.
Таш шәһәрдән, таш нәкышьтән
Шушы хәрәбә калган.
Гөл сарайлар күмерләнеп
Көн-төн сыкрап янган.
Ташлар калган. (Аларны һич
Ташлап булмый дөньядан.)
Таш манара—торып калган
Кара манара булып,
Агармаган бу кара төс
Гасырлар күпме юып...
Бу урында шәһәр булган;
Ә хәзер таш та кылган.
Таш белән сөйләшеп йөрим,
Бер уй китми акылымнан:
Әллә шәһәр читтә калган—
Кергәнмен ялгыш юлдан?

... Матурлыкны каралтырга
Таш бәгырьләр табылган.

* * *


Дала! Чиксез дала,
Атлар чаба.
Кояш-җайдак
Атлар куып бара.
Янып, пешеп атлар чаба,
Киртәләрне ишеп юллар сала.
Уйга калып юл буенда кала картлар,
Ярсып үтә япь-яшь атлар.
Араларны үлчим,
Безгә җиткән ләбаса
Узып китәр чаклар.

* * *

Бу сүземнең башыдырмы,
Уйларым оча ерак.
Әллә бу тормыш бик матур,
Әллә соң кырысрак?
Озатып калам җырларымны
Гомерем урләренә.
Моңсызларга моң өләшеп
Керсен күңелләренә.
Көннәрем чаптар атымдай
Тын алмый чаба, чаба.
Юллары ерак, сагышы
Йөрәктә кала, кала.
Бу сүземнең башыдырмы...
Соңы була күрмәсен.
Күкрәгемдә җыр чаткысын
Язмышлар сүндермәсен



## «Идел» журналына—10 яшь



**Рашат Низами,**

«Идел» журналының баш мөхәррире

## ЯШЬЛЕК УРАМЫНА ЧАКЫРУ

Ун ел вакыт узып та киткән икән...

Әйе, «Идел» журналының чыга башлавына быел июль аенда ун ел тула. Тарих өчен бик тә кыска ара—мизгел генәдер бу, әмма журнал өчен көрәш тарихын, әлеге басманың татар яшьләре, туган тел һәм миллият өчен кыйммәте хакында уйлансак, шушы кыска гына арага мәгънәви яктан әллә ничаклы казанышлар, байлыклар кереп сыйган.

«Идел» журналы турында сөйләшәбез икән, иң элек аның туу тарихына азмы-күпме тукталып узмыйча мөмкин түгел.

«Идел»—1933 елны ябылган. «Колхоз яшьләре» исемле журналның варисы ул. Ватан сугышы беткәннән соң әлеге басманы торгызу өчен көрәш бара баруын. Әмма коммунистик-тоталитар режим татар яшьләре журналын яңадан терелтеп җибәрергә рөхсәт бирми. Ил җитәкчеләре эшчән-тырыш татарны Себергә «күчереп» утырту турында хыялланганда, кая инде аңа яшьләр журналы ачарга ирек бирү!

Һәркемнең исендәдер әле: алтмышынчы елларда яшьләр журналын ачу өчен көрәш аеруча кызып китте һәм татар милли азатлык хәрәкәтенең аерылгысыз бер өлешенә әверелде. Исемнәрен санап тормастан, гаделлек хакына шунысын әйтеп китик: бу изге көрәштә күп кенә журналистлар, язучыларыбыз, хөкүмәт һәм җәмәгать эшлеклеләре актив катнашты. Мең рәхмәт аларга!

Нәтиҗәдә, татар яшьләре хәятендә «Идел» дип исемләнгән яңь-яшь журнал барлыкка килде. Мәгълүм булганча, аның беренче саны 1989 елның июль аенда дөнья күрде. Халык һәм җәмәгатьчелек моны ифрат сөенеп, куанып кабул итте. Журналны, баш мөхәррир буларак, иң беренчеләрдән булып Римзил Вәлиев, аннары Фәиз Зөлкарнәй кебек танылган кешеләр, талантлы каләмдәшләребез җитәкләде.

«Идел» кыска гына вакыт эчендә яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә ихтирамын яулады дисәк, һич тә арттыру булмас. Чөнки яшьләр рухи-мәдәни тәҗрибә туплый, өлкәнрәкләр исә безне укыган саен азмы-күпме яшәреп китә. Яшьләр журналы дип аталса да, аның сәхифәләре ир-атлар, хатын-кызлар, әбиләр һәм бабайлар, абыйлар һәм апайлар, сеңлекәшләр, энекәшләр, киленнәр, кияүләр—кыскасы, һәр гаилә өчен кызыклы, мәгънәле, файдалы булсын дип тырышабыз.

«Идел»—татар һәм урыс телләрендә чыга. Аның колачын, тематикасын, юнәлешен кыскача дүрт сүз белән аңлатып буладыр: әдәбият, мәдәният, миллият,

заман. Анын битләрендә сезне күренекле шәхесләр, әдипләр, сәясәтчеләр, артистлар, бизнесменнар һәм дәүләт эшлеклеләре белән очрашулар да көтә.

«Идел», нигездә, Татарстан һәм анын кешеләре турында яза. Соңгы вакытларда Кукмара, Балтач, Зәй, Әгерже, Азнакай, Апас төбәкләренә багышланган махсус сәхифәләр дөнья күрде. Бу традицияне алга таба да дәвам итәргә ниятлибез.

Мәктәп һәм укытучылар өчен журналыбыз—әдәбият, сәнгать, тарих, туган як, экология, әхлак һәм милли гореф-гадәтләрне өйрәнүдә бай бер чыганак.

«Идел»—барыннан да бигрәк, әдәби журнал, әлбәттә. Анын битләрендә каләм ияләре иҗат иткән өр-яңа повесть һәм хикәяләр, шигырьләр, юморескалар укучыга тәкъдим ителә. Бу җәһәттән шунысын да әйтергә кирәк, журнал аякка басып килгәндә өлкән әдәби туганыбыз—«Казан утлары» журналынын ярдәмен тойды.

Кул тимәгән, мөлдерәмә килеш яңа дәвер—XXI гасыр алда көтеп тора безне. Мөстәкыйльлеген, дәүләтчелеген өр-яңадан торгызу өчен житди көрәш башлаган татар халкы бу яңа гасырга ни рәвешле килеп керер? Алга таба ул үзенең туган телен, менталитетын, интеллектуаль көчләрен саклап кала алырмы? Урыс империясе нишләр, кая таба барыр икән?.. Мондый сораулар безне дә нык уйландыра. Болар хакында без киләчәктә дә, һичшиксез, язып торачакбыз. Безгә алга таба да журнал битләрендә очрашулар насыйп булсын!

Сезне, милләттәшләребезне, «Идел» журналы тирәсенә—яшьлек урамына чакырабыз.

ТАТАРДА ДИССИДЕНТЛЫК

## Рәфикъ Юныс

# ӨЗЕЛГӘН СПЕКТАКЛЬ

*26 ел элек*
*Г. Камал исемендәге театр*
*бинасында «ЧП» булды.*
*Халык тулы залда буран уйнады.*

*Листовкалар бураны.*
*Листовкаларда*
*бер таләп куелган иде:*
*«Идел» журналы чыгарылсын!*

1968 елның 25 марты. Партер, ике кат балкон шыгрым тулы. Тамаша тиздән башланып китәчәк. Әмма залдагы шау-шу спектакль башланыр алдыннан була торган гадәти гөрелтеише генә түгел. Зал умарта күче кебек кайнап тора. Тамашачыларның һәркайсы, утырган, баскан йә барган килеш, кем белән дә булса сөйләшә. Монда бөтенесе дә бер-берсен белә. Чөнки тамашачылар сайлап чакырылган: театрда Татарстан язучыларының чираттагы VII съезды үтәчәк.

Димәк, залда утырган Марсель Сәлимҗановның булачак тамашага бер катышы да юк. Залдагыларның да бер өлеше үзләрен тамашачылар итеп түгел, ә бәлки татар мәдәнияте тарихында мөһим урын алачак олы мәҗлеснең катнашчылары яки хәтта каһарманнары итеп тоя. Кайберәүләр, әнә, «Ну, әйтәм фәләнгә!» «Ну, бу юлы бетерәм тегене!» дип, инде хәзер үк кыбырсып утыралар. Кайберләре исә, «Әйтергә микән, әйтмәскә микән?» дип, киләчәктә языласак җырның сүзләрен тәкърарлыйлар.

Әмма залдагыларның күбесе белә: аларны спектакль көтә. Биш елга бер була торган гап-гади спектакль. Анын сценарие-пьесасы язылган инде. Чыгыш ясаучылар исемлеге, докладларның, кабул ителәчәк карарларның текстлары,

идарәнең яңа исемлеге—болар күптән өлкә комитеты әһелләренең папкаларында ята. Кәгазьгә төшмәгән сценарийда хәтта булырга мөмкин «ЧП»лар да күздә тотыла. Берәрсенең, әйтик, трибунага салмыш килеш чыгуы бар. Карт язучылар «Мине син саттың!», «Юк, сатмадым!» дип сатулашырга мөмкиннәр. Зыян юк. Мондый «детальләр» спектакльгә чынлык төсмере генә өстәячәк. Гадәтенчә, Салих Баттал сүз сорар. Ипле генә сылтау табылмаса, бирергә туры киләчәк...

Менә кыңгырау чыңлады. Тамаша башланып китте.

Тарихи документка—«Социалистик Татарстан» гәҗитенең 1968 ел, 26 март санында бирелгән хәбәргә күз салыйк.

«Кичә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстан язучыларының VII съезды эшли башлады. Съездны кереш сүз белән әдәбиятыбызның өлкән вәкиле Гомәр Бәширов ачты. Бертавыштан КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы составындагы съездның почетлы президиумы сайланды. Республика язучыларының һәм союз идарәсенең эше турында идарә председателе Мирсәй Әмир доклад белән чыкты... Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Ә.Табеев, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе С.Г.Батыев, ТАССР Министрлар Советы председателе С.Г.Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре М.Ф.Вәлиев иптәшләр катнашты...»

Өлкә комитетының культура бүлеге мөдире мәрхүм М.Мусин, бәлкем, баштарак авторлык ләззәте дә кичереп утыргандыр әле. Ләкин... ул—чын сценарист түгел, президиумда түш киереп утырган агайлар—чын хуҗалар түгел. Съезд күптән калыплашкан сценарий буенча бара. Спектакль «Сталиниславский» системасы буенча уйнала. Бу системада татарның милли мәнфәгатьләренә урын юк. Аның «сверхзадача»сы, астыртын максаты—«татар» сүзен, тарихи термин итеп, үткәндә калдыру.

Республика җитәкчеләре дә, әлеге съезд кунаклары кыяфәтендә тәти генә утыра биргән астыртын орган әһелләре дә канәгатьләр: съезд сценарийдан бер карыш та читкә тайпылмыйча бара бирә. Күрче, татар үзенең йөзек кашы санаган докладчы нинди сүзләр тезә: «Россиядә Октябрь җиңешенә китергән данлы революцион көрәшнең художестволы тарихын язган, шул көрәшләрдә катнашкан, җитәкчелек иткән тарихи шәхесләрне үз исемнәре белән гәүдәләндергән әдәби әсәрләргә безнең татар совет әдәбияты соң дәрәҗәдә мохтаҗ...» «Заман темасына язылган әсәрләребезнең идея-эстетик эчтәлеге җәмгыятебезнең бүгенге характерыннан чыгып билгеләнә. Илебез коммунизмның материаль-техник базасын төзү буенча елдан-елга яңа уңышларга ирешә бара...»

«Тарихи тема» дигәч, залдагыларның бер өлешенә җан инде: менә хәзер, ниһаять, әйтәчәк! Әмма «сценаристлар» тыныч. Алар белә: «профессиональ революционер-большевик» турында роман язган әдипнең «зур һәм батырларча кыю адымы» турында әйтәчәк ул...

Юк, мин берәүне дә гаепләмим. Кемнәрнеңдер чирек гасыр элек бөтенләй бүтән заманда кылган гамәлләрен тикшереп утыру егетлек түгел. Мин бары тик әлеге съездны татар тарихына гына салып карыйм. Болак арты татар республикасы тар-мар ителгәннән соң 50 ел вакыт узган. Суверенитет турында Декларация кабул ителәчәк көнгә 22 ел бар әле. Күпме еллардан соң зарыктырып килгән ирек, аны алу һәм сатулар шушы корылтайга да бәйле ләбаса. Бәйсезлек алган җөмһүриятләрдә язучылар халыкны әнә шул чакларда ук яки күп алданрак уята башлады ич. Ә монда татарның милли аңын тәшкил иткән асыл затлар үзләре оеп-йоклап яки дошман уенына катнашып утыралар. Уятасы иде аларны, бозасы иде бу уенны! Листовкалар түгел, чиста кәгазьләр ыргытып булса да. Әмма листовкалар язылган, аларны ыргытасы кешеләр тиешле урыннарга менеп кунаклаган инде.

Кемнәр соң алар? Сәер хәл. Бу вакыйга күпме еллар телдән төшмәде. Ә менә листовка ыргытучыларның үзләрен белүче юк. Бу да татарның милли үзенчәлегенә бәйле бер нәрсә инде. Безгә каһарманлык һәм аның нәтиҗәләре—кирәк, каһарманнар үзләре—кирәкми. Кемнеңдер данга манылуы безнең өчен күрше гаражга яңа машина керү белән бер!

Кыскасы, Татарстан язучыларының VII съездында листовкалар ыргыткан егетләрнең исемнәре матбугатта беренче мәртәбә игълан ителә. Менә алар:

Разил Вәлиев, Зөлфәт (ул чагында—Зөлфәт Маликов), Мирза Мансуров. Зөлфәт белән Мирза—группадашлар. Университеттагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенең данлы 456 группасыннан алар («Кисек тел» поэмасы вакыйгасын искә төшерегез. «Идел», 1994 ел, №3). Аларның әле 3 курста укыган чаклары. Разил исә, журналистика бүлегендә ике ел укыгач, Мәскәүдәге Әдәбият институтына керде.

Хәзер сүзне «ЧП» авторларының үзләренә бирик.

Зөлфәт:

*—Бөтенебез котыра идек бит инде, яшьләр журналы, яшьләр журналы дип. Ике сүзнең берендә шул. Съезд буласы. Разил кайтып төште. Мәскәү һавасын сулаган бит инде. Аңардан чыкты бу идея. Минем университеттагы «Әллүки» иҗат берләшмәсенең җитәкчесе чак. Егетләрне җыйдым.*

Разил:

*—Мин 1 курсны гына бетереп килә идем әле. Анда хәлләр башкачарак бит инде. Мәскәү зыялылары дөнья илләренә йөреп тора. Идән асты гәҗитләре, журналлары чыга. Әдәбият институты аеруча хөр урын. Анда гел язучылар, шагыйрьләр булгач, аның укытучылары да шундый инде. Чит илләрдән килеп укучылар күп, алардан да йога. Бөтен Мәскәү язучыларының телендә—Польша. Анда безнең идеологиягә каршы бик каты чыгышлар бара. Минем башка уй керде: без татарлар да халык бит! Аннан, күреп торам, урыс егетләрен-кызларын көн саен редакцияләргә чакыралар. Аларның журналлар күп. «Молодая гвардия», «Юность», «Ровесник»...—очына чыкмалы түгел. Ә минем басылыр урын юк. Александр Гаврилов дигән бер бик яхшы урыс егете бар иде, минем яшьтәш. Аның инде беренче курста укыганда ук китабы чыкты. Ярославльдән килгән ул—аның Ярославльдә дә басылырга мөмкинлеге бар, Мәскәүдә дә. Мин Казанда нәшриятка җыентыгымны алып килгәч, безнең инде ун елга планнар төзелеп куйган, диделәр. Гәҗитләрдә исә шигырьне айда бер, кайда бер дип кенә басалар... Менә шуларны уйлап-уйлап ятам инде. Нишләп соң безнең басылырга мөмкинлек юк әле? «Идел» журналы турында сүз аңа кадәр дә әйтелә килә иде. Болай сүз сөйләп кенә булмый икән, кыюрак эш итәргә кирәк, дим. Польшада әнә студентлар урамнарда ду килеп йөри. Шул вакытны Казанга, язучылар съездына чакырып кайтардылар. Шул үзебезнең 2 нче тулай торакка кайттым инде. 28 нче, почмак бүлмәгә. Зөлфәт шунда. Мирза, мәрхүм Фәрит Гыйльми, Әмир Дәминев. Киңәшеп-сөйләшеп алгач, татар язучыларына, Татарстанның җитәкчеләренә мөрәҗәгать язарга утырдык. Яшьләр журналы чыгарырга кирәк, дип. Мөрәҗәгатьне бирәү чыгып укый, дип уйлыйбыз инде. Яза торгач, барып җитте безгә: моны бит барыбер укытмаячаклар, съездда сүз бирмәячәкләр. Листовка итеп ыргытыйк, дигән фикер шуннан соң туды ул... Ярый, яздык. Инде бит ишәйтергә кирәк. Кәгазе дә юк әле аның. Матуррак кәгазьдә булсын дибез. Кәгазь табу, 1-2 курс егетләрен күчереп язарга утырту кебек эшләрдә Мирза бик тырышты. Таңга хәтле күчереп утырдык. Кайберәүләр үзләреннән дә өстәгән булып чыкты. «Татарсанга ирек кирәк!» дигән сүзләр дә бар иде әле анда. Ярар, күмәкләп күчереп бетердек, аларны җыеп алдык. Күп булды, 200-300 ләп. «Кем ыргыта?» дигәч, барысы да сагаеп калдылар. Кемнең бу көнне тегендә, кемнең монда барасы бар икән. Мирза шунда ук риза булды. Зөлфәт тә. Мин инде. Листовкаларны өч өлешкә бүлдек. Съездга 5-6 егет җыелышып киттек. Театрга җиткәч, күңелгә шом керде. Ничек ыргытырбыз? Безнең кырыйда утырган кешеләр нишләр?*

Зөлфәт:

*—План шундый: икенче кат балконда урнашабыз. Разил—сәхнәдән карaганда сул кул якта, мин—уң якта. Мирза—артта. Без бөтен залны капларга тиеш—листовка төшмәгән урын калмасын. Миндек өскә, әзерлек бара. Ул Мирза йөри инде, бик тә серле кыяфәт белән. Яка күтәрелгән, караш каш астыннан. Коеп куйган боевик! Гомере буена детектив укыган кеше бит инде. Мин кереп урнаштым. Артта нәрсәдер шытыр-шытыр килә. Менә гомер ачылмаган ишек*

*ачылып китте, анда Мирза күренде. «Шушыннан таярсың!»—ди. Моннан туры шул, югыйсә, ыргыткач, кеше күз алдында йөгерәсе була иде. Мин әйтәм: «Үз урыныңда бул!» Шуннан югалды бу. Килеп басты урынына... Мирсәй Әмирнең докладында бара. Без каяндыр белдек: Мирсәй абый «яшьләр журналы кирәк» дигән сүз әйтәчәк, без әнә шуны көтәбез. Шуннан соң мин сигнал бирергә тиеш. Мирза килеп басуга, Мирсәй абый теге сүзне әйтте...*

Зөлфәт сигнал биргәнче мин дә берничә сүз кыстырыйм әле. Бу «каһәрләнгән» съезд матбугатта эз калдырмаган диярлек. Хәтта «Казан утлары» журналында да бары М.Әмир доклады гына басылган. Яшьләр журналы хакында Мирсәй абый менә болай дигән (әлбәттә инде, урысчалатып): «Яшьләрнең аеруча проза өлкәсендә нормаль үсүенә тоткарлык иткән җитди сәбәпләрнең берсе итеп алар өчен махсус журнал булмау һаман әйтелә килә. Бу турыда без кирәкле урыннарга да җитәрлек ишеттердек. Шәт иншалла, дигәндәй, мин үзем киләсе съездда яшьләр өчен журнал юк дип зарлану урынына, инде барлыкка килгән ул журналның уңышлары һәм кимчелекләре турында фикер йөртербез дип ышанам». Әңгәмәгә бу съездда булган тагын бер язучыны катнаштырыйк әле.

—Марс абый, Мирсәй Әмирнең «һаман әйтелә килде», «җитәрлек ишеттердек» дигәннәре ни аңлата?

Марс Шабаев:

*—Күпләр «Идел»не сугышка кадәр чыккан «Колхоз яшьләре»нә бәйләп карыйлар. Ләкин мин үзем «Идел»не сугыш башлангач ябылган бөтен татар журналларының да дәвамы дип саныйм.* (1940 елда татар телендә 23 журнал чыккан. Аларның ким дигәндә өчесе—яшьләр журналы. Бу—«Колхоз яшьләре», «Комвуз студенты», «Яшь эшче»—Р.Ю.) *Язучылар идарәсе җитәкчеләре сугыш бетү белән үк яшьләр өчен кабат журнал чыгара башлау мәсьәләсен күтәрә килгәннәр. Тукай клубында Кави Нәҗминең шул хакта мишәр акценты белән кызып-кызып сөйләгәнен хәтерлим әле. Бу мәсьәлә РСФСР язучыларының I (Афзал Шамов), II (Мирсәй Әмир), III (Гариф Ахунов) съездларында да кузгатылды. һаман шул партия Үзәк Комитетына терәлеп кала иде. Сезгә бирсәң, башкортларга да бирәсе була, аларга бирсәң, бүтән автономияле республикалар сорый, янәсе. Ләкин бу—сылтау гына. Татарга журнал бирүдән курка иде алар.*

Ярар, бусы аңлашылды, инде кабат театр бинасына әйләнеп кайтыйк.

Зөлфәт:

*—Мирсәй абый теге сүзне әйтүгә, мин өч мәртәбә кул болгадым. Өченчесендә төшеп китәргә тиеш. Селтәп җибәргәч, сибелеп киттеләр, мин сиңайтим. Матур сибеләләр икән. Әле һаман күз алдында тора. Мирза да шулай селтәп очырды. Разил ике бармак арасыннан гына төшереп җибәрде дә, берни булмагандай утыра бирә. Ул тамчы да каушамады. Разилнең листовкалары төшә-төшә таралды. Безнең исәп дөрес булган, листовкалар бөтен залны каплады. Телевидениегә туры репортаж бара иде. Соңыннан сөйләделәр: операторлар, рәсми оештырылган эш дип уйлап, листовкаларның очканнарына кадәр күрсәткәннәр... Минем кырыйда портфелен тотып Х.Курбатов тыңлап тора иде докладны, бик тә бирелеп. Күрде дә—выжт!—мине дә узып чыгып ычкынды.*

*Алдан килешенгәнчә, буфетка чабып төштем. Мирза да төшеп җиткән. Лимонад алдык, эчкән булабыз. Имеш безнең бу мәрәкәгә бер катнашыбыз да юк. Ләкин стакан тоткан куллар калтырый инде. Шулвакыт Шәйхи Маннур килеп керде. Тартырга чыккан булгандыр. Карап-карап торды да: «Ни эчәсез, егетләр?»—ди. Безнең җавап бирерлек рәт юк әле. Буфеттан чыксак, бөтен халык гөж килә, бар да шуны сөйли. Фәрит Галиев, безнең группадаш: «Листовкалар ыргыттылар бит, күрдеңме?—ди. Минем балконга күрсәтеп:—Менә бу яктан ыргытканын күреп калдым, кап-кара бер егет»,—ди. «Кит аннан, негр мәллә?»—дигән булам.*

Разил:

*—Минем тирәдә галим-голәмә утыра иде. Ыргыткач, башта шым булдылар. Аннан әкрен-әкрен тая башладылар. Бераздан берьялгызым торып калдым.*

*Өстән күзәтәм инде. Зал—кырмыска оясына таяк тыкканнармыни! Президиумдагыларның кайберләре мәет кебек ап-ак булды...*

*Бик күп язучылар, курка-курка гына булса да, алып яшерәләр. Минем бик хәтердә калганы Марс Шабаев. Сиздермәскә теләп, мыштым гына кесәсенә тыгып куйды. Чөнки теге оешма егетләре җыеп йөри башладылар. «Кемдә бар, кемдә бар?»—дип.*

М.Шабаев:

*—Өстән кәгазь ява башлагач, башта хатын-кыз тавышы ишетелде. Аптыраулымы, сискәнүлеме тавыш. Шуннан бар да шым булдылар. Аннары бөтен зал берьюлы аһ итеп куйды. Шул истә калган: Зәки Нури бик кинәт кенә, кып-кызыл булып, президиумнан чыгып йөгерде... Теге кәгазьләр аяк астына бөтерелеп төшә бит инде. Мин алдым аның берсен шунда. Анда инде рәт араларында матур гына егетләр чабыша башлады. Тәнәфес игълан иттеләр.*

Зөлфәт:

*—Тәнәфестән соң Разил янына мендек...Театрда теге форма кигән ханымнар бар бит әле. Шуларның берсе килде дә, сезне аста көтәләр анда, ди. Төшеп киттем инде. Төшеп җитүем булды, таза гына ике егет эләктереп алдылар да алып чыгып китеп баралар. Бәхеткә каршы, каяндыр Марс Шабаев килеп чыкты. Тәҗрибәле кеше, ул аңлап өлгергән инде эшне. «Кая алып барасыз аны!» дип, шалт эләктереп алды да мине, партерда үз янына китереп утыртты: «Утыр, селкенмә!»...*

*Ничек өлгергәннәр, диген, шул кичне үк бу хакта «Азатлык» радиостанциясеннән хәбәр иткәннәр...*

*Икенче көнне ике балконның да ишекләрен бикләп куйганнар иде. Тик бу инде ат урлаткач йозак элгән кебек кенә...*

—Моның ахыры ни булып бетте инде?

Разил:

*—Тәнәфескә чыгу белән Зәки Нури кулдан эләктереп алды. Союзның җаваплы секретаре. Алып кереп китте мине директор бүлмәсенә. Анда 45 яшьләр тирәсендәге юантык кына кеше утыра иде. Минем хәтердә пистолет калган. Пистолетын өстәлгә салып сөйләштеме ул?.. Юк, пиджак чабуын менә болай кайтарып—пистолет күренеп торсын өчен. Яшь малайга үзенчә психологик басым ясамакчы инде. Бик каты сөйләште, мин хәтта азрак шөлләп тә калдым. Хәзер утырталар да алып китәләр икән, дип. Ләкин, курку белән бергә, «Алып китсәләр ни инде?» дигән уй да бар. Күрмәгән нәрсә булгач, бу әле артык куркытмый да. Ни өчен куркытмый? Хәсән Туфан 17 еллап утырып кайтканнан соң бездә шуңа охшарга тырышу бар...*

*Тәнәфесләрнең берсендә—шул ук Зәки Нури инде—мине җитәкләп алып килеп Вәлиев каршысына бастырды. М.Мусин да шунда. Вәлиев мине урысчалатып сүкте. «Ты брось московские штучки! Это—Казань, здесь совсем другие порядки!»—диде. Кулы Мәскәүгә дә җитәчәген сиздереп куйды. Мәскәүгә бару белән мине институт ректоры Пименов чакырып алды. Минем чын куркуым әнә шул чакны булды. Институттан куалар икән дип. Ләкин Пименов бик тә кешелекле кеше иде. Аңлаттым инде, башкалар басыла, минем басылыр җир юк, шуннан башланды бу эш, дип. Гаепләп берни дә әйтмәде. Ләкин шуннан соң бер сәбәпсез өч ай стипендия түләмәделәр. Монысы Казанга яки КГБга җавап бирү өчен кирәк булгандыр инде...*

*Шунысы шәп, без куркып калмадык. Съездга шул көнне төштән соң да, икенче көнне дә бардык, кирәк чакта сызгырып та утырдык. «Казан утлары»ның баш редакторы Рафаэль Мостафин бик кыю чыгыш ясаган иде бит. Эштән алалар икән, дигәч, яклап мөрәҗәгать язып имза җыярга да уйлаган идек, үзе «кирәк түгел» диде.*

*Ул көнне кич съезд тулай торакка күчте: бөтен общежитие гөж килде. Бары тик шул турыда гына сөйлиләр. Кем ничек ыргыткан, ничек йөгереп төшкән, кем ни күргән, ни ишеткән!..*

Зөлфәт:

*—Мине һәм тагын «Әллүки»дән ничәдер егетне-кызны кафедрага чакырып алдылар. Берләшмәнең отчетын тыңларга, дигән булып. Нигә икәнен чамалыйбыз, әлбәттә. Хатип Госман бүлмәсендә безнең берничә остаз утыра. Һәм тагын уң кул якта дүрт кеше. Сөйләшмиләр, ахыргача бер генә сүз дә әйтмәделәр.*

*Бик зурдан кубып бирәм отчетны. Шигырь язып маташучы бар икән—шагыйрь, берәү пьеса язып караган икән—ул инде драматург! Саннар да шәп. Татар бүлегеннән генә түгел, башка бүлекләр, башка факультетлардан да яшьләр күп. Отчетны тәгәлләдем. Сорау бирәләр миңа: «Ниндирәк әсәрләр языла соң?» Гөнаһ шомлыгы, шундый чакта башка иң кирәкмәгән нәрсә килә бит ул. «Мисал өчен, шушы араларда гына Рәшит Әхмәтҗанов яңа шигырь язды»,— дим. «Укып күрсәтә аласыңмы?» Мин әйтәм, ике юлын хәтерлим:*

Төне буе кара карлыгачлар
Йөрәгемә кайгы ташыды.

*Тинтерәтеп җанымны ала яздылар: «Ниткән кайгы инде ул? Нишләп кара карлыгачлар инде ул?»*

*Кафедра җитәкчеләре белән киңәшеп, рөхсәт сорап тору юк иде. Тотам да, «Әллүки» утырышына берәр өлкән язучыны чакырам, Нәкый Исәнбәт килгәнне бер дә яратмадылар. Яки Уфадан башкорт студентларын чакырып китерәм—бу хакта тегеләр килеп төшкәч кенә мәгълүм була. Хәзер менә безгә, нигә берләшмә утырышларын университетта түгел, тулай торакта үткәрәсез, нигә укытучыларны чакырмыйсыз, дип бәйләнәләр. Шуннан төп сорауны бирделәр: «Съезд вакытында менә шундый вакыйга булды, сез белдегезме аны?» Килешеп куйган идек инде. Мин әйтәм, белдек кенә түгел, без аны оештырдык. Хатип ага әйтә: «Улым! Менә ничек уйлыйсың, ялгыш эшме бу? Әллә дөрес эшләдек дип уйлыйсыңмы?» «Хатип абый, ялгыш эшләгәнбез,—дим.—Өстән ыргытасы түгел, астан таратасы булган аны».*

*Хатип агага минем җавапның икенче өлеше кирәк түгел. «Менә дөрес, улым, хата эш булган, ялгыш эш булган! Империализм һәр ярыктан безнең дәүләт строен җимерергә маташкан чакта...—Элеп алып китте, мин сиңайтим. Тегеләр өчен сөйли инде, әлбәттә. «Мин гаепле, шулкадәр иҗади көч тупланганлыгын белмәгәнмен, мин моны белергә тиеш идем,—ди.—Сезне идарә итәргә кирәк икән»,—ди. Тагын күпмедер куркышып йөрдек әле, нәрсә булыр, нәрсә булыр, дип. Тик шуның белән бетте бу эш.*

М.Шабаев:

*—«Эш»нең менә мондыйрак дәвамы булды әле. Өлкән язучыларыбызның бит тәҗрибә бөтенләй башка. Алар бит белә: бу тегермәнгә бер эләксәң, беттең, бөтен тормышың сынды дигән сүз. Үзара сөйләшкәннәр булса кирәк, шушы талантлы малайны харап итәләр бит, дип. Хәсән ага Туфан миңа: «Зөлфәтне «Чаян»га эшкә урнаштырасы иде»,—диде. Хәсән аганың Зөлфәтне «Чаян» канаты астына тыгуы тикмәгә генә түгел. «Чаян»ның Бөтенсоюз журналы дәрәҗәсендә йөргән, бик тә абруйлы чагы, аны Табеев та хөрмәт итә. Кыскасы, ышык урын... Һәм бит аның иң кызыгы шул: илтеп тәрткәннән бирле Зөлфәт шунда эшләп утыра бит әле менә!*

*VII съездда идарә рәисе итеп Ибраһим Гази сайланды. Ибраһим агай мине чакырып алып, яшьләр журналының штат расписаниесен һәм сметасын төзергә кушты. 3 вариантта эшләдем мин моны. Исеменә конкурс игълан иттек. Сугыштан соң башта «Үсү юлы», аннары «Идел» альманахлары чыккан иде бит, икесе дә ябылды. Менә шул «Идел»нең исемен яңадан кайтарырга булдык. Шуннан, журнал сорый торгач, альманах итеп бирделәр. Без көлеп тә йөрдек инде, съездан соң 9 ай үткәч туды, дип. Журнал өчен көрәш исә туктамады, тагын да куәтләнә генә төште...*

«Йә, журнал сораганнар, гап-гади журнал, искитеп сөйләрлек ние бар инде моның?»—берәр яшь укучыбыз шулай дип тә әйтә ала. Бу «ни»не тояр

өчен милли изүнең нәрсә икәнен аңларга кирәк. Ул заманда бит хәтта татарга карата «милләт», «милли» сүзләрен куллану да сәяси гөнаһ санала иде. «Татар» сүзе гәҗит битенә «...театры», «... әдәбияты» кебек сүзләргә ияреп кенә кереп китә иде. Әлеге листовкаларда әнә «Революциягә кадәр татар телендә утызлап журнал чыккан» дип әйтелгән булган. Татарның «чын тарихы» революциядән соң гына башлана лабаса! «Аргументы и факты» гәҗите хәтта татар язуын да революциядән соң барлыкка килгән, дип шаккатырган иде. Р.Мостафинны эшеннән ни өчен алалар? 1913 ел белән чагыштырганда татар телендә китап чыгару кимегән, дигәне өчен. Югыйсә ул бит рәсми рәвештә теркәлгән фактны кабатлап кына әйткән. Сүз алып, трибунадан әйткән. Мостафинның сүзләре залда рәсми идеологиягә төбәп мылтык ату тәэсире тудырса, егетләрнең кылган эше бомба шартлауга тиң булган.

Каян килгән соң бу япь-яшь малайларга милли рух?

Зөлфәт:

*—Мин үзем дә әнә шул чорда милли хис кайнаганга аптырыйм. Бөтенебез дә шул чир белән чирле идек бит инде. Авыл малайлары югыйсә. Каян килеп чыкты икән ул, нәрсәдән килеп чыкты икән? Әллә беренче мәртәбә чынлап торып гыйлемгә тартылганнанмы бу? Сөргеннән кайткан Туфанны укып үскән малайларның бергә җыелып кайнашуыннанмы әллә?*

Разил:

*—Минем нәселдән үк килә бу. Әнкәй ягыннан бабамның тегермәне булган, алты малае үз куллары белән салган тегермәнне. Шул тегермәнне, ике катлы йортларын, бөтен малларын алалар. Ләкин сөрмиләр боларны, кеше яллап эшләтмәгәч. Шушы Нуретдин бабай гомере буе колхозга кермәде. Әткәй—колхоз председателе, коммунист. Көн саен бәхәс чыга торган иде. Әнкәй—бабай яклы. Бабай белән әнкәйнең идеологиясе көчлерәк! Алар Корьәнгә, гореф-гадәткә таянып сөйлиләр. Кеше хокукларына—примитив төстә булса да. Әткәй сөйләгән кызыл фразалар һавада асылынып кала. Бабайның әйтә торган бер сүзе бар иде: «Дин бетте, кешенең кадере бетте, җирнең кадере бетте—бу тормыш барыбер болай бара алмый!..»*



Зөлфәт белән Разил Вәлиев. *1966 ел.*

*Шулай да, авылда чакта мин милләткә бүленүне аңлап җиткерми идем. Түбән Камага килгәч, урыс малайлары бирде миңа беренче милли сабакларны. «Татарва!» дип, бик каты кысарга тырышалар иде. Ләкин без, бер төркем оештырып, кулга алдык аннары шәһәрне... Тагын укытучылар шәп иде... Чаллыга әдәби түгәрәккә йөри башлагач, шул ук язучылардан да шактый йоктырдык. М.Хөсәен, Н.Дәүли, З.Нури, Р.Ишморатлардан. Алар, Казан колагыннан читтә, без балалар белән иркенрәк тә сөйләшә торганнар иде...*

Яшь чактагы җилкенү, дуамаллыклар—уза торган нәрсә. Тормыш кайберәүләрне сындыра да бит әле. Әмма безнең бу ике егет һаман шул юлда. Зөлфәт—милли җанлы күренекле шагыйребез, яшел әләмле сафта аның белән янәшә атларга да туры килгәне бар. Разил—шагыйрь, прозаик, драматург, Милли китапханәбез директоры, Татарстан Югары Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе... Өченче каһарманыбыз кайда соң?

Зөлфәт:

*—Мирза—Ерак Көнчыгышта застава башлыгы... Шул якларга концерт белән баргач, безнең Зөһрә Сәхәбиеваларны бик каты кунак иткән ул. Мөдәррис белән Зөлфәт китапларын салсыннар, тоннасы белән балык җибәрәм, дигән...*

Листовкаларны күчереп язу да тәвәккәл эш булган. Күчерүчеләрнең

исемлеге ачыкланып җитмәде әле. Әмир Дәминов, Равил Кукушкин, Зиннур Мансуров, Рәшит Бәшәр, Марсель Хәбибрахманов, Шәһинур Мостафин исемнәре аталды. Листовкаларның бер генә данәсен дә таба алмадык. Берәр кешедә сакланса, китерүен үтенәбез. Әҗере булыр...

«Идел» журналына әлеге шау-шуы шактый озакка сузылган вакыйгадан соң нәкъ егерме ел узгач кына юл ачылды. Әмма бу «ЧП»ның кәҗәсе генә түгел, мәзәге дә бик кыйммәт иде. «Җаны йокымсыраган» бик күпләрне уятып җибәрде ул. «Идел» өчен көрәш үзе дә шуннан соң милли-азатлык хәрәкәтенең аерылгысыз бер өлешенә әйләнеп китте.

«Идел», 1994, № 7

РУХ

# ЙӘГЕЗ, ЯНӘ БЕР ДОГА

Кешенең күп гомере эштә уза. Мөштәри урамындагы (элеккеге Комлев) без казгана торган шушы бина да күпме сөенечләрнең, күпме көенечләрнең шаһиты булган! Кечкенә генә уңышлардан да биредә чамасыз шатланганбыз, нәни генә тәнкыйтьне дә зур итеп күтәргәнбез. Шагыйрьләрнең җаны көбәсез. Шуңа да моннан мәңгелеккә китүчеләрнең җан балкышы борынгы диварларга аерата мул төшкән сыман...



Фәиз Зөлкарнәй.

Мәрхүм Фәиз Зөлкарнәйнең дә аңлы гомереннән биштән бер өлеше шушы калын диварлар эчендә узган икән. Язучылар берлеге Бауман урамындагы йортның кысан бүлмәләреннән шушы бинага күчә дип ишеткәч, гөр килеп сөенешүебез әле дә истә. Бер урыс сәүдәгәренең (Оконишников) инкыйлабка кадәр үк салынган йорты бу. Биек түшәмле затлы заллар, мәрмәр баскычлар. Мәһабәт сарайга терәтеп хезмәтчеләр өчен салынган кумырыгы да бар. Берничә елдан соң яшьләр өчен «Идел» журналы ачылыр да, без әлеге кумырыкта татлы да, ачы да елларыбызны уздырырбыз дип кем уйлаган...

Әлегә без «йөкчеләр». Тузанга буялып иске җиһазларны, Язучылар союзының дистә еллар буена җыелган архивын, китапханәне, хан заманыннан калган олы сейфларны «яңа өйгә» ташыйбыз. Рәисебез Туфан Миңнуллин көр тавыш белән безне рухландырып тора, Марсель Гали тузаннан качып читтә акыл өйрәтә.

Монда монарчы балалар хастаханәсе эшләгән. Дару исен, тагын безгә әле таныш түгел бөтән исмерләрне җуяр өчен шактый вакыт кирәк булачак.

Менә без, тар баскычтан түбән төшеп, йортның подвалын чистарта башладык. Шунда кинәт шадра стеналардагы богау-ыргакларга күз төште. «Революциядән соң бу бинаны чекистлар үзләренә алган, диде кемдер.—Ә әлеге подвалда алар тоткыннарны җәзалаганнар».

Сәер хәл—икенче көнне подвалдагы бу ыргаклар юкка чыкты. Кемдер безнең җан тынычлыгыбызны сакларга тырышкандыр... Әмма күчену шатлыгына дәһшәтле елларның күләгәсе төшкән иде инде. Шундый аянычлы тарихка ия икән ич бу йорт. Нишлисең, халкыбызның тарихы да шундый бит безнең...

Яңа өйгә күченеп, мөселман кешесе нигезгә Корьән укыта, шунда бәхетле яшәргә өмет итә. Нигәдер бу безнең башыбызга килмәгән. Дистә еллар дәвамында

сендерелгән дәһрилек каныбызга күчеп өлгергән шул. Югыйсә без тамырлардан бөтенләй үк аерылган кешеләр дә түгел сыман.

Фәиз Зөлкарнәй фаҗигале рәвештә һәлак булгач, без—аның белән шушында шактый елларны сарыф иткән кешеләр—күпмегәдер югалып, аңгыраеп калдык. Үзәкне өзеп төрле сораулар да башка килде. Хәсән Туфан язган бит әле: «Кемгә тидек? Кемне рәнжеттек соң? Кем соң безне шулай каргады?..» Нигә безгә шундый олы кайгы төште? Тәңре каршында бирер гөнаһыбыз бар мәллә? Юкса без кемгә тия, кемне рәнҗетә алабыз соң...

Бүтән югалтулар да хәтергә килде. Җаваплы сәркәтибебез урынбасары Рөстәм Халит, рәсемгә төшерүче Әкрам, әдәбият фонды шоферы Рүзәл... Гаҗизләнгән күңелгә мондый сорауларның килүе табигый.

Әлбәттә, дөнья үлем-китемсез тормый. Корьән-шәриф үзе үк безгә сабырчыдам булырга кушкан. Безгә дә шул изге китаптан юаныч эзләргә кала. Бердәнбер юаныч. Китүчеләр бит бөтенләй юкка чыкмый, бары тик мәңгелеккә, бакыйлыкка күчә. Мәңгелек йортның нигезенә чекистлар богау-ыргаклар беркетә алмый.



Мөфти Госман хәзрәт Исхакый

Тик, китүчеләрнең рухын Корьән сүзе белән, яхшы ниятләр белән яктыртып торырга гына кирәк. Менә шуна күрә дә без, баш мөхәрриребез Фәиз Зөлкарнәйнең вафатына бер ел тулган көннәрдә, Татарстан Диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакыйны редакциябезгә чакырып, мәрхүм рухына Корьән укыттык. Әлбәттә, бу изге аятьләр шушы йортның нигезенә дә багышланды. Монда кылынган гаделсезлекләр бүтән кабатланмасын, дога өмет иткән җаннар тынычлансын, шәһит киткән, вафат булганнарның каберенә нур инсен, ярабби...

Корьән укыганнан соң мөфти вәгазь дә сөйләде. Иң беренче нәүбәттә ул басма сүзнең күңелләргә Ислам нуры сеңдерүдәге әһәмиятенә тукталды. «Идел»не без күптән күзәтеп барабыз,—диде ул.—Сез, нәшер итела башлау белән үк, дин мәсьәләләренә игътибар юнәлттегез, татар гәҗит-журналлары арасында беренчеләрдән булып «Хак юл», «Мәдрәсә» кебек махсус сәхифәләр ачып, укучыларны динебез нигезләре белән таныштырдыгыз, «Ислам йолалары», «Иман шарты», «Йасин һәм Тәбарәк» дигән китап вә җыентыклар чыгардыгыз. Без бер уртак эш эшлибез. Бурычыбыз—кан кардәшләребез күңеленә югалган иманны кайтару, Аллаһы тәгаләнең изге сүзен җиткерү. Киләчәктә дә кулга-кул тотынышып бер максатка шулай хезмәт итик».

Мөфтинең салмак агышлы тавышын үзләренә сеңдереп утыручы ак яулык бөркәнгән хатын-кызларыбызны, амин итәргә дип ике кулны күтәргән ир-егетләрне мәрхүм Фәиз күзәтеп тора сыман иде. Без бу көнне аның рухын, аның сулышын тойдык шикелле. Ул үзе дә иманлы, әдәпле, әхлаклы кеше иде—Рамазан айларында уразаны калдырмады, башка фарызларны да үтәргә тырышты.

—Рухи байлыгыбызны саклау өлкәсендә без, әлбәттә, элеккеге юлыбызны дәвам итәчәкбез,—диде хәзерге баш мөхәррир Рашат Низамиев.—Зәңгәр экраннардан әхлаксызлык белән яшь буынның миен агулаган заманда бу аеруча мөһим.

Әйе, Ислам дине безне дәһшәтле елларда милләт буларак саклап калган. Изелгән, кыерсытылган, җәберләнгән чорларда да татар бер Аллага ышанычын югалтмаган, киләсе көнгә өмет белән караган. Билгеле, бүген дә җинел түгел. Әмма күңелләрдә иман нуры булганда бер генә дәһшәтле көч тә, бер генә карагруһ та безнең вөҗданыбызга үтеп керә алмас.

Башкача безне Ахырзаман көтә.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Нәбирә
Гыйматдинова

# «МУСА ГЫНА ГАЕПЛЕ ТҮГЕЛ...»

Төгәл генә хәтерләмим, моннан ике дистә еллар элек бугай, колагыма гайбәткә тартым бер хәбәр чагылып киткән иде. Имеш Муса Җәлилнең Зәкия исемле сөйгән кызы булган да, шушы мәхәббәттән уртак бала—Люция туган. Бүтән алар турында ишетмәдем. Җәлилнең юбилейларында да, ана багышланган кичә-бәйрәмнәрдә дә, матбугатта да Зәкия белән Люция хакында ләм-мим, сүз булмады шикелле. Сәер һәм гаҗәп диясе юк анысы. Бит Муса кебек танылган шәхесләрдән гөнаһсыз фәрештәләр ясап, курчак уйнаган заманнар иде. Ә хакыйкать, күпме генә яшермә, барыбер өскә калка. Муса Җәлилнең дә шәхси тормышындагы моңарчы ябылып торган битләре, ниһаять, ачыла башлады. Шул битләргә Зәкия-Люция, Рауза-Альберт исемнәре дә тирән яшерелгән иде. Кемнәр отты соң мондый ясалма уеннан? Чыш-пышларга, гайбәтләргә караганда чын дөреслек кыйммәтрәк түгелмени?.. Кабереннән терелеп әйләнеп кайтса, шагыйрь моңа бик тә рәнҗер, үземне фәрештә итеп таныту хисабына балаларымнан ваз кичмим, дияр иде, мөгаен.

Еллар узды, ә тыелган-сызылган ике исем һич хәтеремнән чыкмады. Кайда икән бу җаннар дип уйланып йөргәч, эзләп карарга ниятләдем. Борма-борма сукмаклар Зәкия апа Садыйкова фатирына илтеп куйды. Аллага шөкер, әбиебез 82 яшен тутырып исән-имин генә яшәп ята, эштән китүенә дә... 2 генә ел икән әле! Ә Люция Муса кызы Җәлилова Мәдәният һәм сәнгать академиясендә студентларга белем бирә, гимназиядә балалар да укыта, ана белән кыз көн саен телефоннан сөйләшеп, очрашып-күрешеп торалар, кыскасы, матур гына гомер кичерәләр икән.

Ике тере табышмак... Ә табышмакларга җавап табасы килә.

Кем син, Зәкия?

Казан кызы Зәкия 1913 елда шахтер гаиләсендә туа. 13 яшендә чакта әти-әнисе белән Донбаска күчә ул, һәм 7 еллык мәктәпне тәмамлагач, Кузнецкий шәһәрендәге укытучылар әзерли торган техникумга укырга керә. Шигырьләр язу белән шунда мавыга башлый, чөнки монда Латыйф Җәләй әдәби түгәрәк оештыра, алар Сәхаб Урайский белән шул түгәрәккә йөриләр. Бер утырышта Җәләй абый сорый: «Йә, кем нәрсә алып килде?» Зәкия торып баса да кычкырып үзенең «Кулак разведчигы» дигән поэмасын укырга керешә. Ошый поэма җитәкчегә, син редакцияләрнең адресын беләсең, ди ул Урайскийга, бу кызның шигырьләрен, поэмасын туплап Муса Җәлилгә «Октябрь баласы»на җибәр әле.

Кыз язган әйберләрен сөенә-сөенә Сәхабкә тоттыра, ләкин поэма чыкмый да чыкмый. Көтә-көтә түземлеге төкәнгән Зәкия беркөнне Урайскийны туктатып: «Кая куйдың әсәрләремне, җибәрдеңме, юкмы?» дип төпченә. Егет кызарына-бүртенә һәм ахырдан: «Югалттым, гафу ит»,—ди.

Җылый-җылый кыз тагын поэмасын күчерә. Озак та үтми, Муса Җәлилдән хат килә. «Акыллым,—дип яза шагыйрь.—Синең поэмаңны укыдым, тиздән басарбыз. Фотосурәтеңне сал».

Ике арада хатлар йөри башлый. Муса яшь шагыйрәнең киләчәк планнары, нәрсәләр язуы белән кызыксына.

Зәкиянең әти-әнисе кире Казанга кайта. Кызга да укуын бүләргә туры килә. Казанда ул өйрәнчек сыйфатында телеграфка эшкә урнаша.

Беркөнне аңа: «Сине аста бер ир-егет көтә» дип әйтәләр. Зәкиянең аппарат көйләп яткан чагы, кулы мазутка буялган, шул килеш кенә ул аскы катка—почта бүлекчәсенә йөгереп төшә. Һәм аптырап китә. Бәрәч, Муса Җәлил! Киртәдән башын чыгарып карап тора. Шагыйрь, кыздан көлеп: «И акыллым, син бигрәк кечкенә икән!»—ди. «Абый, сез үзегез дә бик зур түгел икән»,—дип җавап бирә чая кыз.

Бу аларның беренче мәртәбә күзгә-күз очрашуы була. «Нишләп йөрисез, абый?

Ни йомыш?»—ди Зәкия, дулкынлануын яшереп. Шундый мәртәбәле шагыйрь аны эзләп килсен әле!

«Яшьләрне кичкә редакциягә жыябыз, син дә кил, Казанда «Октябрь баласы»н чыгарабыз»,—ди Жәлил.

Кич белән, кыз редакциягә ашыга. Анда яшь язучылар бертавыштан журналның мөхәррире итеп Галимҗан Мөхәммәтшинны сайлыйлар, ә сәркәтип вазифасы Зәкия Садыйковага тапшырыла. Тик алар «Октябрь баласы»ның 2 генә санын әзерләп өлгерәләр, журнал ябыла.

Әмма очрашу-күрешүләр өзелми. Шагыйрьнең йөрәгендә гыйшык уты кабына. 1935 нче елда Муса, кызга мәхәббәтен белгертеп, кушылырга тәкъдим ясый, әнисеннән дә кулын сорый.

— Сез шунда ук ризалаштыгызмы, Зәкия апа?

— Юк, өйләнешик дигән көнне тугыз тапкыр яныма килде, ә мин гел качып калам. Телеграфтагы кизү хатынга өенә китте дип алдашырга кушам, ә өйдәгеләргә эштә дип әйтегез, дим. Ә кичен бездә калды инде ул... Әни, теләсәгез нишләгез, диде. Мусаны өнәмәде, гел «шуның нәрсәсен яратасың», дия иде. Ярату булган шул инде. «Мин сезгә никах укытам»,—дип, әни өйгә бер бабайны дәштерде. Ә без Муса белән, шырык-шырык көлеп, такта белән бүленгән бүлмәдә тыңлап утырдык. Ул вакытларда дингә караш тискәре иде бит. Шулай яңа тормыш башлаган көннәрдә ул миңа серен тиште. «Зәкия, синең алда гаепле мин»,—ди. «Ничек гаепле?»—дим. «Минем Раузада малаем бар»,—ди бу. Әлеге хәбәр һушымнан яздырды. Раузалар белән бергәләшеп театрларга йөри идек, аны-моны сизгәнем юк иде. Мусаны житәкләдем дә Раузаларга бардым. «Рауза,—дидем,—без кушылып бик аз яшибез, элегрәк синең хакта Муса бернәрсә дә әйтмәде, хәзер нишлибез?»—дидем. Аның җавабы кыска булды: «Мин беренчесе, ә син актыккысы түгел, Зәкия».

Моны бик авыр кичердем, житмәсә, балага да узган идем. Муса «Мәскәүгә китәбез, жыен» ди, ә мин кабаланмаска өндим. Ник дигәндә, укып кайтып, телеграфта местком рәисе вазифасын башкара идем. Декрет акчасы да шактый гына тиясе. «Син дә ярлы, мин дә ярлы, Муса, әйдә, бала акчасын алгач барырмын, син китә тор»,—дигәч, ул: «Дөрес әйтәсең, Зәкия, тик үпкәләмә генә»,—диде. Ник үпкәлим, мәйтәм, үпкәләмим.

Ул арада Мәскәүдән төрле сүзләр ишеттерә башладылар. «Ник монда корсагыңны күтәреп йөрисең, бар, ирең янына кит»,—ди бермәлне Фатыйма Ильская, куа. Вакыты житкәч, китәрмен, генә дим. Менә Мәскәүгә жыендым. Әни яңа юрганнар сырды, күчтәнәчләр төйнәде. Вокзалда Муса машина белән каршы алды. «Кая барабыз?»—дип соравыма, «Өйгә кайтабыз»,—ди. Күңелем тартмый гына бит, ул өйгә бүтән берәүнең килеп йөргәнен ишеткәч. «Бу синең икенче алдашуың инде, башка жиргә илт»,—дидем. Ә аннан, берничә көннән, Ташкентка—дус кызым янына китәргә карар кылдым. Муса юлыма әйберләр сатып алып бирде. Соңыннан хат язды: «Син мине жәзалый аласың, газитләргә яза аласың»,—диде. Тик мин алай ямьсезләнеп йөрмәдем. Ташкентта кызыбыз Люция туды. Жәлил ана акча салып торды. Бирсендә: «Зәкия, һич акчаны арттырып булмый, син судка бир инде»,—дигән. Ярар, үзе кушкач, үзе үтенгәч, алиментка бирдем. Берьюлы Раузага да түләде ул.

— Ташкентта ничек яшәдегез?

— Бала тапкач, кечкенә генә бүлмәгә урнаштырдылар. Татар театрында тәржемәче идем. А.Пушкинның «Барышня и крестьянка» белән «Цыгане» әсәрләрен тәржемә иттем, икесен дә сәхнәгә куйдылар.

Казан сагындыргач, тоттым да туган жиремә кайттым. Беркөнне Язучылар берлегенә килә идем, урамда китап нәшрияты управляющие Закир Тинчурин очрады. «Кая барасың, Зәкия?—ди.—Эш эзләпме? Әйдә безгә! Аптыраган менә, бөтенесен дә утыртып бетерделәр, китап чыгарырга кеше юк». Зур гына бүлмәгә кертте дә, идән уртасындагы кульязма өеменә төртеп күрсәтте. Шулардан китап жый, ди. Шулай нәшриятта кульязмаларга чумдым инде. Без бишәү—Ибрай Гази, Кави Нәжми, Рахман Ильяс, Авзал Шамов, мин—бер бүлмәдә кайнадык. Күңелле яшәдек. «Биш шадра» дип көлешә идек, чөнки бишебез дә аз-маз шадра иде. Минеке—борында. 40 нчы елда үзем дә «Гөлкәй» исемле беренче жыентыгымны бастырдым.

Ә сугыш алдыннан бөтен мөхәррирләрне дә кыскарттылар.

— Сез озакламый кияүгә дә чыккансыз икән.

— Әйе, 1939 елда мине хатыны үлеп ике баласы белән тол калган иргә ярәштеләр. Педагогия институтында политэкономия укыта иде. Уртак улыбыз да туды. Җәмгысе 4 бала иде миндә.

— Ә Муса белән мөнәсәбәтләрегез начарланмадымы соң?

— Юк, ул Казанга килсә, Люцияне күрергә ашкына иде. Ирем көнләшкәнгә күрә аларны читтәрәк күрештерә идем. Берсендә сөткә барырга җыенам, бу хакта алдан ук Мусага әйтеп куелган, Люция белән икәү барабыз, фәлән тыкрыкта көт, диелгән. Безнең белән үги кызым да иярмәкче. Аны кочкә көйләп-җайлап калдырдым. Люцияне Муса сөйде, иркәләде, кәнфитләр бирде һәм юл буе күтәреп барды. «Әллә кемгә охшап бармаклары зур»,—дигәч, «Минеке кебек»,—диде. Бик сагына, бик ярата иде инде кызын...

Зәкия апа сөйли-сөйли дә, матур күзләрен бер ноктага төбәп, тынып тора, ә мин, шул тынлыктан файдаланып, өстәлдә сибелеп яткан документларны, фотосурәтләрне, хатларны караштырам. Аның «Бик сагына, бик ярата иде инде кызын» дигән сүзләрен раслагандай, Муса Җәлилнең латин хәрефләре белән Зәкиягә язган хаты күземә чалына.

«Зәкия!.. Люцияне бик күрәсем килә. Ул үсеп зур булыр. Мине белмәс тә. Минем менә шундый авырлыклар белән ярты гомерем кыскарганны аңламас та. Сез аңа мине начар итеп сөйләрсез. Ул үзенең бәхетсез әтисе өчен йөрәгеннән сызланса да, бернәрсә дә әйтә алмас. Ул бәлки үскәч, аңы ачылгач, минем язуларны табып, укып, яшерен генә җылар. Күп усал сүзләргә карамастан, ул үскәч, минем шигырьләрем белән танышыр, үзендә миңа карата бик тирән якынлык сизәр. Ул мине йөрәгендә саклар: ник сакламасын?! Мин әти бит аңа!.. Ул минем ялкынлы шигырьләремдә минем тормышымны күрмәсмени?! Ул минем бер идиот булмаганымны, ә йөрәк белән янып яшәгән, зур кичерүләр белән гомер иткән шагыйрь икәнемне белмәсмени?! Кызларның йөрәге йомшак була. Ул минем көндәлекләремдә үзе һәм үзем турында укыганда «И бер генә күрсәм иде»,—дип җыламасмыни?!

... Мин бик теләр идем Люцияне үземә алырга!.. Син бир миңа Люцияне! Сездә болай да өч бала. Сезгә авырдыр. Мин Люцияне синнән ким тәрбияләмәм. Аннан соң Зәйнәп (сеңелем) Казанга күчә бит! Ул инженер. Ирсез, баласыз. Ә бала бик ярата. Ул карар. (Миңа да якын булыр).

... Дусларча килешенгәч семьяда да татулык туар, балалар белән очрашу күңелле булыр.

Тәкъдимемне кире каксагыз—миңа үлем белән бер. Аны аңлагыз.

Мин озын яздым. Ләкин сүзем әле тагын бик күп иде. Йөрәктән, чын күңелдән язам. Аңлашасым килә. Аңлашып яшисем, иҗат итәсем килә.

Хуш, акыллым!.. Теләсәң нишлә, ихтыяр синдә!

Сәлам белән Муса.»

Бу хатта шагыйрьнең теткәләнгән йөрәк авазы да, өзгәләнү-бәргәләнүләре дә, кызы өчен янып-көюләре бар. Бит Зәкия апа аны нечкә күңелле, диде. Нечкә күңелләр артык тиз җәрәхәтләнә шул. Язмыш ник аны болай газаплаган, баласыннан аерган икән, әгәр аермаса... Уйларымны сизгәндәй, Зәкия апа:

— Муса гына гаепле түгел,—диде.—Минем горурлыгым комачаулады Мәскәүдә калырга. Кит димәде бит ул, кумады. Кал, диде, күз яше түкте. Миндә дә гаеп. Кайбер кешеләр Мусаның өч хатыны булган дип, гайбәт саталар. Мин аларның авызын тиз ябам. Булса ни! Ул беребездән дә баш тартмады. Миндә аның: «Өчегез арасында сине генә яратам» дигән хаты да бар.

— Сез Рауза апа белән хәбәрләшеп, хатлар язышып бик тату-дус яшәгәнсез, диләр, дөресме бу?

—Хак сүзләр, хак. Безне балалар якынайтты. Бервакыт Тажи Гыйззәт Альбертны урамда күрә дә: «Синең әтиең—Муса Җәлил, әле Бутлеров урамында сеңелең дә яши»,—ди. Малай тизрәк өенә чаба, дәү әнисеннән сорый. Әниеннән сора, ул сөйләсен, ди әбисе. Шуннан Рауза миңа шылтырата. Минем малайның синең кызыңны күрәсе килә, нишлибез, Зәкия? ди. Мәйтәм, килсен, танышсыннар.

— Муса белән бергә үткәргән көннәрдән нинди вакыйгалар хәтерегездә ныграк уелган?

— Күбесен сөйләмим, ачуланма, хатларны да укытмыйм. Үзем үлгәч, укырлар.

Әле кушылып яшәгәнче булды бу хәл. Телеграфта местком рәисе бит инде мин. Акча түләп тоталар бу эштә. Бер генә минутка каядыр чыккан идем. Муса кабинетыма кергән дә, шаяртып шкафка качкан. Ике янмый торган шкафым бар иде: берсендә документлар тотам, икенчесенә кием эләм. Ирле-хатынлы кешеләрне чакырткан идем, шуларны ияртеп, кабинет түренә уздым. Ир дигәнен яшь кенә кызны кочләргә теләгән, мина шул хакта жалу китергәннәр иде.

Рәис буларак орышам инде моны, акыл өйрәтәм, үзем дә япь-яшь кыз әле. Озакка сузылды сөйләшү. Муса тирләп-пешеп беткән, кочкә сулый. Шкафның бит тишеге бәләкәй генә. Тончыгып үләрсен, дим, ник качтын, дим, әй тиргим.

Бервакыт икәү Маркиз утравына чыктык. Чирәмгә сузылып ятып, Муса «Алтынчәч» либреттосын укый, мин тыңлыйм. Куймыйлар бу әйберенне, дим, син менә хат ташучы егет турында яз. Егет бер кызга гыйшык тота, аңа хат яза, ә иң кыены шул: хатларны үз кулы белән үзе тапшырырга тиеш. Безнең тавышка тирә-ягыбызга кеше жыелган, кеше жыелган, барысы да авыз ачып тыңлый. Әй тордык та йөгердек!

— Димәк, Муса Жәлилнең «Хат ташучы» поэмасына сездән дә өлеш кергән?

— Шагыйрьләр, шигырьләр, ижат турында без күп бәхәсләшә идек. Син яз, син талантлы, дияр иде ул.

— Ә сезнең шигърияттә остазыгыз кем иде?

— Мине Хәсән абый Туфанга беркеткәннәр иде. «Черек күл»гә чакыртып, астыртын сораулар да бирделәр. Мин ул чакта Галимжан Ибраһимовка хат язучы яшьләр төркемендә идем, Одессада булып калып кына хатка имзамны сала алмадым. «Казанда булсаң, хатка кул куяр идеңме?—ди тикшерүче. «Эчтәлеген белмәгән килеш ничек куяр идем дип әйтим»,—дидем. Шул тапкыр жавабым аркасында гына алар тырнагыннан исән-имин котылдым. «Хәсән Туфан синең шигырьләреңне ничек төзәтә?»—ди. Мәйтәм, мин өтер-ноктаrange белмим (шулай ялганлыйм), Туфан шуларны гына куеп бирә, шигырьгә кагылмый. Ул сезнең Есенин кебек әйбәт шагыйрь, дим.

— Зәкия апа, сугышка киткәндә Муса Люцияне күрдеме?

— Ниндидер озату кичәсе оештырганнар иде. Кызыбызны киендереп бардым. Муса чыкты да, Люцияне үбеп-кочаклап, хушлашып кереп китте...

Язмыш Зәкиягә сынауларны өя генә бара. Төпчек улы салкын тиеп үлә, соңрак бик яраткан үги кызы вафат була, сугыш башланганда эшсез дә кала яшь хатын. Ләкин унган, тырыш, житез, чая Зәкия кайда да югалмый, хәрби госпиталь иданнәре дә юа, китапханәче булып та эшли, яралы солдатларга үзәк китапханәдән чанага төяп китаплар да ташый, госпитальнең местком рәисе итеп сайлангач, Чуашстаннан кадәр орлык юнәлтеп, бәрәңгесен дә чәчтерә, шул бәрәңгене урламасыннар дип кырда төнге каравылда да тора. Район партия комитеты булдыклы хатынны, партия мәктәбендә укытып чыгаргач, Г.Камал театрына әдәби бүлек мөдире һәм партоешма секретаре итеп жибәрергә ниятли. «Син, профсоюз өлкә комитеты президиумы әгъзасы буларак, анда күп йөрдең, артистлар мохитен беләсең»,—диләр аңа. Тик Зәкия театрга барырга теләми, Гариф Гобәй тырышлыгы белән радиокомитетка—балалар редакциясенә урнаша. Кара сакал кая барсаң да артыңнан калмый дигәндәй, биредә дә аңа местком рәисе камытын кигезәләр. Кыш житә, утын юк, бинада 17 мич ягылырга тиеш! Житәкчеләр тагын аңа ялваралар. «Зәкия, хужалык эшен дә ал инде»,—диләр.

Шул кышны 400 куб метр утын ташый ул. Машина әржәсенә үзе төйи, үзе бушата. Житмәсә, «Тизрәк бул, зуррагын сал», дип шофер ашыктыра.

Мәскәүдән тәэминатчы штаты килгәч, житәкчеләр ыкы-мыкы итенәләр. Янәсе, иптәш Садыйкова, эшли алырсың микән? Ә-ә, ди Зәкия, бушлай чиләнгәндә эшләде апагыз, ә хәзер юкмы? Женлекамал шикелле 6 ай вакыт бирегез, шунда күрерсез!

Радио белән телевидение кушылгач, Зәкия Садыйкованың мәшәкатьләре икеләтә арта. Ул чираттагы ялында Мәскәүгә барып тәэминатчының вазифалары нидән гыйбарәт икәнен өйрәнә, кирәк-яраклар артыннан чаба. «Квартал бетә, ә сез безгә бернәрсә дә жибәргәнегез юк»,—ди ул Бөтенсоюз радиокомитетының тәэминат бүлегендә утыручыларга. Жибәрдек, диләр тегеләр, күз дә йоммыйча. Зәкия тикшертеп карагач, ах та вах киләләр. Казан урынына ялгышып Рязаньга озатканнар икән әйберләрне! Зинһар, башлыкларга әйтмә, үзең кайтып житкәнче барысын да жибәрербез, диләр.

Эш белән кайнап яшәгән хатын беркайчан да йөрәгеннән Мусаның исемен сызып ташламый. «Сатлыкжан» дигән сүзгә ышанмый ул, кызында атасына карата олы мәхәббәт тәрбияли, синең әтиең—Җәлил, дип тәкърарлап үстерә.

— Люция әтисенә охшаганмы?

— Бәләкәйдән ук «Муса бу», диләр иде. Берзаман артист Ситдыйк Айдаров Ташкентка килде дә сабыйга карап: «И, кызың Мусага охшаган икән»,—ди. Люциянең атлап йөрүләре тач әтисенеке. Муса ике аяк сөяген бергә бәреп атлый иде, кызы да шулай.

1954 елда СССР Югары суды Люция белән Альбертның М.Җәлил мирасына хаклары бар дигән карар чыгара. Шагыйрьнең «Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска» дип аталган васыятендәге (1943 ел, декабрь ае) «Моны язды татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил. Аның тарихы болай: ул 1906 елда туган. Гаиләсе Казанда һәм Мәскәүдә» дигән юлларны укысаң, бөтенесе дә аңлашыла кебек.

Мусаның җәзалап үтерелүе турындагы белешмә закон нигезендә алар кулына да тапшырыла.

— Ә.Ерикәйнең «Әти безнең кайтмас инде» исемле шигыренә сценарий язган идем,—дип сөйли Зәкия апа.—Шуны шагыйрьгә күрсәтергә дип, Язучылар берлегенә киттем. Барсам, Әдәби фонд сәркәтибе Халикъ Садри очрады[1]. «Зәкия,—ди бу,—йөзләрегез тәмам агара хәзер»,—ди. Аңламадым. «Минем йөземнең каралганы да юк»,—дидем. «Мусаның икенче дәфтәре килде, син аның почеркын таныйсыңмы?»—ди. «Ничек танымыйм, без хат алышкан кешеләр бит»,—дидем. «Дәфтәрне райкомга укырга алып киттеләр әле»,—ди Садри.

Закир Тинчурин китап нәшриятының партоешма секретаре иде, аңа дәфтәр хакында белгерттем, ул Зөбәйдә атлы сәркәтип кызны чакыртты да, дәфтәрне бастырып, бер данәсен Зәкиягә бирерсең, диде. Төн ката елый-елый Мусаның язмаларын укыдым. Ул дәфтәрнең данәсе бүген дә архивымда саклана.

Дәфтәрнең озак еллар дөньяга чыкмавына эчем пошып берәүдән төпченгәч, кисәткәннәр иде мине: «Тик кенә тор, җиле сиңа да тияр», дип. Куркыталар, янәсе.

Ә Зәкия куркаклардан булмаган. Бервакыт Хәсән Туфан белән Ибраһим Салаховны Опера һәм балет театрында күрә ул. Ике әдипнең төрмәләрдә утырып, әлегә «халык дошманы» тамгасыннан арынмаган көннәре. Яннарына килеп исәнләшергә берәү дә җөрьәт итми. Шунда бәләкәй генә буйлы Зәкия йөгереп килеп икесен дә кочаклап ала. Икенче көнне Яңа Бистәгә әнисенә кунакка, пилмән ашарга алып китә.

— Зәкия апа, Муса белән ни дәрәҗәдә якын булуыгыз турында кешеләргә сөйли идегезме?

— Кычкырып йөрмәдем, белгәне белде, белмәгәне юк. Мәскәүдә бер тапкыр сорыйлар, сезнең радиода Муса Җәлилнең иптәше эшли икән, нинди әк ул, диләр. Буе минем хәтле, кара гына, дим. Минем урынга калган тәэминатчы Мәскәүгә баргач, аңа, Зәкиягә сәлам әйт, дигәннәр. «Ә сез аның кем икәнен белә идегезме соң?—дигән безнеке,—Ул Җәлилнең хатыны булган кеше». Шаккатканнар, кара, бездән яшерде, дип.

«Мин кем!»—дип күкрәк төеп, дөнья шаулатып, үз өлешен, үз урынын даулап йөрмәгән шул Зәкия, йөрәгендә беренче мәхәббәте хакында якты хатирәләр саклап, тын гына гомер кичергән. Чү, гомер елгасы тын гына акмаган бит аның! Язмамның башында, ул 80 яшендә генә ялга чыккан, дигән идем, бу һич тә шаярту түгел, радиокомитетта гына да ул 47 ел 7 ай хезмәт көчен түгә! 56 яшендә ял йортына комендант булып күчә. Радио-телевидение хезмәткәрләре җәйге матур көннәрдә нарат урманы эчендәге йортларда бала-чагалары белән рәхәтләнеп ял итәләр икән—алар Зәкия апага бурычлы. Заманында, Мәскәүдән акча теләнеп, Зәкия Садыйкова салдыра бу йортларны! Хуҗалыкка кирәк вак-төякне—мендәр-юрганын, кашыгын, тәлинкәсен, кәчтрүлен берәмтекләп үзе җыя. 80 яшьлек комендантның каравылчы йортына мич чыгарганда аяк сенере тартылмаса, эшен ташларга исәбе булмый әле. Аны анда бүген дә сагыналар, бүген дә юксыналар.

Ниһаять, табышмакка да җавап табылды... Менә кем икән ул, Зәкия! Менә кем!

1 СССР Әдәби фондының Татарстан язучылар берлегендәге вәкиле.

## Һәйбәт гайбәт

### Бүрек

«Салават күпере»нен баш мөхәррире булып эшли башлаган елны туганнары З. Хөснияргa затлы бүрек бүләк иткәннәр иде. Ләкин озак куанырга туры килмәде ана ул бүрек белән. Атна үтте микән, гадәтенчә соңлап эштән кайтып барганда башыннан салдырып алганнар.

—Ярый инде, бушка килгән иде,—дип юатты ул үзен.—Хатыннан яшереп, бүрекнең маңгай өстенә илле сум акча кыстырган идем, малай тугач бала тәпие юарга дип, шунысы кызганыч,—дип озак сөйләп йөрде.

Быелгы кышның зәмһәрирләре башланып, иске бүрегенең җылысы бөтенләй калмагач, базарга киткән бу. Бернәчә йөз меңгә алып (акчалар үзгәрде шул инде!), бик үк янадан булмаса да, матур гына бүрек киеп кайткан. «Идел»гә кергән чагында егетләр моны шундук күреп алдылар. Әлеге урлаткан бүрегенә охшаган икән, дип мактаучылар да булды. Зиннурның да хатирәләре уянды:

—Менә шушы төшенә иске акча белән илле сум яшергән идем,—дип сөйләп китте ул. Һәм бүрегенең маңгай турын кайтарып күрсәтте.

Аннан урталай бөкләнгән яшел кәгазь акча килеп төште. Иске иллелек.

Гали Мәүли.

### Хыялый

Татар академия театры янынннан үткәндә дуңгыз акырган тавыш ишетсәгез, гөнаһ алып, чучка суялар икән, дип уйлый күрмәгез. Шамкай акыра анда. Зөлфәт Хәкимнең балалар өчен язылган «Кар малай» исемле яңа пьесасында Рәшит әфәнде, ниһаять, гомере буе хыялланганын—дуңгыз ролен уйный.

### Апарадан—Афродита

Башкорт язучысы Й. Солтанов үз халкының тарихы турында күп хезмәт язган кеше. Менә быел да «Агыйдел»дә аның яңа әсәре чыкты. Ул анда да башкортларның бик борынгы халык булуын исбат итә. Баксаң, грекларның мифик Афродитасы да башкорт кызы булган икән, аның чын исеме Һапратути, имеш. Һәм ул греклар уйлаганча дингез күбегеннән түгел, ә апарадан яралган, дип яза Й. Солтанов. Бу сиңа тәгәрмәч уйлап табу гына түгел инде!

Й. Солтановның эзләнүләре безне дә гаҗәп табышларга этәрә. Без үз чиратыбызда Нефертитинең татар кызы булуын ачтык. Аның чын исеме Нәбирә түти булырга тиеш. Фамилиясе дә Гыйматдинова түгел микән әле...

И. Сантый

### Бергә йоклаган хатын

Заманында Югары Совет рәисе Батыев кабинетына чибәр генә бер ханым килеп керә. Бик мөһим бер документка кул куйдырасы бар икән.

—Сез кем буласыз соң?—дип сорый Батыев.

Хатын энҗе тешләрен елтыратып елмая:

—Әллә оныттыгыз дамы? Күптән түгел бергә йокладык ласа...

Батыев хатынның йөзенә жентеклэбрәк карый. Юк, хәтерли алмый бу чәчби белән чуалганын. «Бәлки, булып та онытылган хәлдер, бәласеннән башаяк...»—дип уйлап, тегенең кәгазенә кулын сырлап куя. Инде хатын рәхмәт әйтеп чыгып барганда, туктатып сорыйсы итә:

—Шулай да, әйтегез әле, без кайда, кайчан э-э... бергә... йокладык икән, ә?

Хатын көлеп җавап бирә:

—Шәһәр партактивы җыелышында ич. Сез президиумда йоклап утырдыгыз, ә мин—залда..

ШаМан

## Йомгак тәгәрәмәде...

Элегрәк әдәби ел йомгаклары ике көнгә сузыла иде. Шау-шулы уза иде җыелыш—ярсып бәхәсләшәләр, коридорда гасабиланып пыш-пыш тәмәке төтәтәләр иде. Соңыннан обком вәкиле язучыларга ничек язарга кирәген өйрәтеп кайтып китә иде. Хәзер җыелыш төштән соң башлана да ике-өч сәгатьтән тәмамланып та куя. Билгеләнгән чыгыш ясаучыларның (алар арасында һичшиксез Фоат Галимуллин була) мәдхиягә корылган нотыкларыннан соң фикер алышырга вакыт та калмый. Әллә язучылар кыска сөйләргә өйрәнгән, әллә йомгакларлык әдәби ел юк...

Әйе, җыелышлар хәзер шактый күңелсез үтә. Бары тик Әмир Мәхмүднең поэзиягә кагылышлы чыгышы вакытында гына шау-шу, көлешү булып алды. Югыйсә нотыкчы ике сүзнең берендә: «шигърият яңа үрләр яулый, яңа баскычларга күтәрелә»,—дип кабатлады. Белмим, монда нинди көлке бардыр? Ул үзе дә сизмәстән канатлы гыйбарәләр дә очырды: «шагыйрьләрнең чын йөзе ачыла бара. Ренат Харисның яңа китабы шуңа бер дәлил...» Моңарчы мөхтәрәм шагыйрьнең йөзе чын булмаган микәнни?

Шулай да иң жентекле чыгыш Гариф Ахуновныкы иде. Карт бүре шул! 1997 елда чыккан романнар турында сөйләде ул. Тәлгат Галиуллин романының корама теленә бик озаклап тукталганнан соң: «Роман әйбәт. Аның теленә бәйләнеп тору үзе үк мәгънәсез эш»,—диде. Чынлап та шулай шул: Роман язганда телнең ни катнашы бар?

Фикер алышырга Ркаил Зәйдулла да чыкты. «Мондый җыелышларның хәзер кирәге дә юк,—диде ул. —Әле аның съезды да кирәкми. Шуңа идарә былтыр уздырыласы корылтайны ике елга чигереп куйгандыр. Мөгаен, аны бөтенләй үткәрмәскә кирәктер. Өстәмә чыгым, һаман бер балык башы: әдәбият, әдәбият. Дөрес, кайберәүләрнең моңа эче поша булса кирәк. Имеш, идарәнең съезд карарын үзгәртергә вәкаләте юк иде. Нигә булмасын - кемнең кулында, шуның авызында! Әйе, съездны көтеп йөрүчеләр бар: узганында бер шешә аракы белән бер кило шикәр комы өләшкәннәр иде. Әйбәт ич! Ринат Мөхәммәдиевне дә гомерлек персидәтел итәргә кирәк. Анардан башка тагын кемебез бар: үзе чибәр, озын буйлы, карашыннан кызлар абына, кулына акча ябышып тора, төрек телен белә. Бик нык кыстасак, ул моңа авырлык белән генә риза булыр, мөгаен. Әдәбият дигәндә җанын бирергә әзер кеше ул! - дип нотыкчы язучылар союзы рәисенә ялагайланды. Әмма нигәдер аның сүзләрен туры мәгънәсендә кабул итмәделәр.

Җыелышта ахыргача утырган язучылар өйләренә зур күтәренкелек белән таралдылар. Инде моннан соң да әдәбият тәрәккый итмәсә!..

И'Сантый

## Хатын белән киңәшсәң

Конгрессның пленар җыелышында тәнәфес игълан иттеләр. Концертлар залының баскыч төбендә халык арасында Фикрәт Табеевны күреп алдым. КПССның Татарстан обкомы беренче секретаре. Заманында аның исемен ишетүгә

үк түрә-каранын коты алынган, имеш. Ялгыз гына басып тора, элекке мәһабәтлек тоныкланган, чәчләр сирәгәйгән, борынны зәңгәр тамырлар чуарлаган. Мин ана берничә сорау белән мөрәҗәгать итәргә булдым.

—Фикрәт ага, сез күп еллар Татарстанның башлыгы булып торган кеше. Үзегез идарә иткән республика белән бүгенге Татарстан арасында нинди аерма күрәсез?

—Аерма зур. Татарстан хәзер больше самостоятельность алды. Хәзер каждый «независимость» дип кычкыра ала. Ә без теләми идекме аны? Тик ул вакытта бу турыда сүз кузгатып кара—хәзер күтенә тибәләр иде. Но мин Татарстанның экономический потенциалын күтәрергә нык тырыштым. Промышленностьны үстерергә нык внимание бирелде. Шуңа күрә хәзер аяк терәп сөйләшергә дә була. Юкса хәерчене кем игътибарга алсын? Бүген эте дә, бете дә теге заманнарны сүгә. Хәзер һәркем батыр. Ә ул вакытта Мәскәүдән ни дә булса пробивать итү бик авыр иде. Татарстанның хәзерге уңышларында үземнең дә өлешем бар, дип уйлыйм.

—Татарстанның кайчан да булса бәйсез дәүләт буласына ышанасызмы? -

—Үзенә кирәгенчә хәзер дә бәйсез инде ул. Россиянең уртасында бөтенләй независимый булу...Мөмкин түгел. Армия булдыру, башка илләрдә посольстволар тоту нигә кирәк?

—Аурупа уртасында нәни генә дәүләтләр дә бар ич әле —Люксембург, Лихтенштейн, Ватикан...

—Ул бит Европа. Ә монда—Россия...

—Хәзер ни белән шөгыльләнәсез? Берәр җирдә эшлисезме?

—Пенсионер. Ну мина күпләр советоваться итәргә килә. Консультацияләр бирәм.

—Сезнең турыда бездә, чынмы-ялганмы дигәндәй, күп гыйбрәтле хәлләр сөйлиләр. Сүз ахырында шуларның берсен сөйлимме?

—Валяйте...

—Табеев кемнедер министр итеп билгеләргә чакыра. Теге кабинетка керә, үрә ката. «Сез министр булырга ризамы?» —дип сорый Табеев. Теге, әлбәттә, риза, әмма хуҗа алдында үзен бик тотнаклы, гаилә җанлы итеп күрсәтәсе килә. Уйларга бер көн вакыт бирегез, Фикрәт Ахметзянович, ди, хатын белән кайтып киңәшим. Конечно, конечно, ди Табеев, кайт, киңәш, иртәгә килерсең. Икенче көнне теге тагын кабинетка килә. «Йә, ничек?—дип каршы ала аны Табеев,—хатыныңбелән киңәштеңме, ул ризамы?» «Риза»,—ди теге. Табеев әйтә: «Мин дә хатыным белән кайтып киңәшкән идем, но ул уже риза түгел»,—ди.

Табеев көлде, минем җилкәмә сугып: «Ну, про бывших все можно рассказывать»,—диде дә Концертлар залына кереп китте.

И' Сантый.

Ша—Ярыш

# Ләбиб Лерон

## Балыкчы Галләм

— Хатын! Мин балыкка киттем!—диде Галләм һәм балык тоту өчен кирәк булган әйберләр салынган биштәрен кулына алды.

—Берүк бүген минтай ала күрмә,—диде хатыны. —Акчаң җитсә, скумбрия генә ал!

## Игълан

Җирән чәчле, тукмак борынлы, соры күзле (уң күз төбендә зәңгәр «фонарь» бар), буе ике уклау озынлыгы хәтле ирем югалды. Аны тапкан хатынга ак бәхетләр, корычтай нык сәламәтлек, мәңге какшамаслык нервы телим.

## Һәр хатын алтын булмас...

*(Ир-атларга әз-мәз киңәш)*

Булачак хатыныңны айлы төндә өенә озатканда «Сиңа йолдыз бүләк итәрием!» дип шапырынма, соңыннан үкенергә туры килмәгәе. Мәңге хәтереңдә тот: хатын-кыз заты туры мәгънәсендә аңлаучан.

Беркайчан да өеңә соңлап кайтма. Инде кайбер сәбәпләр аркасында соңга калып кайткансың икән, берүк хатының каршында мескенләнеп, акланып маташа күрмә. Ни сәбәпле сонаруыңны хатының үзе ничек аңлата бит әле. Әүвәл аның вариантын тыңлап кара. Бәлки ул вариант синең өчен кулайрактыр?!

«Балаларның берсе дә минеке түгел бугай...» дип уйлама. Әгәр шулай уйлыйсың икән, димәк, хатының да үзеңнеке түгел.

«Туйдым синнән, җирбит! Син хәсис белән бер минут та яшәмим. Хәзер үк әниләргә кайтып китәм!» дип хатының бик яман тузына икән, син сөенгәнеңне сиздермәскә тырыш. Хатыныңның кире уйлавы бар.



*Идел журналының бер төркем хезмәткәрләре (сулдан уңга) баш мөхәррир Рашат Низами, рәссам Фәридә Хәсъянова, беренче урынбасар Рәфикъ Юныс, бүлек мөхәррирләре Нәбирә Гыйматдинова, Ләис Харрасов.*

## ЧЕГӘН ҖЫРЛАРЫ

*Гомерлеккә күңелгә уелып калган хатирәләр була. Алар һич онытылмый, еллар үткән саен җетеләнә генә бара, сагындырып, һаман искә төшеп, яңарып тора.*

*Шундый татлы хатирәләремнең берсе—Минзәлә ягындагы Ык буе болыннарында һәр ел саен җәй җәйләүче чегән таборы, кичләрен шул таборның ымсындыргыч учак җемелдәүләре, төтен исе, чегән атларының пошкырынулары, кыз-егетләрнең тыенкы-серле көлешеп алулары, һәм әлбәттә инде, күңелне ашкындырганы—чегән җырлары. Булса да булыр икән сихри моңнар: кайгы-сагыш та, шуклык-шаянлык та, аякларны үзеннән-үзе биетеп-тыпырдатып торучы дәртле бию ритмнары да... Үзәкләрне өзеп гитара елый, гитара ыңгыраша... Мин яшүсмернең күңеле тула: «Их, шул чегәннәргә ияреп кит идең дә, бу соры- күңелсез, ач-ялангач ятимлек дөньясыннан мәңгегә котыл идең!..»*

Чегәннәр минем өчен әнә шулай гомергә серле, хөр-ирекле, матур бер халык *булып калды. Еллар үтеп, шәһәр тормышы белән яши башлагач, чегәннәрнең кайбер кырын эшләрен ишетеп-күреп, яшьлек хыялларымның чынбарлыктан шактый аермалы булуын тойсам да, чегәннәргә карата җылы хисләрем аз гына да тоныкланмады-төссезләнмәде. Алар мине һаман да ымсындыра, ашкындыра, әллә кая—әкияти дөньяларга чакыра шикелле.*

*Бу мавыгуым шактый еллардан соң, чегән халык авыз иҗатын өйрәнеп, «Чегән әкиятләре» дигән тәрҗемә китап булып җимешләнде (Татарстан китап нәшрияты, 1991). Китап саллы-калын гына, тиражы да зур—утыз мең иде, тиз арада таралып та бетте.*

*Ул китапның «Чегән җырлары» дигән кушымтасы да бар иде. Күләм сыйдырмау сәбәпле, анысы китапка кермәде, архивымда ятып калды.*

*Телевизор яки радиодан чегән җырлары ишетсәм, йөрәгем кузгала. «Кара әле, дим, безнең эстрада җырчыларыбыз хәзер нинди генә җырлар җырламый. Еш кына, берәр гүзәлкәйне мактап җырлаганда, җырчы тирәсендә чегән кызларына охшатып бөтерелеп йөрүче сылулар да була. Ә нигә чегән җырларын да татарча җырлап карамаска?!»—дим.*

*Менә шундый теләк белән укучыларга журнал сәхифәләрендә кайбер чегән җырларының татарча тәрҗемәсен тәкъдим итәргә булдым.*

*Әүвәле чегән җырлары турында бераз мәгълүмат биреп китү дә зарурдыр.*

*Рәсәйдә яшәүче чегәннәрнең җыр иҗаты төрле-төрле йогынтылар кичереп формалаша-камилләшә барган.*

*Бу очракта иң әлек чегән җырларының башкарылу үзенчәлекләренә, аларның бик борынгыдан килгән традицияләренә игътибар итәргә кирәктер. Чегән җырларының үзләренә генә хас алымнары бар: алар һәрвакыт диярлек гитарага кушылып, импровизация рәвешендә җырланып килгәннәр. Шунлыктан җыр текстларында еш кына тотрыклы ритмик үлчәм дә сакланмаган, рифмалар да булса булган, булмаса—юк, дигәндәй генә. Җырчы, гадәттә, гитарасын чиртеп, үзенә уңай*

*бер моң-аһәңле аккорд алган да, ритмик үлчәмне ирекле рәвештә «ай-һай»лаулары белән тулыландыра-тулыландыра яки гитара чиртүләре белән музыкаль паузатынышлар ясый-ясый җырлый биргән.*

*Икенчедән, чегән җырларына урыс халык авыз иҗатының тәэсире дә шактый көчле булган. Бу йогынты күп кенә җыр текстларының сюжетында-эчтәлегендә сизелә. Шул рәвешле Рәсәй чегәннәре гаять күп урыс җырларын үз иҗатларында «эретеп-кайнатып» чыгарганнар. Байтак кына урыс халык җырлары чегәннәрнеке дә булып киткән.*

*Аннары килеп, чегән халык җырларына аларның профессиональ сәнгатешәһәрләшеп киткән башкаручыларның атаклы чегән романслары зур йогынты ясаган. Рәсәй зыялылары, байлары-алпавытлары чегән романслары белән мавыкканнар. Күпләр үз йортларында җырчы-музыкант чегәннәр тотканнар. Шәһәр романсларының текстлары һәм музыкасы, нигездә, урыс шагыйрьләре һәм композиторлары тарафыннан иҗат ителеп, аннары башлап урыс җырчылары авызыннан яңгыраса да, ул романслар чегән җырчылары тарафыннан баетылыпбизәлеп, үзенә бер «чегән рухы» белән яши башлаганнар. Шуңа күрә саф чегән халык җырларында да ул романсларның аһәңе һәрчак яңгырап тора.*

*Биредә китерелгән җыр текстлары, оригиналдан үзгә буларак, еш кына рифмалаштырып тәрҗемә кылынды. Алай да кайбер җырлар ак шигырь итеп кенә дә бирелде. Укучы аларны укыганда үзе күрер, аңлап кабул итәр дип ышанабыз.*

*Тагын шуны да искәртеп үтәргә кирәк: бу җыр текстларының кайберләре «Сказки и песни, рожденные в дороге» (Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1985) дигән китапта ноталары-көйләре белән дә китерелгән. Чегән җырлары белән тирәннәнрәк кызыксынып, аларны җырлап карарга теләгән укучыларыбыз шул китапка мөрәҗәгать итә алалар.*

**Марс ШАБАЕВ**

---

## Тункаем

**Һай ли, салкынмы соң мине өшетә, кадерлем,**
**Һай, салкынмы соң мине туңдыра, әнкәем?**
**Туңдырадыр ул, өшетәдер тәмам**
**Ертык булганга тункаем ла минем.**

**Һай, чегәннәрнең, ромалэ, байларында**
**Җиде-сигез ат булыр, кадерлем.**
**Ә безнең күк, ромалэ, ярлысында,**
**Бездә, ромалэ, бер сукыр тиен юк.**

**Һай ли, чегәннәрнең кердем байларына,**
**Табынга дәшеп, җырлатмадылар.**
**Табын янынннан ук кудылар явызлар,**
**Калтырча атымны, һай бәла, урлап калдылар.**

**Һай ли, салкынмы соң мине өшетә, кадерлем,**
**Һай, салкынмы соң мине туңдыра, әнием?**
**Һай, тункайларым ертылып беткән минем,**
**Һай, кесәләрдә бер сукыр тиен юк.**

## Сәләмә

Йокларга ла ятсам, йокы алмый—
Әнкәм килеп баса алдыма:
Изге догаларын укый-укый,
Елый энкәм сабый баладай,
Елый энкәм сабый баладай.
Карагыз сез сәләмәләремә,
Кайгы-хәсрәт кенә йөрәктә.
Озак еллар йөрдем сукбайлыкта,
Туган җирләремнән еракта,
Сөйгән җирләремнән еракта.

Елый-елый кайтып киләм инде,
Әнкәемнең эзләп каберен.
Озак еллар йөрдем сукбайлыкта,
Гафу итче, энкәм-бәгырем,
Гафу итче, энкәм-бәгырем...

## Ал кулыңа гитара

Йәле, Макся,
Ал әле син, Макся,
Ал әле син кулларыңа гитара...
Тыңласыннар,
Тыңласыннар әле,
Тыңласыннар әле сине чибәрләр.

Йә, сөйләгез,
Йә, сөйләгез әле,
Йә, сөйләгез егеткә тик дөресен.
Нәрсә булыр,
Ниләр күрер Макся,
Быел Макся ниләр генә күрер соң?

## Шәлъяулык

Их, энекәем,
Шәлъяулык алсаң миңа,
Бүләк итәр идем аны
Каен сеңелкәемә.

Җик, эткәем, мал булсын шул,
Атның ефәк яллысын:
Барыйм әле, барыйм әле,
Кыз сорап карыйм әле.

Ефәк яллы җирән атым
Юыртмый да алдыра.
Җан сөйгәнем, кара кашым
Йөрәгемне яндыра.

## Барыймчы, чыгыймчы

Барыймчы, чыгыймчы,
Барыймчы, чыгыймчы
Караңгы урманнарга шул,
Караңгы урманнарга.

Барыймчы, кисимче,
Барыймчы, кисимче
Бер күпер өч баланнан ла,
Бер күпер өч баланнан.

Барыймчы, чыгарыйм,
Барыймчы, чыгарыйм,
Һай ла, өч йөз атымны шул,
Һай ла, өч йөз атымны.

Түзмәде күперем,
Түзмәде күперем,
Күперкәем сынып китте,
Атларым батып бетте.

Һай ла, жәл түгел лә,
Һай ла, жәл түгел лә,
Һай ла, өч йөз аткаем шул—
Жәл кара турыкаем.

Ефәктер ялкае,
Ефәктер ялкае,
Мин егетне каплыйдыр шул,
Мин егетне саклыйдыр.

Үткендер колагы,
Үткендер колагы,
Мин егетне аңлыйдыр шул,
Мин егетне таныйдыр.

Катыдыр тоягы,
Катыдыр тоягы,
Кара җирне тырныйдыр шул,
Кара җирне чокыйдыр.

Озындыр койрыгы,
Озындыр койрыгы,
Үз эзен себерәдер шул,
Үз эзен себерәдер.

Йомшактыр ирене,
Йомшактыр ирене,
Диңгез эчеп бетрәдер шул,
Диңгез эчеп бетрәдер.

Һай ла, жәл түгел лә,
Һай ла, жәл түгел лә,
Һай ла, өч йөз аткаем шул—
Жәл кара турыкаем.

## Черкиләр

Черкиләр тиде теңкәмә,
Усал Себер черкие—
Ах, тәмам талап бетерде.

Уйга баткан, ди, чегән:
Узмыш юк шул язмыштан—
Байга ялчы буласы,
Билкәеңне бөгәсе.

Ах, нигә мин хәсрәт чигәм?
Булдым бәхетсез чегән—
Ах, туйдым хәерчелектән.

Уйга баткан, ди, чегән:
Узмыш юк шул язмыштан—
Байга ялчы буласы,
Билкәеңне бөгәсе.

## Күлмәгем юк

«Юк күлмәгем, итәгем,
Әткәм, алып бир әле».
«Бер кияүгә чыгарсың,
Иркәеңнән сорарсың!».

«Әткәм, алка сатып ал
Елык-елык алтыннан.
Әгәр алып бирмәсәң,
Китәм—хәлем беләсең...»

Бакчаларга кердем мин,
Гөлчәчәкләр өздем мин.
Син яратсын, ошатсын дип,
Чәчләремә тездем мин.

Әткәм алып бирмәде,
Юк итәгем, күлмәгем.
Чыккан идем кияүгә—
Үтәлде бар теләгем.

## Туй җыры

Атлар чаба,
Тузан туза.
Сөйгәнемнең күзе кара,
Сөйгәнемнең күзе.

Атларыгыз сусаганнар,
Су бирегез аларга.
Сусадым мин сөйгәнемнең
Күзләренә багарга.

И ходаем, сөйгәнемә
Мулдан бир,
Мәхәббәтне, ак бәхетне
Мулдан бир.
Карагызчы сөйгәнемә—
Ул чибәр.
Кызганыч, кесәмдә уйный
Тик җилләр.
Шулай да яучылап барам,
Атым шәп.
Шул чибәргә өйләнергә
Тик исәп.
Ялкынлана күлмәккәем,
Ал гына.
Йөгереп чык, гүзәлкәем,
Алдыма.

## Чегән-молдаваннар

Һай, килгән, ди, бары
Бер чегән таборы.
Кайсы ыру болар?—
Чегән-молдаваннар.

Чалгый мыеклары,
Кара бөдрәләре.
Тартмасында чыңлый
Алтын тәңкәләре.

Чатырларын теккән
Кардай ак киндердән.
Ишек чабуларын
Чәчәк-чуклап чиккән.

Һай, җилдер син, җилдер,
Ефәк яллы атым.
Һай, кыз яучыларга
Шул таборга чаптым.

## Гиздем...*

Гиздем йөзәр чакрым җирләрне,
Тик тапмадым тиң бер гүзәлне.

Юлны Мәскәүгә бордым,
Шунда хатынлы булдым.

И ходаем, кызган син мине!
Гүзәлкәем, утыр, кил бире!

Алмачуар атлары,
Дагалары тамгалы:
Ал икесе—алтындыр,
Арт икесе—чиста көмештер.

---

*Бу җыр Л. Н. Толстойның «Тере мәет» дигән драмасына да кертелгән булган.

# ПУБЛИЦИСТИКА

Миркасыйм Госманов

## КАҺИРӘ ОЧРАШУЛАРЫ

БУ СӘФӘР күптән күңелләрдә борныган бер кыю хыялның тормышка ашуы кебегрәк булды...

Без, гарәп язма мәдәниятенең мәгълүм белгече ориенталист Әнәс Халид белән икәү, менә ничәнче көн инде Каһирә китапханәләрендә «актарынабыз». Урта гасыр Идел буе тарихына, шул җөмләдән Мәмлүкләр чорына караган яңарак мәгълүматлар эзлибез. Бер дәү китапны ябып куюга Әнәс чак кына уйланып калды һәм, үз-үзенә әйткәндәй, тезеп китте:

—Бу китапны моннан күп еллар элек Каһирәдә дә, Димәшкъта дә, Бәйрут белән Рабатта да эзләп таба алмаган идем. Менә, ниһаять, бастырып чыгарганнар икән... Карале, илле яшьлегемне шушы Каһирәдә билгеләгән идем бит!..—Хатирәдән ул бераз елмаеп та куйды.—Кунакханәдәге бүлмәмдә бер үзем бер калай шешә сыра эчеп билгеләгән идем. Ул чакта ике ай гомер уздырган идем бит монда...

* * *

БУ СӘФӘРНЕ «хыял» иде дип атауның үз сәбәбе бар. Мәгълүм булганча, Урта гасырларда Җучи Олысы (Алтын Урда империясе) белән ерак Мисырдагы Мәмлүкләр дәүләте арасында тыгыз сәяси-иҗтимагый һәм мәдәни-икътисадый мөнәсәбәтләр урнаша. Ике башкала, ягъни Сарай белән Каһирә арасында өзлексез илчеләр йөреп тора, дәүләт башлыклары үзара битикләр (дипломатик хатлар) язышып, бер-берсенә кыйммәтле бүләкләр җибәрешәләр. Дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытыр өчен кодалашу, ягъни туганлык урнаштыру фактлары да күзәтелә. Мондый күренешнең барлыкка килүенә, падишалар арасында була торган сәяси мәнфәгатьләрдән тыш, ике дәүләт хөкемдарларының, хәтта илдәге бөтен өстенге катламнарның тел уртаклыгы, беркадәре кан кардәшлеге дә (этник чыгышлары да) сәбәп иде, әлбәттә. Чөнки Мисырда хакимият башында торган мәмлүкләрнең күпчелеге чыгышлары буенча төрки телле кабиләләрдән, бигрәк тә кыпчаклардан иде.

Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Кешелек цивилизациясенең бер алтын бишеген тәшкил иткән бу Мисыр иленә—комлы тузанга күмелгән, мәгәр гаҗәп бәрәкәтле Нил дәрьясы буена борын-борыннан төрле баскынчылар—чит ил яулап алучылары омтылып торган. Шуңа күрә монда соңгы дүрт-биш мең ел дәвамында әллә ничә династияләр алмашынган. Безнең эрага кадәр 3000 еллар элек башланган борынгы фиргавен дәүләтләреннән соң монда азмы-

күпмедер гасыр финикиялеләр, ассорлар (ассирияләр), борынгы юнаннар (греклар), римлылар, фарсылар, бизанслар (Византия румнары), гарәпләр һәм тагын башка әллә кемнәр хөкем сөрәләр. Кайбер династияләр дистәләгән еллар дәүләт башында торсалар, икенчеләре әллә-ничә гасыр буе илне биләгән. «Бәхри» дип атала торган кыпчак мәмлүкләре (элекке гарәп хөкемдарлары тарафыннан сатып алынган коллардан оештырылган гвардия гаскәрләре; «мәмлүк» сүзе кол дигән мәгънәгә якын) 1250—1390 елларда тәхет яулап, Мисыр белән идарә итәләр. 1390—1517 елларда ил башында «бурҗ» дип исемләнгән кавказлы чиркәс мәмлүкләре тора. 1517 елдан алар Госманлы империясенә—Төркиягә буйсыналар. 1811 елда төрек солтаны тарафыннан Мисырның хөкемдары итеп билгеләнгән албанлы Мөхәммәд Гали (1769—1849), мәмлүкләрнең соңгы тамырларын йолкып алып, тора-бара Мисырны тәмам мөстәкыйль дәүләт дәрәҗәсенә күтәрә. Шул рәвешчә яңа династия—хәдифләр династиесе барлыкка килә. Тик илгә кул сузу тукталмый: инглизләр, французлар да Мисырны яулап алырга тырышалар. Шуңа күрә Мөхәммәд Галинең күп гомере сугышларда уза. Әмма гасыр ахырында илдә Англия тәэсире көчәя. XX гасыр уртасында мөстәкыйльлеге бик чамалы булган соңгы хәдиф Фарук тәхеттән төшерелеп, җөмһүрият игълан ителә (1953). Моннан соңгы вакыйгалар—генерал Нәгыйб, Советлар Союзы Герое Җәмал Габденнасыйр, Суәйеш сугышы, Әнвәр Садат үтерелү—болар инде безнең чор вакыйгалары...

Каһирә китапханәсендә «актарынудан» безнең максат, әлбәттә, бу биш-алты мең еллык тарихта казыну түгел иде (ул бай тарихны өйрәнүчеләр җитәрлек...). Безне билгеле бер чорга караган гарәпчә чыганаклар кызыксындыра иде. Әйтик, Болгар дәүләте, Хәзәр каганлыгы, бу иләрдәге борынгы шәһәрләр хакындагы мәгълүматлар. Шулай ук Идел буенда да, Нил үзәнендә дә кыпчаклар хөкем сөргән чорларны яктырткан хәбәрләр. Аларның күп булуы фәндә яхшы мәгълүм. Моңарчы киң билгеле булмаганнары да әледән-әле табыла тора. Әгәр XIII—XIV гасырларда Идел буеннан Мисырга китүче әдипләр, галимнәр хакында да яңа мәгълүматлар табылу ихтималын исәпкә алсак?..

Моңарчы без бер фактны—«Гөлестане бит-төрки» дигән мәшһүр әдәби истәлегебез авторы Сәйфи Сарайиның беркадәр гомере Мисырда узганлыгын яхшы беләбез. Әмма Идел буеннан ул якларга китүчеләр шул Сәйфи Сарайи һәм аның берничә дусты белән генә чикләнде микән? Әгәр алай гына булса, XIY гасырда төркичә әдәби тел Мисырда да тәэсирле телләрнең берсенә әверелер идеме? Шуңа да игътибар итик: XIII—XIV йөзләрдә уйгыр хәрефләре белән төрки телдә язылган битикләр (дипломатик хатлар) бер Идел буеннан гына китми. Мисырдан да мәмлүк солтаннары Сарай ханнарына үз мөктүпләрен төркичә яза башлыйлар!.. Тик, кызганычка каршы, мондый документларның үзләре генә сакланмаган. Дөресрәге, хәзергәчә табылмаган. Бәлки Мисырда аларның эзләре саклангандыр?..

Хәер, безнең эзләгәнебез бер төркичә истәлекләрнең генә эзләре түгел. Безне Урта гасыр Идел буе тарихына караган мәгълүматлар тупланган гарәпчә әсәрләр дә якыннан кызыксындыра. Андыйларның бер төркемен XIX гасырда В. Тизенгаузен дигән ориенталист бастырып чыгарган иде. Әнәс Халидның менә шул гаять әһәмиятле чыганаклар җыентыгын тулыландырып, төзәтеп яңадан чыгарырга теләге бар.

Әлбәттә, Алтын Урда тарихына караган чыганаклар белән кызыксыну безнең гасырда да дәвам иткән. Тик СССРда күпкә кадәр бу юнәлештә актив эшләү мөмкинлеге юк иде. Бигрәк тә Үзәк Комитетның 1944 елгы карарыннан соң. Сарай—Каһирә мөнәсәбәтләрен яктырту да тыелган темалар исәбенә керә иде. Бары 1960 елда Мәскәүдә уздырылган XXY Халыкара ориенталистлар конгрессында

яңгыраган бер докладта—Мисырдан килгән профессор Әмин әл-Холиның чыгышында әлеге сюжет әтрафлы яктыртылыш таба. Каһирә университетының профессоры үзе белән Мәскәүгә шул темага багышланган китапның кульъязма текстын да алып килә. Хезмәтнең гаять эчтәлекле, нык дәлилле булуы һәм, иң мөһиме, ул елларда СССР белән Мисыр (Берләштерелгән гарәп җөмһүрияте!) арасында хөкем сөргән «кода-кодагыйлыкның» тәэсире нәтиҗәсендә әлеге китапны русчага тәрҗемәләп, «Связи между Нилом и Волгой» дигән исемдә, 40 битле брошюра итеп, бастырып чыгаралар (Мәскәү, 1960). Әл-Холи китабы дөнья күргәч, ленинградлы автор Салих Закировның шул темага караган бер популяр китабы да чыга алган иде.

Каһирәгә килеп, «Китап йорты» (Дар-ел-көтб) дип атала торган иң зур дәүләт китапханәсендә үз эшебезне шул Әмин әл-Холи әсәрләрен караудан башладык. Галимнең әлеге әсәре 1964 елда гарәп телендә дә басылып чыккан һәм вак хәрефләр белән җыелган гарәпчә оригинал 110 бит тәшкил итә икән! Димәк: русча тәрҗемәдә китапның яртысы, иң кимендә өчтән бер өлеше кыскартылган—төшерелгән булып чыга. Ә совет чорында тарихи хезмәтләрдән нәрсәләр күбрәк кыскартылуын күз алдына китерүе артык кыен булмаса кирәк.

Безнең үтенеч буенча шул китапның ксерокүчермәсен тиз генә эшләп бирделәр. Аны актарып утырганда, әл-Холиның гарәпчә басма өчен язган кереш сүзендә аның 1960 елда Ленинградта «остаз Халидоф» белән очрашканлыгы телгә алына.

—Әйе, без беркадәре әңгәмәләшкән идек,—ди Әнәс Халид.—Хәтерем ялгышмаса, сүз Тизенгаузен китабына өстәмәләр кертеп яңадан бастырып чыгару хакында барган иде.

Бу хәбәр миңа беркадәре кызык булып тоелды. Чөнки Әнәс Халидның Алтын Урда тарихына караган әлеге җыентыкны яңадан бастыру идеясе белән мавыгуы, мин моңарчы уйлаганча, соңгы елларда гына башланмаган икән. Юкса безнең арада бу хакта сүз моннан ике-өч ел элек булган иде.

Мәсьәләнең бу ягына игътибар итү очраклы түгел. Моңарчы күпләр өчен, җөмләдән миңа да, саф гарәпче, гарәпчә язма истәлекләр белгече буларак танылган Әнәс Халид, баксаң, 60 еллардан бирле үз халкының тарихын да кайгыртып яшәгән икән. Фикерләрем төгәлрәк аңлашылсын өчен галим хакында тулырак мәгълүмат бирү, аның тәрҗемәи хәленә киңрәк тукталу зарур булыр.

Әнәс Бакый улы Халидов 1929 елның 25 февралендә хәзерге Буа районындагы Казма авылында гади игенчеләр гаиләсендә дөньяга килә. Шул ук вакытта нәсел агачының бик үк гади булмаган тармаклары да бар: аның бабасы Мөхәммәдзакир, мәсәлән, хәлфә булып, мәдрәсәләрдә шәкертләр тәрбияләгән; үз әнисе Зәйнәп тә (кыз фамилиясе Мостаева) яшь чагында кызлар укыткан. Аерата 1905 елда туган әтисе Мөхәммәдбакыйның тормыш юлы гаҗәп катлаулы да, кызыклы да була. Моңа махсус тукталу артык булмас.

Егет чагында Бакыйга шактый дөнья гизәргә туры килә. Бары 20 елларда Ленинградта мәшһүр дин әһеле, галим Муса Биги Җарулладан гарәп теле буенча дәресләр алу мөмкинлегенә ирешә. Ләкин советлар тарафыннан атаклы җәмәгать эшлеклесе илдән сөрелгәч, житәкчесез калган шәкертләрдән өч егет—бертуган Габдулла, Габдрахман Таһирҗановлар һәм Бакый Халидов—бәхет эзләп ил гизеп китәләр, Бакуга барып чыгалар, аннары Ашхабадка юл тоталар. Монда алар берара татар журналистлары ярдәмендә оештырылган төрекмәнчә гәзитләрдә эшлиләр. Шул елларда фарсы телен өйрәнә башлыйлар. Ниһаять, 1934 елда алар «яңача» укырга дигән карарга киләләр. Нәтиҗәдә, Таһирҗановларның олысы Ташкентка, Габдрахман Ленинградка юл тота. Бакый исә, Казанга килеп университетта рабфакка керә,

аннары механика-математика факультетында астрономия буенча белгечлек ала. 1940 елны аны эшкә Ташкент обсерваториясенә җибәрәләр. Ләкин нәкъ шунда аның тормыш юлы тагын кырт борыла: 1941 елда ул армиягә алына һәм фарсычадан хәбәрдар Бакыйны хәрби тылмач сыйфатында Иранга җибәрәләр. Анда тынгысыз Бакый, фарсычаны камилләштерүдән тыш, пушту телен дә өйрәнә. 1945 елда Ташкентка кайта һәм 1946 елда Ташкент университетында яңа ачылган шәрекъ телләре факультетында бер-бер артлы пушту, фарсы, гарәп телләрен укыта. 1952 елда пушту теле буенча диссертация яклый. Моннан соң гарәп теле кафедрасын җитәкли. 1962 елда гарәп теле буенча мәгълүм дәреслеген нәшер итә. 1968 елда вафат булган Бакый Халидов китабы хәзергә кадәр иң яхшы дәреслекләрнең берсе дип исәпләнә.

Бу урында тагын бер нәрсәгә игътибар итү кирәктер. Элекке гел бәхет эзләүче, гел көченеп һөнәр алыштырып йөрүче татар «ала канатларына» хас рәвештә Бакый да егерменче елларның уртасында ук үз авылында өйләнгән була. Шуңа күрә вакыт-вакыт Казмага кайткалый, бер-бер артлы балалары туа тора. Авылда сыер савучы булып эшләгән җәмәгате Зәйнәп апа балаларын тәрбияләп үстерә. Ташкент обсерваториясендә эшләгән чакта Бакый ага үсмер улы Әнәсне үз янына алдыра. Шунда Әнәс сугыш елларында Ташкентта эвакуациядә яшәгән ориенталист галимнәрне күрә, аларның кайберләре белән якыннан таныша. Мәсәлән, атасының элекке дусларыннан Габдрахман Таһирҗанов, Әмир Нәҗипләрдән тыш, мәгълүм ориенталистлардан Е. Бертельс, А. Семенов, В. Беляев, М. Боголюбовларны күрергә, аларның әңгәмәләрен ишетергә туры килә.

Бу фактларга махсус игътибар итүем очраклы түгел. Элек авылда, беркадәре вакыт Казанда, аннары Ташкентта татар мәктәпләрендә җидееллык белем алган Әнәс урта мәктәпне русча укып тәмамлый. 1946 елда ул Ленинградка юл тота—андагы мәгълүм университетның мәшһүр шәрекъ телләре факультетына керер өчен. Конкурсны һәм уңышлы, һәм көч-хәлгә дигәндәй узган Әнәс гарәп теле бүлегендә чын-чынлап белем алу бәхетенә ирешә.

Бәхет сүзен куллануым да очраклы түгел. Атаклы академик Ю. И. Крачковскийдан, кайчандыр Ташкентта үз күзләре белән күргән «тере профессорлар» В. И. Беляев, И. Н. Винников белән әле генә сөргеннән кайткан мәгълүм А. П. Ковалевскийдан гарәп теле, гарәп әдәбияты буенча лекцияләр тыңлау, алар җитәкчелегендә курс эшләре, диплом хезмәтләре язу күпләргә (һай, бик күпләргә!) тәтемәгән бәхет... Болардан тыш аңа мәшһүрлеге, дәрәҗәләре ягыннан элгәргеләреннән бер дә ким булмаган атаклы Мисыр тарихчысы В. В. Струве, күренекле тюрколог А. Ю. Якубовский, мәгълүм иранчы И. П. Петрушевский, гаҗәп күпкырлы белгеч В. М. Жирмунскийлардан да лекцияләр тыңларга туры килә... Болар классик рус ориенталистикасының чын мәгънәсендәге «соңгы могиканнары» иде. Алар үз нәүбәтендә белемлелек, намуслылык ягыннан соңгырак дәвер галим-голәмәләреннән күпкә югары торган дөньякүләм мәшһүр В. В. Радлов, В. В. Бартольд, П. К. Коковцев, А. Н. Самойлович, К. А. Иностранцев, Б. Я. Владимирцов һәм башкаларның шәкертләре иде...

Сугыштан соңгы ярым җимерек Ленинградта үҗәтләнеп белем эстәгән Әнәсне, укуын тәмамлауга ук, аспирантурага тәкъдим итәләр. Аспирантураны ул «Таха Хөсәеннең әдәби прозасы» дигән темага диссертация яклап тәмамлый (1954).

Бу урында тормышның бер кызыклы очрагын билгеләп узасы килә. 1998 елның 30 ноябрендә кичен Каһирәгә килеп, без тукталган «Президент-отель» кунакханәсе шул яңа чор мисыр-гарәп әдәбияты классигы Таха Хөсәен исемендәге урамда урнашкан икән.

Иртәгесен урамга чыгып, туктаган урамыбызның әлеге язучы

исемендә булуын белү Әнәстә төрле хисләр, хатирәләр уяткан иде. Аның болай дулкынлануы минем өчен дә уйланырга сәбәп булды. Дөресен әйткәндә, аның беренче зур гыйльми хезмәте яңа дәвер гарәп әдәбиятына багышланган булуы минем өчен яңалык иде. Чөнки галим белән утыз елдан артык таныш булсам да, мин аны нигездә борынгы һәм Урта гасырлар чорына караган гарәпчә язма истәлекләрнең зур белгече сыйфатында белеп килә идем. Мәсәлән, аның сәяхәтче Әбү Дулаф язмалары, Әбү Рәйхан Бируни хезмәтләре, Усама ибне Мункыйз әсәрләре, Әбел-Фәраж «хикмәтләре», Ибне Сина (Әбүгалисина) мирасы, «Диване лөгатит-төрк»нең кайбер чыганаклары, Табари тарихы өстендә эшләвен, гарәпчә борынгы кульязмаларның каталог-тасвирламалары һәм гомумән классик гарәп язма культурасына багышланган фундаменталь монографияләрнең авторы булуын яхшы белә идем. Йөздән күпкә артык мәкаләләренең, китапларының өч дистәдән артыгы русчадан гарәпчәгә, инглизчәгә тәрҗемә ителеп, Каһирәдә, Димәшкъта, Бәйруттә, Күвәйттә, Лондон белән Парижда, Будапешт һәм Калифорниядә басылган булуы да мәгълүм иде. Алар нигездә классик истәлекләргә, димәк, борынгы чор ядкәрләренә багышланган хезмәтләр. Баксаң, Әнәс Халидның яңа һәм өр яңа чор гарәпләренең рухи мәдәниятләренә караган хезмәтләре дә бар һәм шактый икән. Әйе, ул гарәп филологиясе буенча киң колачлы, тирән белемле галим.

Моның шулай икәнлеген башка фактлар да раслый. Мәсәлән, ул 1961 елдан, кем әйтмешли, «кандидат кына башы белән» Көнчыгышны өйрәнү институтының элек гел академик Ю. И. Крачковскийның «канаты» астында булган мәшһүр «Гарәп кабинетына» җитәкчелек итә. 1978 елдан бүгенгә кадәр, әлеге «кабинет» Урта шәрекъ секторына үзгәртелгәч тә, шуның башында тора.



*Илнең мәгариф министры (уртада) профессор Әнәс Халидовны Марокко короле Хәсән II белән таныштыра.*

Галим абруеның халыкара урынын күрсәтә торган дәлилләр дә җитәрлек. СССР һәм Русиянең зур шәһәрләреннән тыш, гарәп һәм инглиз телләрендә яңгыраган докладлар белән ул, 1966 елдан

башлап, Аден, Алжир, Багдад, Бәйрут, Димәшкъ, Каһирә, Күвәйт, Рабат шәһәрләрендә, шулай ук Будапешт, Галл, Лондон, Лейден, Париж һәм Хельсинкиларда халыкара конференцияләргә катнаша. Гарәп илләрендә уздырылган халыкара гыйльми конкурсларның жюри әгъзалыгына чакырылуы, хөрмәтле кунак сыйфатында әмирләр, корольләр белән дә очрашкалавы шуңа дәлил булса кирәк (моны раслаган бер фоторәсем журналга да тәкъдим ителә). Шулай да Ә. Халид үзенең фәнни дәрәҗәсе хакында аз уйлана. Бары 1983 елда гына ул «Гарәпчә кулъязмалар һәм гарәп язма традициясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 1987 елдан профессор.

Диссертацияләр яклауда, формаль гыйльми дәрәҗәләргә омтылуда Әнәснең болай беркадәре «сүлпәнлек», ашыкмаучанлык күрсәтүе, минемчә, очраклы түгел. Бу хәл аның холкындагы үзенчәлекләргә бәйле булса кирәк. Шуңа күрә галимнең шәхес буларак кайбер сыйфатларына да тукталу кирәктер дип уйлыйм.

Әнәс Халидны, гадәттә, коры һәм кырыс кеше диләр. Кайберәүләр хәтта сүзгә күнмәс кире, холыксыз дип тә өстәп куялар. Мин исә, үзе белән 60 еллардан бирле таныш, турыдан-туры мөнәсәбәттә торган кеше буларак, аны башкачарак характерлар идем. Гыйльми мәсьәләләр буенча фикер йөрткәндә дә, кешеләр, бигрәк тә яңа танышлар белән мөнәсәбәткә кергәндә дә, ул үзен бик сак, җаваплы тота, башкалардан да шундый ук җавап көтә. Буш сүз, нигезсез дәгъвачелекне кабул итмәс. Бигрәк тә өрсезлекне, тыйнаксызлыкны җене сөймәс. Дилетантлардан, ягъни саййозәрләрдән, бигрәк тә гыйлем битлеге кигән наданлыктан читкә китәргә тырышыр (фән тирәсендә дә оятсыз карьеристлар, «җиңел әдәпле» кешеләр дә аз түгел бит). Үзе ышанмаган, йәисә ышандырырлык итеп әйтелмәгән фикерләрне «күңел өчен генә» дигәндәй хуплап тормас; «ярар әле» дип буш вәгъдәләр бирмәс. Вәгъдәсезлекне үзе дә кичермәс. Мондый чакларда фикерен турыдан ярып, хәтта кискен рәвештә әйтүдән дә баш тартмас. Һәрхәлдә, ул җиңел холыклы кеше түгел. Шуңа күрә аның кайбер гамәлләрен артык кырыслык, кирелек дип тә кабул итәргә мөмкиндер.

Әмма дәлилләрең җитәрлек һәм көчле икән, ул чакта Әнәс үзенең элекке карашларын үзгәртүдән дә баш тартмый—шыгырдап булса да чигенә. Аңлы гомеренең барысы да диярлек гел китаплар арасында, гел академик даирәләрдә узган, андагы чын зыялылык вә затлылык белән, кызганычка каршы, әхлакый түбәнлекләрне, икейөзлелекләрне дә җитәрлек күзәткән һәм, иң мөһиме, шул шартларда да сәяси-иҗтимагый «эшмәкәрлектән» читтәрәк тора алган галимнең сүздә дә, гамәлдә дә «үзе булып» калырга тырышуы табигый хәл, минемчә. Аның өчен гыйльми хезмәтнең сан ягыннан күләме түгел, ә эчтәлек, мәгънә җәһәтеннән сыйфаты, димәк, хакыйкатькә якынлыгы кадерле. Шулай ук мин аны тормышның төрле шартларына тиз һәм шома гына күнегүчән сыгылма холыклы кеше дип тә әйтмәс идем. Минемчә, аның табигатенә беркадәре айнык консерватизм, дәресрәге традициялек тә хас булса кирәк. Шуңа күрә ул бер кат кисәнче җиде кат үлчәү тарафындарак.

Бер үк вакытта ул кечтеки генә бер кызыктан кулларын селки-селки балаларча шаркылдап көлә ала. Кайбер чакларда юк кына нәрсәдән, әйтик, хәреф хатасыннан да ачуы килеп, пыр-пыр тузына башлый. Чак кына ошамаган сүздән дә кәефе кырылып, төксәеп калырга мөмкин. (Каһирәдә дә бер мәртәбә сүзсез һәм тавышсыз-нисез «кычкырыша» язган идек...) Кыскасы, сәбәбе булса, тәртәгә тибәргә күп сорамас...

Әнәс Халиднең тормыш юлы һәм характеры формалашуда ул үскән гаиләнең, әтисенең нинди урын тотканлыгы хакында югарыда беркадәре әйтелгән иде инде. Бирелә шуны гына өстисе бар. Бакый

ага Халидовның өч улы да билгеле кешеләр. Әнәснең абыйсы Әнвәр (1926), яшьли сугышта катнашып, «Мәскәүдән Ауропаның үзәгенә кадәр түшендә шуып барган» хәрби разведчик, полковник, хәзер Мәскәүдә яши. Энесе Әхмәт (1935) биология фәннәре докторы, профессор, Казан университетында укыта.

Галимнең үз гаиләсе дә аның үзе күргән тәрбиянең, эшчәнлеге белән тоткан юлының дәвамы кебегрәк. Хәләл җефете Лилия ханым Тугушева филология фәннәре кандидаты, борынгы уйгыр теле, иске уйгыр язуы буенча күренекле, хәтта бөтен Русиядә бердәнбер дип әйтерлек зур белгеч. Аларның олы уллары Искәндәр математика фәннәре докторы, профессор; икенче улы Камил исә компьютерлар буенча белем алган.

Галимнең гаиләсенә игътибар итүемнең тагын бер сәбәбе бар. Каһирәгә дип юлга чыккан чакта без Әнәс белән бер кыю хыял да корган идек. Әгәр, элекке кайбер танышларыбызның сүзләре дөрескә чыгып, хикмәт белән дигәндәй, Мисырда мәмлүкләр чорына караган борынгы документлар табыла калса, һәрберебезгә дә эш булачак: гарәп телендәге истәлекләрне Әнәс үзе тикшерер, гарәп язулы төркичә язмаларны мин өйрәнермен, ә инде уйгырчалары табылса, аларны, һичшиксез, Лилия ханымга тапшырырбыз... Тик барсы да хыял иткәнчә килеп чыкмады.

Каһирәгә килүнең икенче көнендә, әлбәттә, үзебез хезмәттәшлек иткән галимнәр эшли торган Айн-Шәмс университетына юл тоттык. Якын шәрекъ тарихын өйрәнә торган бүлегенә (кафедрасына) барып, танышларыбыздан профессорлар Мөхәммәд Сәйед Җәмалетдин, Насрулла Тарази, Гадел Савәйлемнәр белән очраштык. Болар узган елны Казанда булган һәм Алтын Урда тарихына, Идел буеның тарихи географиясенә багышланган безнең халыкара конференцияләргә катнашкан кешеләр иде.

Әңгәмәдәшләребездән карт профессор Насрулла ага шактый кызык язмышлы кеше иде. Аны бала чакта ук әтисе Үзбәкстаннан чит илгә алып китә. Әфганстанда, Иранда, Төркиядә һәм берничә гарәп илләрендә яши, төрле уку йортларында белем ала, ниһаять, Каһирәгә килеп урнаша. Алтмыш елдан артык читтә, күбрәк гарәпләр арасында яшәсә дә, ул үзбәк телен һич тә онытмаган (без аның белән күбрәк яртылаш үзбәкчә, яртылаш татарча гаплəштек). Төрекчәне дә әйбәт белә. Гарәпчә лекцияләр укый. Фарсы теле, фарсы әдәбияты һәм Иран тарихы буенча да дәресләр алып барган. Инглизчә һәм французча да иркен сөйләшә. Дөрес, туган теленә кардәш төркичә сөйләшүче табылганга аның сөенүе йөзенә чыгып тора...

Университетта минем исне китәргән нәрсә—аның ишек алдындагы, аудиторияләрендәге студентларның күплеге—мыжлап торуы иде. Мәсәлән, Каһирә өчен «уртача» дип исәпләнә торган Айн-Шәмснең без барган бер Әдәб (гуманитар) факультетында гына да 20 меңнән артык студент укый икән!

Студент кызларның кием-салымы, үзләрен тотышлары да минем игътибарны җәлеп итте. Озын күлмәк киеп, яулык ябынып йөрүчеләре белән чалбарлы, гадәти яланбашлылары да җитәрлек. Ләкин мини итәк ярышлары оештырып, әдәпсез чинашу, ямьсез чыркылдашу, тәмәке көйрәтү ише күңелсез галәмәтләр күзәтелми. Күпчелек халык гади һәм пөхтә киенгән. Монда мин 1996 елда Таһран урамнарында, андагы китапханәләр белән университетта күргән гел кара чүпрәккә төренеп йөрүче, борыннары гына күренеп тора торган, кара каргаларны хәтерләтүче хатын-кызлар очрамый диярлек. (Бары шәһәрнең иске һәм ярлы районнарында бит-күзен каплаган хатыннар күренгәли.) Укытучы хатын-кызлар да гадәти, якынча ярым ауропача дип әйтерлек стильдә киенгәннәр. Исәнләшү, сөйләшүләре дә табигый әдәплелек һәм хөрлек белән башкарыла.

Икенче көнне университеттагы дусларыбыз белән бергә-бергә Гарәп кульязмалары институтына бардык. Гарәп илләре Лигасы тарафыннан оештырылган, нефтькә бай әмирлекләр исәбенә матди яктан бик мул тәэмин ителгән гыйльми институт иде бу. Тик анда кульязмаларның үзләре түгел, бәлки барлык гарәп илләрендәге төрле китапханәләрдә саклана торган әһәмиятле кульязма китапларның микрофильмнары, фото һәм ксерокүчермәләре саклана. Институт хезмәткәрләре шуларны өйрәнү, аларның каталогларын, тасвирламаларын, кайбер сирәк мөһим әсәрләрнең исә тәгәл текстларын бастырып чыгару белән мәшгульләр.

Институт тарафыннан безгә бүләк ителгән белешмәлек китапларны кичен карап утыру шуны күрсәтте: бу институтта барлык гарәп илләрендәге кульязма китаплар хакында шактый бай мәгълүмат бер җиргә тупланган һәм гел туплана килә икән. Чорыбызның информация чоры икәнлеген исәпкә алсак, мондый институтның әһәмияте бәяләп бетергесез.

Әйткәнемчә, институт сирәк очрый торган аерым истәлекләрнең үзләрен бастырып чыгару белән дә актив шөгыльләнә икән. Алар бастырган бер китап безнең өчен дә мөһим табыш булып чыкты. Хәер, бу хакта алга таба махсус сүз булыр...

Югарыда бер мәртәбә телгә алынган Китап йортында (Дар-ел-көтб), аннары Гарәп теле институты китапханәсендә һәм Дар-ел-вәсаикъ (Документлар йорты) дип атала торган үзәк дәүләт архивында, бигрәк тә аның хәзинәләгендә булу, алардагы фондлар белән танышу нәтиҗәсендә без Каһирә өчен саналган көннәребезне кульязмалар карауга түгел, бәлки басма китаплар дөньясындагы яңалыкларны эзләүгә багышлау дөресрәк булыр дигән фикергә килдек. Моның бәхәссез сәбәпләре бар.

Беренчедән, архив документлары арасында безне кызыксындырырдайлары юк икән. Борынгырак чорга караганнары төрле җирле юридик актлар булса, калганнары Мөхәммәд Гали дәвереннән бирле җыела барган соңгы чор документлары. Мәмлүкләр чорына караганнары элекке заманнарда бөтенләй харап булган, яки XYI йөздә госманлы төрекләре тарафыннан Истанбулга күчерелгән... Һәрхәлдә, монда сакланмаган.

Икенчедән, бер кульязманы җентекләп карап чыгар, яхшы аңлар өчен дә күп вакыт, әллә ничә көн кирәк булачак, ягъни җиде-сигез генә эш көнебездә каралган истәлекләрнең саны ике-өчтән артмаячак.

Өченчедән, басма китаплар арасында да безнең өчен яңа, ягъни моңарчы мәгълүм түгел, йәисә исемнәре генә чит ил басмалары аша беленеп, үзләре Русия китапханәләрендә булмаган әсәрләр дә җитәрлек икән.

Димәк, ике-өч кульязма белән чикләнгәнче, дистәләгән китапларны өйрәнү күбрәк нәтиҗә бирәчәк. (Әнәс исә андыйларны минем кебек бармак белән төртә-төртә таныш сүзләрне, билгеле исемнәрне эзләп тормыйча, кем әйтмешли, диагональ буенча күз йөртеп кенә укый...) Шуңа күрә безнең күпчелек вакытыбыз борынгы чыганакларның басмаларын карап, алардан тарихыбыз өчен кирәклеләрен сайлап, шулардан тиз-тиз ксерокүчермәләр ясату эшенә багышланды.

Кичләрен исә, Мөхәммәд Сәйед Җәмалетдин өенә кунакка чакырылган бер очрактан башка, гел кулга төшергән күчермәләрне карап, бүләк ителгән йәисә сатып алынган китапларны актарып утырдык. Кафедан бүлмәләребезгә китереп бирә торган кайнар сөтле чәйне чөмерә-чөмерә ул истәлекләрдә очрый торган һәр яңалык турында сөйләшә-сөйләшә төнге унбер-уникеләр җитүен сизми дә кала идек. Ә бер кичне өченчеләргә кадәр Гарәп кульязмалары институтыннан алган китап белән мәш килдек.

Моңа сәбәп Әбү Фазыл Шиһабеддин Әхмәд бине Гали Ибне

Хәҗҗәр әл-Гаскалани (1372—1449) дигән мәшһүр гарәп галименең соңгы елларда ачылган һәм аерым китап рәвешендә басылып чыккан әсәре иде. Каһирәдә яшәп иҗат иткән Ибне Хәҗҗәрнең фәндә киң мәгълүм төп хезмәте күп томлы «Әд-Дәрр-ел-Кямин фи агъян әл-къәрн ес-саминә» (ягъни «Сигезенче гасырның күренекле кешеләре турында яшерен энҗеләр») дип атала. Ул һиҗри ел исәбе белән YIII йөздә, ягъни миладичә 1300—1397 елларда яшәгән, үлгән атаклы шәхесләрнең тормыш юлларына, эшчәнлек һәм иҗатларына караган материаллар җыелмасыннан гыйбарәт. Дөресрәге, шул чор мөселман дөньясының күренекле шәхесләре хакындагы атаклы био-библиографик энциклопедия. Аерым кешеләр хакындагы мәгълүматлар, мөселман дөньясында кабул ителгән кагыйдә буенча, шул шәхесләрнең вафат тарихларына карап бер-бер артлы урнаштырылган (Ибне Хәҗҗәр традициясен дәвам иткән Шиһабеддин Мәрҗанинең «Вафият»ы белән Риза Фәхреддиннең «Асар»ендә дә материаллар шулай вафат елы тәртибендә бирелгән).

Безне дулкынландырган китап исә «**Зәйл** әл-Дәрр-ел-Кяминә», ягъни «Дәрр-ел-Кяминәгә **өстәмә**» дип атала иде. 452 битле бу китапны 1992 елда фәннәр докторы Гъәднан Дәрвиш исемле галим Ибне Хәҗҗәрнең хәзерге бердәнбер автографы, дөресрәге, эшкәртелеп бетмәгән каралмасы буенча Каһирәдә дөньяга чыгарган. Г. Дәрвишнең кереш сүзенә караганда, «Зәйл»дә элекке томнарга өстәмәләр белән бергә һиҗри буенча IX йөздә (милади: 1397—1494) үлгән кайбер шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре дә теркәлгән икән.

Бу мәгълүматлар белән танышу Гарәп кулъязмалары институтыннан кайткан көннең кичендә үк булды. Мин үз бүлмәмә китерсеннәр өчен кичке чәйгә заказ биреп, ул килгәнче дип телевизор кабызып, кәнәфигә кунаклаган гына идем, кемдер каты итеп ишек шакыды. Чәй китерүчедер дип ишекне ачсам, анда Әнәс басып тора иде. Үзе әллә ничек елмайган, уң кулында сул кулының чәнчә бармагын «тешләгән» китап. «Тиле вәзиреңне сүндер, кызык нәрсә бар!—диде ул дулкынланып. Һәм, утырып та тормыйча, китапта тәртип буенча 44 нче бүлекчәнең—һиҗричә 801 елда үлгән Мәхмүт бине Габдулла әл-Гөлестани әс-Сарайи дигән кешенең тәрҗемәи хәленә багышланган мәкаләнең кыскача эчтәлеген сөйләп чыкты. Басмада нибары ярты бит чамасы урын алган, энциклопедия өчен уртача күләмдә булган мәкалә гаять бай эчтәлекле иде.

Мин кәгазь-каләм алырга дип тора башлауга, Әнәс ничек кергән булса, шулай ук тиз-тиз үз бүлмәсенә чыгып китте. Яңалыктан айнып өлгермичә утыра идем, ул тагын килеп керде: «Менә монда тагын икенче бер Сарайи хакында да бар икән!» Күп тә узмый, китапны тиз-тиз актара торгач, Ибне Хәҗҗәр «Зәйл»ендә гомумән дүрт Сарайи хакында мәгълүматлар булганлыгы ачыкланды.

Ә инде без, бераз айнып, китерелгән чәйгә тотынганда, ул тәмам суынган булып чыкты. Сәгать төнге өченчене күрсәтә иде...

Икенче көнне кичен китапханәдән кайтуга ук, «Зәйл»дәге безнең тарихка караган мәкаләләрне тәрҗемәләү белән шөгыльләнә башладык. Әнәс һәр җөмләне гарәпчә укып, шунда ук татарчага юлга-юл тәрҗемәли, мин кәгазьгә терки барам. Мәкаләнең бер өлеше беткәч, әлеге сүзгә-сүз тәрҗемәнең әдәбиерәк вариантын эшлибез. Тексттагы аерым исемнәргә, атамаларга Гъәднан Дәрвиш биргән бай искәрмәләрне дә исәпкә алабыз. Шулай итеп, бөтен кич буе Сарайилар хакындагы мәкаләләрне «үзләштерү» белән мәш килдек.

Хәер, эш процессы турында сүз куерткачы, аның нәтиҗәсе хакында да әйтергә кирәктер.

Һәр мәкаләнең башында тәрҗемәи хәле язылa торган шәхеснең тулы исеме, гыйльми дәрәҗәләре, титуллары китерелә. Мәсәлән, тәртип буенча 44 сан белән бирелгән мәкаләнең башы болай яңгырый иде: **Мәхмүл бине Габдулла әл-Гөлестани әс-Сарайи әл-Хәнәфи Бәдреддин.** Бу катлаулы исемдәге **хәнәфи** сүзе Мәхмүднең Ислам динендә

хәнәфийә мәзһәбендә торуын күрсәтсә, **бәдреддин** исә «Диннең яңа ае» дигән мактаулы дәрәҗәне белдерә. Гөлестани тәхәллүсенә карата Гъәднан Дәрвиш искәрмәдә шәхес хакында берничә чыганак күрсәткәч, мондый аңлатма биргән: «Фарсы шагыйре Сәгъдинең «Гөлестан» исемле китабын күп укыганы өчен шулай аталган. Ә ул китап төрки һәм гаҗәми *(фарсы—М. Г.)* телләрендә булган».

Шундый мәгънәле баштан соң китерелгән мәкалә текстының татарча тәрҗемәсен беркадәре адаптацияләп, ягъни текстның үз эчендә аңлатып тәкъдим итәм. Г. Дәрвиш тарафыннан бит итәгендәге аңлатмаларның кыскача мәгънәсе гади җәяләр [...] эчендә, аңлаешлылык өчен тәрҗемәчеләр өстәгән сүзләр почмаклы [...] җәяләрдә петит хәрефләр белән булыр. Текстны болай катлаулы рәвештә бирүнең үз сәбәбе бар: шулай эшләгәндә, документальлек сакланган хәлдә, Ибне Хәҗҗәр Гаскалани текстын Г. Дәрвиш биргән аңлатмалардан һәм тәрҗемә вакытында өстәлгән сүзләрдән аерып карау артык кыен булмас. Шулай итеп, мәкалә тексты түбәндәгедән гыйбарәт.

«Үз ватанында фәкыйһ [*шәригать хокукы белгече*] булып җитлеккән. Аннары Димәшкъка килгән һәм (574 һиҗридә [1178-79м.] Әмир Такъәвәддин Гөмәр нигезләгән шәфигый мәзһәбендәге) Әт-Такъәвийә дигән мәдрәсәдә урнашкан. Соңыннан Мисыр иленә күченгән. Аннары [*Алтынбога*] Чубани исемле (*зур дәрәҗәләр билигән, 792/1390 елда үтерелгән*) кеше белән бергә Сүриягә кире кайткан; Сүрия әмиренең наибы [*урынбасары*] булып торган. Бу кайту 789 һиҗринең рабигъ-ес-сани аенда [*1387 ел м. апрель-маенда*] булган иде һәм дә 670 һиҗридә ([*1271—1272 м.*] Әз-Заһир Бәйбарс Бундукдар нигезләгән) Әз-Заһирийә [*мәдрәсәсендә*] мөдәррис булып торган. ([*Шулай ук*] *564 һиҗридә (1169 м.) үлгән Әсәдеддин Ширкуһ нигезләгән*) Әсәдийә [*мәдрәсәсендә*] шәех булып торган. Өмәвиләр *(династиясе VII гасырда төзегән)* мәчетнең зур абруйлысы да иде. Аннары [*тагын*] Каһирәгә кайтып, *(757 һиҗридә [1356 м.] әмир Сәйфеддин Саргатмыши төзегән, Каһирәдә хәзергә хәтле сакланып калган мәдрәсә)* Саргатмышийәдә [*баш булып*] тора башлады. Соңыннан, [*солтан*] әз-Заһир *(баркук әл-Чиркәси)* Җәмаледдин әл-Гъәҗәмигә ачуланган чакта, аны да [*Сарайины да*] эзәрлекләгән иде. Аннары, Җәмаледдин белән [*солтан*] татулашкач, Саргатмышийә тагын Бәдреддингә [*Сарайига*] кайтарылды. Соңыннан әз-Заһир аны кятиб-ес-серр—яшерен эшләрне язып баручы итеп билгеләде. Бу эшне ул бик яхшы итеп башкарды. Ул үзе турында: «Шушы җаваплы эшкә билгеләнгәнемдә минем бер дирһәмем дә [*тәңкәм дә*] юк иде. Ә моннан соң падишаһлар рәтенә кердем»,—дип сөйли иде.

Язуы матур иде; зиһенлелеге, шигъри һәм чәчмә [*әсәрләр*] язуга сәләте бик югары иде. Һәръяклап белемле [*кеше*] иде. Шунысы да бар: [*якын белүчеләр*] аның бик тиз һәм җиңел кызып китүчәнлеген дә билгелиләр иде. [*801 елның*] җөмади-ел-әүвәл аенда [*1399 ел м. гыйнварда*] үлде, бик күп байлыгы калды, аны бәдрәфтә яшергән җиреннән таптырып, солтан әз-Заһир хәзинәгә алдырды» («Зәйл әд-Дөрр-ел-Кямина», 79—80 бб.).

Ибне Хәҗҗәрнең яшертелгән байлык турындагы сүзләре безне бераз фаразлар корырга мәҗбүр итте. «Моны,—диде Әнәс Халид уйга калган килеш,—Мәмлүкләр дәүләтендә дә тыныч тормышка ышаныч булмау белән аңлатырга кирәктер...» Ләкин, бу мәкаләнең шушы һәм башка төшләрен анализлый башлаганчы, «Зәйл»дәге башка Сарайилар хакындагы хәбәрләрдән дә кыскача белешмәләр китерик.

Китапның 86 битендә, 59-нчы тәртип саны белән һиҗричә 802/1399—1400 елда үлгән кешеләрдән **Ибраһим бине Габдрахман бине Сөләйман әс-Сарайи** телгә алына. Ибне Хәҗҗәр аның хакында да: «Үз илендә белем алып осталыкка ирешкән иде»,—дип язган. Ибраһим иң элек хәдисләр буенча күп укыган, күп галимнәр белән аралашкан, кайбер хәдис китапларына язылган хашияләргә—аңлатмаларга өстәмәләр

кушкан икән. Ул тотрыклы матур язу белән китаплар күчерергә яраткан, мәдрәсәдә дәресләр алып барган, зур ханкаларда да (дәрвешләр йортында) шәех булып та торган. Үлгән вакытында 60 яшьтә булган.

Безнең өчен кызыклы өченче шәхес **Йосыф бине әл-Хәсән—бине Мәхмүд әс-Сарайи әл-Асыл әт-Тәбризи** дигән кеше иде. Исем һәм титуллардан күренгәнчә, бу Йосыф чыгышы буенча Сарайда туган булып, соңгырак чор гомеренең бер өлеше Кавказдагы Тәбриз шәһәрендә узган (ике шәһәр исеменең тәхәллүс булуы шуңа ишарә итә). Мәгълүм булганча, Тәбриз шәһәре күпкә кадәр Җучи Олысының (Алтын Урданың) карамагында булып, соңрак Һулагулар тарафыннан басып алынган һәм бу Тәбриз өлкәсе, гомумән Кавказ арты өчен ике ил арасында ике йөз елга якын өзлексез сугышлар барган.

Ибне Хәҗҗәр мәкаләсенең башында ук Йосыф Сарайиның 730/1329—1330 елда туган булуын әйтеп, күренекле галимнәрдән остазларының исемнәрен санап чыга. «Күп төрле гыйлемнәрдән хәбәрдар югары белемле мөдәррис иде»,—дип, кайбер әсәрләрен телгә ала (әл-Бәйзавиның «Минһаҗ»ына шәрех язуын). Галим Тәбриздә торган чакта, шәһәрне Тука-Тимер ханның сугышчылары җимергәч, Йосыф Сарайи Мардин шәһәренә күченә, бераз вакыттан тагын Тәбризгә кайта. Шунда ул берничә хәдис китапларына шәрехләр яза. «Ул бик тәкъва, итагатьле һәм дөнья эшләреннән өстен булып, гыйлемгә бирелгән [кеше] иде»,—дип күрсәтә Ибне Хәҗҗәр. Хаҗ сәфәренә баруын әйткәч, автор: «Тормыш аңар нинди авырлыклар китерсә дә, ул һаман ачык күңелле булып кала иде»,—дип, галимнең гел күченеп йөрүен, 804/1401—02 елда Җәзирәт ибне Гомәр исемле шәһәрдә вафат булуын әйтә. Бәдреддин Гали һәм Җәмаледдин Мөхәммәд исемле укымышлы ике улы калган... («Зәйл...», № 167, 126—127 бб.).

«Зәйл»дә теркәлгән безгә кирәкле дүртенче шәхес **Шәрәф бине Әмир әс-Сарайи әл-Мардини** да Сарай шәһәрендә туып, шунда бер кадәре тәрбияләнгәч, Мардинга килеп торган икән. Монда ул кятиблыкка укыган, «дөрес һәм тотрыклы язу үзләштерүе вә үзенең яхшы рәвештә [башкаларны] укытуы белән дан казанган». Күп түрәләр аны үзләренә кятиб итеп алып, аңардан файдаланганнар. Хәтта аны Тимерләңнең улы үзенә хезмәткә чакырган, тик Шәрәф аннан качып калган. Төрле шәһәрләрдә хаттатлык (каллиграфия) буенча дәресләр биргән Шәрәф Сарайи 832/1428—1429 елда вафат булган («Зәйл...», № 625, 379 б.).

Ибне Хәҗҗәр әл-Гаскалани хәзрәтләренең яңа басылып чыккан китабыннан, ягъни «Зәйл»дән өстә генә «ялтырап яткан» исемнәр, дөресрәге Сарайи тәхәллүсе буенча гына сайлап алынган бу мәкаләләр хакында бик иркенләп фикер йөртеп булыр иде, әлбәттә. Әгәр китапта Г. Дәрвиш биргән күпсанлы өстәмә чыганакларга да мөрәҗәгать итсәң, тикшеренүнең күләме, минемчә, бермә-бер артыр иде. Ә инде «Зәйл»дә генә түгел, «Дөрр-ел-Кямине»дә тәхәллүсләре артык «кычкырып» тормаган башка кыпчакларны да чүпләп, әтрафлы итеп тикшерә башласак, тәгәл бер китап килеп чыгуы ихтимал... Ләкин андый тәфсилле эзләнүләрне киләчәккә һәм башкаларга калдырып, иң элек бер-ике гомум мәсьәләгә генә тукталып узыйк.

Игътибар ителгәндер: «Зәйл»дә Сарайи тәхәллүсен йөрткән дүрт кешенең өчесе үз туган илләрендә, ягъни Идел буендагы Сарайда ук, гарәп-фарсы телләрен кямил үзләштергән тирән белемле фәкыйһ—мөселман юриспруденциясе буенча дәрәҗәле белгечләр булып җитлеккән, Мисырга килгәч андагы зур мәдрәсәләрдә мөдәррислек итәргә, хәтта дәүләт идарәләрендә җаваплы хезмәттә эшләргә сәләтле зыялылар булган икән. Бу хәл моңарчы рус, совет тарих белемендә һәм шуңа сукырларча ияргүче кайбер татар авторлары тарафыннан Алтын Урда дәүләтенең мәдәни хәятенә карата йөртелгән тискәре шаблон фикерләрнең бөтенләй нигезсезлеген күрсәтсә кирәк. Чөнки XIY йөз гарәп дөньясы, бигрәк тә Мисыр дәүләте шул чордагы иң мәдәни, алдынгы илләрне

тәшкил итә иде әле. Тәре сугышларыннан һаман айнып җитмәгән, күп очракта ярым кыргый хәлдә булган Аурупа илләре исә алардан өйрәнә генә иде. Бу—беренчедән.

Икенчедән, әлеге анализлана торган истәлеккә һәм башка дистәләгән чыганакларга караганда, Алтын Урда һәм Сарайдан укымышлы төрки телле кешеләрнең гарәп илләренә, бигрәк тә Мәмлүкләр Мисырына күпләп күчерүләре XIY йөзнең икенче яртысына, аерата аның соңгы унеллыгына туры килә икән. Ягъни мәгълүм тагун чиреннән (кара үләт—чумадан) соң Җучилар империясендә барлыкка килгән башбаштаклык, тәхет өчен барган туктаусыз көрәш һәм, иң мөһиме, Аксак Тимер һөҗүме вакытында шәһәрләр җимерелгән, илнең бөтенлеге какшаган чорга карый икән бу характерлы һиҗрәт—киләчәге шик астында калган өметсез илдән качу күренеше. XX гасырда бер бөек империя башыннан ике мәртәбә кичкән хәләткә, тәмам җимерелү алдында торган хәләткә охшаган гыйбрәтле күренеш!..

Шул чорда төрки телле кешеләрнең кыпчак мәмлүкләре биләгән Мисырга күпләп күченүләрен анда төрки телле әдәбиятның күтәрелүе, төркичә-гарәпчә, гарәпчә-төркичә әллә ничә сүзлекләр, дәреслекләр язылуы да раслаша кирәк. Шул чор Мисыр тарихын җентекләп өйрәнгән Әмин әл-Холи үзенең югарыда телгә алынган хезмәтендә Каһирәдә төрки теленең киң таралуы аркасында язма гарәп теле кичергән «кыенлыклар» хакында махсус өйтеп уза. Хәер, моңа, ягъни төрки теленең дәрәҗәсенә ишарә итә торган бер кызыклы хәбәр безнең алдагы «Зәйл»дә дә бар. Мәсәлән, **Гайсә ибне Хәҗҗаҗ әс-Сәгъди әш-Шатранҗи** дигән, һиҗричә 807/1404—05 елда үлгән кеше хакында Ибне Хәҗҗәр мондый сүзләр язып куйган: «Шигырь язуга оста иде, бик күп төрле сүзләр куллана иде. Төрки телен белә иде һәм хирыс кешеләргә аны өйрәтә иде. Шатранҗ [шахмат] уенында оста һәм гали дәрәҗәгә ирешкән иде. Менә бу өч нәрсә—(шигырь язу, төркичә белү һәм шахматта оста уйнау!—М. Г.)—иң сәләтле, тирән белемле кешеләрдә генә очрый» («Зәйл», № 239, 162 б.).

Ибне Хәҗҗәр әл-Гаскалани ишарә иткән өч дәлилгә гаҗәпләнергә урын юк: бездә дә бит берәр «дәрәҗәле» телне белү иш өстенә куш булып йөри.

Инде килеп, тәрҗемәи хәлләре китерелгән шәхесләрдән иң мәшһүрләренә карата: «Мәхмүд Сарайи кем соң ул?..»—дигән сорауның куелуы табигый.

Мәкаләне беренче кат укуга безнең, ягъни Әнәс Халид белән икебезнең хәтергә иң элек «Гөлестане бит-төрки» әсәре, аның авторы Сәйфи Сарайи килеп төште. Текстны, бигрәк тә искәрмәләрне кат-кат җентекләп карап, Сәйф исеменә берәр ишарә-мазар булмасмы дип эзләндек. Чөнки икеләтелгән тәхәллүснең аерата Гөлестанинның кулланылуы, ә Сәйфи Сарайи биографиясе исә тәгәл билгеле булмавы андый шикләнүләргә урын калдыра иде. Өстәвенә безгә киңрәк мәгълүм «сәйф» сүзенең чын исем түгел, бәлки «кылыч» мәгънәсендәге псевдоним булу ихтималы хакында да фаразлар булуы билгеле. Шул ук вакытта Сәйфи әсәренең күчермәсе ахырына теркәлгән башка авторлар арасында Мәхмүд исемле берәүнең дә булуы, шигырьләр язуы мәгълүм. Аның тәрҗемәи хәле, эшчәнлеге хакында кайбер өзек-өзек мәгълүматлар Әмин әл-Холига һәм кайбер төрек авторларына күптән билгеле булган. Бу хакта Х. Миннегуловның «Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты» исемле китабында шактый киң язылган. Тик анда Мәхмүднең үлгән вакыты 1374 ел дип (32—33 б.), бәхәсле саннар кабатланган. Димәк, төрек галимнәре файдаланган чыганак вакыйганың замандашы булган Ибне Хәҗҗәр әл-Гаскаланиның ышанычлырак хәбәренә туры килми дигән сүз. (Әгәр төрек авторлары соңгы галимнең берденбер автографын караган булсалар—бу да ихтимал—Мәхмүднең үлү тарихына күрсәткән саннар ялгыш укылган булып чыга.)

Шулай итеп, җыеп әйткәндә, тикшерәсе, уйланасы мәсьәләләр күп икән әле. Яңа ачылган чыганак исә Урта гасыр Идел буе төрки-татар әдәбияты тарихчылары алдына яңадан-яңа сораулар һәм, иң мөһиме, чыганаклар эзләү мәсьәләсен кабыргасы белән куя икән.

Мондый эшләрне башкарыр өчен, әлбәттә, безнең әдәбиятчыларга классик гарәп телен яхшы белергә, алай гына да түгел, борынгы кульязмалар белән яратып, белеп эшли алырлык махсус археографик белгечлеккә ия булырга кирәк дигән сүз. Ә гарәп телен гомумән белүчеләр бездә аз булмаса да, кульязмалар белән эшләүчеләре юк дәрәҗәсендә диярлек. Эшли башлап, ташлап китүчеләре күбрәк. Сөтле чәй янында мәсьәләнең шушы ягына кагылгач, Әнәс Халид казанлы галимнәргә үзенең үпкәсен дә белдереп куйды: мөмкинлекләр бар заманда Казаннан максатчан аспирантурага кешеләр җибәргән булсалар, ул бик теләп аларны махсус әзерләп биргән булыр иде.

Үпкә урынлы да һәм беркадәре каршылыклы да иде. 60 елларның башында романтик рухлы Хатип ага Госман иренмичә йөри торгач, министрлыктан махсус лимитлар алуга ирешеп, Лениградка бишалты егетне җибәртә алган иде. Ләкин ул егетләрнең берсе дә Казанга кире әйләнеп кайтмады: тәрҗемәче сыйфатында чит илләргә бару, йөисә КГБ системасына күчү алар өчен ул чорда күпкә файдалырак иде...

Гарәпчә белгән кешеләр арасында кульязмалар һәм гомумән чыганаклар белән эшләргә теләүчеләр аз булуга карата Әнәс Халидның үз фикере бар иде: «Төмен тапмасаң, бик күңелсез вак эш бит ул,— диде, беркадәре елмайган сыманрак итеп.—Менә без дә бит монда шәһәр гизәсе, театр һәм музейларга барып, дөнья күреп, гыйбрәт алып йөрисе урынга һәркөнне тузанлы китаплар актарып, кичләрен хәреф чүпләп, һәр сүзнең мәгънәсен төпченеп утырдык. Ә кульязмалар дөньясыннан нәрсәдер табар өчен айлар, еллар буе шулай чокчынырга кирәк... Тиешле кадрлар җитмәүдән бай тарихыбызның күпме сәхифәләре ачылмыйча, күпме мөһим фактлары табылмыйча ята!.. Институттагы планлы эшләр күп булганлыктан, мин дә моңарчы әллә нәрсәләр майтара алмадым...»—диде ул, ниһаять, көрсенеп.

Ә. Халидның соңгы сүзләрендә беркадәре дөреслек тә бар иде, әлбәттә: аның төп һәм күпчелек эшләре гарәп дөньясына, аның да классик чорына караган. Шулай да ул бервакытта да үз халкының тарихына, мәдәниятенә битараф булып калмады. 60 елларда, мин Ленинград архивларында «казынган» чакта, ул һәрвакыт эзләнүләремнең нәтиҗәсе белән кызыксынып торган иде. Кандидатлык диссертациямнең авторефератына рецензия язып, бер урынсыз гыйбарәм өчен тәнкыйтьләве дә хәтердә. 1976 елда «Әл-Гарнатыйның Болгарга сәяхәте» дигән исемдә мөһим истәлекнең текстын «Казан утлары» журналында бастырган иде.

1995 елда Таҗетдин Болгариның «Әт-Тирйак әл-Кәбир исемле 1220—21 елда гарәпчә язылган әсәренең бер тексты табылгач, аны тәрҗемә итү, искәрмәләр белән басмага әзерләү эшен ул үз өстенә алды, бик сыйфатлы дәрәҗәдә башкарып та чыкты. Һәм монгол яуларына кадәрге болгар авторларыннан хәзергәчә безгә мәгълүм шушы бердәнбер истәлек өстендә эшләгән чакта, Әнәс Халид тагын бер бик борынгы болгар галименең әсәре сакланганлыгын ачыклады. (Бу истәлекнең текстыннан да күчермәләр кайтарасы бар әле...) Соңгы елларда ул Казанга докладлар, диссертацияләргә язылган рецензияләр белән ешрак килә башлады. Аның, юк вакытны бар итеп, минем белән Каһирәгә килүе дә үз халкына, үз тарихына тартылуның, якыная баруның галәмәте иде.

Киләчәктә дә чыганаклар эзләп, тагын бер-ике сәфәрне планлаштырып утырабыз Каһирәдә...

Әнәс Халиднең безнең Каһирәдә гел китапханәләрдә эзләнеп,

кичләрен гел «төпченеп утыруыбыз» хакындагы сүзләре дә тулаем дөрес иде. Шәһәр буларак Каһирә минем истә, нигездә, китап киштәләре, яннары кырылып беткән машиналар тулган тар, тузанлы урамнары һәм кунакханәдәге бер бүлмәсе белән калыр дип уйлыйм. Һәркөнне диярлек кунакханәдән китапханәләргә бардык, китапханәдән Президент-отельдәге бүлмәләребезгә кайттык. Бары бер ял көнне генә, ун көнгә туры килгән бер җомгада гына, шәһәрнең кайбер тарихи урыннарын карадык. Иң элек Каһирәнең мәшһүр кальгасендә Җамигъ мәчеттә җомга намазына катнашып, мәмлүкләр чорыннан калган гаҗәеп мәчетне карап йөрдек, аннары Мөхәммәд Гали салдырган, эче Италиядән китерелгән алсу мәрмәр белән тышланган мәчетне күрдек. Кальгадә кечкенә генә музей да бар икән. Ләкин шәһәрдәге Ислам сәнгате музее тәэсирлерәк иде. Кечке яктарак Әл-Әзһәр мәдрәсәсе тирәсендә борынгы архитектура истәлекләре белән танышкан кебек булдык. Кебек кенә дим, чөнки йөгереп-йөгереп узу иде болар.

Дөрес, «күз туйганчы» караган объектлар да булды. Мәсәлән, иртәнге чәй эчә торган унынчы каттагы ресторан тәрәзәләреннән шәһәрнең бер өлеше шактый яхшы күренә иде. Тыгыз утырган соры төстәге йортлар, шул тарлыктан котылыр өчен иркен күккә таба омтылган нечкә манаралар дөньясы. Берәр чакырымга кадәр генә яхшы күренә. Аннары шәһәр өстендә оешып торган төтен һәм тузаннан—смогтан—дөнья төссезләнеп, тоныкланып кала иде.

Смог дигәннән, моңа һич тә гаҗәпләнәсе түгел: шәһәрдә реаль һәм даими яшәүче 20 (егерме!) миллион халык өстенә Каһирәгә көн саен 5 миллион кеше килеп, шуның кадәрлесе китеп тора икән! Бу егерме биш миллионның тын алуына, кырык-илле миллион тәпинең тузан туздыруына тагын кимендә ике-өч миллион машинаның корымлы төтен пыскытып һава бозуларын да кушарга кирәк.

Машиналарның күплеге шулкадәр ки, тар-тар урамнарда алар бер-берсенә ышкыла-ышкыла ике-өч рәт булып йөриләр. Дөресрәге, әкерен генә елышалар. Зур урамнардагы эстакадалар да әллә ни ярдәм итми шикелле: өске катламдагы юл киң булса да, аскы каты тагын да тарая төшкән. Еш кына «бөкеләр» барлыкка килә. Мондый әкерен кыймылдаудан кайчакларын эч пошып, машинадан сикереп төшәсе дә, җәяү генә китәсе килә. Ләкин җирле халыкның моңа исе китми—күнеккән, күрәсең.

Тар юлларда бер-берсенә ышкылудан, «сөзешүдән» кабыргалары-яннары тырналмаган, яисә борыны, арты яньчелмәгән машина юк диярлек. Без утырган машиналар да ике-өч мәртәбә башка берәрсенә тиеп, эләгешеп калгалаган иде. Бездә булса, мондый чакта җәнҗәл чыгар—сүгенү сүзләре сибелеп, монтероклар күтәрелер, иң киме, «дурак син!» дигәндәй, бармак белән үз чигәләренә бәргәләрләр иде. Ә болар билгеле хәрәкәтләр һәм шаярулы сүзләр белән бер-берсен тынычландырырга ашыгалар, эләгешеп калган машиналарының берсен күмәкләшеп күтәреп, читкәрәк елыштырып куялар һәм көлә-көлә үз урыннарына утырып китеп тә баралар. Гомумән, Каһирәдә узган ун көн дәвамында, исерекләрне очратмаган шикелле, сугышу түгел, кычкырышкан кешеләрне дә күрергә туры килмәде.

Каһирәдә булып та андагы мәшһүр әһрамнарны—пирамидаларны күрмичә китсәң, башкалар түгел, хатын да кичермәс иде. Шуңа күрә бер иртәнге якта барлыкка килгән иркенрәк вакыттан файдаланып, Җизәгә барырга булдым. Җизә (мисыр диалектында—Гиза, шулай ук мәсҗед түгел, ә мәсгид, Җәмал түгел—Гәмал һ. б.) элек аерым шәһәр булган, хәзер зур Каһирәнең бер өлешен генә тәшкил итә. Минем тәкъдимнән Әнәс баш тартты: «Үзең бар, мин аларны күргән. Фоторәсемнәрдә матуррак алар. Бар, бар әйдә, мин Алман археологик институтына барып, бераз эзләнеп кайтырмын...» Киттем таксида.

Әһрамнар турында күп ишеткән, күп укылган булса да, үз

күзләрең белән күрү башка нәрсә икән. Комлы таулар итәгендәге «Үле шәһәр»—борынгы зират һәм галәмәт зур таш «өчпочмаклар» белән очрашу миндә каршылыклы хисләр тудырды. Дөньяның җиде могҗизасының берсе булган бу гаҗәеп корылмалар, бер яктан, гадәттә без «мәдәниятсез, фән-техникасыз, примитив», дип исәпли торган борынгы кешеләрнең дә искитәрлек кодрәткә ия булуларын күрсәтә. Икенче тарафтан, аларның янында башыңны артка каерып торган чакта, кеше дигән затның (әллә нәрсәләр дәгъвә итә торган җан иясенең!) тарих дигән хикмәт алдында бик кечкенә, бик бәләкәй икәнлегенә ышанасың...

Мин Җизәдән шулай бераз исәңгерәгән хәлдә кайттым.

Алман институтына барган Әнәс исә каршылыклы хисләр белән түгел, бер бик сирәк очрый торган мәмлүкләр хакындагы Урта гасыр истәлегенең басмасы белән кайткан иде. Аны Институт директоры бүләк иткән. Көтелмәгән табыштан, кем әйтмешли, авызы колакларына җиткән иде аның.

Иртәгесен: «Гыйбрәт өчен карап кайт»,—дип, ул мине дә әлеге институтка алып китте. Андагы байлыкны: һәр бүлмә саен иләннән түшәмгә кадәр менгән киштәләрдәге китапларны күрүгә сөенсәм, киштәләрне бераз актаргач, ул китапларның йөздән туксаны булса да, сиксәне безнең якларда табылмачагын аңлап ихлас күңелдән көендем. Күпчелеге «тимер пәрдәләр чорында төрле Аурупа илләрендә аз тираж белән чыккан кыйммәтле, сирәк китаплар иде. Биш-алты бүлмәдәге китапларны карап чыгар өчен генә әллә ничә айлар җитмәс иде.

Ә тәртибе ни тора! Идәннәренә келәмнәр түшәлгән һәр иркен бүлмәләрдә тынлык. Бүлмә саен берәр кешелек ике-өч өстәл, урындык. Китапларны киштәләрдән үзең сайлап аласың, бернинди кәгазь-фәлән язып, чүп арттырып торасы юк. Тик, карап чыккач, аларны өстәлләрдә калдырырга кирәк—кире киштәләргә институт хезмәткәрләре үзләре алып куячак. Шуңадырмы, ул китапларда тузан-фәлән күренми. Гомумән, арулык, пакьлек...

... Иртәгә китәсе көнне кичен җыелган китапларны, ксерокүчермәләрне тагын бер кат барлап, тәртипкә салдык. Өстәмә йөк кеше башына 15—20 кило туры килә иде. Соңгы кичтәге сөтле чәй янында мин юлдашымның моннан бер атна элек әйткән, шушы Каһирәдә илле еллыгын ничек уздыруы хакындагы сүзләрен искә төшердем. Чынын-шаяруын бергә кушып: «Бәлки 70 еллыгыңны да шушы Каһирәдә уздырырсың—яңа командировка оештыру мөмкинлеге юк түгел. Кульязмалар өстендә дә, Герман институтында да иркенләп эшләп алыр идең. Без сиңа туган көнең белән котлап телеграмма җибәрер идек...»—дидем. Әнәс исә җитди кыяфәттә башын гына чайкады: «Булмас хәзергә. Бу юлы табылганнарын да «сеңдерәсе» бар. Коръәннең татарча тәрҗемәсе дә өстә. Алда Төркия сәфәре дә тора дисең бит...»

* * *

СҮЗ БАШЫНДА мин Каһирәгә булган сәфәребез «кыю хыял кебегрәк» дип әйткән идем. Нәтиҗә биргән «кыюлыгы» да булды аның, эшләнеп бетмәгән эшләре дә күп калды. Борынгы шәһәрдәге төрле очрашуларның да гыйбрәте аз булмады. Каһирәнең үзен күрдем дә кебек, яхшылап күрмәдем дә шикелле. Китап киштәләре генә күбрәк истә сакланып...

Күренекле галимебез Әнәс Бакый улы Халидов белән дә, утыз елдан артык танышлыкта торуыма карамастан, бу сәфәрдә мин чын-чынлап беренче кат очрашкан төсле булдым.

*Каһирә—Казан*
*1998—1999*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

## Фоат Галимуллин:

Соңгы ун-унбиш елда күңелгә куаныч китергән әсәрләр байтак язылды һәм укучыларга барып иреште. Мондый сөенечле хәл сүз сәнгатенең барлык төрләрендә дә күзәтелде. Мин аеруча күзәтеп барырга тырышкан прозага килгәндә, эш болайрак тора: бередә тормыш күренешләрен инләүдә, мөһим темаларны күтәрүдә киң колач сизелә. Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый мирасының кайтуы, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Р. Фәхретдин һәм башка затлы шәхесләребезнең мона кадәр читкә тибәрелеп киленгән әдәби һәм фикри хәзинәләре бүгенге иҗатчылар өчен таяну ноктасына әверелде. Милләтебезнең үзбилгеләнүгә, дәүләтчелеген торгызуга, хакыйкый тарихын булдыруга омтылышы та каләм көчләрен активлаштырды. Тарихилык принцибының һәм публицистик пафосның өстенлек итүе, барыннан да элек, әнә шушы алшартлар белән билгеләнде.

М. Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә-ханбикә һәм Иван Грозный», «Батый хан һәм Ләйлә», «Атилла», Р. Батулланың «Сөембикә», Ф. Латыйфиның «Хыянәт», Ж. Рәхимовның «Батырша» кебек романнары халкыбызның тарихи фикерләвен үстерүдә аеруча мөһим роль уйнадылар. Шул ук вакытта егерменче гасырның иң вәхшилек чорын—шәхес культы котырган елларның афәтен күрсәтеп бирү дә үткән мәсьәләләрнең берсе

сыйфатында алга килеп басты. Бу юнәлештәге иң олы сүзне инде хәзер мәрхүм булган әдибебез, Колыма газапларын кичергән И. Салахов әйтте. Аннан соң Г. Тавлинның «Афәт», Р. Кәраминең «Каргышлы этаплар», Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере», А. Гыйләжевның «Йәгез, бер дога», Л. Бадыйкшанның «Мөртәт», Г. Ахуновның «Идел кызы» һәм башка әсәрләр бу хәлләрнең үзәк өзгеч күренешләрен җанлы итеп күз алдына китереп бастырдылар.

Безнең илебез дөньяда иң көчле һәм дәһшәтле империяләрнең берсенә әверелгән иде. Ләкин аны җимерү бер-ике кеше тарафыннан бик тә җиңел эшләнде. «Ни өчен шулай булып чыкты?» дигән сорауга җавап табу да әлләни кыен түгел. Чөнки көч-куәтнең нигезе изгелеккә таянып тормый иде. Шуны ачып бирүгә Р. Мөхәммәдиевнең «Кенәри—читлек кошы», А. Гыйләжевның «Балта кем кулында?», Т. Галиуллинның «Тәүбә», Н. Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» әсәрләре багышланды, алар укучылар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан игътибар белән кабул ителделәр, киң яңгыраш алдылар. Өлкән әдибебез Ә. Еникинең «Кояш баер алдыннан» дигән китабы аерым бер вакыйга булды.

Соңгы елларның тагын бер игелекле ягы шунда: нәкъ менә әлеге чорда безнең әдәбиятта З. Зәйнуллин, Т. Галиуллин, Р. Сибат, З. Хәким, Н. Гыйматдинова кебек берсеннән-берсе талантлы, хәзер әдәбиятыбызның төп көченә әверелгән язучылар пәйда булды. Алар ике меңенче елга каләм көчләренең олы традицияләрен үз җилкәләрендә күтәргән хәлдә кереп баралар. Бәхетебездән, татар әдәбиятының иҗат көчләре әле һаман тулылана бара, өлкәннәр каләм куюга, эстафетаны заман рухын һәм таләпләрен сизгеррәк тоючылар күтәреп ала. Татар әдәбиятының яшәүчәнлек чыганагы әнә шунда да инде.

Ә инде «туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди унай сыйфатлар бар? Кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырда әдәбиятыбызда нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?» дигән сорауга җавап мондый.

Туксанынчы еллар әдәбияты, минем карашымча, егерменче гасырның бер генә унъеллыгына охшамаганча, үзенчәлекле булуы белән аерылып тора. Ул—чын мәгънәсендә азат әдәбият. Социалистик реализмның тынны кыса торган кыршауларыннан арынып, күңел кушуы буенча иҗат ителә торган әдәбият. Халкыбызның олы тарихын, затлы асылын булганынча сурәтләү—шулай ук аның иң күркәм сыйфатларыннан. Кешенең күңел дөньясы, иң тирән интим хисләре матур рәвештә, шактый иркен, шул ук вакытта, халкыбызга хас булганча, тыйнак, оялчан итеп сурәтләнә торган хасияте дә—төп үзенчәлекләрнең берсе. Дини эчтәлек, кеше рухының бай катламын тәшкил иткән ислам тәгълиматына бәйле хис-кичерешләр бирелешенең торган саен киңрәк урын ала баруы турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Детектив әсәрләр урынына җинаять кылуның бөтен эзлеклелеген күрсәтүгә корылган әсәрләр барлыкка килү дә—заман билгесе. Боларның бөтенесе тормышыбыздагы гаять кискен үзгәрешләр белән бәйле. Әдәбият—ул чынбарлыкның көзгесе, телиме-теләмиме, андагы хәл-әхвәлләр каләм әһеленең фикерләү һәм хис итү хасиятләренә тәэсир итми калмый. Ләкин, югарыда санап кителгәннәрнең күбесен хуплаган хәлдә дә, җенси азгынлык һәм җинаятьне пропагандалаган әсәрләр иҗат ителү күңелгә шом сала. Чөнки борын-борыннан матур әдәбият бездә саф әхлак һәм сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү чарасы булып хезмәт иткән. Аның бу сыйфатына алга таба да тугры каласы иде.

Кайберәүләр: «егерменче гасыр ахыры татарлар өчен шушы йөзнең беренче унъеллыгына охшаш», диләр. Болай дию-челәрне аңларга мөмкин. Ник дигәндә, 1905 елның октябрь аенда халык басымы астында патша хөкүмәте кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр булды. Аерым алганда, безгә—татарларга да—үз телебездә вакытлы матбугат булдырырга мөмкинлек барлыкка килде. Шуңа охшаш хәлне без гасырның соңгы унъеллыгында да күрәбез. Дөрес, коммунистлар хакимлеге елларында матбугатсыз яшәдек дип әйтеп булмый. «Ватаным Татарстан» газетасы (төрле елларда «Кызыл», «Совет», «Социалистик» кебек аергычлар белән) чыгып килде, «Безнең юл» (соңыннан «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары») журналы хәтта 1941-45 еллардагы сугыш вакытында да яшәвеннән туктамады. Балалар, яшьләр, хатын-кызлар һәм юмор-сатира ярат-учылар өчен дә махсус

матбугатыбыз булды. Алар халкыбызның иҗтимагый аңын формалаштыруда гаять мөһим эш башкардылар. Әдәбиятыбыз-сәнгатебезне үстерүдәге рольләре гаять зур булды. Автономияле җөмһүрият шартларындагы кысынкы шартларда да без театр, рәсем, музыка һәм башка төр сәнгатьләребезне шактый югары дәрәҗәдә үстерә алдык. Татар халкының зур өлеше илнең икътисады, мәдәнияте, иҗтимагый үсеше белән идарә итү мәктәбен үтте. Димәк, йөзьеллык ахырындагы татарлар үзләренең гасыр башындагы элгәрләреннән бик нык аерылалар.

Әйе, 1917-1980 еллар ахырындагы татар матбугаты рәсми хакимият рөхсәт иткәнне генә яза алды. Ә мондый хәл иҗтимагый фикер, әдәбият-сәнгать үсешенең беръяклы булуына китерде. Шулай килеп чыга, көндәлек матбугат булдыра алмаганны (аңа рөхсәт ителмәгәнне) әдәбият үз өстенә алды. Әдәби әсәрләрдә, юл араларына гына яшереп булса да, яшәп килүче җәмгыятькә тәнкыйть карашлары да үткәрелде. Совет хакимияте елларында мондый әсәрләрне бәяләү өчен махсус иҗат ысулы да уйлап чыгарылды, ул—тәнкыйди реализм. Ләкин бер шарт белән—тәнкыйди реализм, алар карашынча, социалистик чынбарлыкка кадәрге яшәешне генә фаш итәргә тиеш иде. Ләкин чынбарлыкта алай булмады. Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай», Ә. Еникинең «Саз чәчәге», «Рәшә», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир», Н. Фәттахның «Артта калган юллар» («Кырык дүртнең май аенда») кебек әсәрләр язылды, Ф. Әмирханныкыннан башкалары үз вакытында ук укучыларга да барып ирешә. Беренче карашка, алар төрле шартлардагы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне күрсәтеп бирүгә багышланганнар кебек. Ләкин, шул ук вакытта, әлеге әсәрләр социалистик чынбарлыкка бик нык тәнкыйть буларак та кабул ителде. Бередә социалистик реализмның төп принципларыннан берсе—чынбарлыкны революцион үсештә сурәтләү таләбе бозыла. Бу нәрсә хакында сөйли? Рус шагыйрьләренең берсе әйтмешли, «Россиядә шагыйрь бары тик шагыйрь генә булып кала алмый». Г. Ибраһимов икърар иткәнчә, шагыйрьнең «хыялы әллә кая, ерак, югары һәм хыялый галәмгә алып китә, ләкин хакыйкатьтән китә алмый. Һаман шул үзе сөймәгән, нәфрәтләнгән вак, түбән тормыш эчендә яшәргә мәҗбүр була... Шуннан бик күп шагыйрьләрнең эшгаре «аһ-зар илә», тормышка ләгънәт илә тула. Чөнки тормыш аның теләгәнен бирми, җуанычлар калдырмый». 1911 елның 4 мартында—тарихта реакция еллары дип аталган чорда—Г. Тукайның Әстерханда яшәүче каләмдәше Сәгыйть Рәмиевкә язган хатындагы менә бу юллар шагыйрьнең чын йөрәктән ачыргалануы булып чыккан да: «Күз алдым караңгыланды, милли тормыш, милли хәяттән вә үземнең хыялларыннан тәмам өмид кистем. Мин бит синең шикелле, саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит».

Г. Тукай, шул замандагы Г. Исхакый кебек ук, милләт шатланганда гына шатланган, милләт кимсенгәндә үзен хәсрәтле хис иткән. Татар милләтен чын мәгънәсендә дәүләтле, телле, иректе итү мәсьәләсе, уналтынчы йөзнең авыр мирасы буларак, егерме беренче гасырга да хәл ителмәгән хәлдә кереп бара. Шуңа күрә туар гасырның язучысы (ихлас милли рухлы каләм әһелләре) табигать хозурлыгын, күзен иркәләгән матур күренешләрне генә җырлаучы булмас, ул иң әүвәл кавемдәшләренең бүгенге хәле, киләчәге турында гамьләнер. Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда да аның халык мәнфәгатьләре белән яшәвенең дәрәҗәсе билгеләячәк.

Әлбәттә, мәхәббәт, гыйшык турындагы әсәрләр дә кирәк. Болар—яшәүнең бер ямен тәшкил иткән хасиятләрдән. Әмма халкына, иленә мәхәббәттән аерылган яратуның кыйммәте шуның кадәр генә. Язучының җәмгыятьтәге урыны туган халкының кояшыбыз астындагы урыныннан, аның тулаем язмышыннан бәйле. Шул язмышның якты булуына каләм осталары кертә торган өлеш кимемәскә тиеш!

Фатих Урманче

# БОРЫНГЫ МИФ
# ҺӘМ БҮГЕНГЕ ШИГЫРЬ

### Икенче бүлек

Гасырлар чиге—кешелек тарихы өчен аеруча җаваплы, хәтта, әйтергә мөмкин, куркыныч бер чор булса кирәк. Дини легендалар буенча, безнең эраның беренче елында Иисус Христос—Гайса пәйгамбәр дөньяга килә. Мөхәммәт пәйгамбәрнең изге эше дә VII гасыр башына туры килә. XIX һәм XX йөзләр чигендә исә Русиядә марксизм тарала башлый. Ә ул тәгълиматның XX гасырда нинди дөньякүләм фаҗигаләргә китергән без хәзер бик яхшы беләбез.

Кешелек тарихы менә тагын бер тапкыр гасырлар чигенә якыная. Шуның белән бергә илдәге сәяси һәм икътисади катаклизмнар безнең өскә ябырылып килә... Тик иҗтимагый хәлләр, вакыйгалар нинди генә булмасын һәм ничек кенә бармасын, кешелек дөньясы үзенең төп юлын беркайчан да югалтмый, югалта алмый.

Катлаулы иҗтимагый процесслар белән бергә гасырлар чигендә гадәттә сихерчелек, магия, мистика, астрология киң тарала һәм... шул ук вакытта борынгы һәм бик борынгы дини карашларга, мифологиягә, дастаннарга һәм әкиятләргә игътибар да бермә-бер арта. Язма шигърияттә дә бу үзеннән-үзе күренеп тора. Безнең игътибар үзәгендә торган Равил Фәйзуллин иҗатында да шулай ул.

* * *

Халык әкиятләренә һәм дастаннарга игътибар һәрбер талантлы шагыйрь иҗатының нигездә башлангыч чорына туры килә һәм еш кына гомере буена дәвам итә. Равил Фәйзуллин шигърияте дә әкият традицияләрен читләтеп үтми. Ул әкият сүзенә дә, әкиятләрнең аерым төсмерләренә дә үз иҗатында еш мөрәҗәгать итә.

Мәгълүм ки, әкият сүзе дә, халык иҗаты төре буларак әкиятләр үзләре дә безнең көннәрдә башлыча балалар дөньясы белән бәйләнгән. Моны Равил Фәйзуллин да яхшы белә. Шуңа күрә ул «әкият» сүзен, гадәттә, үзенең яки башкаларның балачагы, гомумән—кеше тормышының иң гүзәл чоры булган еллар белән бәйләнештә куллана. Менә аның шактый моңсу яңгырашлы «Әй, кайтасы килә кайчакта» (1971) шигыреннән бер өзек:

«Вакыт» төшенчәсен гел үсү дип,
Яңару дип йөргән бер чакта,
һәлак булмас кебек күренә иде
боз өстендә яккан учак та!
Ул чак безгә һәр кыз тыйнак иде,
бөтен ир зат—батыр, тугрылар!
Әкияттә генә явызлыклар—
сатлык җаннар, залим, угрылар.

Бу шигырен язганда шагыйрьгә 28 яшь була! Тик ул инде, күрәсең, тормышның ачысын-төчесен татып өлгергән. Балачактагы «әкияти» гүзәллекләр, маҗаралар юкка чыккан. Шагыйрь дөнья хәлләренә, чыннан да, олыларча карый башлаган. Чөнки балачактагы әкият дөньясы кайдадыр еракта—кырыс чынбарлык артында калган. Ярыйсы ук иртә булса да, шагыйрь тылсымлы әкият дөньясына тәрелгән балачагын сагына! Һәм бу бик табигый: кеше олыгайган саен аның балачагы, ул

---

Ахыры. Башы журналның 6 нчы санында.

нинди генә авыр, катлаулы, хәтта фаҗигале узмасын, кадерлерәк була бара! Шагыйрьнең «Җуясы килмәгән әкият» өчьюллыгында да шул ук хисләр хөкем сөрә кебек... Тик әсәр нечкә юмор белән дә сугарылган:

Абагалар шау чәчәктә, имеш!
Ел да төнен барып карыйм, димен,—
Һаман вакыт житми...

Әкияттәге эчтәлек буенча абага елына бер генә тапкыр чәчәк ата. Шул чәчәкне өзеп алсаң, кешегә күренмәс буласың, имеш. Хәтта бәхеткә дә ирешергә мөмкин... Әлеге шигырьнең фәлсәфәсе бөтенләй башка: абага чәчәге могҗизасына ышанудан көлү. Шагыйрь әкиятнең бу үзенчәлеген бик оста тотып алган.

Әйе, халык әкияте ул—барыннан да элек могҗизалар дөньясы. Изге, гөнаһсыз балачак белән бәйләнгән әкият һәрвакыт нинди дер матурлыкны, гүзәллекне хәтерләтә. Әкиятнең тиз бетүен бала-чага да ризасызлык белән кабул итә. Шагыйрь фикере исә тормыш фәлсәфәсенә юнәлтелгән кебек. Һәрхәлдә, аның «Эфемерида» дүртьюллыгын укып чыккач, шундыйрак тәэсир кала:

Шундый кыска булды әкият!
Серле рәшә эреп таралгач,
моржа кебек утырып калды
тотып карап булыр чынбарлык.

Шигырьдә сүз әкияттән башланса да, аның икенче-өченче юллары безне заман чынбарлыгына алып китә: «моржа кебек утырып калды» сүзләрен укыгач та, күз алдына сугыш яисә большевикларның мәгънәсез сәясәте нәтиҗәсендә тик мич торбалары гына утырып калган бихисап бәхетсез авыл урыннары килеп баса. Моннан да зур, куркыныч фаҗига булырга мөмкинме соң?! Шагыйрь ифрат үтемле итеп әйткәнчә, әкият чыннан да беткән. Әкияттәге гүзәллекнең, матурлыкның эзе дә калмаган!

Халык әкиятләрен беренче мәртәбә телгә алгандагы самими бер хис—изгелек хисе Р. Фәйзуллин иҗатының буеннан-буена бара һәм кат-кат кабатлана. 1976 елда язылган бер шигырендә ул болай ди:

Күзең йом да
оныт бүгенгеңне!
Күм тирәнгә—
күңлең төбенә—
ваклыкларны,
мәшәкатьләрне...

Кит беразга әкиятләргә,
чык сабый чак сукмакларына,
йөгер каеннарга каршы болын буйлап...

Шигырь тагы да җитдирәк юллар белән тәмамлана:

Күзең йом да,
кайт үзеңә,
асылыңа—ялгызлыгыңа!
Якынай бер балачагыңа!..

Безнең бүгенге шигърияттә, димәк—Равил Фәйзуллин иҗатында да, әкиятләргә махсус багышланган шигырьләр дә бар. Аларның барысы да халык әкиятенә тирән ихтирам белән сугарылган. Кайвакыт, ә бәлки, еш кынадыр, шундый бер закончалыкка тап буласың: шагыйрь олыгайган саен аның әкияткә игътибары арта бара. Бу—бик күп шагыйрьләрдә, әлбәттә, Равил Фәйзуллинда да шулай:

Тагын кайттым әкиятләргә!
Рәсемле китапларга!...
«Балачак Иле!»—диюгә—
рәхәтлек иңә җанга!

Бу очракта иң әһәмиятлесе: шагыйрь халык әкиятләрен хәтта роман, драмалардан да өстен куя: «Әкият белән тиңләгәндә нәрсә—драма, романнар!» һәм шагыйрь хаклы булса кирәк. Язма әдәбиятның барлык төрләре дә, ахыр чиктә, халык иҗатыннан, шул исәптән—халык әкиятләреннән үсеп чыккан. Ә әкиятләр халык прозасының төп өлешен тәшкил итә. Бу—барлык халыкларда да шулай. Бездә, Идел буе, Казан татарларында—бигрәк тә! Түбәндәге фактларга гына игътибар итик. Гасыр башында танылган галим Гали Рәхим: бездә, Идел буе татарларында, Урта Азия һәм Казакъстан халыкларындагы кебек зур күләмле шигъри дастаннар юк һәм беркайчан да булмаган. Бездә дастан урынын бәетләр алган,—диебрәк язып чыккан иде![1] һәм галим хаклы булса кирәк: Казан татарларында саф фольклор дастаннары чыннан да юк һәм беркайчан да булмаган. Шулай дигәч укучыларның: «Ә мәшһүр «Идегәй» дастанын кая куябыз?»—дип сораулары мөмкин. Бу четерекле сорауга түбәндәгечә җавап бирергә мөмкин: «Идегәй» дастаны нигездә Себер татарларыннан язып алынган. Идел буенда исә XVII-XVIII йөзләрдә аның зур булмаган прозаик версияләре генә мәгълүм була [2].

Аның каравы биредә—Урта Идел буенда—китаби дастаннар һәм халык дастаннарына якын торган зур күләмле батырлык әкиятләре киң колач җәя.[3] Бәлки, нәкъ әнә шуның белән бәйле рәвештәдер, безнең бүгенге шигърияттә халык эпосына караганда китаби дастаннар һәм халык әкиятләре йогынтысы күп тапкыр көчлерәк сизелә. Бу тезисны Равил Фәйзуллин иҗаты нигезендә дә дәлилләп була. Кайвакыт шагыйрь хәтта әкиятләрнең жанр чикләре мәсьәләсенә тукталып, аларның иң җитди үзенчәлекләрен билгеләп үтә:

Дөрес, «Әкият Иле»ндә дә
сине төрле хәл көтә!
Әкиятнең шунсы әйбәт:
ахыры яхшы бетә!

Чыннан да, трагик әкият булмый! Әкият ахырында (мәҗбүри рәвештә) явызлык һичшиксез җәзага тартыла һәм яхшылык җиңә. Әнә шул үзенчәлеге белән әкият башка төр әсәрләрдән генә түгел, хәтта тормыш чынбарлыгының үзеннән дә нык кына аерылып тора. Әкиятнең төп сәнгати көче дә шунда ки, анда әдәби чынбарлык, билгеле бер дәрәҗәдә, югары романтика әсәрләрендәге кебек, тормыш чынбарлыгыннан өстен тора. Гомумэстетика таләпләренә сыймаган бу үзенчәлекне ничек аңларга һәм аңлатырга? Биредә «әкиятне яклап», кимендә өч аргумент китерә алабыз:

Беренчесе. Әкиятләрдә гади халыкның яхшы тормыш турындагы гасырлар буена дәвам иткән, тик беркайчан да, хәтта безнең көннәрдә дә тормышка ашмаган һәм ашмаячак якты хыяллары чагыла (бәлки әкиятләрнең безнең көннәрдә аеруча җанланып китүе нәкъ әнә шуның белән аңлатыладыр?!). Икенче төрле итеп әйткәндә, әкиятнең мәгънәсе—тормыш чынбарлыгын түгел, ә бәлки халык хыялын чагылдыруда. Икенчесе. Тылсымлы әкиятләр барлыкка килеп, формалашкан ыруглык җәмгыяте чорында аерым шәхес тик билгеле бер коллектив, ыру, кабилә әгъзасы буларак кына ниндидер роль уйный алган. Ыру яки кабилә аерым кеше мәнфәгатьләре турында «уйланмаган да»! Аңлашыладыр, ыруглык җәмгыяте дәверендә аерым шәхеснең һәлак булуы да мөмкин. Ә коллектив беркайчан да юкка чыкмый, дип уйланылган ул заманнарда. Димәк, фаҗига да мөмкин түгел. Өченчесе. Борынгы заманнарда ук цивилизациянең югары дәрәҗәсенә күтәрелгән борынгы Шәрекъ, һинд, иран, грек, рим халыкларының бик борынгы мифологиясендә кешелекнең алтын гасыры хакында бихисап мифлар сакланып калган. Әлеге мифларда сөйләнүенчә, ул чорларда кешеләр ачлык-ялангачлык, явызлык, авырусырхау, картаю, үлем кебекләрнең берсен дә белмәгәннәр, Җир кешеләре Күктәге аллалар дәрәҗәсендә яшәгәннәр.[4]. Халык әкиятләрендәге әнә шул алтын гасыр турындагы мифологик күзаллаулар да чагыла. Нәкъ әнә шуңа күрә әкияти чынбарлык гадәти тормыш чынбарлыгыннан өстен тора да! Әкиятләргә хас бернәрсә белән дә чикләнмәгән оптимизм әнә шул сәбәпләр белән бәйләнгән булырга тиеш. Бәлки, әкиятләрнең гасырлар, мең еллар буена халык күңелендә нигездә бернинди үзгәрешсез яшәве дә әнә шул гасырлар тирәнлегеннән килгән көчле традицияләр белән аңлатыладыр?!

Әгәр бу чыннан да шулай икән, димәк—әкиятнең дөньякүләм әһәмияте дә әйтеп бетергесез зур. Мәсьәләгә әнә шул яктан якын килсәк, Равил Фәйзуллинның әлеге шигыренең соңгы юллары да дөреслеккә тулысынча туры килә:

... Тагын кайттым әкиятләргә!
Рәсемле китапларга!..
Кешелек, бәлки, яшидер
Җирдә әкият барга.

Әкиятләрнең гасырлар тирәнлегеннән килгән шигъри һәм иҗтимагый үзенчәлекләрен ачыклау белән бергә шагыйрь аларның бүгенге көндәге төп функциясен дә онытмый: әкият хәзер нигездә балалар дөньясында яши, әйтик, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә... Әби-бабайлар, кайвакыт әти-әниләр дә, баланы вакытында йоклату өчен, аңа әкият сөйлиләр. «Йокы әкияте» (1990) шигырендә әнә шул хакта сөйләнә:

Йокы кунсын күзеңә,
Әкият сөйлим үзеңә!

Булган, ди, Мияубикә.
Торган, ди, Мияубикә.
Беркөн ул чыгып киткән,
тырысын иңгә киеп,
гөмбә җыярга диеп.

Шул рәвешчә, шагыйрь балага үзе уйлап чыгарган әкиятнең эчтәлеген сөйли. Шул арада бала да йокыга китә...

Балалар фольклоры белгече Рәшит Ягъфәров балаларның әкиятләргә мөнәсәбәте турында түбәндәгеләрне яза: «Балалар әкиятләрне бик яраталар. Әгәр берәр кешенең әкият сөйләгәнен белеп алсалар, вакыты бармы-юкмы, кәефе ничек, кыскасы, аның ай-ваена карамыйча, «әкият сөйлә» дип йөдәтә торган булалар. Шундый вакытларда әкиятче балалардан «котылу» яки аны шаяртып алу өчен үзенчәлекле бер әкият сыман шаян әсәрләр сөйли. Аларны Н. Исәнбәт алдавыч әкиятләр дип атады. Бу әсәрнең хасияте шунда: алар чыннан да әкият сөйли башлаган шикелле башланып китәләр дә, кызыктырып, колакны торгызып җитүгә, берәр тапкыр сүз әйтеп, яки рифмага туры китереп берәр сорау биреп, әкиятне «кырт кисәләр дә куялар»[5].

Балаларның әкиятләрне ифрат та яратуын безнең шагыйрьләр дә бик яхшы белә. Әнә шул нигездә Роберт Миңнуллин, мәсәлән, әкиятләрнең бөтенләй яңа, бигрәк тә сабыйлар күңеленә хуш килгән кечкенәкият жанрын уйлап чыгарды: «Хәтерсез балыклар турында кечкенәкият», «Койрыксыз куян турында кечкенәкият», «Бүренең кешеләр белән дуслашуы турында кечкенәкият» һ. б.[6].

Күрсәтелгән закончалыкларны Равил Фәйзуллин да бик яхшы белә һәм әкиятләрнең исеменә, гомуми эчтәлегенә, аерым мотивларына гына түгел, кайбер персонажларына да мөрәҗәгать итә. Безнең заман кешесенең әхлак сыйфатлары турында сөйләгәндә, шагыйрь халык әкияте батырын үрнәк итеп ала. «Син нишләрсең?» (1977) шигырендә ул болай ди:

Булган диләр
Камыр батыр,
Агач батыр,
Тимер батыр...
Һәркайсысы
зур эшләргә
маһир батыр!
Игелекле
асыл батыр!

... Син нишләрсең
Кеше батыр?...

Камыр батыр—татар халык әкиятләренең популяр геройларыннан берсе.

Ләкин безнең әкиятләрдә Агач батыр, Тимер батыр исемле персонажлар юк бугай?.. Алай дисәң тагы..., бездә «Тимеркендек» әкияте бар. Аксак Тимер дә безнең тарихи риваять-легендаларның шактый еш очрый торган персонажы...

Аерым очракларда Равил Фәйзуллин шигырьнең бер генә юлында билгеле бер әкиятнең тулы сюжетын күз алдына китереп бастыра. Әйтик, түбәндәге шигырьдә сүз безнең көннәрдә коточкыч бер юнәлеш алган экологик катастрофалар турында бара:

Күлне шулай тончыктырып
агулап үтергәнче,
кодрәтең житсә, Кеше,
аны Күккә элсәңче!

Әкият сюжетына нигезләнгән шигырен автор шундый ук шаян рухта тәмамлый:

... Күлне Күккә аскан егет тә
моңа куаныр иде!

Әкият персонажлары турында сөйләгәндә, тагы бер нәрсәне истә тотарга кирәк: кайвакыт бер үк каһарман хакында әкиятләрдә дә, дастаннарда да сөйләнә. Мәсәлән, төрки халыклар эпосында житди урын алып торган Алпамыш—Алпамыс образы татар фольклорында «Алпамша» дастани әкиятендә сурәтләнә. Бәлки, шуңа күрәдер шагыйрь бу геройның әле генә китерелгән исемнәреннән баш тартып, киңрәк мәгънәдә яңгыраган Алып исеменә мөрәжәгать итә.

Алып батыр исеме белән бәйле легендалар татар халкында әле хәзер дә яши. Аларның иң зур күпчелеге—төрле жирләрдә, төрле якларда очрый торган таучыклар, курганнар белән бәйләнгән: имеш, Алып батыр көне буена жир сөреп арыган да, ялга туктаган. Жайлап, ял итәргә утыргач, ул чабатасын кага торган булган. Алып батырның чабатасы шундый зур булган ки, әлеге жирдә таучык, курган килеп чыккан. Әнә шундый курганнарны әле хәзер дә «Алып батыр чабатасын каккан жир»,—дип сөйлиләр. Шагыйрь бу легендаларның эчтәлеген сөйләп тормый, тик, изге бер хис-хыял белән бергә, аның исемен генә телгә ала. Әйтик, «Тәрәзә» (1980) шигырендә:

«Туган як!» дигәндә,
күз алдымда—
йортыбызның бер тәрәзәсе—
урам якка карый торганы,
ачылмалысы,
зәңгәр рамлысы.

Малай чакта аннан күпме бактым,
офыклардан эзләп,
Алып батырларның шәүләсен!

Шагыйрьнең 1980 елда язылган исемсез бер шигырендә тормышның төрле каршылыклары: тарих та, безнең заман галәмәтләре дә бергә кушылып бирелә. Шул уңайдан шагыйрь Алып батыр исеме белән бәйле курганнарны да телгә алып үтә:

Гомер бакый Яхшы белән Яман
якалашкан, канда буталган...
Тарих—сәер: хәтерендә рәттән—
изге жан да, зина кылган да.
Алып бабай өйгән курганнар да,
Герострат яккан храм да,
Клеопатра хатын патшаның
күкрәген чаккан елан да.

Биредә шагыйрь татар һәм төрки мифологик әкият-легендаларына мөрәжәгать итү белән генә чикләнми, ә бәлки борынгы грек һәм борынгы Мисыр тарихына, дөресрәге—мифология элементлары белән сугарылган тарихына да тукталып үтә. Сүз Герострат һәм Клеопатра исемнәре турында бара. Аларның

беренчесенә карата түбәндәгеләрне әйтеп була: Герострат—Кече Азиядәге Эфес шәһәреннән чыккан бер грек. Борынгы грек мифологиясе мәгълүматларына караганда, шул ук Эфес шәһәрендә Зевсның кызы, аучылык алиһәсе Артемиданың Җир шарындагы җиде могҗизаның берсе дип хисапланган храмы була. Герострат б.э.к. 356 елда әнә шул храмны яндыра һәм... чыннан да тарихка кереп кала[7].

Клеопатрага килсәк, аның язмышы күп тапкыр катлаулырак. Ул—Мисырның соңгы патшабикәсе, б.э.к. 69 нчы елда дөньяга килеп, 30 нчы елда һәлак була. Борынгы Мисырда тәхет хатын-кызлар аркылы гына күчә торган булган. Тәхетне үз гаиләсендә саклап калу өчен, Клеопатра бер-бер артлы үзенең ике энесенә кияүгә чыга... Тәхет иясе булган кызның туган абыйсына яки энесенә кияүгә чыгуы, ир затыннан булган патша-фиргәвеннең үзенең сеңлесенә, хәтта үз кызларына өйләнүе—Борынгы Шәрекъ өчен гадәти бер күренеш булган. Мәсәлән, Эхнатон (Аменхотеп Ш, мәшһүр Нефертитинең ире, якынча б.э.к. 1455-1419 еллар (үзенең ике кызына өйләнә)... Мисырны яулап алгач, Юлий Цезарь, тәхет иясе булу өчен, Клеопатрага өйләнергә тиеш була (б.э.к. 48-44 еллар). 47 нче елда Цезарьдан Клеопатраның улы туа—Цезарион. Алар өчәүләп Римгә киләләр. Римлылар, Клеопатра Цезарь белән бергә безнең тәхетне яулап алырга килгән икән дип, Цезарьны ерткычларча үтерәләр. Клеопатрага «Александрия фахишәсе», «Нил еланы» дигән кушаматлар тагалар. Дөресен әйткәндә, үзенең бернинди дә гаебе булмаган, тик тирән фаҗигале язмышка дучар ителгән Клеопатраның яманатын римлылар тараталар. Гасырлар буена колонияләр яулап алу белән шөгыльләнгән римлылар өчен бу гадәти күренеш булган дип уйларга кирәк. Клеопатра язмышы безнең гүзәл ханбикәбез Сөембикә язмышында турыдан-туры кабатланадыр сыман. Хәтта аларга кагылган әшәке гайбәтләр дә бер үк төсле, бер-берсен сүзгә-сүз кабатлыйлар диярлек!... Юлий Цезарь үтерелгәч, Клеопатра Мисырны яңадан яулап алган Антонийга кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Әмма б.э.к. 31 нче елда Октавиан Август Антонийны тар-мар итә. Легендалар буенча, Клеопатра мәрхәмәтсез Августка кияүгә чыгудан кискен баш тарта. Клеопатра үтенече буенча, аңа кәрзиндә бүре җиләге китереп бирәләр. Шул җиләк арасында яшеренгән елан патшабикәнең ялангач күкрәгеннән чага: Клеопатра үзен-үзе үтерергә мәҗбүр була[8]. Югарыда, шигырьдән китерелгән өзекнең соңгы ике юлында Равил Фәйзуллин әнә шул фаҗига хакында сөйли.

Шагыйрь әсәрләрендәге Алып образына әйләнеп кайтсак, 1978-1980 елларда гаҗәеп бер илаһи талант көче белән язылган «Сәйдәш» поэмасында, бөек композиторның фаҗигале язмышын сурәтләгәндә шагыйрь шул ук экияти-дастани батыр исемен телгә алып үтә:

Алып-затны кайчак балавыздай
эретеп кенә сала марҗалар!

Татар халкының күп гасырлык милли фаҗигасен чагылдырган бу юлларны укыгач, күңел тетрәнми мөмкин түгел! Гадәттәгечә, хәтергә төрле янәшәлекләр килә: мәсәлән, тарих фәннәре докторы Равил Әмирханның катнаш никахның татар халкы өчен тирән фаҗигале күренеш булуын ачып бирүгә юнәлтелгән «Милләт тамырына балта белән» мәкаләсе...[9].

Алып батыр образы бер Равил Фәйзуллин иҗатында гына түгел, ә безнең хәзерге шигърияттә, гомумән, еш очрый. Ренат Харис шигырьләренең берсендә, мәсәлән, Алып батыр турындагы легенданың эчтәлеге тулысынча диярлек сөйләнә. Горур Алып батыр турында дастан сөйләп, шагыйрь болай ди:

Кәвешеннән туфрак каккан—
Үзән җирдә тау калыккан.
Кайгысыннан бер елаган—
Елгаларның суы арткан.
Шатланып ул бер елмайган—
Корыган үлән чәчәк аткан...
Дошманына бер селтәнгән—
Яулар кабер булып баткан.
Дуслары йөрер юлларда
Үзе күпер булып яткан.

Биредә Алыпта булмаган сыйфатлар турында да сөйләнә. Борынгы легенданы шагыйрь бүгенге көн темасына «яраклаштырырга» тырышып карый һәм Алып турындагы дастан хәзер дә яши, «Татарстан—яңа дастан», дигән фикергә килә. Шул ук фикерен дәвам итеп, шагыйрь икенче бер әсәрендә Алып батыр образына тагы бер тапкыр туктала, аны Яр Чаллыда «очратуы» турында яза: «Яр Чаллыда мин очраттым Алып батыр кебек бер батыр». Өченче бер очракта шагыйрь шул ук образ ярдәмендә хикмәтле сүз әйтә: «Кылыч тотар өчен кирәк Алып көче...» Ренат Харис тарафыннан безнең Алып батырга карата әйтелгән сүзләрне укыгач, ирексездән казакъ халык эпосы «Ер Саин» һәм аның төп героена хас сыйфатлар хәтергә килә. Дастанда сөйләнгәнчә, әгәр 90 яшьлек карчыкларга Ер Саин кагылса, алар яшь кызларга әвереләләр икән. Батырның күз карашы төшкән җирдә бөтен нәрсә яшәреп, төрле гөлләр чәчәк ата, имеш.

Марс Шабаевның «Янә сәлам бирү» шигырендә Алып батыр образы шагыйрьне Болгар чорларына алып китә:

Бабайларның юлы, һай, бормалы
Болгардан ук, борын-борыннан.
Карурманнар турап, бура бурап,
Шәһәр корганнардыр Алыплар.

Сүз биредә Алыпның сугышчан батырлыгы турында түгел, эпик геройның көндәлек эшләре хакында да бара. Безнең халыкның әкият, легенда һәм дастаннарында да Алып еш кына гади крестьян буларак сурәтләнә. Эпик батырның безнең фольклорда чагылган милли үзенчәлекләрен шагыйрь биредә оста гына тотып алган.

Дастани «Соңгы сынау» поэмасында Илдар Юзеев Бөек Ватан сугышы геройларын борынгы чор батырлары белән рәттән куя. Поэмада Муса Җәлил исеменнән түбәндәге сүзләр әйттерелә:

Иң авыр минутларда,
Җирдәге тәмугларда
Көч алдым мин халыктан—
Алпамыштан, Алыптан.
Үч кылычы сынганда,
Йөрәктә дәрт тынганда—
Җик Мәргәннән ук алдым...

Биредә сүз татар халык иҗаты хакында гына түгел, ә бәлки гомумтөрки халыкларның дастан-эпос геройлары турында бара. Җик Мәргән, бигрәк тә Алып батыр татар легендаларында гына түгел, башка төрки халыкларның героик дастаннарында да очрый.

Ниһаять, кечкенә генә бер дүртьюллыгында Илдар Юзеев Алып батыр образы ярдәмендә мөһим мәгънәгә ия булган хикмәтле сүз әйтә:

Уйлама үзеңне халык дип,
Шул халык эчендә Алып дип.
«Ул халык эчендәге Алып», дип
Әйтергә хаклыдыр халык тик...

Шундый ук яки шуңа якын мисалларны безнең бүгенге шигърияттән тагын да китереп булыр иде. Без югарыда Алып батыр—бүгенге татар поэзиясендә киң таралган геройлардан, дидек. Алып батыр үзенең борынгы чордагы популярлыгын безнең көннәрдә яңадан яулап алды кебек. Чыннан да, алып сүзе беренче тапкыр борынгы төркиләрнең Орхон-Енисей язмаларында һәм берничә вариантта очрый: Йигин Алп-Туран, Инанчу алп[10]. Шушы ук алып сүзе, күрәсең—соңра, төрле халыкларның эпик батырларының исемнәренә кушылып йөртелә башлый: Алтай Төркиләрендә—Алып-Манаш (кыргызларның Манасы белән чагыштырыгыз!); казакъларда—Алпамыс; үзбәкләрдә—Алпамыш; безнең якын күршеләребез башкортларда—Алпамыша; бездә, Идел буе татарларында—Алпамша. Ягъни, Алып батыр Алтайдан һәм Ерак Себердән башлап Идел буйларына кадәр юл үткән, безнең Урта Идел җирләрен дә «үзләштергән».

Мәсьәләнең тагы бер ягына игътибар итеп үтәргә кирәк: безнең бүгенге шигырь-поэмаларда татар халык әкиятләрендәге Алпамша хакында түгел, ә бәлки борынгы болгар-татар легендалары һәм Көньяк Себер, Урта һәм Үзәк Азия, Алтай төркиләре дастаннары белән бәйле Алып батыр турында сөйләнә. Икенче төрле итеп әйткәндә, хәзерге шагыйрьләребез Алып батыр исемен соңгы чорлар үзгәрешләреннән (Алпамшадан!) «азат итеп», борынгы төрки формага мөрәҗәгать итәләр. Бүгенге шагыйрьләр Алып батырны әкият батыры итүдән баш тартып, нигездә халык эпосы каһарманы дип карыйлар.

Алып батыр турында сөйләгәндә, аның Акбүзатын да читләтеп үтеп булмый. Чөнки халык эпосы батырының аты—аның иң якын дусты, киңәшчесе, яклаучысы һәм саклаучысы. Төрки халыкларның дастаннарындагы батырлар беркайчан да атсыз булмый. Моны шагыйрь Равил Фәйзуллин да яхшы белә. Әмма әлеге эпик мотивны ул бөтенләй башка яссылыкка күчерә. «Ирешү» дүртьюллыгында ул лирик герой исеменнән болай ди:

Акбүз атта. Иңдә—җилән. Башта—бүрек.
Киттем тауга үзәннәрдән качып.

... Мендем. Торам. Ялгыз. Атым—үлде.
Тауда җилләр. Яланбашмын. Күкрәк—ачык...

Шигырьнең чын мәгънәсе бик тирәнгә яшеренгән. Ни өчен соң бу батырны аты үлгәч? Дүртьюллыкта сорауга җавап юк. Димәк, милли мифология мәгълүматларына таянып башка материалларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Безнең бик борынгы әкиятләрнең эчтәлегенә һәм башка халыклар мифологиясе мәгълүматларына караганда, Тау—барыннан да элек икенче дөнья, ә бәлки аллалар дөньясы ул. Бик күпләргә мәгълүм булганча, борынгы грекларның аллалары һәм алиһәләре Олимп тавында гомер кичерәләр. Яһүдләрнең иң бөек пәйгамбәре Моисей (Моше, мөселманнарда, Коръәндә—Муса пәйгамбәр, якынча б.э.к. XII гасыр) Яхве алла белән очрашу өчен Синай тавына күтәрелә һәм шунда Яхве белән 40 көн буена әңгәмә кора[11]. Шулай ук, билгеле булганча, үлемле кешеләр үлемсез аллалар торган җирдә яши алмыйлар. Татар халык әкиятләре мәгълүматларына караганда, ниндидер могҗиза ярдәмендә Тауга күтәрелгән геройлар шунда һәлак булырга тиеш. Чөнки безнең әкиятләрдәге Тауларның барысы да диярлек—Үлеләр дөньясы[12]. Бәлки, әлеге дүртьюллыкта әнә шул карашларның ниндидер үзенчәлеге чагыладыр? Хәтта бу мәсьәләне киңрәк яссылыкта да күтәрергә мөмкин: соңгы елларда татар шигъриятендә Тау образы гомумән еш очрый башлады (монысы хакында махсус сүз алдарак булыр). Бу үзе безнең көннәр галәмәте булып, коточкыч фаҗигале чорыбызның яшәү белән үлем арасында торуын чагылдырган бер үзенчәлек түгелме икән?! Шагыйрь күңеле гадәттә ифрат та сизгер була бит!

Заманалар катлауланган саен халыкның тарихи аңы тирәнәя, катлаулана, кырыслана бара. Безнең көннәр—халкыбызның рухи яктан яңадан туу чоры булуы турында югарыда искәртелгән иде инде. Искиткеч зур иҗтимагый әһәмияткә ия булган бу күренеш сиксәненче еллар ахырына—туксанынчы еллар башына туры килә. Әмма зур һәм мөһим талантка ия булган шагыйрь шаман, кам, хәтта пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрелеп, күрәзәлек кыла, тарих вакыйгаларының кая таба баруын алдан сизә. «Үзгәртеп кору» турында әле сүз дә булмаган 1970 елда, мәсәлән, тирән фәлсәфи эчтәлеккә ия булган «Идел ага» шигырендә Равил Фәйзуллин түбәндәгечә язган иде:

Идел ага. Ил барыбер
Идел-йортын онытмады.
Ярларында яши бирә
Идегәйнең оныклары.

Җитмешенче еллар башында мәгънәсез тоталитар идеология әле тулысынча үз көчендә булып, идарә большевиклар кулында иде. 1944 елның 9 августында большевиклар тарафыннан кабул ителгән һәм татар халкына каршы юнәлтелгән мәгълүм карар да әле тулысынча үз көчендә иде. Бу карар буенча, Идегәйнең исемен телгә алу да тыелган иде. Нәшриятта да «Идегәй» дастаны яңадан тик 1988 елда гына басылып чыкты. Әмма заман җилләренең кая таба исүен шагыйрь бик иртә сизеп ала һәм, әйтелгәнчә, Идегәй исемен беренчеләрдән булып күтәреп чыга.

Заманалар үзгәрү белән бергә «Идегәй» дастанының яңадан халыкка кайтуы да шагыйрь игътибарыннан читтә калмый. «Килде заман!» дүртьюллыгында ул бу хакта түбәндәгечә язды:

Халык аңы ташмый калмас
бар дөнья чаң какканда!
Милли манкортларга көн юк!—
«Идегәй»ләр кайтканда.

Илдә башланган «яңадан туу» чоры халыкның милли аңын нык кына үзгәртә, тирәнәйтә һәм киңәйтә. «Идегәй» дастаныннан кала, кайчандыр тыелган тарихи бәетләр («Казан бәете», «Сөембикә бәете»), мөнәҗәтләр, борынгыдан килгән саф милли йолалар да яңадан халыкка әйләнеп кайта. Тик илдә 70-80 ел дәвамында эзлекле һәм максатчан тәрбияләнеп килгән манкортлар шуның белән бетә дип уйлау да дөрес түгел.

Хәзерге татар шигъриятендә төрки-татар халыкларының мәхәббәт дастаннарыннан килгән геройларның исемнәре ярыйсы ук еш очрый. Исемнәре дибез, чөнки бу геройларның үзләре турында бернәрсә дә сөйләнми: алар дөнья, шул исәптән—татар әдәбиятында да шулкадәр киң таралганнар ки, аларны һәркем белә. Исемнәре үк билгеле бер әхлакый сыйфатларның эталоны булып тора. Биредә тагы бер закончалыкка игътибар итәргә кирәк: гадәттә иҗатының башлангыч чорында һәрбер шагыйрь халык иҗатының аерым образларына, детальләренә, һәркемгә мәгълүм булган күренешләренә туктала. Менә Равил Фәйзуллинның 1965 елда язылган исемсез бер шигыре. Монда сөеклесен шифаханәдән алып кайту шатлыгы турында сүз бара:

Ә мин—Мәҗнүн!
Үз-үземне белештермичәме,
әллә сөенүдән каушапмы,
әле уң ягына чыгам, әле сул ягына:
бу ягыннан тотсам, аңа җиңелрәк булыр,
бу ягыннан тотсам, җиңелрәк булыр...

Биредә халык дастаннарыннан килгән Мәҗнүн образыннан тыш илаһи Күк мифологиясе дә шактый киң чагылыш таба:

Кайтып җиткәч,
баскычтан күтәрелгәндә,
башларыбыз Күккә тиеп-тиеп алды,
аяз Күк—зәңгәр шатлык!—үзе безне үбеп алды.
Кеше сөенүенә мәрхәмәтле Күк битараф буламы соң!

Бу очракта шагыйрь үзенең һәрбер сүзен—хисен—фикерен дастани-мифологик төсмерләргә төреп бирә; үзенең мәхәббәтен, чиксез шатлыгын Күк, Йолдызлар, чәчәкләр хәрәкәтендә күрә: «Әллә нинди бүген көне! Күк тулы карлыгачлар, чәчәкләрдә тәклетура, бал кортлары...»; «Хәлеңне белергә дип синең янга йолдызлар төште...» Үзенең иң изге хисләрен, зур шатлыгын гәүдәләндерүне һәркемгә диярлек мәгълүм дастани Мәҗнүннән башлап, шагыйрь бик борынгы мифларның Күк, Йолдызлар, гөл-чәчәкләр белән бәйләнгән якларына алып китә. Сөйләгәннәр нигезендә Равил Фәйзуллин шигъриятенең җитди үзенчәлеген ачыкларга мөмкин: шагыйрь әсәрләренең иң зур күпчелеге борынгы мифологиянең бик күп детальләрен, төсмерләрен, персонажларын үз эченә ала. Хәер, бу үзенчәлек хәзерге талантлы шагыйрьләрнең байтагында бар!

Шул ук дастани исем шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә кулланыла:

Бәлки, мәҗнүни бу мизгел—
бүтән кайтмас сәгадәт?..
Онытылып, иркәләнеп,
әйдә, бер йөрик әле!
Серле, тансык гөлләр өзеп,
уйнап, көлиек әле!

Җитмешенче еллар башында, үзенә 28 яшьләр тирәсе булганда шагыйрь нindидер серле, тылсымлы, могҗизалы, тирән мәхәббәт кичергәндер төсле. Һәр—хәлдә, аның шигырьләре нәкъ әнә шул хакта сөйли: сүз инде Мәҗнүн турында гына бармый, аның Ләйләсе дә телгә алына:

Күз алдында күпме картайдылар!
Бер без бирешмәдек шикелле.
Һаман унсигездә! Хисләр—ташкын,
гашыйк күзгә дөнья сөйкемле!
Ләйләсенең Мәҗнүнедәй әзер
тилерергә теләсә ни көнне!

Бераз вакыттан соң, 1977 елда, шагыйрь әлеге мәхәббәтнең үкенечле булуын, сөйгәне белән кавыша алмавын искә төшереп, үзенең индеерактарак калган мәхәббәтен шул ук Мәҗнүн исеме белән аңлата:

Тарып рәхәт газапларга,
Мәҗнүннәрчә яраттым.
Чак кына төссезләнсә дә,
хыялымда яңарттым.

Бүгенге шагыйрьләр Таһир белән Зөһрә исемнәрен дә читләтеп үтмиләр. Равил Фәйзуллин дә «Хыялга» (1965) шигырендә югарыда күрсәтелгән шигъри алымга мөрәҗәгать итә. Бик күпләргә мәгълүм булган бер дастани персонаж образы берничә борынгы миф эчтәлегенә төреп бирелә:

Хәтереңдәме,
сабый чакта
күктән йолдыз
алып төшеп бирәм, дидең.
Малай булгач,
зәңгәр күктән өлге кисеп,
күлмәк тегеп бирәм, дидең.
Егет булгач,
иң инсафлы Зөһрә кызны
Айдан алып бирәм, дидең.
Ата булгач,
бишек сакларга
яшеннән
кылыч алып бирәм, дидең...

Китерелгән өзектә безгә күптән таныш булган бер генә сюжет бар: ул борынгы мифологик хикәяттә сурәтләнгән Айдагы Зөһрә кыз образы белән бәйләнгән. Ә башкаларының шигъри нигезләрен, чыганакларын, тамырларын ачыклау өчен махсус эзләнүләр, тикшеренүләр алып барырга кирәк: илаһи Күктән алып бирелгән йолдыз, шул ук зәңгәр Күктән өлге кисеп тегелгән күлмәк, яшеннән ясалган кылыч... Соңгысы инде халыкның батырлык эпосыннан, героик дастаннардан килгән традиция булса кирәк. Күрсәтелгән образлы берәмлекләрнең нигезендә дә борынгы мифологик күзаллаулар ята.

Таһир-Зөһрә образларына әйләнеп кайтсак, алар Равил Фәйзуллин иҗатын еллар буе озата йөри. Һәм еш кына—халык тарихы белән бергә. Шагыйрьнең борынгы Болгар фаҗигаләренә багышланган бер шигырендә (1971) мондый юллар бар:

... Әй, күрмик әле дөньяның гел
харәбәсен, аһ-зарын!
Монда мәшһүр мәркәз
булган, булган Агабазары!
Гел яшь кенә күрмәгәндер
бу мәгърур Кама яры.
Булгандыр Зөһрәләре,
Булгандыр Таһирлары.

Әйе, һәрбер тарихи чор, ул нинди генә булса да, фаҗигаләрдән генә тормый: кайгы-хәсрәт һәм шатлык, нәфрәт һәм мәхәббәт, үлем һәм үлемсезлек бик күп очракларда рәттән йөриләр. Болгар тарихында да ул шулай булгандыр...

Театр тормышына багышланган «Әйләнә, сәхнә әйләнә...» (1973) шигыренә дә бик табигый рәвештә шул ук исемнәр килеп керә:

Кемдер Зөһрә, кемдер Таһир,
кем әле Хәлил бүген.
Ялга чыккан карт артистның
үз хәле хәлдер бүген...

Һәм, ниһаять, баштан ахырга кадәр мәхәббәт турында сөйләгән «Җуймагыз мәхәббәтне» (1994) җырында шагыйрь шул ук, борын-борыннан изге һәм саф, шул ук вакытта тирән фаҗигале мәхәббәт символы булган Таһир-Зөһрә образларына мөрәҗәгать итми булдыра алмый. Җырның кушымтасы түбәндәгечә яңгырый:

Тере күбәләк кенә,
тәүге мәхәббәт кенә
күңелдә
җилпенә,
кагына.
Бул икән нык һәм көчле
Таһир-Зөһрә төсле
беренче
мәхәббәт
сагында.

Шагыйрьнең борынгыдан килгән дастани мотивларга бай мәхәббәт лирикасын күзәтүне «Шаяру» дип аталган дүртьюллыгы белән тәмамлыйсы килә:

Гашыйк Гарип... Гашыйк Гомәр...
Гашыйклары белән данлы ил!
Шул гашыйклар арасына
сыймас дисез мәллә бер Равил!..

Дүртьюллыктагы мәшһүр исемнәргә шагыйрь түбәндәгечә аңлатма бирә: «Гашыйк Гарип, Гашыйк Гомәр—Шәрекъ дөньясының мәшһүр шагыйрьләре». Гомәр дигәндә шагыйрь, һичшиксез, Гомәр Хәйямны күздә тота. Әмма безнең күңелгә нигәдер борынгы грек шагыйре, мәшһүр «Илиада», «Одиссея» һәм төрле гимнар авторы дип саналган Гомәр килде. Һәм, күрәсең, һич тә юкка түгел! Билгеле булганча, «Одиссея» сюжетының төп өлеше Үзәк Азиядә формалаша. «Илиада» вакыйгалары Кече Азиядәге Илион (Троя) шәһәрендә була. Кайчандыр шул тирәләрдә килеп чыгышлары белән төрки булган этрусклар яшәгән. Борынгы эллин дип саналган шагыйрьнең дә Гомер булмыйча, чынлыкта Гомәр булуы бик мөмкин.

Равил Фәйзуллин иҗатында чагылыш тапкан әкияти яисә дастани-мифологик образ-персонажларга әйләнеп кайтсак, бер-береңнән мәңгелеккә аерылуны чагылдырган юллар шагыйрьнең тагы бер шигырендә китерелә:

Кайтмас безне эзләп,
Сак-Сок моңы белән,
яхшы авазлар йөрер каңгырып
җирдән—җиргә,
офыктан—офыкка,
бушлыктан—бушлыкка.

Билгеле булганча, җидешәр яшьлек ике сабыйның бетмәс фаҗигасе—кара урман белән бәйләнгән: алар мәңгегә шунда яшәргә мәҗбүр ителгәннәр, ата-аналары, туганнары, хәтта бер-берсе белән дә беркайчан, һәрхәлдә—ахырзаман, кыяматкә кадәр кавыша алмаячаклар. Әнә шул мәңгелек фаҗига бәеттә тик бер генә җөмлә белән әйтелә: «Кавышабыз дигәч—хәзер таң ата». Бәетнең бу конкрет мәгънәсен шактый киңәйтеп, шагыйрь Сак белән Сокның үзәк өзгеч авазларын кара урманнан «җирдән-җиргә, офыктан-офыкка» күчерә. Ягъни, мифик «кара

урман»да гына мөмкин булган Сак-Сок тавышы бөтен дөньяга, Җиһанга («бушлыктан—бушлыкка») тарала. Бәлки, бу очракта шигырьдә безнең заманның коточкыч фаҗигасе дә чагыладыр?! Бәлки, шагыйрьнең шул ук Сак-Сок образы белән бәйләнгән дүртьюллыгы әле генә китерелгән фикерне дә раслыйдыр:

Белми генә күпләр:
без бит—Сак-Сок!..

Әкияттә түгел, чында булгач,
тик исемнәр генә бүтәнчә.

Мәгълүм ки, Сак белән Сок—бәхетсез, мәңгелек ялгызлыкка дучар ителгән адәм балалары. Аналары каргагач, мифик затларга әверелсәләр дә, алар әле бу дөньядан—кешелек дөньясыннан аерылмаганнардыр төсле. Бәлки, аларның кискен фаҗигасе дә шуның белән бәйләнгәндер: алар бу дөньядан бөтенләйгә аерыла алмыйлар. Димәк, әле теге дөнья вәкилләре дә була алмыйлар. Аларның трагик язмышы мәңгелеккә Җир белән Күк, ике дөнья, үлем белән үлемсезлек арасында эленеп торадыр төсле. Бу фаҗига дөнья беткәнче дәвам итәчәк...

Төрле дастани-мифологик сюжетларга, мотивларга, образларга мөрәҗәгать иткәндә Равил Фәйзуллин беркайчан да аларны кабатлап чыгу белән чикләнми, ә бәлки аларның болай да тирән, серле-сихри мәгънәсен тагын да киңәйтә, тирәнәйтә, әгәр шулай әйтеп булса—аларга яңа, без белмәгән шигъри-мифологик мәгънә өсти. Бу яктан шагыйрьнең шактый иртә, 1966 елда язылган «Карт һәм Шагыйрь» әсәре аеруча игътибарга лаек. Ул—диалог формасында язылган сирәк шигырьләрдән: анда сүз Кеше, конкретрак алганда—Шагыйрь һәм аның бу дөньядагы максаты, бурычы, кылачак эшләре турында бара. Әсәрдә халыкчан җырау (акын) белән бүгенге көн шагыйре арасында бәхәс бара кебек: үзенең оппонентын шагыйрь акын дип тә атый. Һәм ул—әлеге акын—төрки шигърияттә күптән мәгълүм булган хаким-чичәнне, әйтик, «Идегәй» дастанындагы 195 яшьлек Субра-Җырауны хәтерләтә. Шагыйрьнең һәрбер соравына хикмәтле сүз белән җавап бирә, киңәшләрен әйтә ул:

Көлү—көлү, елау—елау,
елап да елый диләр.
Мәгънәсез елаган—мескен,
мәгънәсез көлгән—юләр.
Максатсыз черки дә очмый—
син сүзләр очырасың.
Йә бәхетең ташый синең,
йә сызып ачыкасың.

Шагыйрьнең максаты ачык. Бу хакта ул Картка болай ди:

Әгәр Кояш күпсенмәсә,
чын кешеләр чит итмәсә,
тормыштан тиз китмәмен!

Бик борынгы карашлар буенча, Кояш алла дип саналган һәм аңа, соңгырак чорларда аллаларга табынган кебек, табынганнар. Чөнки кеше үзенең яшәү-үлеме дә шул Кояш ихтыяры белән бәйләнгән дип уйлаган. Китерелгән өзектә Шагыйрь әнә шул бик борынгы карашларга мөрәҗәгать итә... Шагыйрьнең үз-үзенә артыграк ышаныч белән каравы, берникадәр шапырынуын сизеп алган Карт аңа борынгы чичәннәр рухындарак җавап бирә. Бу дөньядагы бик күп кешеләрнең изге максатларга ирешү өчен янып йөрүләре турында кисәткәч, Карт үзенең сүзләрен саф дастани-мифологик яссылыкка күчерә:

Әй, ул туры акыл белән
мәйданга килүчеләр!
Мин моны болай эшлим дип
лаф орып йөрүчеләр!
Шул янып йөрүче йөздән
туксан тугызы кимендә
мәңгелеккә мәйдан тапты
Билгесезлек Илендә.
Кабер, кабер, кабер,
кабер, кабер—кая карама.
Кайсысында эрем үсә,
кайсысында—карама.

Барыннан да элек биредә төрле халыклар, шул исәптән татар халкы мифологиясендә дә чагылыш тапкан Билгесезлек Иле гыйбарәсе игътибарны җәлеп итә. Биредә сүз «теге дөнья», соңгырак чорлар карашлары буенча—Җир асты патшалыгы турында баруы үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк. Тик, безгә билгеле булган фәнни мәгълүматлар буенча, бер генә халыкта да «теге дөньяны»—Билгесезлек Иле дип атау юк. Бу—шагыйрь Равил Фәйзуллин үзе уйлап тапкан һәм һичшиксез уңышлы әкияти-мифологик гыйбарә. Моның шулай булуын төрле халыклар мифологиясе нигезендә дәлилләп була. Мәсәлән, татар халык дастаннарыннан «Йир Төшлек»нең баш каһарманы Барса Килмәс патшаның иленә барып, Көнәр-сылу исемле кызны алып кайтырга тиеш була. Бу очракта дастанда нindидер аңлашылмаучылык киткән булса кирәк: Барса Килмәс—кеше исеме булмыйча, географик атама булуы үзеннән-үзе күренеп тора. Сүз Арал диңгезе уртасындагы утрау хакында бара. Казакълар бу утрау турында могҗизалы легендалар сөйлиләр һәм аңа якын килергә дә куркалар. Шул легендаларның берсендә әйтелгәнчә, әлеге утрауда бер тау бар икән. Тауның түбәсе—өстәл кебек тигез. Тау башындагы шул җирдә искиткеч матур гөлләр, чәчәкләр, җимеш агачлары үсеп тора икән; чишмәләрдә чылтырап аккан су—пыяла кебек чиста һәм көмеш парча кебек ялтырый; тирә-якта искиткеч саф һава. Шунда оҗмахтагы хур кызларына охшаган кызлар, җырлап, биеп, күңел ачып, юлчыларны үзләренә чакыралар икән. Нәтиҗәдә әлеге утрау янынnan беркем дә узып китә алмый, шул кызлар янына килә... Һәм шунда һәлак була икән[13]. Билгеле булганча, шуңа якын сюжет Гомерның «Одиссея»сында да бар[14]. Димәк, Барса Килмәс утравы да, андагы тау да—Үләләр дөньясы. Тауның «теге дөнья»га мөнәсәбәте турында югарыда әйтелгән иде инде. Көньяк Себердәге төрки халыкларда, алтайлыларда, кыргызларда Барса Килмәс—эпик ил, аннан беркайчан да кире кайтып булмый. Җөмләдән, шумер мифологиясендә дә (б.э.к. III меңьеллык) Җир асты патшалыгы кур яки кире кайтып булмастай ил дип атала. Шунда ук тагы әйтеп үтик: әлеге шигырьдә автор үлем турында «мәңгелеккә мәйдан тапты» ди. Бу да—саф мифологик гыйбарә: борынгы Мисырдагы бихисап пирамидалар мәңгелек йорты дип аталган. «Теге дөнья»ны мәңгелек йорт дип атау урта гасырлар татар прозасында—«Мәҗмугыл хикәят»тә дә бар.

Китерелгән өзектә берничә тапкыр кабатланган кабер сүзенә килсәк, аның бик борынгы катлаулы карашлар, мәетне җирләү йолалары, архаик ышанулар белән бәйле үз мифологиясе бар. Мәсьәләнең бу ягын әлегә атап кына үтеп, шигырьдә ачыктан-ачык чагылыш тапкан бер дастани-мифологик моментка игътибар итик. Сүз кабер өстендәге әрем яки карама турында бара. Бу сүзләрне укыгач та, татар халкында да киң таралган «Таһир белән Зөһрә» һәм «Кузы Күрпәч белән Баян-сылу» дастаннарының соңгы күренешләре: тирән мәхәббәт корбаны булган, вакытсыз үлемгә дучар ителгән каһарманнар кабереннән үсеп чыккан агачлар, гөлчәчәкләр, шулар арасында карама яки тигәнәкнең дә булуы хәтергә килә. Бик күп әсәрләрдә кабатланган мондый күренешләрнең мифологик һәм тарихи-этнографик нигезләре бер үк яисә бер-берсенә бик якын. Алар бик борынгы анимистик карашларга, безнең тирә-яктагы барлык «җанлы» (кошлар, хайваннар) һәм «җансыз» (Ай, Кояш, Йолдызлар, тау, елга, үсемлекләр һ. б.) затларның җаны бар дип ышану белән бәйләнгән. Кайбер халыкларның ышануынча, үлгән затларның җаны агачларда гәүдәләнә. Кытайда, мәсәлән, бик борынгыдан бирле кабер өстенә агач утырту гадәте бар: шуның белән үлгән кешенең агачта гәүдәләнгән җанын саклап калып була, имеш[15]. Моңа өстәп тик шуны гына әйтергә мөмкин: Казан татарларының зиратлары гадәттә каен урманы эчендә урнашкан була.

* * *

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Равил Фәйзуллин шигърияте үзенең башлангыч чорыннан ук халык иҗатының хикмәтле сүз, борынгы һәм бик борынгы мифология, әкият, дастан кебек фундаменталь һәм гасырлар тирәнлегеннән килгән җитди традицияләренә таянып үсә. Наис Гамбәр бик дөрес әйткәнчә, «ул үз эшен белде—әдәбиятка җиңүче булып килеп керде, тикшеренүче-эзләнүче булып, иманын раслап яшәде һәм яши» [16]. Моңа өстәп, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин: бик борынгы

шаманчы-анимистларча, Равил Фәйзуллин үзенең һәрбер шигыренә, каурый каләм астыннан чыккан һәрбер шигъри юлына җанлы вә изге, илаһи бер затка караган кебек карый, аларны ирексездән рәнҗетмәмме, кыерсытмаммы дип борчыла. Аның һәрбер шигыреннән ниндидер серле-сихерле изгелек рухы бөркеп тора. 1970 елда язылган бер сигезьюллыгына ул мондый эпиграф биргән иде:

Гомерләре җыр булалган
Кешеләр иң бәхетлеләр!

Сигезьюллыкның үзе исә шигъри иҗатка мәдхия булып яңгырый:

Язсам гына яшәвемне раслыйм.
Юньле эшем—йөзем аклыгы.
Язсам гына—Җирнең улы булам,
сөелүгә-назга хаклымын.

Язсам гына—бәхтем тулы, бөтен.
Язу эше—намус, кан эше.
Язсам гына—илгә, кешеләргә
файда итсәм генә мин кеше.

Гомере буена яраткан изге эше белән шөгыльләнүче, иҗат белән яшәүче чын шагыйрь поэзиясе—халык, аның бик борынгыдан килгән илаһи-изге карашлары, якты өметләре белән бергә яшәүдән генә барлыкка килә ала, тик шул нигездә генә бу дөньяга, Җиһанга аваз сала ала!..

**ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ:**


1 Рәхим Гали. Халык әдәбиятымызга бер караш. // Аң.—1914.—14 сан.—265 бит.
2 Усманов М. А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв.—Казань, 1972.
3 Бу хакта киңрәк мәгълүматларны карагыз: Урманчеев Ф. Героический эпос татарского народа. Казань, 1984; аның ук. Народный эпос «Идегей».—Казань, 1999.
4 Темкин Э. Н., Эрман В. Г. Мифы древней Индии.—М., 1982; Беккер К. Ф. Мифы древнего мира.—Саратов, 1995; Рак И. В. Мифы древнего и раннесредневекого Ирана.—СПб., 1998.
5 Ягъфәров Р. Балалар фольклоры турында. // Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры.—Казан, 1993.—15-16 битләр; Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. Казан, 1941.—184 бит.
6 Миңнуллин Р. Күчтәнәч. Балалар өчен шигырьләр. Казан, 1995.—119, 136-137 битләр.
7 Зурабова К. А., Сухачевский В. В. Мифы и предания. Популярный энциклопедический словарь.—М.; 1993.—С. 38-39.
8 Котрелл Л. Во времена фараонов.—М., 1982.—С. 260-265; Бауер В., Дюмоц И., Головин С. Энциклопедия символов.—М., 1995.—С. 408-411.
9 Әмирхан Равил. Иманга тугрылык.—Казан, 1997.—127-135 битләр.
10 Малов С. Е. Енисейская письменность тюрков.—М.; Л., 1952.—С. 21, 57.
11 Мифы народов мира. Энциклопедия.—Т. 2.—М., 1988.—С. 164-168.
12 Җамалетдинов Л. Тылсымлы әкиятләр // Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап).—Казан, 1978.—9-10 битләр.
13 Энциклопедический лексикон.—Т. 6.—СПб., 1836.—С. 35.
14 Гомер. Одиссея. Пер. В. Вересаева.—М., 1953.—С. 142.
15 Фрэзер Дж. Дж. Золотая ветвь. Вып. I.—М.; Л., 1931.—С. 139.
16 Наис Гамбәр. Шигъри дөньяга сәяхәт // Фәйзуллин Равил. Сайланма әсәрләр.—3 том.—Казан, 1995.—276 бит.

ПУБЛИЦИСТИКА

# МИЛЛИ МУЗЕЙ СӘХИФӘЛӘРЕ

**ЮНЕСКО** карары нигезендә 18 май көне 1978 елдан башлап Халыкара музейлар көне буларак билгеләп үтелә.

Элеккеге СССРда 2 меңнән артык музей исәпләнеп, ул дөньяда 29 урында тора иде. Җөмһүритебездә дәүләт карамагында эшләүче 88 музей бар. Алар арасында иң өлкәне 100 еллык тарихлы Татарстан Дәүләт музее булса, ә инде яшьләреннән—1992 елда нигез салынган, элеккеге Ленин мемориалы бинасында урнашкан Милли мәдәният музее. Җиде еллык кына биографиясе булуга карамастан, бу музейның эшләгән эшләре шактый саллы, планнары колачлы, тарихы да үзенчәлекле.

«Бу музей бөтен дөнья татарларының тарихи һәм мәдәни мирасы белән таныштырырлык, заманча җиһазландырылган илаһи бер сарай булырга тиеш. Бу мөмкинлекне безгә язмыш үзе бирде һәм аны кулдан ычкындырсак, тарих безне кичермәс!»—әлеге юллар 1990 елларда матбугат битләрендә басылган мөрәҗәгатьтән алынды.

«Әдәбият-сәнгать музее кирәк!»—дигән баш астындагы, халкыбызның Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Еники, Ә. Кәримуллин, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Р. Мостафин, Р. Фәйзуллин, М. Мөлеков кебек олпат шәхесләре кул куйган ачык хатлар, мөрәҗәгатьләр республика газеталарында кабат-кабат басылды, ул уй халыкның аңына, йөрәгенә кереп утырды. Милли каһарманнарның хәтта Ленин мемориалы бинасын саклап, анда кунып калган көннәре дә булды.

Кызу бәхәсләрдә узган гыйльми утырышлар, түгәрәк өстәлләр, әле барыбызның да хәтерендә, ә инде җыелышларның беркетмәләре, мөхтәрәм шәхесләр имза салган хатлар хәзер Милли музей елъязмасында урын алдылар. Яңа музейның тарих башы—1992 елның 16 сентябре, ул көнне Татарстан республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Милли мәдәният музее төзү турындагы рәсми карар кабул ителде. Әмма ләкин ераграк тарихка күз салыйк әле.

Музейлар төзү традициясе халкыбыз өчен чит-ят әйбер бүгел. Борынгы төрки бабалардан, Болгар, Казан дәүләте чорларыннан исән калган язма истәлекләрдән шул заманнардагы музей образын да күзалларга мөмкин.

Ул сарайны менә шулай эшләтсеннәр:
Ун мен төрле нәкыш белән бизәсеннәр,
Диварларын бәллүр белән эчләсеннәр,—
Алтын-көмеш белән балкып торсын имди.
Түшәмнәрен сурәт белән бизәсеннәр,
Дүрт диварга төрле рәсем ясасыннар,
Йосыфның да сурәтен ясап куйсыннар,—
Үзенә дә охшаш сурәт булсын имди.

Болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан китерелгән бу өзектә Зөләйха төзеткән сарай турында сүз бара. Бу бит чын мәгънәсендә, бөек сәнгать сарае, шул заманның музее!

Ә чит ил сәяхәтчеләрен таң калдырган мәчет-мәдрәсәләр, зиннәтле хан

сарайлары, андагы хәзинәләр, Сөембикә ханбикә китапханәсе—болар үзләре үк музей бит! Белгәнебезчә, хәзинәләрнең язмышы аянычлы—алар юк ителә, Мәскәүгә озатыла, ә татар милли сәнгатенең ин камил үрнәге булган һәм дөнья җәүһәрләре исемлегендә саналган Казан тажы хәзер Мәскәүнең Кораллар палатасын бизи.

Татар тарихы күп фажигаларга, югалтуларга дучар булса да, халык өметен сүндерми, милли хәтерен җуймый. Татарның милли каһарманы Г. Исхакый үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә хәтта татар музеенын өлгесен дә сурәтләп бирә, үз халкының шанлы тарихы, даһи шәхесләре, бөек мәдәнияте белән горурлана. Бу музейда—бөтен бер халыкнын тарихы, әдәбияты, сәнгате.

«Рәсемнәр берлән зал тулган иде. Һәм дә һәммәсе дә болгар тормышыннан булганга, болгар мохиббанына күп мәгънә алырлык иде. Унтугызынчы гасырдан башлап беткәнчегә кадәр килгән болгарларның зур кешеләре, мөхәррирләре, әдипләре, галимнәре, шагыйрьләре, драматурглары, хәкимнәре, музыкантлары, народниклары—һәммәсе үзләренең иң мәгълүм вазгыятьләрендә төшерелгәннәр иде...



*Шәһәр йортының эчке күренеше. XIX гасыр ахыры—XXгасыр башы.*

Җәгъфәр әфәнде икенче залга чыкты...

Монда тарих белгән заманнан бирле булган болгарларның әйберләре бар иде. Акчалары, киемнәре, зиннәтләре, өй җиһазлары, хатын-кыз зиннәтләре, табаксавытлар—һәммәсе бар иде. Болар арасында Үзбәк ханга Мисыр хәлифәләреннән җибәрелгән кылыч та бар иде...»

Әсәрнең герое Җәгъфәр «Болгар әдәбият музее»н да карый. Болгарларда матбагачылык эше башланганнан алып шул соңгы көннәргә кадәр чыккан бөтен әдәбият, газета-журналлар белән тулы була ул. «Болгарларның калдырган нәрсәләре бик күп булса да, моның да иң әһәмиятлесе, иң файдалысы—болгар әдәбиятыдыр... Болгар әдәбиятында без ачык болгар тормышын таптыгымыз кебек, бик ачык әхлак дәресе дә алачакмыз»,—ди Г. Исхакый үзенең 1904 елда басылган фантастик әсәрендә.

Ә инде 1912 елда татар музее төзү идеясе җәмәгатьчелек тарафыннан чынлап торып күтәрелә, тик тормышка гына ашмый.

Казан университетының география кабинетында профессор Б. Ф. Аллер тарафыннан Л. О. Сиклерның татар тарихына нисбәтле гаҗәеп бай коллекциясеннән күргәзмә оештырыла. Күргәзмә зур кызыксыну тудыра, татар җәмәгатьчелеге исә милли тарихыбызның барлык дәверләрен дә яктырткан музей оештырырга

кирәклеген яклап чыга. Б. Ф. Адлер әлеге мәсьәләне уңай хәл итүне сорап шәһәр хакимиятенә мөрәҗәгать юллый, ләкин үтенеч кире кагыла. Әмма өмет сүнми, 1917 елгы вакыйгалардан соң ул яңара гына. Бу юлы да университетта оештырылган «Шәрык халыклары мәдәнияте» күргәзмәсе материалларыннан музей булдыру мәсьәләсе күтәрелә, аның исеме—аталышы, бина хакында да сүз кузгатыла. Ләкин күргәзмә ябыла, аның коллекцияләре Татарстан Үзәк музееның этнография бүлегенә күчерелә, ә музей аянычлы язмышка дучар була.

Татарларда шәхси музейлар булуы да мәгълүм. Шуларның икесе махсус игътибарга лаек.

Күренекле галимебез Ш. Мәрҗани борынгы кульъязмалардан, китаплардан, документаль һәм нумизматик чыганаклардан торган бай коллекция туплый. Кызганычка каршы, аның күп өлеше янгында һәлак була, исән калганнары хәзер Казан университеты фәнни китапханәсендә һәм Татарстан Фәннәр академиясенең кульъязмалар бүлегендә саклана.

Мәшһүр эшмәкәр Хәсән Акчурин да зур милли байлык туплаган була. Анда халкыбызның борынгы тарихы һәм мәдәниятенә кагылышлы бик күп кызыклы материаллар, алтын-көмеш һәм башка кыйммәтле әйберләр булуы билгеле, заманында аларны шагыйребез Г. Тукай да кызыксынып караган, диләр. Бәхетсезлеккә каршы, 1918 елда бу коллекция эзсез югала һәм аның язмышы бүген дә билгесез килеш кала бирә. Тагын югалту, тагын фаҗига, ләкин эш тукталмый.

1895 елда Казанда ачылган шәһәр музее совет чорында республиканың Үзәк музеена әйләнеп, анда татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча бай коллекция туплана, сиксәнгә якын музей-филиаллар барлыкка килә, аерым музейга тиң булган татар әдәбияты тарихы бүлеге ачыла, милли кадрлар тәрбияләнә. Әмма җәмгыятьтә үзгәртеп кору җилләре исә башлау белән, Милли музей идеясе яңадан баш күтәрә. Бу инде өченче омтылыш, яңа XXI гасыр бусагасына атлаганда яңадан туган хыял, хыял гына түгел, ә зарурият иде.

Милли музей—ул хәтер хәзинәсе. Халкыбызда кадерләп сандыкларда сакланган яки ваемсызлыкка очрап чәчелеп-аунап яткан ядкарьләрне эзләп табып кире халыкка кайтарган, тарихыбызны барлап, милли хәтеребезне яңарткан хәлдә генә, без милләт буларак сакланып кала алабыз.

Дөньяга сибелеп яшәүче җиде миллионлы татар халкының меңьеллык бай матди һәм рухи мирасын туплап, музей залларында халкыбызның иң борынгы дәверләрдән алып, хәзерге көннәргә кадәрге тарихын һәм мәдәниятен күрсәтүне төп бурыч итеп куйган Милли музей Татарстанда әле юк иде. Татар халкы турындагы төрле уйдырмалардан арындырылып, аның чын, гадел тарихын яктырткан, татар миллиятенең кешелек дөньясында тоткан урынын күрсәтеп, аның гыйбрәтле язмышы аша милли фаҗигасын да ачып бирә алырлык булырга тиеш. Яңа музей! Без бу эшкә бөтен җаваплылыкны аңлап-тоеп, музейның зарурлыгына инанып алындык.

Яңа музейда Татарстан Дәүләт музееның әдәбият бүлегеннән, Сынлы сәнгать музеennан күчеп килгән һәм Ленин музееның элеккеге хезмәткәрләреннән торган 10-13 кешелек энтузиастлар коллективы оешып, ул бераз үзгәргән хәлдә бүгенге көнгә кадәр эшләп килә—даими экспозиция төзү эшләре белән беррәттән, ел саен тарих, әдәбият, сынлы сәнгать өлкәсендә яңадан-яңа күргәзмәләр оештыра, экскурсияләр үткәрә, ядкарьләр туплый, аларны өйрәнә, саклый... Әлбәттә, коллективның үзенә генә зур тарихны колачлау мөмкин эш түгел. Музейның фәнни концепциясе Р. Фәхретдинов, С. Алишев, И. Таһиров, Г. Вәлиева-Сөләйманова, М. Әхмәтҗанов, Д. Исхаков кебек милләтпәрвәр галимнәр тарафыннан эшләнде, алар хәзер дә безнең иң зур киңәшчеләребез, фикердәшләребез һәм дусларыбыз.

Музейлар ничек төзелә соң?

Әлбәттә, музей эшенең үз кануннары, үзенчәлекләре бар. Бу турыда мәгълүматне музеология фәненнән алырга мөмкин, бу хакта аерым китаплар, кызыклы хезмәтләр дә язылган. Хәзерге заман музейлары фәнни нигезләре һәм сәнгатьчә бизәлешләре белән бер-берсенә тәңгәл булып, милли традицияләргә таянып эшләнергә тиеш, шундый экспозицияләр генә тамашачы тарафыннан кабул ителә. Музей хезмәткәре исә үз эшенең профессионалы булу белән бергә, күп нәрсәдән мәгълүматлы, югары зәвыклы, сәнгатьчә күрә һәм фикерли белә торган зат та булырга тиеш.

Музей хезмәте ул авыр да, кызыклы һәм мавыктыргыч та. Мәскәүдәге Пушкин музее директоры А. Крейн үзенең «Рождение музея», «Жизнь музея» дигән китапларында музей тормышының көндәлек мәшәкатьләреннән башка иҗат романтикасын да бик оста итеп сурәтләп бирә. Музейның хасияте шундый—анда эшкә килгәннәр йә шундук китеп баралар, йә гомерлеккә калалар.

Һәр музейның—үз язмышы, үз йөзе, үз мәсләге бар, ләкин шунысы бәхәссез, коллекцияләрсез музей була алмый.

Дөнья музейлары, үзебезнең Татарстан музейлары тәҗрибәсенә күз салсак, без аларның күпчелегенең билгеле бер маядан башланып киткәнен күребез. Мәсәлән, 1824 елда Лондонда оештырылган Милли галерея өчен Англия хөкүмәте махсус рәвештә 38 картина сатып алып бирә. Бүгенге Татарстан Дәүләт музее 1890 елда Казанда үткәрелгән Бөтенрусия күргәзмәсе материаллары һәм галим А. Ф. Лихачев коллекциясенә нигезләнеп ачыла. Ә Татарстан сынлы сәнгать музее башта Дәүләт музеенда бүлек буларак эшләсә, соныннан үзенең коллекцияләре белән аерылып чыгып мөстәкыйль музей булып китә.

Безнең Милли мәдәният музее рәсми карардан башланып китте дияргә була, чөнки Ленин музееннан калган мирас исәптә булса да һәм күпмедер дәрәҗәдә файдаланылса да, һич кенә дә яңа музейның нигезе була алмый иде. Шуңа күрә дә, безнең алдыбызда торган иң актуаль, хәтта беренчел мәсьәлә—музейның фондын булдыру, ягъни коллекцияләр туплау иде һәм бүгенге көндә дә шулай булып кала.

Инде ничәмә-ничә буын мирасыбызны җыю белән мәшгуль булсалар да, халкыбызның сандыклары әле буш түгел икән! Мәскәү һәм Касыйм, Әстерхан һәм Кырым, Үзбәкстан һәм Башкортстан, Пермь һәм Оренбург, Минск һәм Санкт-Петербург төбәкләрендә экспедиция-командировкаларда йөргәндә, без моны үз күзебез белән күрдек, гасырлар аша исән калган ядкарьләрне табып чын күңелдән шатландык һәм бәхетле мизгелләр кичердек. Иң куанычлысы шулдыр, милли җанлы кардәшләребез үзләренең хәзинәләре белән уртаклашып риясыз ярдәм кылдылар.

Касыймнан 92 яшьлек Әхмәт Ишимбаев һәм Фатыйма Тугиева, Мәскәүдән Гөлнар Мамлеева, Оренбургтан Мәдинә Рәхимкулова, Казаннан Зәкия Рәсүлева, Илсөяр Сөнкишева һ. б. бик күпләр әнә шундыйлардан.

Музейның мирасханәсендә 1999 елның башына 27.537 саклау берәмлегә исәпләнә (аның 10 меңгә якыны элеккеге Ленин музее экспонатлары),—шуның 17.842 төп фондка карый, калганнары—ярдәмче материаллар.

Экспонатлар төрләре буенча түбәндәгечә бүленә: нәкыш—517, графика—790, скульптура—73, нумизматика—926, этнография—250, документаль фонд—11.198, фоторәсемнәр—1.240.

Мирасханә материалларына күз ташлагач, музейның төп игътибарын мәдәният өлкәсенә юнәлткәнен күрәбез, чөнки ул үзенең профиле буенча тарихи-мәдәни. «Мәдәният» төшенчәсен без киң мәгънәдә аңлыйбыз—аңа әдәбият, сәнгать, сәнгатьнең төрле төрләре дә, сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать, музыка һәм театр сәнгате, тел, дин һәм гореф-гадәт, философия, архитектура, хәтта сәясәт тә керә. Ләкин төп кыйблабыз, барыбер, тарих булып кала, чөнки мәдәният тарихы халык тарихыннан аерылгысыз.

Классификациядән күренгәнчә, мирасханәдә иң зуры—документаль фонд. Аның күп өлешен шәхси архивлар һәм төрле коллекцияләр тәшкил итә. Әлбәттә, бу язма кысаларында аларга тулы тасвирлама бирү мөмкин түгел, шулай да кайберләренә кыскача гына тукталып китәсе килә.

Милли мәдәният музее төзү турында карар кабул ителгәннән соң экспонатлар җыю максаты белән оештырылган беренче сәфәр Әлмәт төбәгенә иде һәм аннан милли тарихыбызга нисбәтле кызыклы кульязма һәм басма китапларны эченә алган Шамил Сафин архивы алып кайтылды. 114 берәмлектән торган бу тупламада 1732 елда Константинополь шәһәрендә Кятиб Чәләби тарафыннан язылган һәм XIX гасыр урталарында Казанда күчерелгән дип уйланыла торган «Җиһаннамә» җыентыгы да бар. Тарих, география, астрология, математика һәм башка фәнни мәгълүматларны эченә алган бу китап Ш. Мәрҗани һәм аның шәкертләре кулы белән күчерелгән дип фараз ителә. Музейның инвентарь китапларына беренче табышлардан нәкъ менә «Җиһаннамә» кереп китте һәм без аны башлаган эшебезгә фатиха дип кабул иттек.

Әлмәттән шулай ук шагыйрә С. Сөләйманова архивының да бер өлеше кайтты,

аны шагыйрьнең ире, язучы Әдип Маликов тапшырды.

Татар халкы—китаби халык. Безнең музейда борынгы кулъязма һәм басма китаплардан махсус фонд формалашып килә. Анда тарихи чыганак буларак, фәнни әһәмияткә ия һәм китап сәнгате үрнәгенә тиң нөсхәләр туплана. Мәсәлән, югарыда искә алынган «Җиһаннамә», халык медицинасы буенча, пәйгамбәрләр тарихы турындагы китаплар, мөселман хокукы буенча XYIII-XIX гасырларга караган Имам Әл-Газалинең «Ихьяэл голум» китабы, дистәгә якын Коръән—Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовнеке (Ишми ишан), Алишлар нәселендә буыннан-буынга күчеп тапшырылып, 1851 елда Казанда басылганы, Аитов гаиләсеннән XYIII гасырда күчерелгәне һ. б; Габделгаллә м Фәезханов тәрҗемәсендә 1891 елда Казанда басылган Әбелгази Баҗадирханның «Шәҗәрәи төрек» китабы, «Фәлсәфи нәсихәтләр китабы» (Истанбул, 1893), «Сәяхәтләр турында язмалар» (Бомбей, 1879) һәм башкалар.

Борынгыдан килгән китап традицияләренең яңарак заманда дәвамчылыгы музей фондында саклан учы ядкарьләрдә дә ачык чагыла. Ядкарьләрнең берсе—язучы Әнәс Галиевнең Польша һәм Германия концлагерьларында тоткынлыкта үз кулы белән ясап язган шигырь дәфтәрчекләре. Шомлы елларда да сакланып кала алган Г. Исхакый басмаларын язучының 115 еллыгына багышланган күргәзмәгә күренекле галимнәр Л. Гайнанова, И. Нуруллин, Х. Миңнегулов, язучылар Ә. Еники, Т. Миңнуллин һ. б. бүләк иткән иде. Ә менә укытучы Т. Корбанов тапшырган басма аеруча кызыклы—бер китапка Г. Исхакыйның 1904-1918 елларда чыккан тугыз әсәре тупланган, «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның җитмәгән битләре кулдан күчереп язылган!



*Г. Гобәйдуллин һәм Г. Рәхим. 1924 ел.*

Үзебезнең Татарстанда һәм Казанда эзләнүләр алып бару белән бергә, татарлар яшәгән ерак һәм якын төбәкләргә оештырылган экспедицияләр әйбәт нәтиҗәләр бирә. Мәгълүм булганча, Мәскәүдә зур һәм көчле интеллектуаль диаспора бар, без анда махсус әзерләнгән биш экспедиция уздырдык. Милли музей идеясен хуплап, үзләрендә сакланган материаллар белән уртаклашучылар арасында армия генералы Мәхмүт Гәрәев, академик Әдһәм Тенишев, тарихчы Шамил Мөхәммәдьяров, бертуган Шамил һәм Гүзәл Апанаевлар бар; скульптор Садри Ахунның хатыны Юлия Бейер исә ире иҗат иткән Тукай һәм Җәлил бюстларын, сөекле композиторыбыз С. Сәйдәшевнең әле исән чагында битеннән алынган маскасын бүләк итте. Морзалар нәселеннән чыккан Гөлнар ханым Мамлеева да музейга кыйммәтле ядкарьләр тапшырды. Алар арасында—Казан ханлыгы чорыннан исән-имин килеп җитә алган алтын йөгертелгән зур декоратив көмеш төймә, 1912 елгы Ватан сугышы герое, татар-башкорт полкы командиры Гәрәй Кайбишев кушагы, нәселләренә бәйле 26 фоторәсем, бабасы Нурмөхәммәт Бикбулат улы Мамлеевның кулъязма китабы...

Мәскәүдәге шулай ук өч язучы-галим Г. Гали, Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин архивлары алып кайтылды. Репрессия корбаннары булган бу язучыларның архивларында тарих сабагы бирердәй тетрәндергеч документлар сакланган. Алар арасында Гомәр Галинең төрмәдә үзе ясаган бумажнигы (ул анда кызлары Алсу белән Гүзәлнең рәсемнәрен саклаган), хатыны һәм балаларына Владимир төрмәсеннән һәм Красноярск сөргененнән җибәргән хатлары һәм фотосурәтләре, надзирательләр тарафыннан төзелгән актлар, белешмәләр һәм Г. Галинең төрмә начальнигы исеменә язган гаризасы (ул үз хисабына «Правда» газетасы һәм «Большевик» журналын алдыруны үтенә) аеруча әһәмиятле. Архивны язучының кызы Гүзәл Ибраһимова тапшырды.

Татарлардан беренче тарихчы-профессор Г. Гобәйдуллин белән язучы Г. Рәхим татар тарихы, әдәбияты, мәдәниятенә караган күп санлы хезмәтләрнең авторлары. Бу ике әдипне иҗади дуслыктан тыш, туганлык җепләре дә бәйли—алар әниләре ягыннан туганнан туганнар. Бу архивлар Г. Гобәйдуллинның улы Сәлмән Гобәйдуллиннан алынды.

Музейның документаль фондында тагын Мәдинә Рәхимкулова, Габделхәмит Апанаев, Гөлсем һәм Фуад Саллави тупланмалары, С. Хәкимнең тулы архивы (ул 4.492 саклау берәмлеге тәшкил итә) һ. б. материаллар саклана.

Эзләнүләр, кызыклы очрашулар алар мәңгегә күңелгә кереп калалар. Мәскәүдә Маргарита Әхмәрова белән дә шулай булды, ул мәшһүр разведчик Исхак Әхмәровның кызы. Әле соңгы елларда гына милләте белән татар булган бу разведчикның исеме җәмәгатьчелеккә мәгълүм булды. Исхак Әхмәров 1935 елдан Америка Кушма Штатларында 12 ел буена яшерен совет разведкасын җитәкли, бик җаваплы эшләр башкара. АКШта Хелен Лоури исемле америкалы кызга өйләнә. Әхмәровлар үзләре инде вафат, аларның өч кызы Мәскәүдә яши. Олы кызы Маргарита музейга әтисенең берничә фоторәсемен һәм хатларын бүләк итте, ул И. Әхмәровның мирасын бик кадерләп саклый. Маргарита Әхмәрова 1944 елда Америкада туган, тышкы кыяфәте белән дә чын америкалы, сөйләшүендә дә җинелчә акцент бар, урысча, инглизчә сөйләшә, ә паспортында «татар» дип язылган. Исхак аганың теләге буенча барча балалары да «татар» дип теркәлгәннәр. Татарлыкка килгәндә, ул Маргарита ханымда тирәнгә, эчкә яшерелгән, татарлык анын характерында, дөньяга карашында, яшәү рәвешендә чагыла. Татар булу аңар «лаврлар» китермәгән билгеле, хәтта милләтен үзгәртергә, чукындыру йоласын узарга тәкъдим ясаучылар, юкса сиңа Аллаһы Тәгаләдән мәрхәмәт булмас, диючеләр дә очраган. Ләкин ул әтисенә хыянәт итмәгән. Атасының да мөселманлыгы, татарлыгы күбрәк анын йөрәгендә, күңелендә, эшенә,



*Башкортстанның Яңавыл районыннан алып кайткан хәзинәләр*

гаиләсенә тугрылыклы булуында, дип саный Маргарита ханым Әхмәрова.

Үземнең юлдашым, мирасханә мөдире Галия Саттарова белән, урыс мохитендә гомер иткән татарларның урыслаша баруын күреп бер көенсәк, менә шундый иманлы кешеләр белән очрашуга без чын күңелдән сөенеп кайттык.

Без кем, нәсел-нәсәбебез нинди? Менә шушы сорауларга җавап эзләү, милли шәхесләребезне барлау йөзеннән без «Татар шәҗәрәләре» («Буыннар хәтере») дигән күргәзмә оештырган идек. Мәгълүм ки, халкыбызда үзенең җиде яки тугыз бабасын белү мәҗбүри саналган, ул үзенең нәсел шәҗәрәсен кадерләп сандыкларда саклаган һәм изге ядкарь итеп буыннан-буынга тапшырып килгән. Күргәзмәдә күрсәтелгән 400 дән артык экспонат нәсел җебен дәвам итүче хәзерге буын вәкилләре тарафыннан тапшырылган иде һәм күбесе киң җәмәгатьчелеккә беренче мәртәбә тәкъдим ителде. Атаклы галимнәр Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхретдинов, сөекле шагыйребез Г. Тукай, татар дөньясында яхшы мәгълүм Хәлфиннәр, Терегуловлар, Әмирханнар, Максудилар, Алишлар, Шәрәфләр, үз халкы өчен күп игелекле эшләр башкарган сәүдәгәрләр, эре промышленниклар Акчуриннар, Үтәгәновлар, Апанаевлар, Гобәйдуллиннар, Казаковлар... кебек татар милләтенең генофондын тәшкил иткән 20 дән артык нәсел һәм аларга караган шәҗәрәләр, тарихи документлар, фоторәсемнәр, китаплар һәм шәхси әйберләр әнә шундыйлардан.

Күргәзмәгә куелган иң борынгы һәм кызыклы шәҗәрәләрнең берсе—Казан шәһәренең атаклы Үтәмешевләр, Тенишевлар, Кильдишевлар, Аитовлар, Галиевләр, Алкиннар, Юнисовлар, Ишморатовлар һ. б. нәселләрне бергә бәйләүче Фәридә Кадырова (Үтәмешева) тапшырган шәҗәрә булса, «Генеалогические таблицы Йоганна Хюбнера» дигән басма борынгы шәҗәрә китабы иде. 1712 елда Лейпциг шәһәрендә немец телендә басылган бу китап-альбомга шул заманның 333 данлыклы нәселләре рәтендә татар ханнарының да нәсел шәҗәрәләре кертелгән.

Аерым шәхесләр, нәселләр тарихыннан халкыбыз тарихы барлыкка килә, ә аерым ядкарьләрдән милли байлыгыгыз туплана.

Музейга коллекцияләр туплау өлкәсендә күргәзмәләр оештыру иң кулай алым булып тора. Күргәзмәләрнең күбесе «беренчеләр» исәбендә: Мирсәет Солтангалиев, Гаяз Исхакый, «Татар шәҗәрәләре», «Татар сәнгате җәүһәрләре», «Борынгы тарих», «Татар дөньясы»,—аларны Милли үзәкнең тарихи миссиясе дип карарга кирәктер.

Күргәзмәләр арасында иң колачлысы—«Татар дөньясы». Гаҗәеп бай мәгълүматлы һәм заманча итеп бизәлгән бу күргәзмә халкыбызның Төрки каханлыклардан алып хәзерге көннәргә кадәрге кыскача тарихы, аның төрле этник төркемнәре—Казан, Касыйм, Әстерхан, Себер, Литва һ. б. татарларның милли киемнәре, гореф-гадәтләре, яшәү рәвешләре белән таныштыра; этник төркемнәр мәдәниятенең күптөрлелеген саклаган хәлдә, гомуммилли мәдәниятнең бердәмлеген күрсәтә, чөнки татар халкы кайда гына яшәсә дә бер милләт, бер халык.

Чәчелгәнбез,
Сибелгәнбез,
Түгелгәнбез,
Таралганбыз—
Барыбер уртак Казанга
Юлны әле табалганбыз!

II Бөтендөнья татар конгрессы уңаеннан оештырылган бу күргәзмә М. Әгъләмовның әлеге юллары белән тәмамлана.

«Татар дөньясы» күргәзмәсе галимнәр һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнеп, Милли мәдәният музееның төп өлгесе, оптималь моделе буларак кабул ителде, матбугат битләрендә ул Милли музейга беренче адым, дип бәяләнде.

Эш дәвам итә—яңа күргәзмәләр оештырыла, яңа коллекцияләр туплана, даими экспозиция әзерләнә... Милли мәдәният музееның үз йөзе формалашып килә, республика музей челтәрендә аның үз урыны бар. XXI гасырда бу музей татар милләтенең рухи бердәмлеге символына әверелергә тиеш.

**Индүсә МИНҺАҖЕВА,**
*Милли мәдәният музееның*
*әдәбият бүлеге мөдире.*

*Хәтер*

**Рафаэль Мостафин**

# ШАМИЛ УСМАНОВ ТУРЫНДА ӨЧ РИВАЯТЬ

*Язучылар вафат булгач алардан китаплар гына түгел, күп төрле риваятьләр дә, колактан колакка йөри торган кызыклы сүзләр һәм хәтта имеш-мимешләр дә кала. Әлеге сүзләр, риваятьләр теге яки бу язучы хакында басылып чыккан монография яисә мәкаләләр хәтле үк мәгълүмат бирергә мөмкин.*

*Шамил Усманов та үзе хакында байтак риваятьләр тудырган легендар шәхес. Аны исән чагында ук «татар Фурмановы» дип йөрткәннәр. Чыннан да, Усманов та революциягә хәтле үк большевиклар фиркасендә торган, гражданнар сугышында комиссар булган, ә аннары популяр язучы—драматург, прозаик, очеркист, фантастик әсәрләр иҗат итүче. Шамил Усмановка багышланган күп санлы мәкалә һәм монографияләрнең исемнәре генә дә күп нәрсә турында сөйли: «Революция тарафыннан чакырылган», «Кызыл легион комиссары», «Революция сугышчысы һәм елъязмачысы», «Революция солдаты», «Каләмне штыкка тиңләп», «Гасыр каһарманлыгы» һ. б.*

*Бу язмамда мин Шамил Усманов иҗатына анализ ясауны максат итеп куймыйм. Әдәбият сөючеләргә кызыклы һәм файдалы булырдай берничә риваятькә генә тукталып үтмәкче булам.*

## Беренче риваять

Бу хәл 1917 елның феврале белән октябре арасында була. Унсигез яшьлек Шамил ул чагында Акчуриннарның туку фабрикасында (Сембер губернасы) слесарь булып эшли. Әлбәттә, бу инде—тынгысыз еллар, давыллы чор. Күпсанлы фиркалар төзелә, митинглар шаулый. Эшчеләр дә «соңгы һәм хәлиткеч һөҗүмгә» әзерләнеп коралланалар. Шул ук вакытта фабрикантлар да йоклап ятмый. Эшчеләр арасында шундый сүз тарала: имеш Акчуриннар корал һәм башка сугыш кирәк-ярагы туплыйлар икән, аны Тимошкинодагы йортларында яшереп саклыйлар икән. Фирканең Гурьевтагы большевиклар секциясе Шамил Усмановка бик җитди эш куша: кызылгвардиячеләрнең кечерәк кенә бер отряды ярдәмендә Акчуриннар йортына тентү үткәрергә!

Һәм менә өстенә күн куртка кигән, биленә наган таккан Шамил отряды Акчуриннар ихатасына килеп керә. Әмма язмышның усал шаяртуы диген: Акчуриннар бусагасында аны үзенең бертуган абыйсы—патша армиясенең поручигы икенче Усманов—каршылый. Ләкин ул, Шамилдән аермалы буларак, либерал карашларда тора, Акчуриннар белән дә дуслашып алган, хәтта туганлашырга да исәбе бар кебек. Менә шул егет «пролетариатның сугышчан отрядына» юлны бикләмәкче була диген! Шамил шундук кобурасыннан корал тартып чыгара:

—Яки син безне үткәрәсең, яки мин сине үз кулларым белән...

—Ат!—дип катгый җавап бирә ана абыйсы. Шундук, күрәсең, катырак сүзләр дә әйтелгәндер инде. Бәлки әле «манка» да дигәндер—Шамил чыннан да бик яшь бит әле.

Ату тавышы яңгырый. Абыйсының гәүдәсе аша атлап Шамил өй эченә үтә. Анда жентекләп тентү ясый, табылган коралны алып чыга.

Менә бу вакыйга тирә-яктагы татар авыллары халкын шаккатыра—бертуганнар бер-берсен үтерә башлады бит! Ул хакта хәтта бәет тә чыгаралар. Бу бәет илленче еллар уртасына хәтле телдән телгә йөри. Шунысы кызык: бу бәеттә моның үзе хәлләрнең бөтенхалык фажигасе булып тәмамланасы алдан әйтелә, кисәтелә.

Шул ук вакытта бәет Усманов гаиләсе тормышындагы конкрет вакыйгаларны да теркәп калдырган. Анда бу хәлне ишеткәч ана кешенең акылдан язуы һәм шактый вакытлар үз акылына килә алмый йөрүе әйтелә. Ә Шамилнең хак диние әтисе (ул Мәккәгә барып хаж кылган кеше) башкисәр малаен чын күнеленнән каргый, туган йорт бусагасын атлап керүне гомерлеккә тыя. Ләкин инде большевистик идея белән тәмам очынган Шамил моны уйлап та бирми. Ул һаман «дөнья болгатуын» дәвам итә, «архиреволюцион адымнар»ны бер-бер артлы ясап кына тора.

Әле генә без сөйләп үткән бу риваять чыннан да дөрес микән соң?

Үз әтисе турында озак еллар буена материал туплаган һәм «Хәтер күзләре» дигән китап чыгарган Айсылу Сагайдак бу вакыйга хакында бөтенләй искә дә алмый. Бер вакыт мин аннан «Әлеге хәлне нигә бер дә искә алмыйсың?» диеп сораган идем. Аның жавабы шундыйрак булды: бәеттән башка бүтән бер генә дәлил дә юк шул. Үз туганын үтерү кебек фажига чыннан да булса, аның әтисе атмаган булырга да мөмкин. Аның отрядындагы берәр кызылармеец аткан булу ихтимал... Ә халык фантазиясе моны Шамилгә яккандыр... Ә менә икенче бер тикшеренүче Альберт Яхин (аның да бу хакта китаплары һәм бер пьесасы бар) атуын чынлап та Шамил аткан диеп бара, ләкин үзенең абыйсын түгел, ә туган тиешле кешесен. А. Яхин әйтүе буенча да биредә ачыкланып житмәгән нәрсәләр бик күп. Шуңа күрә ул да бу вакыйганы үз китабына кертмәгән.

## Икенче риваять

Әмелә бу вакыйга исә күпкә соңрак була. Инде гражданнар сугышы беткән. Дивизия комиссары булып алган Усманов—хәзерге дәрәжәгә күчерсәң, бу генерал дигән сүз—Казандагы пехота командирлары курсында политбүлек начальнигы булып эшли.

Башта Шамил Усмановның бик чибәр кеше булуын әйтеп узыйк. Атаклы артистка Галия Кайбицкая аны хәтта чын ир-ат үрнәге диеп тә атый. Ул буйга озын түгел, әмма нык, таза гәүдәле була. Һәрвакыт гимнастеркадан һәм галәфи чалбардан йөри, ялтырап торган хром итекләр кия. Хәрби фуражкасы яшьләрчә бер якка янтайтыбрак киелгән, ана сыеп бетмәгән коңгырттрак чәчләр бөселеп чыгып тора. Биленең бер ягына кавалерия кылычы, ә икенчесенә маузер таккан. Менә шушы кеше буш вакыт таптымы—кулына каләм ала...

Бу вакытта инде ул беренче хатыны белән аерылган, анда аның Айсылу исемле кечкенә кызы үсеп килә... Ә Шамил Усмановның күнелен инде ул чактагы татар сәхнәсенең йолдызы булган Асия Измайлова биләгән.

Бер мәлне Асия Измайлова концерт бирергә дип Урта Кабан күле буена урнашкан Командирлар курсына килә. Элек Аркадия бакчасы диеп йөртелгән урын. Менә шушы ямьле урында концерт беткәннән соң алар бик күптән утыртылган паркның матур аллеялары буйлап йөриләр. Шундый тыныч жәйге төн була бу. Күктә ай яктырта. Сандугачлар сайрап тора. Шул чагында кинәт мылтыктан аткан тавыш ишетелә һәм куркынган хатын-кыз тавышы яңгырый. Шундук курсантлар йөгереп килә һәм алар мондый күренешкә тап була: комиссар Шамил Усманов жиргә утырган да, аягыннан итеген салырга азаплана. Ә итек эченнән кан ага. Янәшәсендә артистка Измайлова. Ул аңа итеген салырга булышып маташа.

Билгеле инде, йөгереп килгән курсантлар шундук булышырга тели, кайберләре исә тирә-юньгә таралып комиссарга аткан дошманны эзләп тапмакчы була. Ләкин гажәп: комиссар үзе аларны туктата.

—Кирәкми... Мин үзем бит... Аякка ялгыш үзем аттым бит мин...—ди ул.

Курсантлар яралы комиссарны күтәреп кул буена хәтле китерәләр һәм көймәгә утыртып госпитальгә алып киләләр.

Сонрак исә Шамил Усманов үзенен дусларынын берсенә болай дип серен чишә:

—Аягыма үзем аттым бит мин. Юләрлек белән. Асиягә булган мәхәббәтемне раслыйсым килеп!.. Югыйсә, ул минем яратуыма ышанмый йөри... Яратуымны раслардай дәлилләр таләп итә бит... Менә шуна мин кызып киттем инде... Әлбәттә, бер «гөнаһсызга» яраланган аяк табаны шактый нык җәрәхәтләнгән була, ул әле озак төзәлми, Шамилне байтак газаплый. Ләкин, анын каруы, безнен комиссар үз максатына ирешә—Асия Измайлова ана кияүгә чыга.

Бу бер риваять кенә булса, шушы урында нокта куярга да мөмкин булыр иде. Ләкин бөтен хикмәт тә шунда шул—бу вакыйга чынлыктан алынган, чынлап та булган икән. Сонга таба гына ул риваятькә әйләнгән. Һәм ул риваятькә тора-бара төрле-төрле үзгәрешләр кергән. Кыскасы, халык авыз иҗаты «эшли» башлый. Гайбәтчеләр дә тик ятмаган, әлбәттә. Ахыр чиктә шундый түзә алмаслык хәл килеп туа ки: гаилә Казанны ташлап, Шамилнен яраткан эшен калдырып, Мәскәүгә күчеп китәргә мәҗбүр була. Ләкин аларнын уртак гаилә тормышы анда да килеп чыкмый.

Мона гаҗәпләнергә дә кирәкмидер мөгаен—чөнки икесе дә баш бирергә яратмый торган, көчле шәхесләр. Бер-берен битәрләүләр, гаепләүләр торган саен ешая бара һәм аптырагач алар аерылыша.

Шамил Усмановнын мона бик исе киткәндер дип әйтәсем килми. Чөнки яраткан кызы белән аерылышунын беренче трагедиясен ул яшь чагында ук, әле өйләнгәнче үк, бер мәртәбә кичергән була инде. Ул вакытта Шамилнен муенынннан гашыйк булган кызы бүтән кешегә кияүгә китеп бара. Бу хакта белеп алгач Шамил нишләргә дә белми, шундый нык газаплана, хәтта үз-үзенә кул салмакчы була һәм йөрәгенә төбәп ата да. Ләкин ул йөрәкнен кайда урнашканлыгын гына белмәгән икән. Аны ун якта дип уйлап, күкрәгенен шул ягына аткан була. Үпкәсен генә яралый.

## Өченче һәм сонгы риваять

Бу Шамил Усманов гел дә үзенә атып һәм туганнарын атып кына йөргән икән дип уйламасын иде укучы. Юк, ул барыннан да элек язучы булган. Һәм андый-мондый гына язучы да түгел—ә бик тә актив иҗат итә торган әдип. Егерменче-утызынчы еллар әдәбиятында сизелерлек эз калдырган язучы.

1919 елда Шамил Усмановлар гаскәре Ырынбур шәһәрен сугышып алганнан сон берникадәр вакыт тыныч көннәр була. Менә шул чагында инде ул үзенен беренче пьесасын—«Канлы көннәрдә»не яза. Билгеле, бүгенге көн биеклегеннән торып караганда әсәр бик примитив тоелырга мөмкин. Анын буеннан буена сыйнфый көрәш идеясе белән сугарылган булуын да ошатмаска мөмкин. Чөнки әсәрдә революциягә каршы кеше шәхес буларак та ин начар, ин җирәнгеч кеше итеп сурәтләнә. Инде революция яклы булса, ул—каһарман, ул—фидакарь, ул—сатылмас һәм нык рухлы, кин күнелле имеш. Ләкин шунысы бар: пьеса солдатлар тарафыннан бик яратып, җылы кабул ителә. Аны күбәйтеп төрле-төрле хәрби частьләргә җибәрәләр. Татар гаскәрләре булган бер генә полкта да әлеге әсәр сәхнәгә куелмыйча калмый диярлек. Кайвакытта пьесаны хәтта профессиональ труппалар да куя.

Бу унайдан Шамил Усманов үзе еш кына болай дип сөйли торган була. «Менә Америкада бер драматург үзенен пьесасын мен мәртәбә куйдырган да миллион доллар акча эшләгән...» Анын «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» дигән пьесалары шулай ук күп куела куелуын, ләкин алар авторга бер тиен дә акча китерми. Революция эшенә файда итү—менә шул була авторга ин зур бүләк.

Хәзер, безнен көннәрдә, Шамил Усманов яклап көрәшкән коммунистик идеяләргә төрлечә карарга мөмкин билгеле. Анысы шулай. Ләкин, ничек кенә булса да, Шамил Усмановнын ихласлыгы, анын омтылышынын саф йөрәктән чыгуы сокландыра. Үзенен 1926 елда язган «Памирдан радио» исемле фантастик повестенда ул революциянен дөнья күләмендә җинүен һәм коммунистик хыялнын чынга ашуын тасвирлый. Авторнын ышануынча, бу хәл инде Бөек Октябрь социалистик революциясеннән сон егерме ел үтүгә үк тормышка ашырга тиеш була. Бу вакытта

инде жир йөзендә изүчеләрнең һәм изелүчеләрнең берсе дә калмаска тиеш була. Имеш, сугышлар да бетәчәк, төрле җинаятьләр дә... Төрмәләрне җимерәчәкләр, ә алтыннан—ул беркемгә дә кирәк булмаганга күрә—бәдрәфләр салачаклар...»

Ләкин... ләкин бик тә кызганыч: Шамил Усманов уйлаган егерме ел узар-узмас илдә бөтенләй икенче төрле хәлләр башлана.

1936 елның август аенда Мәскәүдә кайчандыр Ленинның якын көрәштәшләре булган Г. Е. Зиновьев белән Л. Б. Каменевка—большевиклар партиясенең күренекле эшлеклеләренә—ачык суд процессы башлана. Аларга үлем карары чыгарылып ике көн дә үтми, Казанда Язучылар берлеге партия оешмасының шулай ук ачык җыелышы була. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә—«Троцкий-Зиновьев иярченнәре эше уңаеннан язучыларның революцион уяулыгын арттыру турында». Бу җыелышта доклад белән чыккан Язучылар берлеге житәкчесе Кави Нәҗми «дошман элементларга» карата каты тәнкыйть сүзләрен бер дә кызганып тормый. «Дошманнар» дигән исемлеккә исә билгеле язучылар Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Крыймов, И. Рәми һәм тагын байтак әдип эләгә. Шул исәптән Шамил Усманов та.

Аны әсәрләрендә житәрлек дәрәҗәдә анлы булмаган кызылармеецларны сурәтләгәне өчен, гражданнар сугышы чорында партизанлык чагылышлары өчен гаепliләр. Булган жинелүләр һәм чигенүләр турында да тәмләп сөйләргә иренмиләр. Әсәрләрендә тискәре геройлар әйткән сәүләрне авторның үзенеке дип әйтүчеләр дә табыла. Гражданнар сугышы каһарманы образын түбәнәйтеп күрсәтергә тырышуда гаеплиләр. Ә инде бераздан, Блюхер халык дошманы дип кулга алынгач, Блюхерның уңышларын күпертүдә гаепли башлыйлар. Аннары тагын Шамилне үз энесе белән бәйләнешен өзмәүдә дә гаеплиләр. Ә аның энесе сәяси яктан гаепләнеп кулга алынган була.

Әйе, теләк булганда кешегә теләсә нинди гаепне дә тагарга мөмкин икән.

Ике көнгә сузылган бу җыелыш карарында Шамил Усманов әсәрләрендә «буржуаз милләтчелек идеяләрен үткәрергә тырышкан» өчен гаепләнә. Ул «гражданнар сугышы тарихын начар якка бозып күрсәтергә дә тели икән». Карарда катгый таләп тә куела: «татар язучылары берлеген дошман контрреволюцион элементлардан арындырырга».

Менә шушы куркыныч карар чыгарылып күп тә вакыт үтми, Татарстан НКВДсы партия өлкә комитеты секретаре Лепага коммунист Усмановны кулга алуга санкция сорап мөрәҗәгать итә. Бу санкция, әлбәттә, бик тиз бирелә дә. Сүз уңаеннан, Лепа үзе дә бу урында озак утыра алмый. Аны да бик тиздән кулга алалар. Ә Шамил Усманов исә 1937 елның 8 апрелендә Черек күлдәге мәгълүм бинаның ишеген атлап керә.

Аның кунакханәдәге бүлмәсендә тентү үткәргән вакытта (хәзерге «Казан» кунакханәсе) төрле язулар белән тулы 23 папка, 36 данә калын дәфтәр, 14 блокнот, бүләк итеп бирелгән исемле корал һәм бик күп китапны да алып чыгып китәләр. Шәхси милкенә килгәндә исә, ул кыршылып беткән портфельдән һәм иске чемоданнан гыйбарәт була. Тентү актына шундый искәрмә дә язып куелган: Усмановның конфисковать итәрлек башка милке юк.

Шамил Усманов менә шушы кара язмыштан котылып кала ала идеме соң? Юктыр, мөгаен. Чөнки революция дигән нәрсә ул—үзе балаларын ашый торган ерткыч җанвар сыман. Усмановның ул чордагы күренекле шәхесләрдән Блюхер, Тухачевский, Каменев, Зиновьев, һәм башкалар белән якыннан аралашкан булуы, Троцкий янына кергәләп йөрүе һәм аның приказларын үтәве—болар барысы да аны тиешле органнарның авыр чүкече астына илтеп тыга да инде. Моннан тыш, Шамил Усманов дуслары һәм танышлары белән сөйләшкәндә НКВД органнары хакында, аларның артык көчәюе белән килешмәве хакында да сүзләр ычкындыргалый. Бу сүзләрне тиешле урынга житкерүчеләр тиз табыла, әлбәттә. Органнарга хәбәр житкерүчеләрдән берсенең язуына караганда, Шамил Усманов Сталинның яңа конституциясенә зур өмет баглаган, ул шәхес иминлеген тәэмин итәр дип ышанган. Ә күпләп кулга алуларны ул болай аңлаткан: әлеге әйбәт конституция кабул ителгәнче НКВД органнары үзләренә ярамаган кешеләрдән тизрәк котылырга телиләр, имеш.

Кулга алынган кешеләрне әлбәттә инде тулысынча изоляцияләргә тырышалар. Ләкин, шуңа да карамастан, тоткыннар барыбер бөтен нәрсәне белеп тора. Алар Шамил Усмановның сорау алу вакытларында үзен чын ирләрчә тотуын һәм беркемне саттмавын да, советка каршы оешмаларда катнашу гаебе барлыгын танымавын да—

һәммәсен белеп торалар. Аны иң каты җәзага тартуларын да, «конвейерга» куеп атналар буе йоклатмыйча, тикшерүчеләрнең берсен-берсе алыштыра-алыштыра сорау алулар да, сулы карцерга утыртулары да (монда инде тоткын тәүлекләр буе билдән яисә муеннан ук салкын суда тотыла), кыйнаулар, кыерсытулар, ачка интектерүләр дә билгеле була. Соңгы сорау алуларның берсеннән соң аны тәмам хәлсезләнгән, коры сөяккә генә калган һәм бөтенләй һушсыз диярлек хәлдә сөйрәп барганнарын күрәләр. Ә бит әле ана бу чакта кырык яшь тә тулмаган була. Физик яктан ныклык, чыдамлык һәм хәрби әзерлек ягыннан татар язучыларыннан берәү дә аның белән тиңләшә алмый.

Ә тиздән Черек күлдәге эчке төрмәдә Шамил Усмановның үзен үзе үтерүе турында хәбәр тарала. Сөйләүләргә караганда ул соңгы сорау алу вакытында әллә нинди гаепләр тагылган беркетмәгә «кул куярга риза булдым» дигән сылтау белән тимер каләмле ручка сорап ала. Карага манып яза торган гап-гади каләм! Усманов аны кулында әйләндергәләп тора-тора да һәм бер мәлне бөтен көче белән күзенә китереп кадый! Ул шулхәтле ачу белән кадаган күрәсең—каләм баш миенә үк барып җитә. Шамил Усманов тикшерүче бүлмәсендә үк дөнья белән хушлаша.

Легендар шәхес тормышындагы соңгы риваять бу. Сиксәненче еллар уртасына хәтле ул риваять халык теләндә йөрде. Ә инде илгә Янарыш килеп, әлеге куркыныч оешмаларның архивлары ачыла башлагач, чынлыкта эшнең ничек булганын ачыклау мөмкинлеге туды. Шамил Усмановны гаепләп 1937 елның 3 декабрендә тутырылган 2-5187 санлы «эш»тә менә мондый язу бар:

«Минем, ягъни НКВД санчасте начальнигы Шулутко Л. И. тарафыннан түбәндәге хакта 1937 елның 3 декабрендә акт төзелде: тоткын Усманов Ш. 1937 елның 3 декабрендә иртәнге 7 сәгатьтә кинәт вафат булды. Бөтен билгеләр буенча үлем йөрәк параличыннан булырга охшаган».

Бер караганда бу инде чын, дөрес документ кебек. Ул бөтен шартын китереп төзелгән, шуңа күрә мәсьәлә дә ачык шикелле. Ләкин без НКВД дип аталган ул оешманың эш стилен бик яхшы беләбез. Андагы документлар хакыйкатьны теркәп калдыру өчен түгел, ә чынлыкны яшерү, эз югалту өчен төзелә. Менә шушындый шикләр белән КГБ архивында казына торгач мин икенче бер документка юлыктым. Ул 1899 елда туган, элек Татарстан НКВДсының дүртенче (сәяси) бүлеге начальнигы вазифаларын башкарган Лазерь Ефимович Марголинны гаепләү «эш»е. Аны 1939 елның 29 мартында, ягъни органнарга Берия килеп Ежов кешеләрен кулга алулар башлангач, элэктерәләр. Марголинны Шамил Усмановтан сорау алу вакытында физик көч куллануда һәм нәтиҗәдә 1937 елның 4 декабренә каршы төндә Усмановның сорау алу вакытында үлемендә гаеплиләр. Икенче төрле итеп әйткәндә, Шамил Усмановны кыйнап үтергәннәр икән. Ә инде шушы кабахәт дөреслекне яшерү өчен ялган акт төзегәннәр. Мәетне инде, әлбәттә, ярып та тормаганнар.

Марголин мондый ерткычларча алымны бер Шамил Усмановка карата гына кулланмаган, билгеле. Мисал өчен аның Еналиев дигән татар кешесен кыйнап үтерүе дә мәгълүм. Тикшерү вакытында Марголин үзе бу хакта сөйли. Ләкин моны «тулаем эш стиле шундый иде» дип акламакчы була. Әлеге сүзләр дөреслеккә дөрес, билгеле. Күп тикшерүчеләр шулай ерткычларча кыланган.

Күрәсең соңрак Марголинның үзенә карата да шушы стильне кулланганнар. 1939 елның 16 октябрендә менә дигән, тап-таза Марголин «кинәт вафат була».

Әйе, бер караганда Шамил Усманов турындагы өченче риваять расланмый сыман тоелырга мөмкин. Чөнки аны Черек күл төрмәсендә кыйнап үтергәннәр бит. Ләкин, минем фикеремчә, әлеге риваять Шамил Усмановның холкын, табигатен бик тә ачык итеп күз алдына китереп бастыра шикелле. Бары тик аның кебек кыю, тәвәккәл ир-ат кына әнә шундый адымга бара ала! Һәм мин тагын шулай дип уйлыйм—әгәр дә киләчәктә кем дә булса Шамил Усмановның легендар шәхесе турында ниндидер әдәби әсәр: романмы, пьесамы, яисә кинофильммы иҗат итәргә алына икән—ул менә бу трагик риваятькә чынлап та нигезләнә, таяна ала. Чөнки ул дөреслеккә туры килә торган риваять!

*Мирас*

# ӘДИП ИҖАТЫНА ИКЕ КАРАШ...

*Тормышны киң колач белән чагылдыручы, зур талантка ия язучылар иҗаты да кайчагында капма-каршы фикерләр уята. Татар әдәбиятының иң эре фигураларыннан берсе Гаяз Исхакый әсәрләре турында да үз вакытында төрле фикерләр басылган.*

*Менә сезнең алдыгызда бу зур әдипнең бер үк әсәренә багышланган ике мәкалә. Аларның беренчесен шулай ук олы әдип Галимҗан Ибраһимов язган. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» дигән бу мәкалә 1915 елның 26—27 февралендә «Тормыш» газетасында басылып чыга. Ә инде «Тәнкыйть тирәсендә» дип исемләнгән икенче мәкаләне А. Бикташев яза һәм ул 1915 елның 13—14 августында «Кояш» газетасында дөнья күрә. (Сүз уңаенда әйтеп китик: бу автор турында биографик мәгълүмат табылмады, әмма фикер йөртүенә карагында, ул әдәбият мәсьәләләрендә шактый «тирәннән йөзүче» шәхес булырга охшый.)*

*Һәр ике мәкалә дә Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә» исемле драмасы уңаеннан язылган. Укучы инде беләдер: 1914 елда басылып чыккан бу драма—Г. Исхакыйның сәхнәдә иң күп уйналган, җәмәгатьчелек игътибарын иң нык җәлеп иткән, күп кенә бәхәсләр дә уяткан әсәре. Бер 1914 елда гына да бу әсәргә карата җиде авторның рецензиясе матбугатта басыла. Җ. Вәлиди, Г. Кәрам, С. Рәмиев, Ш. Әхмәдиев, Г. Гыйсмәти, Ә. Мөхетдинова кебек исемнәре бүген дә телебездән төшми йөргән зыялыларыбыздан алып, хәзер исемнәре онытылган каләм ияләренә кадәр бу әсәргә мөрәҗәгать итә.*

*Моның сере нәрсәдә соң? Безнеңчә, сер әдипнең татар драматургиясенә әлегә кадәр күрелмәгән яңа хатын-кыз образы—мөгаллимә Фатыйма образын алып килүендә.*

*Гаяз Исхакый—хатын-кызның гаилә эчендә генә йомылып калмавын таләп итеп, аларның ирләр белән бертигез дәрәҗәдә иҗтимагый тормышка актив катнашулары кирәклеген раслап байтак мәкаләләр бастырган әдип. Кайсыбер газеталарда ул хатын-кызлар бүлеген дә алып бара.*

*Гаяз Исхакый үзенең мәкаләләрендә төрки мөселман дөньясында хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен беренче күтәрүче итеп Исмәгыйль Гаспринскийны күрсәтә. Ә безнең татар әдәбиятында бу урынны, шиксез, Г. Исхакый били. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар һәммәсе ул салган эздән киткәннәр.*

*Ә бу әсәргә килсәк, «Мөгаллимә»дәге Фатыйма шикелле, шәхси мәнфәгатьләреннән ваз кичеп салкын Себергә балалар укытырга килгән каһарман татар кызлары ул вакыт әдәбияты өчен генә түгел, тормыш өчен дә бик сирәк күренеш булган. Әдип бу әсәрен язып татар хатын-кызларын киләчәктә шундый каһарман итеп күз алдына китергәндер.*

*Егерменче йөз башы әдәби тәнкыйтен күздән кичергәндә шундый бер үзенчәлек игътибарны җәлеп итә. Әсәрдә типиклык мәсьәләсе күтәрелдеме—шундук «бу образ тормышта бармы?» дигән сорау куела һәм нәтиҗәдә типиклык төшенчәсе үзе шактый тараеп кала.*

*Галимҗан Ибраһимовның «Мөгаллимә» уңаеннан әйтелгән төп фикере дә шуңа якын: ул Фатыйма образын типик түгел дип, әсәр тормыштагы чын мөгаллимәләр язмышын чагылдырмый диеп бара.*

*Һәм, гомумән, бу еллардагы иҗат әһелләрен бәяләгәндә алар иҗаты турында каршылыклы фикерләр әйтү, аларны матбугатта язып чыгу Г. Ибраһимов өчен, аның баштагы әдәби тәнкыйть мәкаләләре өчен хас күренеш. Ул Тукайны да бер урында мактый, ә инде икенче бер әсәрендә «Тукай шагыйрьме?» дигән икеле-микеле сорау куя.*

*Г. Ибраһимов Исхакый иҗатын да күзәтеп барган. Башта ул аны: «Әдәбият мәйданында иң шәүкәт вә иң биек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора» дип, күккә чөеп мактый («Татар матбугаты», 1910). Үзенең «Әдәбият агымы» (1911) исемле*

*мәкаләсендә аның иң яхшы әсәре итеп «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны атый. «Әсәр куәт белән түгел, сихер һәм илһам белән язылган» дип соклана. Әлеге мәкаләсендә ул Г. Исхакый иҗатын чорларга бүлеп карый, һәр чор иҗатының төп үзенчәлекләрен билгели. Бу яктан мәкалә оригинал, кызыклы. Г. Исхакый иҗатын шул рәвешчә чорларга бүлеп карау ул вакытта гына түгел, әле хәзер дә беренче омтылыш булып кала. Бу бүленеш белән мин үзем, нигездә, килешәм.*

*Ә менә Г. Ибраһимовның мөгаллимә образының әһәмиятен юкка чыгаруын аңлап та Г. Исхакыйда бөтен иҗаты буенча сузылып бара торган үзәк идея юк, дигән бәясе белән килешеп тә булмый.*

*Г. Ибраһимов иҗат кешесе өчен мәҗбүри булмаган нәрсәне таләп итә, шул юл белән аның иҗатының иҗтимагый кыйммәтен киметергә тели. Чынлыкта, Гаяз Исхакый егерменче йөз башында иң танылган язучыларның берсе була. Ул бүген дә шул биеклектән төшми... Тәнкыйтьче Г. Ибраһимов исә биредә үзенең үк башта биргән бәяләрен юкка чыгара.*

*Шуңа күрә А. Бикташевның Г. Ибраһимов куйган байтак тезисларны кире кагуы белән килешергә туры килә.*

Фатыйма ИБРАҺИМОВА.

---

# Галимҗан Ибраһимов

## «МӨГАЛЛИМӘ»НЕҢ УФАДА УЙНАЛУЫ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

### I

Кечек бер орлык йомшак туфракка төшә дә, вакытлы янгыр, кояшлы һава тәэсире белән борынлап җир өстенә чыга. Акрынлап сабак үстерә, киңәеп яфрак яра, чәчәк ата, соңра җимеш бирә. Адәм угылының хәяты да, кылган эшләре, гамәл вә фикерләре дә табигать тарафыннан аның йөрәгенә куелган бер орлыкның табигый җимешләредер. Мөхәррир вә сәнгаткяр белән аның гомер буена язган әсәрләре арасында да шундый мөнәсәбәт була, яки булырга тиеш.

Тәнкыйть әдипнең табигатенә куелган ул орлыкны аның әсәрләре аркылы күрә. Аның бөтен язганнары шул илаһи орлыкның төрле суративә, ләкин һаман шул бер асыл матдәдән чыккан чәчәкләре икәнен ачып бирә.

Мөхәррирнең кулындагы каләме, әдәби куәте—аның төп идеясен дөньяга чыгарырга бер чарадан башка нәрсә түгелдер, гомумән, әдиптәге талантның мәгълүм бер ноктага карап агышы, ни генә язылса да, шул асыл идеянең каләм аркылы тышка бәреп чыгышы күренә. Әдәби истыйлях (атама, термин) белән әйтелсә, әдипнең рухани төзелеше, хәят вә дөньяга билгеле бер нокта буенча карашы—әдәби вә фикри йөзе була. Һәммә әсәрләрендә табигать тарафыннан бирелеп, хәят вә язмыш тәэсире белән тәрбия кылына килгән, шул үзенә махсус рухы ачыла. Бөтен язганнарында шул төп идея ал җеп рәвешендә сузылып бара.

Һәм моны бик аз бер дикъкать белән тикшерелгәндә дә һәркем ачык хис кыла ала. Толстой илле еллык әдәби гомерендә утыз-кырык җилд (том) нәрсә язды. Аның язганнары бик төрле, тышкы карашта бер-беренә бик башкалар—ул роман вә хикәяләр яза. Кәлисә (чиркәү) белән, аристократия белән көрәшә. Чыккан әсәрләрне тәнкыйть итә, мәктәп китаплары тәэлиф (төзи) кыла, динне

мөхакәмәләргә (тикшерү, хөкем чыгару) керешә. Тагы бер вакыт үзенең барлык язган әдәби нәрсәләрен гөнаһ саный башлый, ләкин шул тышкы башкалыклар эчендә аның асыл рухы, рухани хәятының төзелешеннән килгән төп идеясе монда һаман да үзен күрсәтә бара—якыннарыңны сөю, милләт талашларына начар карау, түбән вә изелгән халыкка мәхәббәт, фән вә мәдәниятә ышанып бетмәү, әхлакны һәрнәрсәдән югары кую, һичбер турыда тар рамкаларга сыя алмау—иштә (менә) аның иң әүвәлге әсәре булган «Балалык вә егетлек»тән башлап, тимер юл станциясендә җан биргән минутта әйткән соңгы сүзенә кадәр һәрбер әсәрендә, һәрбер сүзендә хис ителә барган гомуми рух һәм төп идея! Арцыбашевта моның тәмам киресен күрәбез. Ул бирәүгә җавап язамы, пьеса эшлиме, роман чыгарамы—мәузугълары, алган типлары тышкы яктан ни чаклы нурлы булсын, аның һәммә язуында тән сөю, дөньяга, хәят вә табигатькә фәкать болардан алу мөмкин булган ләззәт дип карау хис ителә. Аның әүвәлге әсәрләреннән булган «Жена»сыннан алып иң соңгы «Ревность» һәм «Война» пьесаларынача—бар да шул бер идея, бер рух белән сугарылганнар.

Байронда исә җир йөзендәге хәяттан, теләсә нинди рәвеш белән төзелсә дә, канәгать итә алмауны дәртләү, каядыр ашкыну, күз яше изтыйраб (көенү, аптырау) аһ вә зар кебек рухани дулкыннар һәр әсәрендә генә түгел, һәр юлында, һәр сүзендә үзләрен куәтле рәвештә сиздерә баралар.

Боларны укыйсың да, шул язучының һәммә әсәрен тудырган төп ачык сабит (даими) вә билгеле бер идея бар икәнен үзеннән-үзең хис кыласың. Шулай югарыдан алып түбәнгәчә киленсә, һәр язучыда, мәузугъларындагы башкалыкка карамыйча, дөнья вә хәятка караштә табигать тарафыннан куелып, хәят белән тәрбияләнә килгән үзенә махсус бер идея бара, аның бөтен әсәрләре шул табигый идеянең төрле киемдә, төрле сурәттә дөньяга чыгышыннан гыйбарәт була.

Үз дөньямызга килсәк тә моңа мисаллар табылачак. Риза казыйның һәммә әсәрендә әхлак, игътидал, (уртача фикердә булу) исламның голувияте (өстенлек, мәгънәвилек), гарәп әдәбиятының бөеклеге кебек төп бер фикер бара. Ул тәрҗемәи хальме, мәкаләме, тарихмы яза—һәммәсендә шул, хәтта идарәдән язган җавапларында да без шул төп идеяне—хәят вә табигать тәэсире белән мәгълүм бер рәвешкә кергән сабит бер әмәлне хис итәбез.

Рәшит казыйны алсак (хәтта мәсләксезлек белән мәшһүр бер мөхәррирдә дә) ислам кавемнәренең берләшү идеясе, Яурупа христианлыгына дошманлык, Русия мөселманнарының күп бәхетсезлеген Духовное собраниебездән күрү кебек бер җеп сузылып бара. Аның моннан егерме еллар элек язган «Чулпан»ымы, сонрак «Миръат», «Өлфәт», «Тилмиз»ләреме, ниһаять, Төркиядәге «Тәгарефе мөслимин»еме (мөселманнарны таныштыру)—бары да төрле сүз белән төрле сурәттә шуны тәкрарлыйлар.

Исмәгыйль бәк Гаспринский яшь хәлендә, Париждан кайтып, кулына каләм алган көненнән башлап, та йөрәге тибүдән туктаганчы—утыз биш еллык әдәби бер гомердә—төп бер идеяне таратты: ысулы җәдидә, ибтидаи тәгълим, төрекләрнең тел вә әдәбиятта берләшү лөзүме (кирәклек, тиешлек), нәҗатның (яшәү, исән калу) бердәнбер юлын фәкать яурупачылыкта күрү—аның иң әүвәлге «Русия мөселманнары» дигән әсәрендә нигезе салынып, бөтен гомеренчә киңәйтә килгән идеалыдыр.

Шулай югарыдан башлап вагайта килсәк, яки киресенчә тикшерсәк күрәбез ки, Тәңре җитди вә көчле җаннарны мәгълүм бер кавемнең хәятындагы төпле ихтыяҗларның берен үтәү өчен җибәрә, аның йөрәгенә шундый бер орлык, шундый бер төп мәгънә куя, мөхәррир дә, язмышның манигъларына (каршылык, киртә), хәятның туктаусыз алмашынуларына карамыйча, үзе теләсә теләмәсә дә, хәтта үзенә зарармы, файдамы икәнен дә аермыйча, шул Тәңренең теләгән идеясе юлына үзен бирә, шул төп мәгънәне бөтен гомеренчә үткәрә, һәммә әсәрләре, тышкы яктан күренгән башкалыкларга карамыйча, шул рух белән сугарылган, илаһның биргән әманәтен җиренә тапшыру юлында мәгълүм бер ноктага карап хезмәт кылырга юнәлгән була. Тәңренең бу әманәте күп вакыт әдипнең беренче каләм тибрәткәннән үк бик зәгыйфь рәвештә булса да сизелеп,

гомер барынча язган соңгы әсәрләре шул төп идеянең, әйтик, шул илаһи орлыкның киңәеп, тармакланып үсүеннән—аны тагы камилрәк, тагы куәтлерәк рәвештә тәҗәссем иттерелүеннән (гәүдәләндерү) гыйбарәт була.

Моны әдипнең әдәби вә рухани йөзе дип атыйлар. (Ләкин бу бик зәгыйфь тәгъбир).

Язучы белән аның әсәрләрендәге төп идеяне шундый табигый бер ноктадан аңларга тырышкан вакытта мәгълүм мөхәррирләремез арасында иң күнелсез тәэсир калдырганнарыннан бере бу мәкаләне аның соңгы әсәре мөнәсәбәте белән башлаган Г. Исхакый әфәндедер.

Бу мөхәррирнең унбиш елдан артык әдәби гомере бар. Ләкин шул озак заманда аның әдәби вә рухани йөзе төзелеп сабит бер идея рәвешенә кереп житә алмады.

Бик күптән инде аның «Тәгаллемдә сәгадәт»е чыккан. Ул монда ысулы җәдидә яхшы, кадимиләр начар, бәхет вә сәгадәт җәдит белән укуда, ди. «Бай угылы» да шуны куәтли. Монда бай бәтчәнең хәятын начар якка борып җибәргән сәбәпләрнең мөһимрәге—аның Сәхилә карчык (фикере) белән җәдит мәктәбеннән алынып, нинди дер кадим, бохари бер мәхдүмгә бирелүе булып чыга. «Кәләпүшче кыз», «Ике гыйшык», «Өч хатын берләң тормыш»тан «Инкыйраз»гача—монда да ул бәхет вә сәгадәтне җәдитлектә, яна юл белән укуда күрә.

Бу агымның барып терәлгән чиге «Инкыйраз». Шуңа житә дә тәмам була. Аннан соң кадим белән җәдит арасында нисбәт йортеп, бәхет вә сәгадәтне соңгыда күрә килгән милли тәрәккыйпәрвәр җәдитче Исхакыйны бөтенләй югалтасыз.

Чыга «Теләнче кызы», чыга «Солдат», «Зиндан», «Җыентык»—боларда инде элекке җәдит вә кадим нисбәтенең эзе дә юк. Алар хәтердән үк чыкканнар. Монда әүвәлге милли тәрәккыйпәрвәр урынына бик аз гына социализмга охшаш бер ис анкый. Борынгы җәдит вә кадим урынын боларга бер дә вә асла мөнәсәбәте булмаган ике сыйныф—байлар белән ярлылар көрәше ала. Җәдиттерме, кадимдерме—әһәмияте аз. Менә Казанның потомственный почетный гражданин байлары, түбән халыкның көче белән мал җыялар да шул мал куәте белән ярлыларны җәберлиләр. Бер якта буржуйлар, икенче якта мәзлум бурлаклар, бичара чабатачы Шәрип карт гаиләләре.

Эшче белән эшләтүче, халык белән хөкүмәт—шулар арасындагы көрәш. Әмма милләтләр, миллият дип аерулар—алар юк әкият. Шулай итеп, «Инкыйраз»гача язылган әсәрләрдәге милли тәрәккыйпәрвәрлек идеясе югала да, аның җирен марксслыкка аз гына охшаган бер рух ала. Аның бу икенче дәвере—Руссиядә эшче вә түбән халык мәсьәләсенең бик модага кергән чагы иде.

Бервакыт дулкын басылды. Шуның тәэсире белән рус әдәби галәмендә түбән халыкны кайгырткан идеяле мөхәррир арткы сафка калдырылып, мәйданга гая кямалләре (артык житешкәннәре) «Санин» белән тәгалләнгән Арцыбашев, Вербицкая кебек порнографист яшь язучылар тибы чыкты.

Без Исхакый әфәндедең әсәрләрен сугарган идеянең тагы танылмас дәрәҗәдә үзгәргәнен күрдек. Чыкты аның «Тормышмы бу?»ы, «Шәкерт абый» вә «Мәдрәсә йимешләре».

«Өч хатын берләң тормыш»та тәрәккыйпәрвәр зыя милләт тәрәккый итсен өчен «Җәмгыяте хәйрияләр», кыйраәтханәләр ачарга кирәк, дип озын-озын нотыклар сөйли. «Теләнче кызы»нда Мансур байларның мал куәте белән түбән халыкны җәберләвенә, хәтта мәгъсүм (саф, намуслы) кызларның намусына тию дәрәҗәсендә кабахәтлекләргә житүенә кайгыра иде. «Тормышмы бу?»ның исемсез каһарманы, «Мәдрәсә йимеше»ндә мулла исә бөтенләй икенче яктан бәхетсезләр. Алар иске мәдрәсәдә яту сәбәпле теләгән хатыннарына мөнәсәбәт баглап хайвани теләкләрен үтәр өчен кирәк булган кыюлыкларын югалтканнар. Менә кайда аларның төп трагедияләре! Мөхәррирнең бу өченче дәвердәге әсәрләрендә «Инкыйраз»гача чыкканнарындагы кебек милли тәрәккыйпәрвәрлек, җәдит вә кадим көрәше дә, икенче дәвердәге түбән сыйныф хәсрәте дә юк. Монда әсәрдән аңкыган рух—бичара шәкерт белән мулланың хайвани иштиһаны (теләк) теләгәнчә

булдыра алмауларыннан гыйбарәт. Фәхеш исе килеп торган бу нәрсәләр шундый күңелсез тәэсир калдыралар ки, гаилә тәрбиясенә җитди караган затлар боларны өйләренә кертү турында шөбһәгә калалар. Хәтта шул дәрәҗәгә җитә: «Вакытчылар» («Вакыт»—газетасы редакциясе хезмәткәрләре) кебек иң сак бер груһ та милли театр мөнәсәбәте белән язган баш мәкаләләрендә боларны порнография, әдәп вә әхлак бозгыч әсәр, дип игълан итәргә мәҗбүр булалар.

Ләкин бу порнография дә озакка бармый. Чыга «Сөннәтче бабай», «Кияү» һәм «Мулла бабай»лар. Боларда инде әүвәлге дәвернен—җәдит вә кадим нисбәте, милли тәрәккыйпәрвәрлек идеясе, икенче дәвернең социализмы, өченче дәвернең порнографиясе—гомумән, нинди дә булса иҗтимагый бер фикер бөтенләй юк. Мөхәррир боларда һичбер идея-фәлән күзәтмичә, тота да иске татар тормышының тыш ягына тасвир итә.

Болар чыккач, ихтимал, байтаклар менә Исхакый үзенең чын юлына төште, аның талантының асыл зәмине (нигез) шул иске тормышны тасвирда иде, дип уйлаганнардыр. Вакыйган, болар аның әдәби йөзен күрсәтеп килаләр дә кебек иде. «Мөгаллимә»нең чыгуы тагы бозып җибәрде.

Монда «Таң» заманының социализмыннан яки «Тормышмы бу?»ның тәмләп хатын тәнен эстәвеннән әсәр дә юк. Шулай ук «Мулла бабай»лардагы кебек тормышны битараф битописатель сыйфаты белән тасвир да юк.

Мөхәррир үткәндәге бер-беренә каршы идеяләрнең берәрсенә якын китерергә көчләнелсә, моны тик «Өч хатын берлән тормыш»тагы милли тәрәккыйпәрвәр Риза фикерен хәтерләтә диярга мөмкин булыр. Ләкин ул да тик хәтерләтә генә.

Шулай итеп, мөхәррирнең унбиш еллык әдәби гомереннән соң чыккан бу әсәре аның әдәби вә рухани йөзен тагы бозды, аңа табигать тарафыннан бирелеп, хәят белән тәрбия кылыну тәэсире белән сабит бер әмәл мәртәбәсенә житәргә тиеш булган мәфруз (уйланган) төп идеясен тагы югалтты.

## 2

«Мөгаллимә»нең чыгуына байтак булды. Аны күпләр укыганнардыр, укымасалар, сәхнәдә күргәннәрдер, шуңа күрә мин аның мөндәриҗәсен сөйләп торырга кирәк тапмыйм, туры әсәрнең биргән тәэсиренә киләм.

Әсәрнең әдәби кыйммәтен ике яктан үлчәргә мөмкин:

**1. Хәят сәхифәләрен, хәятның тудырган мәгънәле типларын вакыйгада бар көенчә тасвир итмәк.**

**2. Матур вә мәгънәле хыял тудырмак. Әминә туташ «Аң»да үзенең талантлы язылган матур әдәби мәкаләсе (1914 ел, 23 сан.) белән: «Ул тормыштан алынган булмаса булмас, ләкин Фатыйманың характерында цельность бар, бу тип безгә шул ягы белән кыйммәт»,—дип «Мөгаллимә» пьесасын шул икенче яктан тәкъдиргә тырышып карады.**

Әгәр шулай булса, бу гәрчә мөхәррирнең әдәби вә рухани йөзен бозса да, чыннан да, мөһим булыр иде. Ләкин туташның ул карашын Фатыйма беренче пәрдәдә кымыз мәҗлесендә сөйләгән нотыгы белән җимереп ташлый.

Фатыйма Габдулла мөгаллимнең халык өчен бик зур хезмәт биргән икәнен анлый: «Сез, ди, мөгаллим булмасаңыз, бары бер гәзитә вә бер китапханә идарәсендәге унъеллык мөһим хезмәтеңезнең бәйрәмен күрер идегез», ди. Димәк, Габдулла аның каршында татар милләте өчен зур хезмәт кылучылардан бере. Шулай да булса, ул аны (Габдулланы) сөя алмый, теләсә, үзен көчләсә дә сөя алмаячак. Чөнки ул әллә кайдагы, әллә нинди бер Садыйкны сөйгән, аның цельность характеры бүленә алмый, Габдулланы сөю аның иркендә түгел.

Әгәр мәсьәлә шуның белән калса, без, шөбһәсез, Әминә туташны хаклы табар идек. Ләкин шул милләт хадиме Габдулланы әллә нинди бер Садыйкка алмаштыра алмаган Фатыйма тора да: кымыз мәҗлесендә Тукай белән Каюм Насыйрины сөймәгәнлекләре өчен хатын-кызларга дөнья кадәрле итеп бик җитди

шелтә ясый. «Татар хатыннары татарның шул ике хадимен сөяргә тиешлеләр иде», ди. Менә бу монаказә (каршылык) белән Фатыйма характерындагы цельность үзеннән-үзе җимерелә.

Сөю андый нәрсә түгел. Нигә тегене сөймисең, ник моны сөясең дигән игътираз (кире кагу, каршы төшү) бу—сөю психологиясен бик аз гына аңлаучылар каршында көлкедер. Моны үз алдында ни дәрәҗәдә газап чиккән татар хадиме, Габдулланы сөя алмаган Фатыйма башка һәркемнән элек аңларга тиеш иде. Инде килик әсәрнең беренче яктан каралуы мөмкин булган кыйммәтенә—аның хәяттан алынган бер тип бирә алып алмавы җәһәтенә!

Тормыштан алынган тип димәк, ни димәктер?

Ин элек шуны хәтергә төшерик. Алыйк берничә мисал: менә татар шәкерте, татар мулласы, татар сәүдәгәре бар. Татар шәкерте, яки татар сәүдәгәре эчендә бик наданы, галимрәге, бик бае, бәхетлесе, бәхетсезе булырга мөмкин. Аларның һәрбер кешесе—үзенә бер хәят, аерым бер шәхес. Ләкин язмышлары тәэсире белән шул бер сыйныфта төрле «аерым шәхесләр»нең һәммәсе, һичбулмаса күбе арасында уртак булган сыйфатлар бар. Мөхәррир бер шәхесне, мәсәлән, бер Габдулланы ала да аның шәхси хәяты эчендә бөтен сыйныфына гам (уртак) булып, шәкертлегеннән яки сәүдәгәрлегеннән килгән сыйнфый язмыш, сыйнфый сыйфатларын тәҗәссем иттерә (гәүдәләндерә). Сәүдәгәр сыйнфының шәхесендә без аның бөтен сыйныфына гам булган язмыш вә сыйфатларны табабыз. Менә шулай эшләнсә, аны әдәби галәмдә тип дип атыйлар.

Мөгаллимәләр—бездә яңа туып килгән бер сыйныф. Алар арасында төрле кешеләр булыр. Бер-беренә бөтенләй башка характерлар да очрар. Ләкин татар хәятының мөгаллимә сыйфаты белән мәйданга чыккан хатын-кызларга үзеннән-үзе тудырган бер язмыш шул мөгаллимәләрнең мөгаллимә булучылык җәһәтеннән килгән бик күп сыйнфый хасиятләре бар.

Алар сыйныфташлары мөгаллимнәр мәхкүм булган (дучар булган) күп авырлыкларны кичерәләр. Ләкин бик күп турыда мөгаллимә язмышы тагы мөшкелрәк.

Начармы, яхшымы һәрхәлдә мөгаллимнәр чыгара торган, халык каршында бераз инабәт (ышаныч) казанган мәдрәсәләр бар. Алар Духовное собраниегә кереп имтихан да ала алалар.

Мөгаллимәгә исә берсе дә юк.

Ул гыйлемгә сусаган. Аның яше үтүенә карамыйча тәгълим вә тәрбия бабында (мәсьәлә) бернәрсә аласы, мөмкин кадәр яхшырак мөгаллимә буласы килә. Моңа махсус һич гыйлем йорты булмаганга, Уфадамы, Бубидамы башка бер җирдәме җәйге курслар игълан кылына икән, алар, аталарының, ирләренең каһәренә карамыйча, ярлылыкларына да илтифат итмичә, ерак җирләргә—шул курслар бар дигән шәһәрләргә груһ-груһ (төркем-төркем) агылалар. Анда ул мең газап белән яши. Өстәвенә кара халыктан мең төрле төһмәтләр (яла ягу) ишетә.

Ул аңа да карамый, һаман юлында бара.

Көз җитә. Инде урын кирәк. Ел тәүлеге уникe ай. Аңа урын чыга калса, биш ай ач үлмәслек мәгаш (хезмәт хакы) бирәләр. Калган җиде айны ни белән кичендергә?

Җитмәсә барган җирендә шәһадәтнамә сорап җәфалыйлар. Духовное собрание аларны: «Сез хатыннар», дип, үзенең ишегеннән дә кертми. Ләкин боның һичбере аларны туктата алмый. Татар хәятында табигый, хәтта зарури булган шул авыр язмышны күрә торып, алар һаман шул мөгаллимәлеккә ташлана, аларның сафы киңәя, саннары арта бара.

Ләкин моңа карап аларның язмышы рәхимне арттырмый. Бу язмышның аларда тудырган аерым психологиясе, аерым сыйфатлары бар. Әдәбият галәмендә «мөгаллимә» дигәч, менә шул язмышның эчендә яшәгән тугашлар хәтергә килде.

Шул авыр язмыш эчендә яшәп тә үзенең галәттән тыш истигъдады ( сәләтлелек) сәбәпле башкалардан алга чыккан мөгалимәләрдән берсе язган мәктүбендә мөгаллимәлекнең дүртенче елында яңа урынга баргач, алган беренче тәэсирен менә ничек тасвир итә:

—Житмеш бала. Тавык көтүе кебек, мәктәпкә көрт жырып барып кергәч, бинаның тәбәнәклегеннән, идәндә чабып йөргән зур-зур күселәрдән, почмакларны каплаган үрмәкүч ояларыннан йөрәгем ярыла язды. Мең бәла белән дәрес башладым. Житмеш балага бер үзем. Мәктәпкә сыя алмыйлар. Бүген Маһирәнең әнисе килеп:

—Маржа кебек, акча алып укыткан буласың, кичә кызым яңа гына тегеп кидергән күлмәген жыртып кайтты, шуны да карамагач, син кем ул чакле,—дип, чәрелдәп чыгып китте. Иртәгә Гайни карчык:

—Минем балама сурәтле нәрсәләр биргәнсең,—дип, кызын алып китәчәк. Хәзрәткә бу хакларда кинәшәчәк булып намаздан кайтышында урамнан туктатсам, ул миннән кача (диккать итегез, мөгаллимә түгел, хәзрәт кача), аптырагач, хәзрәткә хат белән яздым. Менә тагын бәла, абыйстай минем хатны сизгән дә хәзрәт белән икемезнең өстемезгә дөнья афәтләре куптармасынмы! Бу хәбәр ни арада халыкка да таралып өлгергән. Бөтен авылда:

—Хәзрәт мөгаллимәне икенче хатынлыкка ала имеш,—дип сүз чыгарганнар. Житмәсә тагы авыл егетләре йөрегән юлыма яшелле, күкле хатлар ташлап: «Ялгызсын, эчең пошадыр, мине чакырт»,—дип, жаныма тияләр...»

Бу бер мөгаллимәнең зары. Бу һәм киң Татарстанга чәчелгән ул яңа сыйныфның уртак язмышыдыр да.

Соңгы дәвердәге әсәрләре белән бытописатель булып күренгән Исхакый әфәнденең «Мөгаллимә» дигәне игълан кылынгач, хәят белән реаль әдәбият арасындагы мөнәсәбәтне аңлаган һәркем, әлбәттә, әсәрдә шул яңа сыйныфның мөгаллимәлек-ләреннән туган язмышы, шул язмышның тудырган сыйнфый сыйфатлары, ягъни татар хәятында бар булган мөгаллимә тибы күрсәтелгән дип уйлады, шулай уйлаганнардыр, шулай көткәннәрдер. Ләкин боларның һәммәсе бушка чыкты.

Пьесада күп нәрсә, күп нотыклар, озын-озын хатлар бардыр. Ләкин күпчелегенең язмышы шул югарыча булган татар мөгаллимәсе тибы юк. Мөхәррир әфәнде мөгаллимәләрнең хәятын, табигый вә гади язмышларын тасвир итеп, укучыларны алар хакында уйларга мәжбүр итәчәк бернәрсә бирү кайда, хакыйкый мөгаллимә язмышына гаид (бәйләнешле) бер ишарә дә юк.

Фатыйма трагедиясе бәлки дөньяда бардыр, ләкин ул трагедия татар мөгаллимәсенең типичный трагедиясе түгел.

Пьесада Фатыйманың мөгаллимә сурәтендә күренеп, Габдулла белән янәшә яшәве, кулына дәфтәр тотуы—бар да иттифакый (очраклы) эшләр. Фатыйманың төп трагедиясенең боларга һичбер төрле мөнәсәбәте, бәйләнеше юк.

Ул кемнедер сөйгәнме, шуның өчен Себергә киткәнме—болар аның мөгаллимәлек язмышыннан туган, димәк, типичный булган хәле түгел. Татар хәятының мөгаллимәләргә хәзерләгән язмышы әнә шул югаргы, мөгаллимә диелгәч шул авыр язмышның әдәби бер типта тәҗәссем иттерелүе кәтелә. Бу һәм әдәбиятның вазифасы да.

«Мөгаллимә» исеме астында мондый бернәрсә тәкъдим итүне мин авыр язмышлы мөгаллимәләр сыйныфына каршы җинаять дип беләм. Чөнки бу хакыйкать, хәлне яшерү була. Моны укыгач, моны сәхнәдә күргәч, мөгаллимәләрнең хакыйкый язмышлары аз гына булса да күз алдында югалып, бер төрлеләренең алдануына, мөгаллимәләр турында көн-төн уйларга вә эшләргә тиеш башларының йоклавына сәбәп була.

Чөнки Фатыймада мөгаллимәлекнең авыр язмышы аз гына да күрсәтелмәгән, ишарә генә дә ясалмаган.

Мөхәррир йә матур мәгънәле хыял язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр жәрәхәтләреннән берен укучы алдына ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышны жиңеләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәжбүр итсен!

Әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмияте фәкать шул ноктадандыр.

Пьесаның бу ягына озаграк туктау—шул авыр язмышлы иптәшләремезнең хакыйкый хәятлары, авыр көннәре үзенең бөтен күңелсез яклары белән халыкка күренеп, җинеләйтү хакында бер чара күрә башлауга бундый әсәрләрнең вакытлы булса да бер пәрдә булып тору ихтималларын бетерү өчендер.

«Мөгаллимә»—укып җуаныр өчен күңелле бер әсәр. Әмма әдәби вә иҗтимагый кыйммәте (хәятның көзгесе була алмаганга) нольгә якын.

Пушкинның мәшһүр бер сүзе бар, ул:

—Әсәрне, мөхәррирне тәнкыйть өчен иң элек аның үзенең әдәбиятта нинди кануннарны рәһбәр итә (юл күрсәтүче итә) икәнен белергә, соңра шул кануннар мизаны (бизмән) белән үлчәргә кирәк,—ди.

Исхакый әфәнде күп урында: тормыштан алу, тормыштан алу, тормыштан алу дип тәкрар кылды.

Мәрхүм Сәйдәш бабайның, мәрхүм «Бәянел-хак» гәзитәсендә Ярулла әл-Вәлинең «Җанлы җеназа»сы хакында язган бер тәнкыйтендә:

—Әсәрләр мөхәррирнең рухыннан туган төп бер идеяне ифадәдән (аңлатып бирү) гыйбарәт булырга тиеш,—дигәнгә якын бер фикер әйтте.

«Мөгаллимә» мөнәсәбәте белән зиһенгә килгән бу мөляхәзәләр (фикер йөртү) башка һәр нәзариядән (караш) бигрәк, пьеса иясенең үзенең шул әдәби карашларын хәтергә алып язылдылар.

## А. Бикташев

# ТӘНКЫЙТЬ ТИРӘСЕНДӘ

*Үзләре сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән,*
*Эт кебек һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.*

Г. Тукай

Ни өчендер, Галимҗан Ибраһимовның «Тормыш»ның 194-195 нче номерында Гаяз әфәнде турысында язган мәкаләләрен укыгач, минем күңелемә шул шигырь парчалары килде. Яна гына яфрак ярып килә торган әдәбиятымыз, аның таза-нык терәге булырга тиеш тәнкыйтебез ниләр күрми? Әдәбиятымызда калын, унике тиенлек кечкенә романнар, йөрәк яргыч Нат Пинкертон вакыйгалары, чын тормыштан алынып, ләкин күбрәк русчадан урланып язылган милли драмалар, русчадан үзгәртелеп үз исеме артына язылган тагы милли хикәяләр... (Мәсәлән, Кәбир Бәкернең «Ахунд хәзрәт»е, «Йолдыз» гәзитәсенең бу ел Гаспринский номерында чыккан русларның мәшһүр юмористлары О. Л. Д. ОРдан (Оршер Йосиф Львович) урланган «Дәвер» хикәясе), тәнкыйтебез дә шундый черек юл берлән бара. Һәркем тәнкыйть яза. Аңлаганы да яза, аңламаганы да гәзитләрдә исемен бастырып чыгара. Мәхрүм «Сибирия» гәзитәсендә Вәкъкас (С. Сүнчәләй) дигән берәү Гаяз әфәнденең «Шәкерт абый»сы дөньяга чыккач, бер мәкалә язып, ул әсәрне тетеп ташламакчы булган иде. Сәбәп бик табигый: тәнкыйтьче әфәнде хикәянең рухын түгел, мәфһүмен (эчтәлек) дә аңлап бетерә алмаган. Аныңча, кызның бер тугъма шәкерт абыйсының үзенең сеңлесенә суи касд (начар ният) кылуы мөмкин түгел (Юкса, кыз берлән шәкерт бертуганнар түгел). Бу сәбәп Вәкъкас әфәндегә бик зур бер сәбәп күренә дә, ул бөтен көченнән каравыл кычкыра.

Бичара тәнкыйтьче, ихтимал, хикәяне икенче мәртәбә укып аңлар-төшенер иде дә, ләкин ул нигә кирәк, исем гәзитәгә керде, максуд хасил.

Тагын «Шура»да мөгаллим Сәгъди нинди тәнкыйди мәкаләләр язмады. Бер Аллага гына мәгълүм—бары да булды. С. Сүнчәләй берлән Фатих Сәйфинең сүзләшүләре. Ярулла Вәли берлән Г. Батталның кычкырышулары бары да бит тәнкыйтебезнең бер кисәкләре. Бу әле тәнкыйтебезнең тирес ягы. Уң ягына карасак та, шундый ук кызганыч бер мәнзара. Бервакыт бер динче галим бер юристыбызны шагыйрь диеп, аны Пушкин берлән чагыштырып маташкан иде. Тик бунда бер аерма бар: юрист әфәнде бервакытта шагыйрь булып азапланмаган...

Тагын иң соныннан Галимҗан Ибраһимовның тәнкыйди мәкаләләре. Галимҗан Ибраһимов шактый күп тәнкыйди мәкаләләр яза. Ул Тукаевны да аңар халык тарафыннан бирелгән «Халык шагыйрь»леге урыныннан сөрмәкче булып бер зур гайрәт күрсәткән иде. Ләкин укучы халык Тукаевның Тукаевлыгына шулкадәр ышанганнар ки, бер мәртәбә йөзләрен җыердылар да һичбер тәэсирләнми һаман шул иске фикердә калдылар!

Тукаев шагыйрь! Ул мәҗмугадагы башка мактау мәкаләләре дә шулай ук тавышсыз-тынсыз үттеләр.

Чыннан караганда бу мәкаләләр илтифатка алынырлыклар иде. Андый чалыш карашлы мәкаләләрне җавапсыз калдыру үзе бик зур җавап булса да, «Гыйшык корбаннары»ннан башлап хәзергә кадәр Галимҗан әфәнденең кечкенә генә илтифатны күтәрерлек әдәби исеме дә бар бит. Хәтта «Аң» журналында берәү: «Әдәбиятыбызда булачак үзгәрешләрне Галимҗан әфәндедән башка кеше ясый алмас», мәфһүмендә бер комплемент та әйтеп куйган иде. Килик соңгы мәкаләләргә: мин Гаяз әфәнденең әдәби тарихыннан, «Мөгаллимә»сеннән катгый нәзар Галимҗан әфәнденең «Тормыш»та язган мәкаләсе хакында гына сөйлим.

Мөхәррир—тәнкыйтьче мәкаләсен матур-матур сүзләр белән башлый да «һәрбер мөхәррир бөтен әдәби гомерен тик бер идеягә генә хезмәт итәргә тиеш», дип зур бер казыя (тезис) китереп бастыра. Исбат өчен руслардан Толстойны, Арцыбашевны, читтән инглиз шагыйре елавык Байронны, үзебез татарлардан мәкаләчеләр-публицистлар Риза казый, Рәшид казый, Исмәгыйль Гаспринскийны ала. Анынча менә шул бөтен күрсәткән кешеләр бөтен әдәби гомерләрен гел бер идеягә генә хезмәттә үткәргәннәр. Толстой бөтен нәрсәсен «якыныңны сөй» флагы астында язып, Арцыбашев «Тән матурлыгы» турында гына яза. Риза, Рәшид казый, Гаспринский һаман бер идеягә генә хезмәт иттеләр. Ә Гаяз әфәндедә, никадәр озын әдәби тарихы булса да, бер төс юк. Ул бервакыт «ысулы җәдитче» иде, аннан соң социалист булды, аннан соң порнографист(?) (пычрак нәрсәләр язучы) була башлаган иде. Дүртенче дәвердә бытописательгә әверелеп, иң ахырда «Мөгаллимә»не язып, бөтенләй төсен югалтып җибәрде»,—ди. Ләкин Галимҗан Ибраһимовның алган мисалларын чынлабрак тикшереп карасак бөтенләй башка нәрсә күрәбез. Иң әүвәл Толстой. Бөтен тәнкыйтьчеләр Толстойны «Якыныңны сөй» идеясенә хезмәт итүен белә торып, «Севастополь хикәяләре», «Казак хикәяләре» дигән нәрсәләрен укып, андагы гаскәрнең баһадирлыгына, каһарманлыгына баш июгә бер дә шаккатып калмыйлар. Һәрбер тәнкыйтьче сугышчы баһадирларга, каһарманнарга баш ию «Якыныңны сөй» идеясенә хилаф икәнен белсәләр дә, Толстой бу хикәяләре белән һәм дә бик кадерле хикәяләре белән үзенең әдәби төсен, мөхәррирлек физиономиясен үзгәртте дип кычкырмады һәм кычкырмый. (Бу хакта укыгыз Иванов—Разумникны). Моны белер өчен Толстойның әсәрләрен һәм тәрҗемәи хален уку җитсә кирәк. Килик Арцыбашевка Г. Ибарһимов бу модадагы рус мөхәрриренең шул мәкаләсендәге зикер кылган «Жена», «Ревность», «Санин» дигән нәрсәләрен укыган да ул әсәрләр хакында рус әдәбиятында чыккан бернәрсәгә дә күзе төшмәгән булырга кирәк. Чөнки

Арцыбашевны чынлабрак укыган кеше аны «бөтен әдәби гомере тән матурлыгы турысында рәнҗетә язып үткән» диеп халыкка таныштыру кадәр ялгышлык кылмас иде. Арцыбашевның «Жена»сыннан ул һәм аннан соңгы хикәяләрен, билхасса, (атап әйткәндә) «Смерт Ланде»—«Ланденың үлеме» дигән хикәясен уку аның да бервакыт «Якыныңны сөй» идеясенә хезмәт итүен һәм ул тугрыда язуын күрсәтәләр. Бу бөтен рус әдәбиятына гына түгел, Арцыбашевны аңлап укыган һәрбер кешегә мәгълүм бер факт. Шуның берлә бергә, Арцыбашев ул «Якыныңны сөй» идеясенә хезмәт итеп, соныннан «Тән матурлыгы» диеп яза башлаган икән, аның берлә үзенең әүвәлге физиономиясен үзгәртми. Бу шундый фикерләр: берсенең булуы берлән икенчесенең булмавы лязем булып килми. Гаяз әфәнде дә шулай ук. Ул әүвәл Хәлимне, Ризаны «җәдитчеләр» итеп, Мансурны социалист ясаган икән, соңгысы берлә әүвәлге фикеренә хилафлык кылмый. Мисаллар кирәк булса, бик күп: алыгыз мәшһүр драматург, бөтен дөньяга, иң карангы милләтләргә үзенең «Баткан колокол»ы берлә мәгълүм Һауптманны (1862-1946, немец язучысы) ул элек киндерчеләр—фәкыйрьләр тормышыннан алып «Киндерчеләр» исемле пьесасын язып, соныннан «Ганнеле»дә христианнарда мәхәббәт тугрысында язгач, бер дә мөхәррирлек физиономиясен үзгәртмәде. Бу әсәрләр һәр икесе әдәби кыйммәтләре берлә (гәрчә идеяләре бер булса да), немец әдәбиятында зур урын тоталар. Шул көннәрдә генә Максим Горькийның «Детсво» дигән бер повесте чыгып, бөтен рус әдәбиятын шаулатты. Сәбәп бик зур: бу хикәя берлә талантлы рус мөхәррире үзен бөтенләй икенче ягын күрсәтте. Бу хикәя Горькийның әүвәлге тоткан юлыннан, идеясеннән шулкадәр ерак, шулкадәр аерма зур, бәгъзе бер тәнкыйтьчеләр: «Әүвәлге әсәрләрен язучы Горький моннан да горький—ачы иде. Бу әсәре берлә Максим Сладчайшийга әйләнде» дип кул чаптылар. Гәрчә бу үзгәреш фикрә бөтенләй янадан туу—перерождение булса да, Горькийның әдәби куәсенә бер дә тап сукмады (укыгыз: Чуковскийны)

Килик Гаяз әфәндәнең өченче дәверенә. Галимҗан Ибраһимовча әйтсәк, порнография—«Тормышмы бу?», «Шәкерт абый» дәверенә. «Тормышмы бу?» китап базарына чыккач, шул ук Г. Ибраһимов «Шура»да «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны язып үткән мөхәрриребез өчен «Тормышмы бу?» берлән икенче мәртәбә туды» мәфһүмендәрәк бер сүз әйткән иде инде. Шул ук әфәнде шул ук әсәрләр тугрысында бөтенләй башка нәрсәләр сөйли. Ул бу әсәрләрне порнографиягә кертә дә хәлфәләрчә: «бу әсәрләрне гаиләгә кертергә ярамый» дигән вәгазьләр сөйли башлый. «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый»ларда порнография бар дип порнографиянең нәрсә икәнен белмәүче кешеләр генә әйтә алыр. Порнография дип оятсыз нәрсәләрне, шул оятсызлыкка (яхуд пычраклыкка) укучының дәртен артыру өчен язылган нәрсәләргә әйтәләр ки, бу Гаяз әфәндедә бөтенләй башкача—киресенчә. Аның каләме бу урыннарны язганда, әйтерсең лә, шул тормыш тарафыннан җәберләнгән, кәһәрләнгән каһарманчарның канлы яшьләренә буялып яза, безнең күңелебездә бер җирәнү—кызгану тойгысын уята ки, аңлый алган кеше (порнографияне белгән кеше) ирексез елый. Чөнки бу чын тормыш, чөнки бу тормышта безнең бетмәс-төкәнмәс кешеләремез изелә. Аның былчырак булуында мөхәррир гаепле түгел. Шундый тормышны шулай язып чыгара белү Гаяз әфәндедә булган бер камәләт, аның әдәби тарихына бик зур бер плюс. Икенчедән, рус әдәбиятында ачык—дөрес язу берлән мәшһүр Куприна әдәби таҗ кидергән, сатлык кызлар тормышыннан алынып язылган «Яма» дигән романы, Максим Горькийның бик күп нәрсәләре, билхасса, (атап әйткәндә) «Трое» дигән хикәясе порнографиягә кертелмәгәндә, «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый»ларны порнографиягә кертүне, гомумән, әдәбиятны азрак аңлаган кеше генә булдыра алыр.

Тагын Галимҗан әфәнде порнографист мөхәррирләргә мисал итеп рус мөхәррирәсе Вербицкаяны ала. Рус әдәбиятында тәнкыйтьчеләр Вербицкаяга

нинди генә исем кушсалар куштылар, берсе дә аны порнографистка диеп атамады. Затән, Вербицкая хатын-кызның шәхси хөррияте тугрысында бик күп яза торган бер мөхәррирә ки, буны белер өчен аның берничә романын, калын журналларда чыга торган берничә мәкаләсен уку житә. Г. Ибраһимовның Вербицкаяны халыкка порнографистка диеп таныштыруы ул мөхәррирнең язган нәрсәләре берлән таныш булмауны гына күрсәтә.

Г. Ибраһимовның мәкаләсендә иң ят бер жире булса һәм кичерелмәслек бер хатасы булса, ул да беллетрист (хикәяче) Гаяз әфәндене публицист (мәкаләче) Риза, Рәшид казыйлар, Гаспринскийлар берлән чагыштыруыдыр. Рус әдәбиятындагы ялгышларны һәрбер татар үткәрерлек диеп хисап кылу—монысы да, гомумән, әдәби тәнкыйтьче өчен бер дә гафу ителмәслек. Аның соңында мәкаләчеләр берлән хикәячеләрнең тоткан юллары аерым икәне аз гына әдәби хазы (зәвекъ) бар кешегә дә мәгълүм бернәрсәләр бит. Әгәр дә Галимжан Ибраһимовның «Альбом»ындагы сәнәигы нәфисә хадимнәре арасына юристлар, тарихчылар рәсемен кертүен, андагы «гали вә вөжданлык берлә бизәкләнеп укырлыгы калмаган сатхи (сай) мәкаләсен әлеге ялгышлыкларга кушсак, шундый бер тәэсир чыга ки, шундый кешеләрнең сәнәигы нәфисә тугрысында сөйләүләренә шаккатып каласың. Гади баш берлә генә уйлап карагыз: ысулы жәдидә мәктәпләре, Русия татарларының сәяси вазгыятьләре тугрысында язылган Гаспринский мәкаләләре, Рәшид казыйның мөфти төшерү тугрысындагы мәкаләләре. Риза хәзрәтнең мөселман киеме хакындагы мәкаләләренең Гаяз әфәнденең гел әдәби генә әсәре «Сөннәтче бабай», яки «Остазбикә»се берлә ни мөнәсәбәтләре бар!

Мәкалә бөтенрәк булсын өчен Галимжан Ибраһимов мисал иттереп алган Байрон хакында да берничә сүз әйтергә кирәк булса да, бик озакка китүеннән куркып, мин «Дон Жуан»ны язган, «Поверь, смерть вовсе не страшна» дигән шагыйрьгә елавык шагыйрь исемен бирү көленеч бернәрсә икәнен генә әйтеп үтәм.

Менә Г. Ибраһимовның «Мөгаллимә» тугрысында язган мәкаләсенең мөкаддимәсендә (кереш) шундый нәрсәләргә очрыймыз: бу ялгышлар барысы да «Гаяз әфәндедә идея—гая ул юк» казыясен исбат наменда ясалганнар. Ләкин бу шундый исбат кылынмаслык казыя. Аның өчен бер-ике рус мөхәррирен уку, аларга үз тарафыннан исемнәр тагу гына бик аз. Гаяз әфәнденең әдәби кыйммәтен белер өчен, аның берлә халыкны таныштырыр өчен битараф, чын тәнкыйтьчеләр кирәк. Минемчә, бу урынны Галимжан Ибраһимов тота алмый, чөнки аның жинаять булырлык шул мәкаләсендәге хаталары Г. Ибарһимовның битарафлык, чынлык берлә күпме исәпләшүләрен бик ачык күрсәтәләр. Г. Ибраһимов тәнкыйтьче буласы килсә, Гаяз Исхаковның бездәге әдәби кыйммәтен, билхисса, «Мөгаллимә»нең нольгә мөсавилеген (тигез) исбат итәргә тотынса, ялган мисаллар алмасын, фактларны икенче төрле иттереп күрсәтмәсен. Бу зур мәсьәләне исбат өчен әллә кайчан башка кереп чыккан нәрсәләрне бер чәй янында жыеп чыгарып салу гына аз һәм әдәбиятыбызның мактанырлык бер әгъзасы Гаяз әфәндегә генә түгел, әдәбият тарихымызга да гафу ителмәслек бер жинаять. Тәнкыйтьче булыр өчен сәнәигы нәфисә тугрысында колакка ишетелгән берничә матур жөмләләр, модада булган рус мөхәрирләренең исемнәре генә житеп бетим, чөнки бер инглиз шагыйречә генә әйтсәк тә: «Тәнкыйтьче үзенең матурлыктан алган тәэсseratын (впечатлениясен) башка юллар берлә әйтә ала торган бер кеше» булырга кирәк.

*Яшь тәнкыйтьче сүз ала*

## «КАНГА БАТТЫ ... КУЛЛАРЫМ...»

Һади Такташның тормышы һәм иҗаты җир өстендә яна заман җилләре искән бөек иҗтимагый тетрәнүләр чорына туры килде. Такташ—1917 ел революцияләре нәтиҗәсендә туган беренче татар шагыйре.

Ә Казан чорына тикле ул унай герой эзләү белән мәшгуль иде. Бу елларда шагыйрь, сонрак үзенең бөтен иҗатын сугарачак бәрәкәтле чишмәләр: татар, гарәп, фарсы, рус һәм Көнбатыш Европа шигъри традицияләре белән таныша.

Такташ үткән юл—гади татар авылыннан алып Яна Бохарадагы татар диаспорасына кадәр һәм татар мөселманнары үзгенен берсе саналган Оренбург мәдәни мохитыннан башлап Төркестан башкаласы Ташкентка кадәр булган юлны үз эченә ала. Бөек шагыйрь мөселман халыклары сәяси һәм рухи үсешенен иң мөһим нокталарын уза.

Революция—«карангылык»ка әверелгән «нур», «каранғы төн»гә алышынган «тан», «гакылсызлар йорты»на әйләнгән «җәннәт». Октябрь революциясеннән соң Россия империясе һәм татар халкы кичергән трансформация чагылышы менә шундый. Такташ үзен чолгап алган доньяны политграмота дәресләкләре аркылы түгел, ә бәлки гомумкешелек зирәклеге югарылыгыннан анларга тели. Мондый омтылышның бер нәтиҗәсе дип «Җир уллары трагедиясе»н әйтергә мөмкин.

Иҗатында иң мөһим булган бу әсәрендә Һади Такташ Байронның «Каин» мистериясе нигезендә яткан дини хикәятне куллана. Татар шагыйре Коръән хикәяләгән Адәмнең ике улы—Библиядә бирелгән Каин һәм Авель образларына мөрәҗәгать итә. Бу хакта әдәбият белгечләре Г. Рәхим, Х. Хәйри, Г. Халит, Н. Юзиевлар да язып чыктылар. Билгеле, Коръәндә Адәм улларының исемнәре бирелмәгән, ләкин аларның корбан китерүләре һәм бары тик берсенен генә корбаны кабул булуы турында хикәя бар. Корбаны кабул ителмәгәне үз кардәшенә үлем белән яный, сонгысы исә беренче булып абыйсына беркайчан да кул күтәрмәячәге, чөнки үтерүченен җәһәннәмдә булачагы хакында сөйли.

Бу мәсьәләне тикшерүчеләр Кабил һәм Хабил исемнәрен атап, бәхәснен сәбәбе турында язалар. Ике кардәшнен һәрберсенен игезәк сенлесе була. Адәм аларга берберсенен сенелләренә өйләнергә әмер бирә. Ләкин Кабил Хабилнен ямьсез сенлесе Лабудага түгел, үз сенлесенә— гүзәл Әкълимәгә өйләнергә тели. Бу бәхәсне корбан китерү рәвешендә үткәрелгән шобага хәл итәргә тиеш була да инде.

Мөселман хикәяте Библиягә барып тоташа, Библиядән соң барлыкка килгән яһүди хикәяләргә корылган мотивларны да үз эченә ала. Иң әүвәлге Библия вариантында Каин белән Авель арасындагы бәрелеш—ул игенче белән терлек караучы арасындагы бәрелеш. Алла икенчесенен корбанын кабул итеп, үзенен аны өстен күрүен белдерә. Көнчелектән Каин кардәшен үтерә. Алла һәм җир ана бу эше өчен нәфрәт белдерәләр, ләгънәт әйтәләр. Шуна күрә дә Каин токымы түгел, Адәмнен өченче улы Шет «кешеләр нәселенен дәвамчысы була».

Дини хикәя Байронга да, Такташка да бер яктан кызыклы: алар бу хикәядә бәхәссез догмага каршы кешелек тарихында булган иң беренче фетнәне раслаучы факт күрәләр. Бөек шагыйрьләр үзләренен әсәрләренен каһарманы итеп кардәшен үтерүче Каинны сайлап, аны донья төзелешенә каршы баш күтәрүче дип таныталар. Димәк, дини сюжетны Аллага каршылык мәгънәсе белән тулыландыралар.

Коръәндә дә, Тәүраттә дә югары хөкем йөртүче булып Израил Алласы тора. Тәүраттә Алла Каиннын киләчәген билгели: анын балалары һөнәрләргә һәм сәнгатька

нигез салучылар дип исәпләнә. Әгәр Байронда Каин аны Аллага каршы көрәштә кулланучы Люцифер белән диалогка үзе керешсә, Такташның кабиле исә үз юлы белән китә: ана кодрәтле, бөек көчләр кирәкми. «Җир уллары трагедиясе»ндә Алла— ирешә алмаслык ерак.

Нәрсәне дә булса барлыкка китерүче уңай геройны эзләвен Такташ «Газраилләр»дән башлап дәвам итә. «Газраилләр»дәге фәрештә дә, «Күктән сөрелгәннәр»дәге «Күк кызы» да, Газраил дә, «Үтерелгән пәйгамбәр»дәге Пәйгамбәр дә— алар берсе дә дөньяны коткарып кала алмыйлар. Шагыйрьнең «Айның нурлары астында» исемле шигырендә, ниһаять, барлыкка китерүче, тудыручы көч хасил була— төрки халыкларның ирекле дәүләтен төзү өчен көрәшүче кызылармеец мөселманнар. Шагыйрь дөнья белән шәхси диалогка омтылыш ясый. Такташ Курсави һәм Мәрҗанилардән үк килә торган татар хөр фикерлелеге традициясен дәвам итә. Алла бу традициядә бөтен галәмне булдыручы, ә кешеләр— үз тормышлары өчен җаваплы итеп бирелә. Такташ герое бу җаваплылыкны үз өстенә алырга әзер.

Ислам традицияләре өчен уңай геройларны җирдә эзләү характерлы. Бу традиция динне һәм беренче мөселман дәүләтен булдырган Мөхәммәдкә һәм аның дүрт хәлифенә дан җырлый. Мөхәммәд дәүләте мәҗүсиләр белән сугышлар вакытында барлыкка килә, шуңа күрә Такташ инде «Күктән сөрелгәннәр» шигырендә үк «канлы көрәш» традициясен исенә төшерә. Ислам, башка диннәрдән аермалы буларак, җирдә чын иман тарихы белән билгеле. Бу патшалык Алла иңдергән канүннар буенча яшәгән, ләкин аны кешеләр төзегән. Димәк, кеше үзендә чын яшәеш традициясен алып килгән. Такташ үз героен эзләвендә фәрештәдән пәйгамбәргә кадәр юл үтә, аның инде чираттагы каһарманы— кеше. Хаклыкны шәхес ирегеннән башка күз алдына китерә алмаган татар шагыйре үзенең беренче героен, беренче ирекле шәхесен кешелек тарихында таба. Такташ герое— тормыш тарафыннан изелгән кеше. Ләкин ул кайнар догаларга җавап буларак югары көчләр бирә торган бәхетне табуына өметен өзмәгән әле. Әлегә ул Байронның Каинның берничек тә хәтерләтми. Кабил, Адәм гаиләсенең бөтен әгъзалары кебек үк, Аллаһы тәгаләне данлый, аның мәрхәмәтенә ышанып яши. Ләкин инде бу тирәнтен бәхетсез кеше күңелендә канәгатьсезлек өлгерә башлый— чынлыктан канәгать булмауның беренче чагылышы. Туудан алып үзенә юлдаш булып өлгергән ялгызлыктан ул бик туйган.

Кабилгә ярдәм кулын Алла түгел, ә Идея суза. Башта Такташ Идеяне Газазил дип атый. Бу— Ш. Бабичның «Газазил» поэмасына аллюзия. Ул хакта Г. Халит та язып чыкты. Ш. Бабич поэмасында кодрәтле Газазил (Иблиснең җирдәге исеме) кешеләр, хак динле мөселманнар өстеннән хакимлек итә. Соңгылары аның табанына, әйтерсең лә яһүдиләр «алтын үгезбозауга» җыелышалар. Бабичның 1916 елда язылган поэмасында кешеләр түбән инстинктлар белән генә эш итүче масса булып карала. Такташ исә кешеләрнең кол дәрәҗәсенә төшүләренә ышанмый, Идея дә Каиннан өстен түгел, ә бәлки аның кинәшчесе, өйрәтүчесе булып тора. Каин аңында бары тик пунктир рәвешендә билгеләнгән фикерләр Идеянең фикер йөртүендә инде тәмамланган, ачык һәм ярдәм булып күренәләр. Әгәр Идея образында Такташ кыю, Аллага буйсынмас акыл идеясен алга сөрсә, Кабил образында исә шагыйрь ирекле аңның һәм шәхеснең формалашу процессын ачык күрсәткән.

Такташ күпләр тарафыннан иман белән акыл антиподлар буларак кабул ителгән чорда яши. Ләкин мөселман гореф-гадәтләрен кечкенәдән канына сеңдереп үскән шагыйрь үзе гади халык арасында иман һәм рух ярдәмлеген күрә белгән. Сәясәтчеләр өчен исә акыл һәм идеяләр, халык кулы белән үз максатларына ирешү чарасына әйләнгән. Бохарада, Оренбургта, Ташкентта Такташ 1917 елның изге идеяләренең ачык политиканлыкка әверелүен күрә. «Җир уллары трагедиясе»ндә Идея шул, җирдәге уеннарның кагыйдәләрен үзләштергән һәм теләсә нинди шартларда үзенә урын таба торган акылның җанлы гәүдәләнеше инде. Кабил шулай ук акыл юлы белән барырга тырыша, хаклык патшалыгын эзли, ләкин инде кешелектән баш тарту ысулы белән түгел. Шуңа да Идеядән аермалы буларак, ул үсешкә сәләтле. Идея исә көчкә, куәткә омтыла. Ул объектив, ләкин аның объективлыгында, Х. Госман бик дөрес күрсәткәнчә, кеше язмышы хакында борчылуның бөртеге дә юк. Идея йогынтысында Кабил коллан шәхес дәрәҗәсенә күтәрелә, аның монарчы йокымсыраган, кирәк дип табылмаган аны киеренке рәвештә чынбарлыкны аңлый башлый. Пассив күзәтүдән ул чынбарлыкны төшенә башлауга күчә. Үзенең аның Кабил кешеләргә хезмәт итүгә

багышларга тели, азатлыгында ул башкалар азатлыгынын беренче этабын күрә.

Идея Кабилгә икенче дөнья, икенче тормыш барлыгы турында сөйли. Анда «юк Алла, канун һәм эч пошу, хәсрәт». Ул дөньяда «шатлык һәм ирек шаһлык сөрә», «хөр йөрәк, көчле, батыр ирләр тора». Такташның башлангыч чорында ук төсмерләнгән чын тормыш иле Хәят «Җир уллары трагедиясе»ндә үзенен серен ача төшә, күзгә күренердәй сызымта ала.

Хөрлек, азатлык дөньясын тудырганда шагыйрь янә «нур», «ут», «гөл-чәчәк»ләр символикасына мөрәҗәгать итә. Әгәр Такташ герое мона кадәр ялкынны бары тик бер-ике йөрәктә генә кабызырга сәләтле булса, хәзер инде ул нурлардан бердәмлек һәм гармония символы булган ут дөрли. Чынбарлык инде традицион образларга әверелгән «зөлмәт учагы», «ачлык», «төн», «михнәт, «төтен» образлары аша бирелә. «Нур— төн», «шатлык— хәсрәт» образларынын бәрелеше аша шагыйрь безгә геройнын катлаулы кичерешләрен житкерә, Кабил күнелендә катлаулы рәвештә рухи кичерешләрнен ике агымы үрелә. Беренчесе— хөрлек хөкем сөргән дөньянын якты кичерешләре, икенчесе— жирдәге яшәешнен камил булмавын күзәтү нәтижәсендә туган авыр, күнелсез кичерешләр.

Идея Кабилгә киләчәктәге жир жәннәтен күрсәтә. Жәннәттән куылган Адәм балалары өчен ана кире кайту мөмкин түгел, шуна да ул көтеп, теләп алына. Жәннәт— тоныκ сурәт түгел, ул реаль чынбарлык. Идея жәннәттә тулы азатлык, хөрлек вәгъдә итә. Ләкин ул жәннәтнен бәясе— Алладан һәм коллыктан баш тарту. Үзен тормышка ашырыр өчен Идея шул дөньяны төзергә тиеш һәм Кабил анар ин беренче, шуна күрә дә бик көтелгән корал булып тора. Идеягә Кабилнен жаны кирәкми, ана үзенен тормышка ашуы, ягъни Аллага тин булуы кирәк.

Жирдәге тормышнын камил булмавынын ин беренче сәбәпләрен киеренке рәвештә эзләгән Кабил фикере Идея авызында көтелеп алган жавап таба. Анын әйтүенчә, жирдә явызлык яшәү сәбәбе—коллык. Нәкъ шушы нәтижәгә үз вакытында «Күк кызы» да килгән иде («Күктән сөрелгәннәр»). Чынбарлыкны мондый рәвештә анлавы Кабилне Алла белән көрәшкә этәрә дә инде. Г. Халит Кабилне хаклы рәвештә «ялган һәм золым дөньясына каршы көрәш апостолы» дип атый. Күренекле галим Кабилдә гыйсьянчылыкнын үткендә түбәнсетелгән һәм жәберләнгән, эмма хәзер азат һәм горур, ләкин әле «элеккеге ялгызлыгыннан, бунтарьлегеннән һәм фажигале кичерешләреннән азат булмаган» типик героен күрә.

Кабилнен күнел кичерешләрен сурәтләүдә янә Такташның беренче шигырьләре белән образлы тәнләшлекне күрә алабыз: чынбарлык— «зөлмәт учагы», «шаштыра уй, кайгылар»... Кабил образы шагыйрь тарафыннан тора-бара, акрытын ачыла. Автор акылсызлык чигенә барып житкән авыру һәм тынгысыз анны сурәтли. Ә чынбарлык кабул итәр өчен шул дәрәжәдә авыр! Биредә Кабилнен Пәйгамбәргә якын торуын да күрергә мөмкин («Үтерелгән пәйгамбәр»). Бу хакта Х. Госман да язды.

> Талды рух, сынды канатлар,
> Мин бетәм...—

ди Кабил, төшенкелеккә бирелеп. Ләкин ярдәмне инде ул Алладан түгел, ә рухтан, Идеядән, көтә.

Кабилнен табигатьтән игелекле күнеле үзенен ихтыярын белдергәне өчен нәрсә белән түлисен алдан ук сизеп тора. Анын күнеле көчләү һәм кан коюга каршы чыга, ләкин аны аны үтерүгә этәрә.

Шушы вакыттан Кабилдә Байроннын Каины белән аваздашлык туа. Бу хакта үзләренен хезмәтләрендә Г. Рәхим, Г. Халитлар да язып чыкты. Кабил һәм Каин— икесе дә гыйсьянчылар, кыюлар. Байроннын һәм Такташнын романтик геройларын коллыкка нәфрәт, шәхес иреген чикләүче кануннарны жимерергә омтылыш берләштереп тора да инде. Шагыйрьләр үз геройларын шундый бер чиккә китереп куялар ки, шул чикне үтсәләр алар рухи азатлыкка, Алла һәм жәмгыять кануннарыннан (әгәр дә алар чикләп торса) югары булуга ирешәләр. Әдәбият белгече И. Дьяконова хаклы: «Байрон мистериясенен котылгысыз фажигасе шуннан гыйбарәт: зөлмәткә каршы күтәрелүне данлап, шагыйрь шул ук вакытта үз-үзе белән көрәшкә кергәннәр читләтеп үтә алмый торган әхлакый ике мәгънәлекне дә ачып бирә. Мондый көрәш үзеннен кыйммәтенне, акылынны һәм хөрлегенне саклап калу өчен бик мөһим. Ләкин ул жимергеч көчкә ия булган, газаплар һәм үлем китерүче әхлакый корбаннар таләп

итә. Корбан китерүчегә аткан таш һәм кешелекне саклап калу өчен Кабил күтәргән кылыч бер гаепсезнең башына төшә. Ихтыяр һәм хөрлек башбаштаклыкка әверелә. Кабилнең күзенә күренгәннәре чынга аша: ул чынлап та «юлбарыс»ка әйләнә. Туганын үтерүче—ул гражданнар сугышының мәңгелек символы, билгесез көчләрнең кешеләр күңелендә җиңүне күрсәтеп тора. Канлы корбан алган Идея шул чак үзен көчле, кодрәтле итеп хис итә башлый. Такташ көчләүне тормышта котылгысыз чара буларак кире кага. Шагыйрь тавышы фаҗигадә дә ачык ишетелә:

Ул кылыч батырыр кара канга
Бөтен җир-дөньяны,
Ул кылыч— шәфкать-мәхәббәт дошманы!..

Кабил үзе дә биредә әйтеп үтелгән фетнәнең ялган булуына төшенә: «Канга батты зур теләкләргә сузылган кулларым...». Үз-үзенә кул салу— ул Алла каршында үз ихтыярыңны белдерү генә түгел, ул туганнарыңны үтерү гөнаһысы һәм максатның ялган булуын аңлаганнан соң яшәп алмау да әле. Шулай итеп биредә Такташ дини сюжеттан читкә китә. Ә Байрон, киресенчә, дини сюжет кысасында кала.

Такташның Кабиле моңнарчы һәлак булган «Күк кызы», пәйгамбәр язмышын кабатлый. Шагыйрь өчен киләчәккә рухи чистарудан башка юл юк. Шуңа күрә дә Такташ өчен иң югары хөкем—Кабилнең намусы.

Кабил—кешеләр ихтирамын яулаган беренче герой. Такташның үткен карашы «яңа дөнья»ның «иске дөнья»га кан коюда баш бирмәвен, хәттә кайбер очракта өстенлек итүен дә күреп ала. Шагыйрь революция идеяләренең кешеләрне юк итү механизмына әверелүен таный башлый. Кабил кешене үтерсә дә, революционерлардан аермалы буларак, ул кан аша атлап үтә алмый. Ә Кабил артыннан килүчеләр инде кан белән тапланмаячаклар. Ягъни, икенче төрле әйтсәк, шәхес ирегә идеясе үзен саклап кала ала. Ә шәхес башлангычын үз эченә алмаган Идеянең юлы исә— тупик. Бары тик Кабил юлы— кеше юлы гына—өмет тудыра. Җир кызы Әкълимә дә Кабил өчен янару чыганагы— «Алла», «дин»— булып тора.

Шулай итеп, Кабил мисалында татар әдәбияты Мильтон, Байрон, Пушкин, Лермонтов, Достоевский геройлары белән бер рәткә куярлык гыйсьянчы образын тудыра. Берничә ел буе «Җир уллары трагедиясе»н язу Такташка әсәр рухын бөек тетрәүләр чоры рухы белән бәйләргә мөмкинлек бирә. Шагыйрь үзенең бу әсәрендә коллыктан абсолют ирекка хәтле юл үтәргә мәҗбүр булган шәхес үсешен даһиларча күрсәтә алган. Такташ кисәтә: революцион идеяләр белән ләззәтләнү башкаларны да, үзеңне дә һәлакәткә китерергә мөмкин! Шулай да, колдан ирекле шәхес туа ала һәм бу хакта изге китаплар да хикәяли. Тәүрат, Библия, Коръән, шулай да кешеләр Аллага ышануларын ташламыйлар, ләкин бу ышану аларны җирдәге иҗаттан баш тартуга китерми. Курсави, Мәрҗани, Ататөрек һәм Садри Максудиларның моңа иманнары камил иде. Такташ та хөрлек патшалыгына юл күрсәтә. Кеше нәселен дәвам итүчеләр бу юлны каннан арындырып, аны чиста күңел белән үтеп, балаларына калдырырга тиешләр.

Такташ яңа заман Европа әдәбияты тәҗрибәсе һәм чор чынбарлыгын аңлау аша үз героен үсешкә һәм янаруга сәләтле шәхес дип күрсәтә.

**Миләүшә ФАТЫЙХОВА,**
*Казан дәүләт педагогия университеты аспиранты*

Китап күзәтү

# ТОРМЫШ УЧАГЫ СҮНМӘСЕН

Басылып чыккан һәр яна китап авторны укучыга якынайта. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйга-күренешләр, геройларның эш-хәрәкәтләре артында язучы үзе һәм чынбарлык торуын белгән хәлдә дә, аның белән йә килешәсен, йә бәхәскә керәсен: фикер карашларны чагыштырып, нәрсәнедер яклыйсың, нәрсәгәдер каршы төшәсең. Ю. Сафиуллинның «Пар канат» җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 1997) белән танышып чыккач та шундыйрак халәт кичерү кулга каләм алырга этәрде...

Драматург бүгенге укучыга да, тамашачыга да яхшы таныш. Үткән тарихыбызның фаҗигале чорларын чагылдырган «Идегәй» трагедиясе Г. Камал театры тормышында вакыйга буларак кабул ителде, белгечләр һәм тамашачылар тарафыннан уңай бәяләнде. К. Тинчурин театрында куелып килгән «Ләйсән ире Хәсән» комедиясе дә тормышчанлыгы, куелган проблемаларның ачык-аңлаешлы булуы, чор каршылыкларын уңышлы тотып алуы белән әйбәт тәэсир калдырды. Ю. Сафиуллин пьесаларына Әлмәт, Минзәлә театрларының да теләп мөрәҗәгать итүе мәгълүм.

«Пар канат» китабына тупланып бирелгән пьесалар артында чор, заман вәкилен күрәбез. Ул—җәмгыятьтәге үзгәрешләрне ачык сиземләүче, аларга үз мөнәсәбәте булган, һәртөр әхлаксызлык, битарафлыкны кабул итмәүче кеше. Бу уңайдан Ю. Сафиуллинның «Сабантуй» гәзите укучыларына әйткән теләгенең үзе һәм әсәрләре өчен таяныч-терәк булуын күрәбез: «Гаилә учагыгыздан читкә аерылга бирәүгә дә юл куймагыз! Татарстан дип аталган туган илебез, туган җиребез—ул да бит безгә яшәү бирүче учак. Туган телебез, газиз милләтебез дә учаклар. Алар балкып торганда Татарстаныбыз да, без дә бәхетле булырбыз!.. Бәхетле милләт башка милләтләргә дә бәхет китерә.»

Чыннан да, драматургның әсәрләрен берләштерә, аларны инләп үтә торган хис—яшәешебезнең бүгенгесе һәм киләчәге турында җитди уйлану. Кеше тормышта начарлык, гаделсезлек, әхлаксызлык күренешләре белән очрашып тора. Аларга киртә итеп нәрсәне куярга? Күп гаепне заманга, үзгәрешләргә сылтап үзебезне үзебез акларга гына тырышмыйбызмы? Бездән соң килгән буын нинди булыр? Әлеге һәм башка сорауларга җавап эзләп драматург алгы планга яшьләрне, ягъни аларның үзара мөнәсәбәтләрен, дуслык, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләрен куя. Боларга буыннар арасындагы бәйләнеш, милли үзенчәлекләрне, изге гореф-гадәтләрне саклап калу, яшәүнең олы мәгънәсен аңлау, әхлак сыйфатлары тәрбияләү һ. б. проблемалар килеп кушыла.

Җыентык исеме итеп алынган «Пар канат» драмасы сиксәненче еллар уртасында илдә башланып киткән үзгәрешләр тәэсирендә язылган. Исеменнән күренгәнчә, үзәктә мәхәббәт, гаилә кору мәсьәләсе торса да, авторны авыл-колхозларның хәле, яшәешкә үтеп кергән эчкечелек, әхлаксызлык кебек яман гадәтләрнең артуы борчый.

Авыл хуҗалыгы институты студенты Рафис зур планнар белән яши. Ул авылның, авылдашларының авыр тормышы, алар мәнфәгатьләренең кайгыртылмавы турында ачынып сөйли, аның сәбәпләрен эзли. Шактый акыллы кеше буларак, «гап-гади агроном кисәгенә ат булып җигеләсе, сука булып сукалыйсы бар» икәнен дә аңлый, әмма «әзергә-бәзер булып» яшәргә өйрәнгән егет әлеге авыр эшкә генә алынырга теләми, авылны перспективасыз, үсәргә шартлар юк дип саный. Үзе турында шактый югары фикердә булган Рафис: «Агач булып туганнарга үлән булып калу—җинаять!»—ди һәм ул укучы каршына һавадагы торнага кызыгып яшәүче буларак килеп баса. Әнә шулай икеләнеп, урталыкта калган егет тормыш лабиринтында буталып бетә. Үзе Асияне яратып, аңа өйләнергә теләсә дә, яшь вакытта ошатып йөргән Райхананың «яратам» дигәнен кире кага алмый...

Шәһәрдән кайткан Эльза-ның «без ирекле партнерлар идек» дигән сүзеннән гажиз кала. Әфганнан кайткан кызу канлы, дөреслекне яратучы, шул ук вакытта бөтенесен көч белән хәл итәргә омтылучы Азаматның каршылыкларын да хәл итә алмый... «Миңа башка юл калма-ды. Бөкрене кабер генә төзәтә» дип упкынга сикерә.

Минзәлә театры тарафыннан куелган спектакльгә язган рецензиясендә Н. Ханзафаров: «Шәхси ирек, горурлык, тирәлеккә протест, туачак улы каршында җаваплылык хисе аның соңгы карарга килүендә хәлиткеч роль уйный»,—дип язса да, (Ханзафаров Н. Кая барабыз, җәмәгать? Социалистик Татарстан.—1991, 23 гыйнвар.) укучы аның бу адымын хупларга да, гаепләргә дә белми. Моның белән егет кемгә нәрсә исбатлый соң? Ул бит хәл ителмәслек җинаять эшләмәгән, шуның өстенә Асиянең баласы да булачак. Үз вакытында А. Әхмәдуллинның «Пар канат» драмасында исә табигыйлек һәм психологик мотивлаштыру җитми»,—дип язуы нәкъ менә шундый вакыйга-күренешләрдә автор позициясенең ачык түгеллеген билгели иде. Шуңа да Рафисның ирләр-хатыннар хыянәте турындагы, бигрәк тә «хатын-кыз хыянәтенә очраган ир башта гаиләне, аннары җәмгыятьне, ахыр чиктә дөньяның үзен җимерергә керешә» яисә үлеме алдыннан «Зәйнәп апа, син инанган нәрсәләр изге. Аларны син сакламасаң беркем дә сакламас» дигән сүзләре дөрес һәм автор карашы булып торсалар да, герой эш-гамәленең логик дәвамы булып бетмәгәнлектән, эчке мәгънәсен югалталар. Гомумән, Рафис тулы канлы характер дәрәҗәсенә үсеп җитә алмаган, бу исә әсәрнең гомуми таркаулыгына китерә.

Драмада тагын ике зур мәсьәлә игътибар үзәгендә тора. Берсе—авылларның ташландык хәлгә төшү сәбәпләре. Автор моның бер яктан, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы колхоз җитәкчеләренә, икенче яктан, бөтен ил күләмендә афәткә әверелгән урлашуга бәйле икәнен күрсәтә. Соңгысы аша яшәп килгән системаның шул ук урлашуга һәм аерым оешмаларның колхоз җилкәсендә яшәүләренә юл ачуы, мөмкинлек бирүе тәнкыйтьләнә. Күренешләр артында объектив рәвештә хакимиятнең халыкны тишек чиләк, ватык арба белән калдыруы ачыла. Бу унайдан вакыйгаларның таралып беткән авылның ярымҗимерек мәдәният йорты фонында баруын да билгеләп үтү кирәк. Моның белән драматург татар авылына янаган куркынычның, афәтнең зурлыгын ачык итеп, сәхнә түренә куеп күрсәтә.

Җәмгыятьнең яшәү рәвеше, тормыш шартлары халыкның әхлак сыйфатлары белән бәйле. Бу авылда да инде эчкечелек яшәү рәвешенә, тотрыклы гадәткә әйләнгән. Әтисе үләр алдыннан васыять урынына «улым, җәннәткә чыктыгыз сез, рәхәтләнегез әйдә» дип әйтеп калдырган, шуңа да Ибраһим аракы турында: «Чукынсам чукынам, әмма ташламыйм. Хатынымнан да кадерлерәк ул миңа»,—ди . Иң кызганычы, әхлакый кыйммәтләр урынына буыннар арасында әлеге чир тора. Ул исә иң элек кешене шәхес буларак юкка чыгара, аннары гаиләне тарката һәм әкренләп милләт яшәешенә дә куркыныч белән яный. Әлеге зәхмәт үз кочагына Ибраһим, Шаһинур кебек өлкән буын кешеләрен генә түгел, Финат шикелле яшь ирләрне дә тартып алган. Егет үз тотнаксызлыгы белән әнисенең «бәгырен аяк астына салып таптаган», исерек килеш урлап кайткан хатыны Рәйхананы да бәхетсез иткән. Шуңа да Финатның: «Их, хатын-кызлар, кайда сезнең матурлыгыгыз? Кайда ул безне гашыйк иттерә торган нәфислек. Мөлаемлылык?» дигән сүзләренә Рәйхана җан авазы белән җавап бирә: «Сез сатып эчеп бетердегез!» Бу яшь хатын яшәү матурлыгын, киләчәккә ышанычын югалткан. Аның һәр сүзендә, гамәлендә ялгызлык, мәхәббәт газабы, үзенең бәхетсезлеге сизелә. Рәйхана башкарган җыр да лейтмотив булып, мәхәббәт, гаилә мәсьәләсенә драматург фикерләрен тирәнәйтә, баета: яшәү өчен, тормыш кыенлыкларын җиңү өчен парлы булу, кем беләндер үзара аңлашып, инне ингә куеп янәшә бару кирәк.

Яшь буынның тормышка әзерлеге, гасырлар дәвамында халыкта тупланып килгән изге гамәлләргә, традицияләргә мөнәсәбәте, ата-ананың рухи дәвамчысы була алуы турында уйлану күп әсәрләрнең нигезендә ята. «Пар канат» та Асия белән Рафис, Финат белән Рәйхана язмышлары аша үзенчәлекле чагылыш тапкан бу мәсьәлә «Бердәнберем минем» драмасында Диана һәм Данил образларына бәйле. Вакыйга-күренешләр ике гаиләнең яшәү рәвешенә, тәрбия системасына нигезләнеп тасвирлана. Гастроном директоры әнисе Галия һәм фәнни институт хезмәткәре

булып эшләүче үги әтисе Гыйльфан белән яшәүче ДианаHis әлегә дөньясы түгәрәк: өй тулы байлык, кыйммәтле җиһаз. Суыткыч та затлы ризыктан бушамый, бөтен дефицит әйбер беренчеләрдән булып аларга килә. Кыз акчага да бернинди мохтаҗлык кичерми. 15 яше дә тулмаган Диана бар нәрсәнең дә анынча гына булуын тели. Шуңа да ул Данилның үз-үзен тотышын, эш-гамәлләрен аңлап бетерми. Аның үбешергә теләмәвенә, вино эчмәвенә гаҗәпләнә.

Ләкин автор кызны тиз генә гаепләргә җыенмый. Яшьләр мондый, тегенди дип кычкыручылар әйләнә-тирәбездә еш очрый. Ә соң аларны аңларга, тыңларга теләүчеләр бармы? Без үзебез еш кына начар үрнәк бирмибезме? Диананың әнисе дә өч тапкыр кияүгә чыккан, әмма—барыбер бәхетсез. Кеше тормышында акча, байлык никадәр зур роль уйнаса да, ул яшәү мәгънәсенә әйләнеп калырга тиеш түгел. Адәм баласы дуслары, якыннары белән эчкерсез аралашуга мохтаҗ. Башкача ул күңел тынычлыгын, җан җылысын югалткан, үзен генә яратучыга әйләнә. Шуңа да драматург 17 яшьлек Данилнең авылдан килеп төшкән әнисе Әдибәне һәм әбисе Бибигайшәне яратып, үз итеп сурәтли. Аларның гадилеге, гадәтилеге, үзара самими мөнәсәбәтләре Диананы да үзгәртеп җибәрә. Авыл әбисе Бибигайшә авторның табышы булып тора. Тау ягы диалекты белән сөйләшүче җор, тапкыр телле әби милли образ буларак ачыла. Күңел күтәренкелеге, тирән оптимизм, турысын әйтүе белән ул башка образларны да тулыландырып җибәрә. Халык тәҗрибәсен үзенә туплаган Бибигайшәнең Диана белән бик тиз уртак тел табуы да шактый мәгънәле. Кызга әлегәчә нәкъ әнә шундый мөнәсәбәт, өлкән буынның әхлак сыйфатларын күрсәтүче, сеңдерүче кеше булмаган икән.

Тел тегермәне тартучылар «Нигез туздыручылар» драмасында сүздән эшкә күчә. Алар кешенең аны, акылы белән генә түгел, мал-мөлкәте, йорт-җире белән дә теләсә ничек эш итә алабыз дип саныйлар. Юл төзү оешмасы җитәкчесе Хөлли Кәлиевич, ПМК начальнигы Самит кебекләр өчен изге төшенчәләр юк. Үз мәнфәгатьләрен тормышка ашыру максатында (бу очракта күп бүлмәле фатир алу), алар теләсә нинди түбәнлеккә төшәргә, алдарга, кимсетергә әзерләр. Тагын шунысы бар—әлеге түрәләр бу гамәлләрен хөкүмәт исеменнән эшлиләр. Самитның «Властька каршы барасыңмы? Әле син шулай хөкүмәткә каршымыни?!» дигән сүзләреннән дәһшәтле 37 еллар исе аңкып тора. Әсәрдә Самит, Хөлли Кәлиевич, аның улы Руслан кебекләрнең чын йөзләрен, әхлакый түбәнлекләрен ачуга киң урын бирелсә дә, үзәктә Мәрьямбану әби язмышы тора. Ике бала үстереп, аларны чын кеше итә алмадым дип борчыла ул. Улы Габдулла эчүчелеккә сабышкан, 17 ел инде әнисе янына кайтканы юк, хәтта хат та язмый. Кызы исә, кияве Хөлли белән бер булып, әнисе сүзенә колак салмый.

Драмада бер йорт турында гына сүз барса да, мәгънә күпкә киң. Әлеге матур бизәкле, борынгы осталар тарафыннан салынган йорт ул—милләтебез, аңа хас булган матур сыйфатлар; йорт ул—безнең ата-бабадан килгән яшәү рәвешебез, гореф-гадәтләр, традицияләр; йорт ул—буыннар арасындагы бәйләнеш, васыять итеп тапшырыла торган изге теләкләр, тәрбия чаралары; йорт ул үзара ярдәмләшүгә нигезләнгән мөнәсәбәт, кешене кеше иткән әхлак сыйфатлары. Кешеләргә ярашып, яхшатлы булып матур сүзләр сөйләп йөрүчеләр нәкъ менә әлеге изге әйберләргә, төшенчәләргә кизәнәләр, аларны аяк астына салып таптап, халыкны «кызыл прәннек» белән алдалап, манкортка әйләндерергә телиләр. Моны бит чит-ятлар эшләми. Харитон сүзләре белән әйткәндә «Ятлар туздырганда бер хәл... Үзеңнекеләр туздырганда бу инде чыннан да куркыныч». Һәм өстәргә кирәк—кызганыч та. Шуңа күрә Мәрьямбану әбинең үлеме дә фаҗига буларак кабул ителә. Хәйлә юлы белән әлеге йортта ике бүлмә алган Самит кайчандыр урлап алып кайтып баскыч ярыкларына такталар кадаклаган булган икән (шунысы да бар: әлеге адәм актыгы ике ел яшәгәне өчен әбигә бер тиен акча түләмәгән), качып киткәндә ул шуларны кубарып ташлый. Мәрьямбану әби абынып егыла һәм такталардагы кадакларга бәрелеп башын тишә. Җан газабы аша болай да әбине рухи үлемгә китергән кеше исемен йөртүче бу бәндәләр, аның якты дөнья белән саубуллашуына да сәбәпче булалар.

Вакыйгаларның тормышчанлыгы, интонацияләрнең ачыклыгы, публицистик рухы белән «Нигез туздыручылар» драмасы әдипнең уңышлы әсәрләреннән берсе булып тора.

Драматургның «Ни булган бу ирләргә?» пьесасы җыентыктагы башка

әсәрләреннән аерылып тора. Эш шактый үзенчәлекле исемдә генә түгел. Автор төрле төбәктә, җирлектә үсеп, төрле тәрбия-белем алган кешеләрне очраштыра: 40 яшьлек Картлач—берейтор, ягъни кыргый хайваннарны, җәнлекләрне буйсындыручы, кулга ияләштерүче (ялгышмасам, мондый сәер профессия кешесе безнең драматургиядә беренче тапкыр); 24 яшьлек егет—Рафаэль Ленинградта туып-үсеп, Мәскәүдә белем алган; 28 яшьлек Касыйм да Себер якларын гизгән, ә 17 яшьлек Сөембикә исә яңа гына авылдан килгән. Егетләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, эш-гамәлләрен бәяләүче булып авыл кызы тора. Тормыш тәҗрибәсе дә булмаган, шактый беркатлы Сөембикә үзенең эчкерсезлеге, сафлыгы, бай әхлагы белән кулыннан күп хайван-җәнлекләрне генә түгел, байтак хатын-кызларны да үткәргән Картлачка каршы тора ала. Ул—Рафаэль сүзләре белән әйткәндә, «атаклы берейторның муенын сындырган нәни тай». Әсәрдә «кем кемне» дигән тартыш бара. Картлач, берничә ел элек, йомшак табигатьле Касыймны үзенә буйсындырган һәм аның яраткан кызы Гөлинәне җәберләгән. Егет әлегә кадәр берейторның теләгенә каршы килә алмый. Тормышта үзе теләгәнне эшләргә гадәтләнгән Картлач бу юлы Рафаэль белән Сөембикәдә үз алымын сынап карый, ләкин югарыда әйтелгәнчә житди каршылыкка очрап, качып китәргә мәҗбүр була.

Пьесаның буеннан-буена драматург куйган сорауга җавап эзләнә: бу ирләргә ни булган? Ни өчен берәүләр башкалар ихтыярына тиз бирелеп, алар кулында уенчыкка әверелә, ә икенчеләр исә кешене түбәнсетү, кимсетүдән, буйсындырудан тәм таба? Әлеге сораулар һәрберебезне үз тормышына, әйләнә-тирәсенә игътибар белән карарга этәрә. Үзебез дә еш кына горурлыгыбызны җуеп, кемнәрнеңдер теләген үтәргә мәҗбүр булабыз түгелме? Шомарган, оста «буйсындыручылар» кулындагы мескен, ихтыярсыз «тай» булмасак иде—язучы әйтергә теләгән төп фикер әнә шул.

Әсәр интеллектуаль пьесага якын, анда шактый житди фикер көрәше бара. Шул ук вакытта вакыйгаларның тоныграк булуы, драматик хәрәкәтнең житенкерәмәве дә сизелә. Пьеса жанрын трагикомедия дип күрсәтү дә бәхәсле кебек, ул драма кысаларыннан чыкмый. Дөрес, пьеса режиссер күзаллавы буенча сәхнәгә куелганда жанр үзгәрешләре дә кичерергә мөмкин. Автор, күрәсең, спектакльне трагикомедия итеп күрсәтүне кирәк дип саный. Бу уңайдан шуны да искәртеп китәргә мөмкин: «Пар канат»ның жанрын драматург «драма» дип билгели, ә спектакльгә язган рецензиясендә Н. Ханзафаров «трагикомедия»гә тартым дип күрсәтә.

Пьесаларда куелган мәсьәләләрнең социаль-әхлакый яңгырашы, аларның хәл ителеше әсәрләрнең тулаем сәнгатьчә эшләнеше белән тыгыз бәйләлектә тора, шуңа да авторның уңышлы табышларын күрми мөмкин түгел. Язучы үз әсәрләренең жанр үзенчәлеген ачык сиземли, аларны оста итеп сәхнә закончалыкларына нигезли, шуның белән режиссер һәм артистларга спектакльне эшләүне жиңеләйтә.

Драматургның тагын бер үзенчәлеге—геройлар сәхнәдә күренгәнче үк аларга башка персонажлардан бәя бирдерү. Ә бу исә еш кына әсәрдәге каршылыкны көчәйтә, драматизмны тирәнәйтә. «Пар канат» драмасында ире Ибраһим «овчарка» дип атаган Зәйнәп апа заман алып килгән «авыруларга» каршы тора алмаудан аптырап калган, әмма «гомере буе бөртекләп җыйган изге нәрсәләрне таптатмаган» саф күңелле ана булып ачыла.

Ю. Сафиуллин әсәрләренә публицистик эчтәлек хас. Пьесада барган бәхәс артында һәрвакыт автор үзе сиземләнә. Ул персонажлары аша укучыга эндәшә, аны кисәтә, нәрсәгәдер өнди, ваемсызлыктан арынырга чакыра. Сюжет эчтәлегенә, нигездә, уңышлы бәйләнеп киткән бу күренеш әсәрләрдәге психологик киеренке халәтне, хис-кичерешләр ташкынын укучы-тамашачыга аңларга ярдәм итә.

Шулай итеп, «Пар канат» җыентыгы Ю. Сафиуллинның татар сәхнә әдәбиятында үз урыны, үзенчәлекле урыны бар икәнен тагын бер кат раслый. А. Гыйләжев әйткәнчә, үзе дә «пакъ кеше, ак кеше...» булган шәхес Кеше дигән олы зат өчен, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен тирән борчылып яза.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*Казан дәүләт университеты доценты*

# ЯКТЫ САГЫШ

Бу китапның авторы—соңгы еллар татар әдәбиятының проза жанрында бик актив эшләүче аз санлы әдипләрнең берсе, араларында хәтта «ин-ин» диярлеге—Зәки Зәйнуллин. «Ник ямансу бу күзләр?» дигән шәп һәм матур җыентыкны 1998 елда, басарга кул куелганнан соң ике ел гына тотып, Татарстан китап нәшрияты чыгарган. Китапка бу сагышлы исем Сажидә Сөләйманованың шигырь юлларыннан алынган. Җыентык шул исемдәге бәләкәй эссе белән тәгәлләнә.

Соңгы еллар янарышы татар әдәбиятында да эссе жанрын җанландырып җибәрде. Безнең буын укучысы үзенә ят диярлек булган «эссе» төшенчәсен иң элек Владимир Чивилихинның «Память» әсәрендә күргән иде шикелле. Нәкъ шул елларда мәрхүм халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев, укучылар белән очрашкан чакларда, уйлап чыгарылган социалистик реализм геройларына тискәре мөнәсәбәт күрсәтеп сөйли башлады. Язучы вакыйганы һәм әдәби геройны уйлап чыгарырга түгел, үзе нәрсә күрә, нәрсә кичерә—шуны язарга тиеш, бүтән илләрдә нәкъ шулай итәләр, дия иде ул. Һәм үзе нәкъ шулай яза да башлады. Инде «үзе нәрсә белә, нәрсә кичерә» жанрына Әмирхан Еники, Марсель Гали, Миргазиян Юныс матур-матур әсәрләр бирде.

Эссеның җанлануы әдипләрнең үз үткәннәренә, яшәү мохитенә, кичергән вакыйгаларга, милләтебезнең узганына һәм бүгенгесенә мөнәсәбәтен белдерергә теләүдән, тирәнрәк фикерләргә омтылудан киләдер. Элек «уйлап чыгарып» язган әсәрләрендә ул мөнәсәбәт сизелми калган булырга да мөмкин, чөнки әдипнең шәхси кичерешләре беркемне «кызыксындырмый» иде. Инде менә—уйлы әдәбият җанлана. Әмма Зәки Зәйнуллинның мона кадәрге күп әсәрләрендә дә аның шәхси «мин»е ялтырап күренеп тора, сурәтләнгән вакыйгаларга авторның мөнәсәбәте ярылып ята. «Полковникны озату» исемле документаль повесть турында әйтәсе дә юк (анда вакыйгалар турыдан-туры Зәки Зәйнуллин исеменнән сөйләнә), «Танк училищесы»ндагы һәм «Ракета полигоны»ндагы Зиннурдан да, «Ат караклары» романындагы Зөфәрдән дә автор тормышына һәм кичерешләренә тәңгәллекләрне күп табарга була. Менә шушыларны бер дә кабатламыйча, тагын бер эссе да язу өчен әдип күнелендә бөтенләй яна тема йөрергә, үзгә фикер туган булырга тиештер. Нәрсә ул? Эссеның исеменә карагагда, Әмирхан Еникиның «Кояш баеганда», Миргазиян Юнысның «Соңгы сулыш», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү» кебек әсәрләренә эчке бер аваздашлык та сизелер сыман. Чынлыкта да шулай түгелме?

Юк икән, шундый якты сагыш белән язылган бу әсәр... шигырь хакында икән. Менә гади сурәт: автор очраклы гына кулына эләккән «чуар тышлы» шигырь китабын кибетнең буш залында урта бер җиреннән ачып укый башлый да, аерыла алмый тора. Рухсызланып, шигырь уку ләззәтеннән, матурлык тойгысы кичерүдән, соклanудан һәм күнеле нечкәрүдән үз-үзен мәхрүм иткәннәр аңлый да алмаслар аның бу бәхетен, әмма автор ул хакта уйларлык түгел. Кулындагы шигырьләр—Сажидә Сөләймanованыкы. Ике юлын укуга «йөрәкнең әллә кайсы бер җире селкенеп куя». Шулардан сүз ялганып Дәрдмәнднең шигъри энҗеләре дә телгә алына. Ике шагыйрьдән берничә генә юл. Эссе авторы аларны мактап бер сүз әйтми, әйтә дә алмый, чөнки Дәрдмәнднең үзеннән дә уздырып нәрсә әйтергә мөмкин? Ул бер мизгелдә шагыйрь тойгылары яши генә. Шул тойгылар җирлегендә азга гына үз тормышын, яшәү рәвешен, туган авылы кешеләрен күз алдына китерә, шагыйрә белән институтта дүрт ел бергә укып, аерылышкач, аның хатларына вакытында җавап бирә алмаган Рәшидә апасы хакында сөйли. Рәшидәнең бердәнбер хаты язылганда инде соң була. Күзләребез менә нилектән ямансу безнең! Гомеркәйләребез якын дуска да сөйләп-язып булмый торган фаҗигаләр, үкенечләр белән тулы, яшәү рәвешебезгә үзебез дә төшенерлек түгел. Кешеләр арасында яшәсәк тә, күбебез ялгызлар безнең, бикле күнелләребез белән аулак почмакларга посканбыз, дуслардан да яшеренгәнбез. Ваклandык, җаныбыз куырылды. Бөекләребезне дә ике арага кабер тирәнлеге кадәр җир катламы сузылып яткач кына «күрә» башлыйбыз. Өр-яңа мисал: мәрхүменнән соң бер-ике айда җырчы Хәйдәр Бигичев исемен шулкадәр күп ишеттек, исән чагында гомере буена да аның кадәр кабатлана алмагандыр. Ә бит бөтенесе гадәти, барысы да үзебез күнеккәнчә. Узынып, кемнедер узып китә күрмәсен дип,

олы шәхесләребезгә исән чагында белдерергә курыккан жылы мөнәсәбәтебезне салкын каберләр өстенә сибәбез, каршысында дер калтырап, өн чыгарырга базмаган хакимнәребезне каберендә тыныч ята алмаслык, электәге карусызлыгыбызның үкенече калмаслык, безне табаны астында тотуының үче кайтырлык итеп яманлыйбыз, жаныбызны бер газаптан икенчесенә салабыз... Дәрдмәнд, Сажидә Сөләйманова кебекләрнең чын шигырьләре жирлегендә тугангадыр, бу уйлар жаннарны айкап, үзәкләрне өзә.

Зәки Зәйнуллин эссесын укыгач туган шундый бер фикер күңелгә утырып кала—чын шигырь һәм шагыйрь хакында менә шушы әдипчә генә язарга кирәк. Бүтәнчәсе—язык, нечкә жаннарны рәнжетү генәдер. Ә бит кайбер эссены яки каләм иясе турында соңгы елларда артык күбәеп киткән мәзәкләрне уку белән эсселе-суыклы буласың. Бу әсәрендә Зәки Зәйнуллин үзе дә бүтән: «Полковникны озату»дагы автор белән аны чагыштырырлык та түгел—офицер турылыгы да, холкындагы хәрбиләр кырыслыгы һәм жинүче дуамаллыгы да сизелми монда. Шигъри һәм табигый тема әдипне үзгәрткән дә куйган! Биредә аның рухи халәте, күңелендәге моны-сагышы үзе сөйли торган шагыйрьләрнеке, табигать балаларыныкы белән тиңләшеп-тигезләшеп беткән. Куанычлысы шушы гына да түгел: әдипнең бу китаптагы бүтән әсәрләре дә шагыйранә моң белән язылган. Чөнки алар бөтенесе дә авторның газиз туган ягына, аның гажәп кешеләренә багышланган. Зәки Зәйнуллин боларның бөтенесен шулкадәр яратып, үз итеп тасвирлый, үз араларында шушындый игелекле әдип үстерә алган халыкның үзе дә игелекле һәм киң күңелле булуына тәмам ышанасың, гап-гади жир кешеләренең шул бәхетенә кызыгып та куясың.

Китап «Үрләр аша» исемле жыйнак кына повесть белән ачыла да «Каршы таулар» дигән зуррак повестьта дәвам иттерелә. Каршы тау, каршы жил—халкыбыз узган күп михнәтле тормыш юлының гап-гади алты хатыны шундый тауларны ничек уза—беренче әсәре әнә шул хакта. Хәер, повестьта ул хатыннар кичкән михнәтле тормыш юлының өч-дүрт көне генә сурәтләнә. Иң авыр көннәре дә түгел бу. Ике явызның—Сталин белән Гитлерның—миллион-миллион жаннарны тартачак сугыш тегермәне әйләнә генә башлаган, ирләре дә шул мәхшәргә әле китеп кенә бара, кот алгыч ачлыгы да, үзләренең толлыгы һәм балаларының ятимлеге дә, үз халкына каршы корылган ил сәясәтеннән күрәчәк жәберләре дә алда әле. Зиреклебашның унсигез ире август аеның бер көнендә немецларга каршы сугышка чыгып китәләр дә, Краевка дигән станциядә тукталып, хәрби өйрәнүләр узган рәвеш китереп яталар. Алтысының хатыны аларны соңгы кат күреп, иркәләп һәм иркәләнеп, үз кулларыннан туйганчы бер ашатып калу өчен ризык тулы арба тартып авыр юлга чыккан. Колхоз рәисе Кави абзыйдан ат сорап караганнар иде дә, кая инде ул—авылда урак өсте, ә атларның рәтлесе һәм ирләрнең күбесе инде фронтта. Уракчы хатыннарны да жибәрмәс иде әле, һәр сәгатьләре исәптә.

Алты мосафирда алты уй, алты моң, ә барысыныкын бергә кушсаң Сталин хакимлек иткән «бөек чор» хатыннарының уртак язмышы чагыла. Әмма чордашларының тауларга каршы юлын елау-сыкрау белән генә тасвирласа бу әдип Зәки Зәйнуллин да булмас иде. Мескен итеп сурәтли алмый ул авылдашларын, моның өчен авторның үзенә дә бар булмыш халәтеннән күпмедер тәбәнәкләнергә туры килер иде. Бүтән әсәрләрендә һәръяктан көчле Зиннур Булатовны язып оптимист заряды алган әдип моңа бармаячак инде. Әнә арбаны этешү урынына, күбрәк төенчекләр янында утырып барган гарип Рәйхана да Краевкага житкәч ире Миңлебай янына үз аяклары белән атлап барырлык көч таба. Ә тагын ике көн узгач, ирләрен фронтка озату ыгы-зыгысында, автор аны болай сурәтли: «Иң арттан иненә ике зур капчык аскан, кулларына ике төенчек тоткан Рәйхана титаклый иде. Тыңламаган чатан аягына чыккан ачуын ике күзеннән атылып чыккан күз яшьләре белән юарга тырышып атлый иде ул».

«Каршы таулар» повестенда Зиреклебаш ирләренең фронт юлы тасвирлана, аларның күзаллаулары, истәлекләре белән бергә автор безне еш кына Зиреклебашка, сугышчыларның гаиләләре янына да «алып кайта». Сугыш картиналарын сурәтләгәндә нечкә күңелле, шигырь жанлы әдип белән янәшә үк язучы-полковникны һәм милләт каһарманын таныйбыз. Татарларның бу сугыштагы урынын шулкадәр ачык, табигый, ышандырырлык итеп һәм... борчылып тасвирлый алган әдипләребез күп түгел безнең. Биредә әсәрнең табигыйлеге һәм ышандыру көче—вакыйгаларның автор якыннан белгән, үз иткән реаль кешеләр аша сурәтләнүендә.

Урыс иле бәрелешләрендә сугышчыны, үлемнән тыш, гадәттә, тагын ике зур фажига, ике каршы тау һәрвакыт сагалап тора: уйламаган боерык, булдыксыз командир. Шуна күрә корбаннарыбыз да каршы яктагыдан һәрвакыт күбрәк була. Андый командир, үзенең булдыксызлыгын каплау өчен, теләсә нәрсәгә барырга мөмкин. Солдатларны коралсыз-нисез күрәләтә үлемгә куарга, ялганга, мәкергә... Зәки Зәйнуллинда да бар андыйлар—иблис токымнары. Сугыш

җиһаннәмендә дә исән калып, инде тагын да үрчеделәр. Корбаннары—хәйлә белмәгән гади халык, Рәйхана белән Миннебайларның уллары һәм оныклары. «Каршы таулар»ны укыйсың, ышанасың һәм менә нинди шартларда, нинди «гадел көрәш»ләрдә югалып беткән безнең авылдашлар, дип уйлыйсың. Күбесе сугышның беренче айларында ук, дошманга каршы үзе теләгәнчә сугышырга да өлгермәгән килеш, шәһит киткән, хәбәрсез югалган. Авыл исеме китаптагыча Зиреклебашмы, Зәки Зәйнуллинның туып үскән Эстәрлебашымы, Казанбаш, Ашытбаш, Кенәбашлармы—барысының асыл ирләрен бердәй язмыш кырган. «Каршы таулар»дагы Гыйният язмышы—иң аянычлысы һәм... иң табигыйдыр. Унсигез ир арасында иң көчлесе, иң җор сүзлесе, кыю һәм тәвәккәле ул. Командиры булган кеше, әйтик, лейтенант Прохоров, аның бу асыл сыйфатларын дошманга каршы сугышта акыл белән файдаланып җиңүгә эшләтергә, кул астында шундыйлар булуны бәхеткә санарга тиеш иде дә бит. Әнә батальон командиры капитан Азволинский да «Бу солдатлар синең терәгең булырга тиеш» дип тора. Тик тәкәббер Прохоров астыртын һөҗүмгә күчә: «смерш»чылар кулы һәм мәкер белән Гыйниятне юк итә. Һәм монда безнең «бөек» ил чынбарлыгы өчен гайре табигый берни дә юк: җиңү бит чынлыкта менә шушы Гыйниятләргә, ирләребез исән-сау кайтып, авылдагы эшне җиңеләйтерләр, гаделсезлекләрдән яклар, дип көткән Рәйханаларга гена кирәк. Прохоровлар исә илгә нинди власть килсә дә өстә калу, файдалану җаен табачаклар. Сталинга да ярагannар, Горбачевны да һәм ана каршы оешкан ГКЧПны да чәбәкәйләп каршыладылар, Ельциннан да куанып бүләк алалар. Хәтта Гитлер да, СССРны җиңә калса, бу яңа биләмәсендәге халык өстеннән хакимлек итәргә Сталиннан шәбрәкне таба алмаячак иде. Ә Гыйниятнең хатасы—әнә шундый һәр ибликкә буйсына белмәүдә, куркусызлыгында, власть вәкиле каршында җебеп төшмәүдә, үзен бәйсез кеше итеп тоюда. Зиннур Булатовның рухи туганы ул. Прохоровның гасабиләнеп үз солдатларына каршы күтәрелгән пистолетын кулыннан кысып төшерә Гыйният. Шуның белән ул Прохоров өчен фашист солдатыннан да явызрак дошманга әверелә. «Бунт! Бунт!»—дип буыла-буыла кычкыра лейтенант. Әле генә хәтәр задание үтәп кайткан кыю разведчик өстеннән казына башлыйлар һәм шуны ачыклыйлар: Гыйниятнең әтисе ярлы көтүче Гобәйдулла Папай 1937 елда Уфа төрмәсендә атып үтерелгән икән. «Большевиклар ат каракларыннан да яман халык» дигән сүз өчен. Гобәйдулланың «кәфер» сүзен ана каршы кансыз гамәлләре белән әнә шулай тагын бер раслыйлар. Гыйниятка карата кылган мәкерләре белән дә җөпләп куялар. Тик алар үз эшләренең асылын аңларлык хәлдә түгел. Һәммәсен карусыз буйсындыру, мингерәү чигендә фикерсезләндерү—менә нәрсә мөһим аларга. Оккупант түрәләр холкы. Большевизмга гына хас сыйфат түгел бу, тамырлары тирәндәрәк. Фронтта алар хуҗа, күп солдат язмышлары алар кулында, уйлаган этлекләрен эшләми калмыйлар. Моны Зәки Зәйнуллин гына язмый, Бөек Ватан сугышы хакында иң яхшы әсәр дип бәяләнгән Константин Симонов трилогиясендә дә особистлар шактый эш майтаралар. Шулкадәр зур мөмкинлекләре, «уяулыклары» белән үз ватандашларына, армиянең иң сәләтле командирларына, фикерле зыялыларга, Гыйният тәй кыю солдатларга каршы түгел, чын дошманга каршы көрәшсәләр, илнең фаҗигаләре чагыштыргысыз кечерәк булыр, без дә күптән җиңүче халыкка хас тормыш белән яшәр идек. Әмма чын дошман хәтәр, аның белән бәрелештә башсыз калуың да бар, шуңлыктан күбесе үз батырлыгын «эчке дошманнар»—шушы ил, шушы «яклаучылар» гаебе белән менәрләп-менәрләп немецларга әсир төшкән һәм «азат ителеп» үзебезнең лагерьларга күчерелгән сугышчылар, фашислар табаны астында калдырылып айлар буе мәсхәрәләнгән өнсез халык, ятимнәнә кырдан бер кисә арыш урлаган уракчы хатынга күрсәтү җаен карады, «бүген авылда да фронт» дигән сүзне шулар уйлап чыгарды. «Каршы таулар»да Прохоровның Зиреклебаштагы чагылышы—милиция башлыгы Агишевның сөяркәсе финагент Чолык Зәйнәбе. Шушы явызның мәсхәрәсенә түзә алмыйча, Гыйниятнең хатыны дүрт сабыен ияртеп авылдан чыгып кача. СССР—үз илендә качак булып яшәүчеләр ватаны.

Финагент Чолык Зәйнәбе—Зәки Зәйнуллинның бер әсәреннән икенчесенә күчеп тәмам шомарган, аннан бер карыш та аерылмыйча ээзәрлекләп килгән, камил дәрәҗәдә «яратып» сурәтләгән каһарманы, явызлык символы. Ул «упалнамучен» булып килгән «гучмуй март» колхозында аны бер генә кеше дә яратмый, хәтта икесе бер йөкне тартырга тиеш булган председатель Кави да ана «Синең начальник НКВД белән уйнаш иткәнеңне бөтен авыл белә»—дип ярып сала. Анысына ук ышану да кыен хәтта. Казан тирәсенең Явыз Иван башкисәрләре тарафыннан кат-кат тукмалган, чукындырылган, каһәрләп һәм юмалап умырткасыз калдырылган, диненнән дә яздырылып әхлаксезлеккә батырылган халкы арасыннан бер генә Кави да дәһшәтле райком вәкиленә мондый сүзне

әйтә алмас кебек. Әйтерлек кешене колхоз рәисе дә итмәсләр иде. Ләкин әсәрдәге Кави да—Зиреклебашныкы шул! Күнелендә таулар горурлыгын һәм далалар иркенлеген саклый алган кешеләрне анлау кыенрак безгә. Зәки Зәйнуллинның үзен дә «үзләштереп» бетергән юк. Шундыйлар белән Казан арты татарлары арасында рухи күпер корырга теләгәндәй, автор бу китабын әдип дусты Фәрваз Миннуллин истәлегенә багышлаган.

Әйе, «упалнамучен»га туры сүзен әйтә алган Кави—Зиреклебашныкы, һәм Чолык та райком каршында рәисне эштән алу мәсьәләсен күтәргәндә, анын «шушы авылныкы» булуын зур сәбәп итеп күрсәтә. Чыннан да, колхоз яки район белән шул төбәктә туып-үскән, халыкның үз баласы житәкчелек итүне ил режимы бервакытта да кичерә алмады. Һәр төбәк, һәр хезмәт коллективы башына бәләкәй генә булса да оккупант, басып алучы, халыкны карусызлыкта мактый-мактый буйсындырып тотучы, ә аларнын хезмәт нәтижәсе белән читләрне балда-майда йөздерүче кирәк властьларга. Андый түрә тирә-ягына, кинәш-табышка да үзенә охшашларны гына жыя, чөнки Гыйният кебекләр янында Прохоровнын чикләнгәнлеге ачык күренеп торыр иде. Аларның холкын Зәки Зәйнуллин төгәл тотып алган.

Әмма, беркем яратмауга карамастан, Зәйнәп ялгыз да, көчсез дә түгел. Көче—күзгә дә күренми торган системада, шәфкатьсез жәмгыятьнен кан тамырларында. Шуна да бик яшәүчәннәр алар. Һәм нәкъ шунлыктан Зәки Зәйнуллин әсәрләренә кат-кат әйләнеп керәләр. Әдипнен кисәтүедер бу безгә. Тик менә илдәшләрнен китап укымый торган яна буыны анларммы аны? «Пушкин кирәкмени ана, Пугачев кирәк!»—дип язган Зөлфәт мен кат хаклы бит.

Зәйнәпләргә каршы як та буш түгел. Анда реаль шәхес Гали Тукай. Анын да «яшәү мөхите» әдипнен бер генә әсәре белән чикләнми. Нәселдән килгән муллалыгын ташларга мәжбүр ителсә дә, халыкка мәгърифәт нуры, яктылык һәм миһербанлык таратудан туктамый. Кайдан анын бу көче һәм иманы, Урал туфрагыннан һәм Эстәрлебаш мәдрәсәсеннән генәме? Ә бит анын бабасы Урманай мулла улы Тукай, урысның көчләп чукындыруыннан качып, унжиденче гасыр азакларында хәзерге Татарстаннын Балтач төбәге, Салавыч карьясыннан күчеп килгән. Бу хакта Шиһабетдин Мәржанинен «Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» китабында да мәгълүмат бар. Салавыч—«Керәшен татарлары сөйләшләрен этнолингвистик яктан өйрәнү» дигән темага докторлык диссертациясе яклаган Флера Сәет кызы Баязитованын туып-үскән авылы. Чукындыруның тарихын да, нәтижәсен дә кат-кат өйрәнәсе әле. Зәки Зәйнуллин үз каһарманынын Зиреклебаш-Стәрлебашны тан калдырган сыйфатларын мавыгып яза торгач, Салавыч яклары, андагы чукындыру вакыйгалары белән кызыксынмыйча кала алмады һәм бу төбәктә беренче булып, «Шушма буйларында» исемле тарихи әсәр ижат итте. Эш, бәлки, кызыксынуда гына да түгелдер. Гали Тукайдай иманлы жаннарны тирәнрәк анлау әдипнен дә рухын ныгыта, кыйбласын ачыклыйдыр. Галинен образ буларак эшләнүе барыбер дә Чолык Зәйнәбенекенә житми әле. Автор моны үзе дә тоя. Тукай бабай токымын кайта-кайта өйрәнүе дә шуннандыр.

Әсәрнен азагына таба без Чолык Зәйнәбе белән тагын очрашабыз. Ташкент якларына барып урнашкан да, остазбикә булып, мәжлесләрдә Коръән укып йөри Зәйнәп. Тормышта мисаллары күп булган мондый финал уйландыра да, ышандыра да. Бу ярый бит әле, ни дисән дә Гали Тукайлар изге кыйбладан тайпылмаган, ә имансыз «упалнамучен» дин юлына баскан, дип юанырга да була. Тик менә иблислекнен кирәк чакта кыяфәт үзгәртеп булса да яшәүчәнлеге... Шунын тормышыбызда гел чагылып торуы һәм безнен андый күренешләргә карата «классик» ваемсызлыгыбыз, чын белән ялганны аера белмәвебез... Әдипләр мондый гыйбрәтләрне кем өчен кайта-кайта язалар икән сон?

Зәки Зәйнуллинны күбрәк укыган саен анын сурәтләү осталыгын таный барасын. Үз каһарманнарынын аерым бер вакыт арасындагы халәтен, холкын ачу өчен ана кайвакыт бер-ике сүз, бер деталь житә, жорлыгы да ярдәм итә. Чолык Зәйнәбенен колхоз исемен «Гучмуй март» дип сөйләве, мескен хатыннарның бичара сыерларын жигеп жир сөрүен «передовой опыт» дип яклавы анын кемлеген ача да бирә. Шушындый сүзләре аша гына да үз арабыздан ничә Чолыкны таный алабыз. Ул авылда Гыйният хатынын сүккәндә «Синен ирен бизвисте пропал. Бәлки илен сатып, безнекеләрне атып йөридер»—дип кычкыра. Сүзләр искиткеч нечкә сайланган. «Илебезне» дими Чолык, «илен» ди, «үзебезнекеләрне» дими, «безнекеләрне» ди. Чөнки Зәйнәпләр Прохоровлар үзләрен бүтән илдә, аерым мохиттә яшибез дип исәплиләр, берниләрен дә Гыйниятләр белән бүлешергә теләмиләр, аларны иш-итмиләр. Бу ил—аларныкы гына! Ирләренен яшь гомерләре, үзләренен сәламәтлекләре, балаларынын ятимлеге бәрабәренә яуланган жину шатлыгы да тылдагы Рәйханалар өчен түгел. Повестьнын бер каһарманы дөрес әйткән: жину килгәч СССР дигән илгә маршал

Жуковларның да кирәге калмады. Татарстанга азмы-күпме мөстәкыйльлек алгач, бу эшне башлап йөргән милләтчеләр дә кирәксезгә әйләнде.

Әдипнең тел осталыгы, билгеле, Чолык Зәйнәбен төгәл тасвирлау белән генә чикләнми, китапта Зиреклебаш-Стәрлебашның һәр кешесе нәкъ үзенчә генә, үзе булып кына ачыла. Кайчак бик урынлы бер генә сүз дә әсәр каһарманының эчке дөньясын анларга ярдәм итә. Менә бер бәрелештә Зиреклебашлар ике немец солдаты эләктерәләр. «Стреляйт нет. Найн. Я ес рабочий, арбайтер»—дип ялына берсе.

—Атла, рабучий. Безнең Миңлебай да алпавыт түгел иде,—ди ана Басыйр. Чөнки шушы бәрелештә дүрт балалы Рәйхананың ире Миңлебай дошман белән сугыша-сугыша һәлак булды. Күз алларында да, күңелләрендә дә шул авылдашлары гына. Сөйләмгә «Миңлебай» исемен кыстырып, автор аларның күңелен ачып бирә.

Унсигез ирдә унсигез асыл сыйфат, һәм әдип алар хакында язып һич ялыкмый, укучыны да ялыктырмый. Менә Сәйфулла белән Басыйр авылдашлары Учак Сәләхенең снаряд өзгәләгән гәүдә кисәкләрен капчыкка җыялар. Әйберләре эченнән дугага бәйли торган ике кыңгырау килеп чыга. Тыныч кебек эшләп маташкан Басыйр әнә шул кыңгырау чыңына үксеп җибәрә:

—Сугышка чыгып киткән көннән алып атлар сагынып тилмерде Сәләхетдин. Артиллерия атларын соңгы кисәк икмәге белән сыйлар иде, мәрхүм. Бу кыңгырауларны Зиреклебашка алып кайтып житкерү өмете белән йөрткән инде ул, бахыр,—ди Басыйр.

Без болар хакындагы—Стәрлебаштан, Шушмабаштан, Карадуганнан... киткән ир-егетләрнең ничек сугышулары, күңелләрендә ни йөртүләре, нинди шартларда һәлак булулары турындагы китапларны күптән укырга тиеш идек бит инде. Сугышта катнашучыларны батырларга һәм куркакларга, исәннәргә һәм шәһитләргә генә бүлә беләбез, ә алар һәркайсы жанлы бер кеше булган ич! Кечкенә-кечкенә авылларыбыздан да утыз-кырык-илле ир сугышта ятып калган, хәбәрсез югалган. Ә бит һәр шәһитнең, һәр хәбәрсезлекнең—үз тарихы, үз фажигасе! Зәки Зәйнуллин язган унсигез ир арасында безнең авылдашларга бик-бик ошаганнары да бар. Димәк, әсәр—барысы хакында.

Сугыш турында язамы, әллә, «Урам» повестендагы кебек, үз авылдашларының гап-гади, гөнаһлы тормышын дастаннар югарылыгына күтәреп тасвирлыймы, Зәки Зәйнуллин үз әсәрләренә татар тарихыннан мәгълүматлар кертеп җибәрергә ярата. «Ат караклары»нда тарихи публицистика урыны-урыны белән озынгарак сузылып, әсәр тукымасыннан чыгып-чыгып та киткәндәй була, романның укылышын акрынайта. Ә менә «Атом полигоны»нда тарих укытучысы хохол Аркадий Петрович сөйләгән кызыклы мәгълүматлар Зиннур Булатовның әсәрдәге баш каһарман буларак рухи үсүенә булышучы бер деталь булып урынлы һәм жиңел кабул ителә. Ә мәгълүматлар чынлап уйландырырлык: Хохмыжск шәһәре чынлыкта Котмыш-Кала икән һәм ул татарча «кетмеш» сүзеннән, имеш. «Воронеж—«бармыш», «Харьков—»Шәрә күн» сүзеннән, анда күн әйбер күп эшләнгән. Укытучының сөйләвенә караганда, элек өчесе дә татар шәһәрләре, тирә-ягы—татар жирләре булган. Милләтебезнең үткәнен без белгәннән зуррак, бөегрәк итеп күрсәтүче мондый мисаллар «Ник ямансу бу көзләр?» китабында күп очрый. Аларны бердәнбер дөрес дип уйларга, әдипнең мондый ачышлары тарихыбызны мона кадәргедән чынрак итә дип расларга жөрьәт итмәгән тәкъдирдә дә (безнең чын дигәнебезгә башкалар ничек карар?), аларның әһәмиятен әйтми калу килешмәстер. Әсәрдән-әсәргә теле, сурәтләү осталыгы камилләшә барган әдипнең язганнарына ышану да арта, һәр яңа китабы өметне үстерә. Әле көз ямансулыгы да шигырьдән вакытлыча гына килгәндер аның каләменә.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,**
*Балтач*

❄

*Юмор һәм сатира*

# Илфак Шиһапов

## Комган белән самавыр

Алар элек бер йортта тату гына яшәделәр. Тик заманалар буталгач, озак вакыт берсен-берсе югалтып тордылар. Бүген исә аларга тагын очрашу насыйп булды. Кайда диген әле. Элекке кебек мич алдында да түгел бит—ярым җимерек трактор арбасында. Бу арбага аларның икесен берьюлы ыргыттылар. Бераз вакыт һушын югалтып торгач, комган беренче булып аңга килде. «Их, заманалар!»—дип уфтанды ул, үзенең келәт почмагында ятып каралып беткән җиз түшләренә карап—«Үтте шул, үтте безнең кадерне белгән заман». Шулчак аның күзе, үзе белән янәшә яткан, борыны кыйшайган, яшькелтләнеп беткән самавырга төште. «Кара, бу минем кордаш-чордаш түгелме соң?»—дип уйлады комган.—«Шул бит, шул үзе. Кара, ничек ямьсезләнеп беткән. Ә бит өстәл түрендә кукраеп утырганда нинди чибәр иде. Безнең ише кара халыкка өстән генә карый иде бит ул чакта». Комган ничек кирәк шулай кузгалып, җиз самавырның бөеренә төртте. Тегесенең аңы бар иде, ахры—ыңгырашып куйды.

Бераздан комган белән самавыр трактор гөрелтесен дә күмеп, чынлап сөйләшеп баралар иде инде. Самавыр башта комганны танымыйчарак торса да, бераздан исенә төшерде. Ни дисәң дә, озак еллар бер йортта тордылар бит.

—Их, комган туган,—диде самавыр, ямшәйгән борынын турыларга маташып. Бар иде безнең дә адәм балаларына кирәк чаклар. Утыра идем бит мин табын түрендә. Көн саен юып, чистартып торалар иде үземне. Карт хуҗабикә исән чагында иде инде ул кызык тормыш. Җыелыр иде дә тирә-күрше карчык минем тирәли, тотынырлар иде шакмак белән чәй эчә-эчә гайбәт сатарга. Авылның бөтен яңалыгын белеп тора идем мин ул чакта. Корсагыма бер чиләк су сыя торган булса да, ул гына җитми иде карчыкларга. Тагын тутырып куялар иде. Бигрәк тәмле бу самавырның чәе, дия-дия эчәләр иде мин кайнаткан чәйне. Их, заманалар!

Комган да дәшми кала алмады. Ул да борынынннан яшь тамызып, үткән елларны искә алды:

—Мин дә пачутта идем ул чакта, самавыр туган. Җылы су салып, мич артында гына тотарлар иде үземне. Хуҗа карчык тышка чыга калса, мине гел диярлек үзе белән алыр иде, мәрхүмә. Кадеремне беләләр иде элек минем дә. Хәзер генә безнең кирәгебез калмады, күрәсең.

Бу сүзләрдән самавыр да сулкылдап алды:

—Мине әнә шул газ белән электр харап итте лә. Хәзер бит чәйне калай чәйнектә кайнаталар. Соң, аның чәе—чәйме соң инде—тфү! Юынтык су шунда. Бер чәшке эчкәнче суынып бетә үзе. Әле соңгы елларда, мода дип, миңа охшаган бер нәрсә алып кайтканнар хуҗаларыбыз. Электр самавыры, диләр үзен. Күрдем инде—үзенең ни буе, ни хозурлыгы. Чәйне дә тере утта кайната белми үзе. Ни пычагыма кирәккәндер ул хуҗаларга?

Самавыр авыр сулап куйды. Комганның да сөйлисе сүзләре күп иде, ахрысы.

—Ә мине халыкның денсезләнүе бетерде. Элек мөселман халкы миннән башка йомыш йомышларга бер дә йөрми иде бит. Хәзер генә, бар да кяфергә әйләнеп беттеләр. Минем күптән хуҗаларның өенә кергәнем юк инде. Теге елны хуҗабикәнең шук оныгы, эчемә кызыл борыч салгач, ул кызышуына түзә алмыйча

мине келәт почмагына атып бәргән иде—шуннан бирле өй эчен күргәнем юк. Әле соңгы вакытта ишеттем, дин яңадан кайта башлагач, минем дә кирәк чыккан булган да, ну минем вазифаларны теге кибет катыгы тутырып сата торган шешә алган. Соң аның ни матурлыгы, ни уңайлыгы юк бит инде.

Шулай үткәннәрне исенә төшереп, берсенә-берсе зарланышып барганда, алар утырган арбаны таккан трактор кинәт туктап калды. Бераздан арба ничектер янтайды һәм комган белән самавыр башка тимер-томыр белән бергә, шалтырап җиргә килеп төштеләр.

Бераз аңнарына килгәч, комган белән самавыр телгә килделәр.

—Нинди җир икән бу, самавыр туган?—диде комган, як-ягына каранып.—Кайда китереп ыргыттылар икән безне?

—Ишеткәнем булды минем бу турыда,—диде тегесе, кәкрәйгән борынын рәтли-рәтли.—Металлолом дип аталабыз без синең белән хәзер. Безне озакламый утка тыгып эретәчәкләр, аннары бездән чыккан җиздән бүтән нәрсә ясаячаклар.

—И Ходаем, күрәселәребез бар икән әле,—комганның тавышы калтыранып кына чыкты. Теге карчык-корчык сөйләгән тәмуг шул буладыр инде. Ни гөнаһларыбыз өчен икән соң, ә?

—Шулай инде. Бу адәм балаларын аңламассың. Син үзләренә кирәк чагында, күкләргә чөеп мактыйлар, кирәгең беткәч, утка да ыргыта, суга да ташлый алар сине. Әңгәмәдәшләр шулай сөйләшкән арада, тимер-томыр калдыклары арасына ике үсмер малай килеп чыкты.

—Кара әле, җиз ватыклары,—диде сары чәчле, сипкелле йөзлесе. Төсле металл калдыклары итеп тапшырсаң, ике-өч шешә лимонадлык акча бирәчәкләр. Малайларның икенчесе, күзлек кигәне якынрак килде:

—Син нәрсә,—диде ул иптәшенә карап. Бу бит самавыр белән комган. Боларны тарих укытучысы Искәндәр абыйга илтеп бирсәк, ул безнең икебезгә дә бу чиректә бишле чыгарачак. Әйдә, ал комганны, мин самавырны тотам. Илтик боларны мәктәп музеена.

Берничә көннән, мәктәпнең музейга бирелгән җылы гына бер бүлмәсендә, яңарып, яшәреп киткән комган белән самавыр ялтырап елмаеп утыралар иде инде.

—Бәхет бар безнең, брат, ә!—диде самавыр, комганга өстән карап.—Яшибез болай булгач.

—Аллага шөкер, самавыр туган! Тәки кирәгебез чыкты бит адәм балаларына.

Комган да җиз борыны астыннан гына елмайды. Бу мизгелләрдә җыен искемоскы—чабагач, киле, чабата ише әйберләр арасында булсалар да, алардан да бәхетле затлар дөнья йөзендә юк иде.

## Җыелыш

Ходайның бер бирмеш көнендә, дүшәмбедән алып якшәмбегә кадәр атна эченә тупланган көннәр, кешеләр үрнәгендә, җыелышка җыелырга булганнар. Башлап йөрүче кем булгандыр инде—анысы хәзер караңгы, тик башыннан ук бу эшнең хәерле бетмәячәген чамалап була иде. Бәхәс җыелышны кем алып барырга тиеш, дигән мәсьәләдә үк купты. Җидесенең дә баш буласы килү, көннәрне тәмам ачуланыштырып бетерә язды. Җыелышка җыелуның сәбәбе атна көннәре арасында җитәкче сайлап кую булганлыктан, берәүнең дә баш бирәсе килмәде.

Иң беренче булып сүзне Дүшәмбе башлады.

—Мине кешеләр үзләре беренче итеп куйдылар,—дип башлады ул.—Миннән дә мөһимрәк көн юктыр арада, җәмәгать. Яллардан соң эшкә әйдәүче дә мин. Аннары, кешеләр яңа тормышларын да, миннән башларга тырышалар. Миндер инде сезнең җитәкчегез.

Дүшәмбенең шулай дип әйтеп бетерүе булды, Сишәмбе чәчрәп чыкты:

—Синнән нинди җитәкче чыксын инде, әкәмәт!—диде ул, күзләрен шардай ясап.—Син бит гомергә махмырдан интегәсең. Шуның өчен сине кешеләр дә яратмый. Бу дөньяда, җыен эшләмичә акча алып ятучылардан башка, кемнең атна

башын яратканы бар. Менә миңа туры килгән көнне адәм балаларының чистый күзе ачыла. Миннән дә кулайрак җитәкче юк, минемчә.

—Син дәшми торсаң, юньлерәк булмасмы, Сишәмбе брат,—дип, Чәршәмбе дә бәхәскә кушылды.—Беренчедән, синең исем дә бит Си-шәмбе, бик матур яңгырамый. Аннары сине дә гомер-гомергә кешеләр яратмады. Син туры килгән көнне яңа эш тә башламыйлар, юлга да чыкмыйлар, тырнак кына да кисмиләр. Ә менә мин атнаның уртасы. Ходай үзе мине җитәкче булырга яраткан. Мин ике якны да бертигез күрергә сәләтле. Урыслар бит мине юкка гына Среда дип әйтмиләр. Миннән дә кулайрак кандидатура юк монда.

—Якшәмбе белән сезнең гел шул урыска табыну булыр инде,—дип, салмак кына Пәнҗешәмбе дә сүзгә кушылды.—Синең бит, Чәршәмбе туган, уртада булуың, «ни туды, ни сюды» дигәнне генә аңлата. Синнән бер якка да юк, ягъни мәсәлән. Ә менә мин үзебезнең төркилегебезне саклап кала алган бердәнбер көн. Минем үзебезчә Атнакич дигән исемем бар, ә сездә тик гарәп-фарсы исемнәре генә. Шуңа күрә җитәкчегез итеп мине сайларсыз дип уйлыйм.

Бу сүзләрдән соң, башына чалма ураган Җомга калтыранган тавыш белән сүзгә кушылды:

—Мин сезнең бәхәсләшүегезне гомумән аңламыйм, җәмагать. Мөселман өчен миннән дә изгерәк көн юк дөньяда. Миңа туры килгән көнне, элек-электән, кешеләр намазга йөргәннәр, изгелекләр кылганнар, ял иткәннәр, ниһаять. Үткәннәребезгә кире кайткан вакытта, миннән дә кулайрак җитәкче таба алуыгызга мин шикләнәм.—Җомга сизелер-сизелмәс кенә итеп, Пәнҗешәмбегә ым какты. Икешәр көн ял иткән заманда, аларның бергәрәк булуы, ягъни мәсәлән, Җомга җитәкче итеп сайланган очракта Пәнҗешәмбе аның «зам»ы буласы көн кебек ачык иде.

—Сез нәрсә, җәмагать? Кешеләрдән күреп, дәүләт переворуты ясарга уйлыйсызмы әллә?—Шимбә башкаларның алдына ук йөгереп чыкты.—Син, Җомга абзый, гупчым дәшмә. Бәлки элекке, кадими заманнарда син туры килгән көнне намазга йөргәннәрдер дә, хәзер андый гадәт юк инде. Сине хәзер, беләсең килсә, «шоферлар көне» дип йөртәләр. Беләсеңме нигә? Чөнки сиңа бирелгән көнне бөтен шофер, алай гына түгел, бөтен эшче лаякыл булганчы эчә. Хәзер син—алкаш, Җомга абзый. Ә менә мине кешеләр көтеп ала. Без Якшәмбе туган белән икәү—кешеләрнең иң яраткан көннәре. Без туры килгән көннәрне кешеләр гаиләләре белән бергәләп ял итә, ата-аналары белән күрешә, күпме файдалы эшләр эшли.—Шимбә Якшәмбегә күз ташлап алды да сүзен дәвам итте—Мин җитәкчелеккә дәгъва итмим, булганына шөкер итеп яшәргә кирәк.

—Сез, сез икегез дә бер калыптан,—дип кычкырды моңа түзмичә Дүшәмбе.—Берегез яһүд бәйрәме, икенчегез урысныкы. Сез туры килгән көнне кешеләр гомер күрмәгән кебек эчәләр-эчәләр дә, аннары мин гаепле. Сезнең икегезнең берегезне дә җитәкчелеккә якын китерәсе түгел.

—Дүшәмбе иптәш, сез болай да ил күләмендә киеренке булган милләтара мөнәсәбәтләргә тыгылмагыз, яме.—Шулай дип, моңарчы барысын да тыңлап, блокнотына нидер язгалап утырган Якшәмбе, бәхәскә катнашмый булдыра алмады.—Бүгенгә әле монда мин нәчәлник. Кешеләр дә мине хөрмәт итә. Ә электән килгән тәртипне бозарга мин сезгә не позволю! Җитәр акырышырга. Әнә, кешеләр күпме революцияләр ясап карадылар, берәр тулкы булдымы? Юк! Нәрсә җитми сезгә? Һәрберегезнең үз урыны бар. Кешеләр инде шушы пүрәдеккә өйрәнгән. Хәзер урыннар алыштырып, аларның болай да буталган башларын тагы бутыйкмы? Менә мин атнаны төгәлләп торам. Киредән мине сайлагыз да җитәкчегез итеп, и вәссәлам.

Җыелыш әле озак барды. Акырыш-бакырышлар, берсен-берсе гаепләүләр аз булмады анда. Кышкы вакытка күчкәндә берсеннән-берсе урларга мәҗбүр булган бер сәгать вакыт турында да кешеләр икешәр-өчәр көн ял иткәндә кемнәргәдер өстенлек бирелүе дә игътибардан читтә калмады. Ахырда атна көннәре тәртипне элеккечә калдырырга, дигән тәкъдим белән килешергә булдылар. Чөнки революцияләр ясап, үзгәртеп корулар үткәреп, авызлары пешкән кешеләрнең хәлләреннән алар бик хәбәрдар иделәр.

## Сайлау

Силсәвит Рашатны ике атна буе айнымыйча эчеп ятканы өчен эшеннән куганның икенче көнендә Озын Улак авылы халкы жыенга жыелды. Беркем дә махсус дәшмичә, үзлегеннән жыелган иде халык авыл Советы бинасы каршына. Участковый Харис, «төтен» исерек хәлдә күрше чуваш авылында ятканга, жыелган халыкны куып таратырга да кеше табылмады.

Рашатның «жылы» урыныннан очып төшүе озынулаклыларның авыр замана белән басылган күңелләрен бераз күтәреп жибәрде. Аны авылда беркем дә яратмый иде. Өр-яңа машина алган, малаена өй салып яткан кешене кем яратсын ди инде.

Халыкның жыенга жыелуының сәбәбе дә шул, авылга яңа житәкче сайлап кую иде. Бу юлы район-фәлән сүзенә карап тормыйча, авыл халкы рәис итеп үз кешесен куярга карар кылды.

Уттай эш өсте булмаганга, жыенга кеше байтак килде. Халык тыныч кына Чатан Мөнирне көтте. Чөнки жыенны, астыртын гына, авыл мулласы вазифаларын башкарган шул Мөнир оештырды. Менә аскы урамнан жил-жил атлап, башына кәләпүшен кигән, кәжә сакаллы бер бәндә күренде. Бу—Мөнир үзе иде. Жыелган халык янына килеп житкәч, ул көр тавыш белән: «Әссәламәгаләйкум», дип, халыкны сәламләде дә, кем тарафыннандыр, алдан ук әзерләп куелган буш аракы әрҗәсе өстенә менеп басты. Карчыганыкыдай күзләре белән халыкка бер караш ташлап алгач, Мөнир, мәчеттә вәгазь сөйләгәндәй, сүз башлады:

—Жәмәгать—диде ул, ташларны эретердәй тавыш белән.—Барысы да безнең хәзер демократия чорында яшәгәнебезне белә булса кирәк.

«Беләбез, беләбез»,—диеште халык.

—Шуңа күрә, урыныннан төшерелгән теге алкаш урынына,—Мөнир Рашатлар тора торган югары оч ягына таба кулын селтәп алды,—авыл халкының аһ-зарын, кайгыларын аңлый торган үзебезнең кешене куярга кирәк. Барыбыз да бер сүздә булсак, шәт, район да берни әйтмәс. Мин силсәвит персидәтеле итеп Гыймадиев Дамирны сайларга тәкъдим итәм. Акыллы, инсафлы бала, үзебезнең авылда туып үсте, институт бетергән. Шуңардан да кулайрак кеше таба алмабыз, жәмәгать.

Фермада мал врачы булып эшләүче Дамир—Мөнирнең кияве иде. Кулыннан юньләп бер эш тә килмәгән бу егетнең, каяндыр кергән акчага яңа йорт торгызып ятуы, аның авылда башын бик югары күтәреп йөрүе дә озынулаклыларның күңеленә бер дә хуш килми иде, әлбәттә. Шуңа күрә Дамир исеме ишетелү белән, халык арасында берән-сәрән көлгән тавышлар ишетелде.

—Сыерның бозылган жиренә дару да сөртә белми бит ул,—диде кемдер.

—Мал хәленә кера белмәгән кеше авыл житәкчесе була аламыни!—диде Озын Жәмил.

—Аннары ул аракы да эчми, ә эчмәгән кеше йә кара эчле, йә чирле була, ни чуртыма безгә андый рәис?

—Әнә, Күке Раилен куярга кирәк.

Халык дәррәү көлеп жибәрде.

—Юк, жәмәгать,—диде Мөнир, сүзнең читкә китәргә чамалаганын сизенеп.—Авыл белән житәкчелек итү, бушка мотоцикл алам дип, урманда күке куып йөрү түгел.

Халык тагын бер көлешеп алды. Ләкин шулай да Раилне авыл Советы рәисе итәргә теләүчеләр дә юк түгел иде.

Авыл Советы рәислегенә Мөнир мулланың үзен, тарих укытучысы Исмәгыйльне, тагын әллә кемнәрне тәкъдим итүчеләр булды. Кинәт бөтенесенең тавышын басып, халык арасыннан тагын Озын Жәмилнең тавышы яңгырады.

—Көтүче Сабирҗан абзыйны сайлыйкмы әллә?

... Һәр авылның үзенә бер ата ялкавы, үз алкашы һәм үз диванасы була. Бу—табигать законы күрәсең, чөнки соңгы елларда да әле мулласыз, участковыйсыз

авыллар очратырга булса да, югарыда аталып киткән кешеләрдән башка авыл, чын авыл була алмый.

Озын Улакта ата ялкау, алкаш һәм авыл диванасы исемнәрен, барысын бергә элеккеге сарык көтүчесе Сабирҗан күтәрә иде. Ләкин эчсә дә, тилемсәрәк булса да, Сабирҗанның берәүгә дә үз гомерендә зыян китергәне булмады. Кешеләрне, аннан да битәр, сарыкларны ярата иде Сабирҗан. Ләкин колхозларда сарыклар бетүгә йөз тоткач, ул эшсез калды. Авызына беләк буе тәмәкесен кабып, капка төбендә утырудан башка эше булмаганга, бүген «бу халык кая җыела икән», дип, ул да җыенга килде...

Сабирҗан исеме чыккач, халык тагын бер кат гөрләшеп көлеп алды. Ләкин халык тавышын басып, тагын Җәмилнең көр тавышы яңгырады.

—Нәрсәсе килешми Сабирҗанның. Ялкау дисәгез, Рашат та үз гомерендә сыңар кадак та каккан кеше түгел иде, эшләде бит әле рәис булып, эчә дисәгез, әнә, колхоз рәисе Сабирҗаннан да күбрәк эчә бит, барыбер урында утыра. Баш ягына килсәк,—Җәмил як-ягына каранып алды,—безнең авыл белән йөз прансит нормальный кеше идарә итә дә алмый. Гомер буе берүзе сарык көтүен көткән кеше, әллә авыл халкын гына тыя алмас, дисезме? Аннары тагын бер ягы бар, Сабирҗан бит ул үз гомерендә сорамыйча кешенең энәсенә дә кагыла торган кеше түгел. Иманым камил, рәис булгач та урламаячак...

Халык тынып калды. Бар да Җәмил әйткәннәрне башларыннан үткәрәләр иде. Бераздан: «Булсын, Сабирҗан булсын!», «Тиле булса да яхшы кеше ул»,—дигән тавышлар ишетелгәли башлады.

—Җәмәгать саташмыйк инде.—Мөнир мулла тагын аракы әрҗәсе өстенә менеп басты.—Син дә, Җәмил, халык җыенын исерекләр мәҗлесенә әйләндермә. Авылда Дамирдан да яхшырак кандидатура юк. Тиле кешене рәис итеп сайлый алмыйбыз бит инде.

«Ярар, сайлыйк Дамирны»,—диде кемдер. «Күке Раиле лутчырак булыр», «Сабирҗанны сайлыйбыз»,—дигән тавышлар ишетелде. «Янәдән Рашатны гына сайлыйк»,—диючеләр дә булды. Халык арасында бәхәс купты. Берәүнең дә үз сүзен бирәсе килмәде.

Көтүче Сабирҗанга рәхәт иде. Ул акырышкан халык арасында үзен нәкъ көтүдәге сарыклар арасындагы чакта кебек хис итте. Их, урап-урап берне чыбыркы шартлатасы иде монда. Исеме халык теленә эләккәч, Сабирҗанның борынына влач исе кергән иде. Халык исә гөжләде дә гөжләде...

Озак кына тарткалашканнан соң, авыл Советы рәисе сайлауны җиренә җиткереп үткәрергә булдылар. Каяндыр картон тартма табылды, бөтен халыкка кәгазь кисәкләре таратылды. Барлыгы йөз дә утыз кеше сайлаучы итеп теркәлде. Һәркем, кешегә күрсәтмичә генә, үзе рәис итеп күрергә тиешле кешенең исемен кәгазьгә язып, шул тартмага ташларга тиеш булды. Җыелган халык арасында тыз-быз килеп, Мөнир мулла йөренде. Халык уйга калды...

Бераздан, аракы әрҗәсе өстендә торган тартмага бөгәрләнгән кәгазь кисәкләре төшә башлады. Соңгы кеше булып Сәхибҗамал карчык та үз бөтиен тартмага салгач, санауга керештеләр.

Йөз егерме җиде тавыш белән, үзенә җитәкче итеп, халык көтүче Сабирҗанны сайлаган иде...

# Uqicь syze

. . .

Şøker, latin xərefenə qajtunьn telebezne, millətebezne saqlap qaluda nindi məhim adьm ikənen anlamagan bulьp qьlanucьlar tьnьclanьr kebek.

2001 jьlga qədər aralar jьraq bulsa da, tunnil ocьnda jaqtьlьq cagьldь diərgə məmkin. Bu çəhəttən "Qazan utlarь"na zur rəxmət ajtəse kilə: anьn latin jazmasьnda birelgən uqu kynekmələre əmetlərne əzmicə kətərgə əndədelər. In abrujlь zurnalьbьz kiləcəktə bu izge eşen kinəjtep tə çibərer dip əmetlənəse kilə.

Tik şunьsь beraz xəweflənderə: latin xərefenə kycsək tə, kirillitsa tə'sirennən qotьla almabьz kebek. «Urьs tele arqьlь kergən kənbatьş syzləre nəq urьs transkripsiəsendə jazьlьrga tieş» digən çinəjətcel kyrsətmə beznen milərebezgə dəmbəsləp tutьrьlgan, anda tamьr çəjgən həm yzebeznen məsləkkə əjləngən.

Bu afət xətta «Qazan utlarь»nda cagьlьş taba: latin xərefendəge tikьstta da rogon, protest, avtor, elektr togь, sovet, rajon, metodika, rezissjor, telefon dip birelə.

Kirillitsanьn in zur qortqьclьgь—ber yk xərefnen urьcsa həm tatarca tərlecə jangьrawьnda. Şøker, ы, я, ю, е, э, щ, ц, ъ, ь kebeklərennən qotьlьrbьz, axrьsь. Ə menə O belən E latinga kyckəc tə telebeznen çelegen suьrunь dəwam itərlər kebek. Misal əcen озон, очко, электричество, эшсезлек, болын, авыл kebek syzlərdəge O, E xərefləren tatarca uqьp qarьjq əle.

Əgər bez başqa tellər syzləren urьsca jazudan qotьla almasaq, latinga kycynen əllə ni fajdasь kyrenmi. Qьzganьc, andьj syzlər telebezdə saf tatar syzlərenə qaraganda kyrkə artьq. Xalьq arasьnda «русско-русский словарь» isemen jaulagan 1985 jьlgь urьsca-tatarca syzlekkə ber qaraş taşlau da şuna inandьrьr.

Min, məsələn, jugarьda kiterelgən syzlərne «Qazan utlarь»nda bolajraq jazar idem: pagun, pratist, aftьr, ilektr tugь, səwit, rajun, mitudika, rizissur, tilefun...

Kynelem sizə: berər filaluk, diktьr, prafisьr, mьsqьllь jьlmajьp, mine nadanlьqta gəjeplər. Artta qalganlьqta. Dəres, min tel belgece tygel, учуный ызванием də, şøker, juq. Прастуй tatar balasьmьn. Həm nəq tatar balasь xise izge ana telemne urьs telenə jaraqlaştьru şauqьmьna qarşь ah orьrga məçbyr itə. Tagьn şunь əjtə alam: tarafdarlarьm kyp—tulь ber xalьq, tatar xalqь. Ьşanmasagьz, tugan telne kitaptan uqьp tygel, ə ana səte belən sendergən, şul tel belən gəmer itep jatucь awьl əbi-babajlarь belən səjləşep qaragьz. Awьlga barьrga waqьt tapmasagьz, Tufan Minnullinnьn «Minhaç maçaralarь»n uqьp qaragьz. Minhaç babajga səvit, kalxuz, Jelsin, Garbacuf diərgə jarьj ikən, nigə galimnərgə jaramьj? Jarьj, urьslaşьrga əlgerməgən əbi-babajlar nadan, di. Əmma Gəziz Gəbəjdullinnь nadan diərgə berkemnen də tele borьlmas. Menə şul galim царь, философия, Псков, воевода собор dip tygel, car, fəlsəfə, Pskau, vajьvada, sabur dip jazgan. Əlbəttə, tatar telenə kirillitsanь kəcləp taqqanga caqlь.

Məxtərəm tel belgeclərə igtibarьn şuna da jynəltergə ide. Başqort galimnəre 1938 jьlda uq başqort telen qatь əjteleşle K həm G xəreflərennən

məxrym itməgənnər. Jaqutlar əle də statja tygel, ьstatьja dip jazalar. Xalьq səjləgəncə.

Həm iņ məhime: cit tellər syzləren yzləşterydə bezgə urьs xalqь menə digən ymək bula ala. Alaşa, təņkə, qьrьj, tirmə, ulus, skul, halstüch, Hajnrich Hajne tygel, лошадь, деньга, край, теремок, волость-область, школа, галстук, Генрих Гейне dip jaza ul. W xərefe bulmagac, jə Уильям, jə Вильям Шекспир dip jaza, ingliz syzləren jazar өcen genə əlifbasьna jaņa xəref өstəməgən. (Bezdə də elek vagon tygel—bagun dip jazgannar bit. Ber genə saf tatar syzendə də V xərefe bulmasa da, beznen alfavit V belən «bajьtьlgan».)

Yzen ixtiram itkən tel cittən kergən hər syzne yzenə çajlaştьra. Bəjek urьs telendə bu şulqədər tirən tamьr çəjgən ki, xətta ber genə kirəge bulmagan ocraqlarda da yzgərtelep alьna. Əjtik, Qazan-Sember julьnda Qaramasar, Bortas awьllarьna nigəder Ы xərefe өstəp urьslaştьrgannar. Urьs telenə atamalarnьņ Ы xərefenə betye jaxşьraq ikən dip ujlьjsьņ həm... jalgьşmьjsьņ... Ənə Qarlь jьlgasь tatarca Ь xərefenə betkən, ə urьscasь—Карла...

Mondьj yzgərtylərnen maqsatь turьnda ujlana başlasaņ, Qazanьbьz isemenə də neckəlek bilgese өstəp, anь zinski rutqa əjləndergənnəre iskə təşə.

Gafu, gafu: citkərək kitelde. Atamalar məs'ələse yze ajьrьm zur səjləşyne taləp itə. Xəjer, səjləşy tygel, dəylət qararьn.

Ə bygen barь tik latin belən jazganda kirillitsa tə'sirennən Jotьlu caralarь turьnda gьna.

Beznencə iņ məhim cara—aşьgьc rəweştə dөres jazu syzlege təzi başlarga. Bu syzlek 2000 jьlda qullanьşta bulsa ide inde. Həm jaņa şartlarda təzelgən jaņa syzlek alьnma syzlərne nəq urьs transkrepsiəsendə jazudan telebezne qotqarьr dip өmetlənəse kilə. Bu izge eşkə «totsa məskəylər jaqaņ» kebek nərsələrdən qaltьranьp utьrucьlar alьnmasьn ide. Batьr jegetlərebez, qьju galimnərebez kyp bit əle beznen.

Bulacaq syzlekne təzycelər tagьn ber məhim nərsəne kyzdə totsьnnar ide. Gərəp tele tə'sire arqasьnda telebez singarmunizьmnan məxrym itelgən: səlam, əmma kebek jazьlucь syzlər bajtaq bit.

Qьsqasь, dөres jazu qagidələren qabul itkəndə qьjuraq bulьrga, alga qarap eş itərgə kirək. Ə alda, ьşanьgьz, urьs tele də latinga kycəcək. Əle də ənə reklamalarьnьņ bajtagь latin xəreflərendə. Internettagь məglymatlarnьņ 98 prasintь ingliz telendə, 99,5 prasintь latin xərefendə ikənen iskə alsaņ, urьs telenə də başqa jul juq. Jugisə alga qarap fiker jөrtyce urьs galimnəre Karinskij, Juşmanof, Lunacarskij, Jakovlef 1918 jьlda uq urьs telen də latinga kyceryne jaqlap cьqqannar.

Ə urьs tele də latinga kycsə, ul yze də, şəkətsez alfavitьnnan qotьlьp, gөmum qagidələrgə bujsьnьp kamilləşer ide.

Xəjer, busь beznen eş tygel. Barь tik urьs telenen də latinga kycye qotьlgьsьz dip kenə əjtyem.

**Ajrat IBRAHIM,**
*Sember şəhəre.*

❋

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ XIII КОРЫЛТАЕ

28 майда башкалабызның Актерлар йортында Татарстан язучыларының XIII корылтае ачылды. Иң башта корылтай делегатлары соңгы 5 елда арабыздан киткән каләмдәшләребезне (алар—40 кеше), аягүрә басып, бер минутлык тынлык белән искә алдылар.

Корылтайны татар әдәбияты аксакалы—90 яшьлек әдип Әмирхан ага Еники ачты. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев ике корылтай арасында идарә тарафыннан башкарылган эшләр турында хисап докладьг белән чыкты.

Корылтай эшендә катнашкан Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, җыенны котлап, җәмгыятебезне үзгәртеп коруга, әдәбиятыбызны баетуга керткән өлешләре өчен, язучыларга рәхмәт белдерде һәм әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйләде. Аннары ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллинга «Татарстан Республикасының халык шагыйре», шагыйрә Резеда Вәлиевага «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире—язучы Шаһинур Мостафинга «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелүен игълан итте һәм аларга дипломнар тапшырды.

Корылтайда катнашучылар әдәбиятыбызның бүгенге прозасы, очерк һәм публицистикасы, шигърияте, драматургиясе, балалар әдәбияты һәм рус әдәбияты турында Фоат Галимуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәрит Яхин, Юныс Сафиуллин, Галимҗан Гыйльманов, Владимир Корчагин докладларын тыңладылар, үзләрен борчыган мәсьәләләр буенча фикер уртаклаштылар. Фикер алышуларда Ә. Баян, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, Р. Батулла, Л. Ихсанова, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, К. Булатова, Р. Җамал (Корбанов), М. Маликова, А. Хәсәнов, Ә. Гадел, Д. Салихов һ. б. чыгыш ясады.

Корылтай бу җыелуда үз эшен әлегә төгәлли алмады. Шул сәбәпле, яңа идарә составы да сайланмады. Корылтайның яңадан җыелу вакыты әле төгәл билгеләнмәгән.

## ВЕТАКАДЕМИЯДӘ—«КАЗАН УТЛАРЫ» КИЧӘСЕ

Ректор-академик Рифат Җамал (Корбанов) чакыруы буенча, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә «Казан утлары» һәм аның дуслары» дигән кичә үткәрелде. Бәйрәмгә журналның даими авторлары—Татарстанның халык шагыйрьләре Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм редакциядә эшләүчеләрдән Равил Фәйзуллин (баш мөхәррир), Рәдиф Гаташ, Флүс Латыйфи, Гөлзадә Фәйзуллина, Шаһинур Мостафин, «Мәгърифәт» газетасыннан шагыйрә Рифә Рахман, «Ватаным Татарстан» газетасыннан фоторәссам Мидхәт Шакирҗанов килгән иде. Кичә барышында ветакадемия студентлары, кунаклар янәшәсендә сүз алып, тыңлаучыларны ректор—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рифат Җамал шигырьләре белән дә таныштырдылар, аның сүзләренә язылган җырларны да башкардылар.

Әлеге кичәдә ветакадемиянең элеккеге шәкерте—Татарстанның атказанган артисткасы, М. Җәлил премиясе лауреаты Гөлзада ханым, Татарстанның халык артистлары Мингол Галиев (ул бирегә үзенең укучылары Радик Каюмов, Шәүкәт Хәсәенов, Равил Рәхимов белән килгән иде) һәм Мирсәет Сөнгатуллин да катнашты.

Кичәне ветакадемиянең гыйльми сәркатибе Резидә Муллахмәтова һәм язучы-галим, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин алып барды.

❀

*Тышлыктагы сурәтләр*

# МИЛӘҮШӘ ГӨЛЛӘРЕ

«Казан» милли-мәдәният үзәгендә Миләүшә Вакыйф кызы Нуруллинаның «Гөлләрнең сихри көче» дигән күргәзмәсе белән танышкач, йөрәк әрнүләрем басылып, гаҗәеп бер рәхәтлек кичердем, зәүкыма канәгатьләнү килде. Миләүшәнең нур сирпеп торган чәчәкләр панорамасыннан ниндидер бер серле көч бөркелеп тора. Рәссам тудырган зәвыклы гөлләр дөньясын мин табигать кодрәтенә, аның илаһи көченә мәдхия, изге фәрманына дога итеп кабул иттем. «Җиңүче һәм җиңелгәннәр», «Алабута чәчәге», «Кичә, бүген һәм иртәгә», «Роза һәм башка барлык гөлләр», «Розалар һәм мәкләр» («Опиум»), алсу астралы композиция, «Розалы көзге нәкыш»— әнә шундыйлар. Киндердәге назлы, көяз, сөю-сагыш бөркеп торган гөлләргә карыйсың да, аларны төрле-төрле итеп яраткан бөек кодрәт иясенә сокланасың, аларның кешегә охшаш яклары турында уйлана башлыйсың.

Гөл образы, аның асыл матурлыгы шәрекъ сәнгатендә һәрвакыт камил кеше символы, аның иң якты сыйфатларының чагылышы булып килде (Хәйям, Хафизларны, Сәгъди, Мөхәммәдъяр, Кандалый, Дәрдемәндләрне генә искә алыйк!) Халкыбыз үзенең бөтен талпынуын, моң-сагышын, сәнгатькә сусавын, билгеле сәбәпләр аркасында, гөлләр сурәте белән чикләгән һәм төрләндергән (кул һөнәре сәнгатендәге «гөлле орнамент», шәмаилләрдәге бизәкләр, халык җырындагы «алсу», «исле гөлләр» моның дәлиле). Татар халкы һәм милләтебезнең традицион мәдәнияте өчен бу дөнья аеруча газиз, дулкынландыргыч галәм, яшерен сәнгать теле, шигъри сөйләм...

Гөл теле хакында уйланганда, халкыбызның борынгы дастаннарының берсе «Шаһсәнәм вә Гъәриб» әсәреннән бер эпизод искә төшә. Сөйгән ярыннан фаҗигале сәбәпләр аркасында аерылган Гъәриб мәхбүбенә, бакча гөлләре арасыннан үз күңеленә якын булган гөлләрне сайлап алып, хикмәтле бер букет төзеп җибәрә. Моның кем эше икәнен белмәгән кыз, букетны кочагына алуга: ах, бу минем Гъәрибемнең исе, ул исән икән, бу аның хәбәре дип, куанычыннан елап җибәрә... Менә шулай итеп, гөл теле—яшерен сөю теле, мәхәббәт аллегориясе итеп кабул ителә...

Минемчә, халкыбызның бу борынгы ырымнан үзенә сендергән һәм замандашларына үтә дә зәвыклы итеп, профессиональ осталык белән ирештерелгән сәнгать—милли иҗат үрнәге була ала. Бу сүзләрне мин Миләүшә Нуруллина иҗатына карата кулымны йөрәгемә куеп әйтә алам. Гөлле натюрмортларга яңа сулыш өргән, аларга кыйммәтле экологик мирас итеп караган, гүзәллекнең бетмәслеге, күптөрлелеге, мәңгелегенә дан җырлаган, борынгы гөлбакчаларга «су сипкән» рәссам кыз Миләүшә Нуруллинаның иҗаты—«шомырт җилләре» кебек сискәндергеч, саф һәм өметле.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

**Тышлыкның беренче битендә:** «Чәчәклэрдән натюрморт»—рәссам Миләүшә Нуруллина картинасыннан фотосурәт.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган фольклор галиме, профессор Фатих Урманче.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Марсель ГАЛИЕВ. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда.—Казан: Татар. китап нәшр., 1998. I том—385 б., II том—414 б., III том—430 б., IV том—430 б. Тиражлары—4000 данә.



Үткән ел ахырында күренекле прозаик-эссеист, шагыйрь һәм юмор остасы Марсель Галиевнең дүрттомлык сайланма әсәрләре басылып чыкты. Азнакай якларында туып-үсеп, 70 еллар башында әдәбиятка килгән бу әдипнең моңарчы төрле нәшриятларда басылган унбишләп китабы дөнья күргән иде инде. Ә бу сайланма әсәрләрдә язучының егерме биш еллык иҗаты бар тулылыгы белән бәян ителә. Әсәрләрнең I томлыгына шигырьләр, балладалар кертелгән. «Беренче карлыгачларның эзе кала күкләрдә», «Еллар чалымы», «Сүзләр эзлим», «Апрель кызы», «Сабыйлыкка ни житә?», «Агыла да болыт агыла», «Юлларда—җырлар, җырларда—еллар» дигән бүлекләр авторның шагыйрь буларак үсеш этапларын билгелиләр. Соңгы бүлектә, шулай ук, шагыйрьнең—«Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Кайту», «Көзге моң», «Нинди моң бар төнге күзләреңдә?» кебек популяр җырлары да бирелгән. II томлыкта авторның «Ак абагалар» повесте, аның белән бергә кырыктан артык эреле-ваклы лирик һәм юмористик хикәяләре урын алган III томда «Ерак урман авазы» романы, «Ул чакта», «Нигез», «Алтын тотка» повестьлары һәм «Исемсез утрауда» исемле пьеса кергән. IV томга әдипнең иҗтимагый эчтәлеге ягыннан зур әһәмияткә ия эссе-сурәтнамәләре, заман-чор, тарих, әдәбият һәм аның күренекле вәкилләре турында фәлсәфи-лирик уйланулары тупланган.

Дүрттомлыкның I томында Марсель Галиев иҗаты турында Ә. Еники, М. Кәрим, Т. Миңнуллин, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин кебек күренекле әдипләрнең уй-фикерләре бирелгән. Менә Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники сүзләре: «Марсель Галиев—башкалардан бик нык аерылып торган язучы. Ул бөтен яктан аерылып тора: теле белән дә, стиле белән дә. Бик талантлы язучы. Барсыннан да әһәмиятлерәге, миндә кызыксыну тудырган сыйфаты шул: ул берәүне дә кабатламый, берәүгә дә иярми...»

Индекс 73210



Фатих Урманче

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)